

# КАЗАН УТЛАРЫ

12
ДЕКАБРЬ
1982

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

12
ДЕКАБРЬ
1982

## *Бу санда*

КПСС Үзәк Комитетының, СССР Верховный Советы Президиумының, СССР Министрлар Советының Коммунистлар партиясенә, совет халкына МӨРӘҖӘГАТЕ . . . . . . . 3
Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Пленумы турында информацион белдерү . . . . . . . 6
Иптәш Ю. В. Андропов рече . . . . . . . 7
Иптәш К. У. Черненко рече . . . . . . . 8
Юрий Владимирович Андропов . . . . . . . 11

КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНДА

КПСС Үзәк Комитеты «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәләре турында» карар кабул итте 13

СССРның ТӨЗЕЛҮЕНӘ 60 ЕЛ

З. НУРИ. Очрашсыннар җырда халыклар. Шигырь 16
С. БАТЫЕВ. Бердәм, тату гаиләдә . . . . . . . 17

Ә. ЕНИКИ. Соңгы китап. Истәлекләр . . . . 24
Р. ГАТАУЛЛИН. Алтын кош каурые. Шигырьләр 85
Г. ГАЛИЕВ. Истә, һаман да истә. Хикәя . . . 90
Р. ЗАКИРОВ. Күпер чыкканда. Шигырьләр . . 99
Э. МОСТАФИН. Уйлан, кеше. Шигырьләр . . 101
Ә. МӘХМҮДОВ. Мизгелләр. Шигырьләр . . 103

СССРның 60 ЕЛЛЫГЫНА

К. ФАСЕЕВ. Киләчәге тагын да матуррак . . . 105

ДУСЛАР ҖЫРЫ

А. ЧЕПУРОВ, Г. ВИЕРУ, С. РӨСТӘМХАНЛЫ, С. МАМУР, Г. РАМАЗАНОВ, А. ШОГЕНЦУКОВ, Ф. ЧАНЫШЕВА, Р. ШАММАС, Й. ХАППАЛАЕВ, М. МАЙН, Р. ХАЛИТ шигырьләре . . . . 111

МАЙ ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

М. МӘҺДИЕВ. Авыл белем сорый . . . . . . 119
М. ХӘБИБУЛЛИН. Җирнең хуҗасы турында тирән кайгыртып . . . . . . . . . 124

ПУБЛИЦИСТИКА

М. САДРИ, З. НУРИ, Ф. САФИН. «Рәхим итегез, хөрмәтле язучылар!» . . . . . . . 130
М. САДРИ. Казан коммунары. Шигырьләр . . . 132

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КАЗАН АЛАРНЫ МӘҢГЕ ОНЫТМАС

**Р. САБИРОВ. Лев Толстой һәм Казан** . . . . 135
**Рәсәйнең бөек җырчысы** . . . . . . . . 138
**Истәлекле исемнәр** . . . . . . . . . 141

ТЕЛ БЕЛЕМЕ

**В. ХАКОВ. Совет чорында әдәби телебезнең үсеше** . . . . . . . . . . 146

КИТАП КҮЗӘТҮ

**М. ВӘЛИЕВ. Авыл кешесенең матурлыгы** . . . 154

СӘНГАТЬ

**Г. АРСЛАНОВ. Тел вә ләгать алмашып** . . . 157

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Р. КАМАЕВ. Авыл белән шәһәр арасы.** Социолог язмалары . . . . . . . . . . . 162
**Н. ИХСАНОВ. Сөрген батыры.** Очерк . . . . 165

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Ф. САФИН. Җырчы шагыйрь.** Ә. Ерикәйнең тууына 80 ел . . . . . . . . . . . 170
**М. СӨНГАТОВ. Яшьлек хыялларын җилкән итеп.** М. Ногманның тууына 70 ел . . . . . . 171
**Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Йөрәктәге эзләр.** Г. Мөхәммәтшинның тууына 50 ел . . . . . . . 173
**Р. ХӘНИПОВ. Остаз.** К. Тумашеваның тууына 80 ел . . . . . . . . . . . . . . 174
**Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Матурлыкны яклап.** Дэллюс Ильясовның тууына 60 ел . . . . . . . 175
**Р. КИЛМӘТОВ. Беренче шахматчыбыз.** Рәшит Нәҗметдиновның тууына 70 ел . . . . . . . 176

**З. НУРИ. Хуш, безнең әдәби бәйрәмнәр елыбыз!** 180
1982 елда журналда басылган әсәрләр . . . 183

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 191

Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ

Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН *(җаваплы секретарь)*, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ *(баш редактор урынбасары)*, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ.

Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*
Техник редактор *Р. Сөләйманова*

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.
**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 26/VIII-1982 ел. Басарга кул куелды 26/XI-1982 ел. ПФ 09053. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65049. Заказ Ю-367. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.



## КПСС Үзәк Комитетының, СССР Верховный Советы Президиумының, СССР Министрлар Советының

*Коммунистлар партиясенә, совет халкына*

# МӨРӘҖӘГАТЕ

**Кадерле иптәшләр!**

**Советлар Союзы Коммунистлар партиясе, бөтен совет халкы авыр югалтуга дучар булды. Бөек Ленин эшен турылыклы дәвам иттерүче, ялкынлы патриот, күренекле революционер һәм тынычлык өчен, коммунизм өчен көрәшүче, гаять зур политик һәм дәүләт эшлеклесе Леонид Ильич Брежнев безнең арадан китте.**

Л. И. Брежневның бөтен күпкырлы эшчәнлеге, шәхси язмышы Советлар иле тарихындагы иң мөһим этаплардан аерылгысыз. Коллективлаштыру һәм индустрияләштерү, Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соң илне торгызу, чирәм җирләрне үзләштерү һәм космосны тикшеренүләрне оештыру — болар эшчеләр сыйныфының данлы улы Леонид Ильич Брежнев биографиясенең дә күренекле этаплары. Партия аны кая гына җибәрмәсен, Леонид Ильич һәркайда партиянең бөек идеаллары өчен үзенә хас энергия һәм ныклык белән, кыюлык һәм принципиальлек белән чын күңелдән көрәште.

Совет кешеләре, бөтен дөньядагы дусларыбыз партия һәм дәүләт тормышының ленинчыл нормаларын эзлекле төстә урнаштыруны, социалистик демократияне камилләштерүне иптәш Брежнев исеме белән, КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре һәм СССР Верховный Советы Президиумы Председателе постларында аның ару-талусыз эше белән бәйлиләр. Ул партиянең ленинчыл штабы — аның Үзәк Комитеты, Үзәк Комитет Политбюросы эшчәнлегенә зирәк юнәлеш бирде, бердәм коллектив эшне оста оештыру үрнәген күрсәтте. Ньк үскән социализм этабында партиянең экономик һәм социаль-политик стратегиясен эшләүдә һәм тормышка ашыруда, халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү курсын билгеләүдә һәм гамәлгә ашыруда, илебезнең экономик һәм оборона куәтен тагын да ныгытуда аңа күренекле роль туры килә.

Халыкара мәйданда партиябез политикасын — тынычлык һәм тыныч хезмәттәшлек, киеренкелекне йомшарту һәм коралсызлану, империализмның агрессив казынуларына кискен отпор бирү, атом-төш һәлакәтен булдырмау политикасын эшләүдә һәм үткәрүдә Леонид Ильич Брежневның хезмәтләре бәя биреп бетергесез. Аның бөтендөнья социализм бердәмлеген ныгытуга, халыкара коммунистик хәрәкәтне үстерүгә керткән өлеше гаять зур.

Леонид Ильичның йөрәге типкән чакта аның уй-фикерләре һәм эшләре бөтенләе белән хезмәт кешеләре интересларына буйсынган иде. Хезмәт ияләре массалары белән аны һәрвакыт туганлык элемтәләре, аерылгысыз элемтәләр бәйләде. Коммунистлар аңында, барлык континентлардагы йөзләрчә миллион кешеләр аңында ул ленинчыл идеялелекнең, эзлекле интернационализмның, революцион оптимизм һәм гуманизмның гәүдәләнеше булды һәм шулай булып калыр.

Безнең югалтуыбыз авыр, кайгыбыз тирән. Бу хәсрәтле сәгатьтә Советлар Союзы коммунистлары, барлык хезмәт ияләре КПССның ленинчыл Үзәк Комитеты тирәсенә, Леонид Ильич Брежневның нәтиҗәле йогынтысында формалашкан җитәкче ядросы тирәсенә тагын да тыгызрак тупланалар. Халык партиягә, аның куәтле коллектив акылына һәм ихтыярына ышана, аның эчке һәм тышкы политикасын бөтен күңеле белән яклый. Совет кешеләре яхшы белә: Ленин байрагы, Октябрь байрагы — ышанычлы кулларда, алар белән дөньякүләм-тарихи җиңүләр яуланды.

Партия һәм халык КПССның XXIII—XXVI съездларында эшләнгән мәһабәт коммунистик төзелеш программасы белән коралланды. Бу программа тайпылышсыз рәвештә тормышка ашырыла. Җитештерүне интенсивлаштыру, аның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм эшнең сыйфатын яхшырту, СССРның Азык-төлек программасын үтәү нигезендә халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү өчен партия киләчәктә дә бөтенесен эшләр. Партия киләчәктә дә эшчеләр сыйныфы, колхозчы крестьяннар һәм халык интеллигенциясе союзын ныгыту турында, Совет җәмгыятенең социаль-политик һәм идея бердәмлеген, СССР халыкларының туганнарча дуслыгын ныгыту турында, хезмәт ияләрен марксизм-лени-

низм һәм пролетар, социалистик интернационализм рухында идеологик яктан чыныктыру турында һәрьяклап кайгыртыр.

Совет халкының тынычлыкка ихтыяры даими. Халыкларны үз материаль һәм рухи байлыкларын мәгънәсезгә юкка чыгаруга дучар итә торган сугышка хәзерләнү түгел, ә тынычлыкны ныгыту — иртәгәге көнгә бару юлы менә шундый. 80 нче елларга эшләнгән Тынычлык программасы, партия һәм Совет дәүләтенең бөтен тышкы политик эшчәнлеге шушы якты идея белән сугарылган.

Без халыкара хәлнең бөтен катлаулылыгын, империализмның агрессив даирәләренең янәшә тыныч яшәүне какшатырга, халыкларны дошманлык һәм хәрби конфронтация юлына этәрергә омтылуларын күрәбез. Әмма бу — безнең тынычлыкны сакларга әзер торуыбызны какшата алмас. Хәрби авантюралар яратучылар Советлар иле көтелмәгән хәлдә калды дип уйламасыннар өчен, потенциаль агрессор үзен котылгысыз җимергеч җавап удары көтүен белеп торсын өчен без кирәк булганнарның бөтенесен эшләрбез.

Үз куәтенә таянып, гаять зур уяулык һәм чыдамлык күрсәтеп, үз тышкы политикасының тынычлык сөючән принципларына һәм максатларына даими тугрылыкны саклап, Советлар Союзы кешелек дөньясын атом-төш сугышыннан коткарып калу, киеренкелекне йомшарту, коралсызлану өчен нык торып көрәшәчәк.

Тугандаш социализм илләре, милли һәм социаль азатлык өчен көрәшүчеләр, барлык континентларның тынычлык сөюче илләре, җир йөзендәге барлык намуслы кешеләр бу көрәштә безнең белән. Тынычлык политикасы кешелек дөньясының төп тормыш интересларын чагылдыра. һәм шунлыктан киләчәк — шушы политика ягында.

Совет халкы партияне үзенең сыналган коллектив юлбашчысы, зирәк җитәкчесе һәм оештыручысы итеп саный. Партиянең иң югары максаты һәм аның бөтен эшчәнлегенең мәгънәсе — эшчеләр сыйныфына, хезмәтчел халыкка хезмәт итү. Партия һәм халыкның какшамас бердәмлеге Совет җәмгыятенең җиңелмәс көч чыганагы булды һәм шулай булып кала. КПСС хезмәт иялэре ышанычын изге итеп кадерли, массалар белән элемтәсен даими ныгыта. Вакыйгалар нинди генә борылыш алмасын, нинди генә сынаулар булмасын, партиябезнең үз тарихи миссиясе югарылыгында калачагына халык практикада инанды. КПССның Леонид Ильич Брежнев җитәкчелегендә эшләнгән эчке һәм тышкы политикасы киләчәктә дә эзлекле төстә һәм максатчан итеп үткәреләчәк.

Л. И. Брежневның тормышы һәм эшчәнлеге һәрвакыт Коммунистлар партиясенә һәм совет халкына турылыклы хезмәт итүнең рухландыргыч үрнәге булыр.

Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы Президиумы, СССР Министрлар Советы коммунистларның, барлык совет кешеләренең югары аңлылык һәм оешканлык күрсәтәчәкләренә, Ленин партиясе җитәкчелегендә үзләренең фидакарь иҗади хезмәте белән коммунистик төзелеш планнарын үтәүне, социалистик Ватаныбызның тагын да чәчәк атуын тәэмин итәчәкләренә ышаныч белдерәләр.

# Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Пленумы турында ИНФОРМАЦИОН БЕЛДЕРҮ

1982 елның 12 ноябрендә КПСС Үзәк Комитетының чираттан тыш Пленумы булды.

Үзәк Комитет Политбюросы тапшыруы буенча Пленумны КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, КПСС Үзәк Комитеты секретаре иптәш Ю. В. Андропов ачты һәм чыгыш ясады.

КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежневның вафат булуы сәбәпле Үзәк Комитет Пленумы членнары Леонид Ильич Брежнев истәлеген бер минут тынлык белән хөрмәтләделәр.

Үзәк Комитет Пленумы Коммунистлар партиясенең, совет халкының, бөтен прогрессив кешелек дөньясының авыр югалтуга дучар булуын күрсәтеп үтте. Коммунистлар партиясенең, Совет дәүләтенең, халыкара коммунистлар һәм эшчеләр хәрәкәтенең, милли азатлык хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, тынычлык өчен ялкынлы көрәшче безнең арадан китте.

Леонид Ильич Брежнев, 50 елдан артык ленинчыл Коммунистлар партиясе сафларында, шуның 18 елын партия җитәкчесе постында булып, аның сафларының монолитлыгын ныгытуга, Советлар Союзының политик, социаль-экономик һәм оборона куәтен ныгытуга гаять зур өлеш кертте. Тынычлык һәм халыкара иминлекне ныгытуда аның роле искиткеч зур. Леонид Ильич Брежневның исеме Советлар Союзы Коммунистлар партиясе, бөек Ватаныбыз тарихына мәңгегә кереп калды: илебез тормышындагы бөек җиңүләр — индустрияләштерү һәм авыл хуҗалыгын коллективлаштыру, Бөек Ватан сугышында совет халкының тарихи җиңүе, сугыштан соңгы елларда Ватаныбызның халык хуҗалыгын торгызу, космосны тикшерү, Совет дәүләте экономикасын, фән һәм культурасын үстерүдәге барлык уңышлар аның исеме белән турыдан-туры бәйле.

Үзәк Комитет Пленумында катнашучылар мәрхүмнең туганнары һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклашалар.

Үзәк Комитет Пленумы КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретарен сайлау турындагы мәсьәләне карады.

Үзәк Комитет Политбюросы тапшыруы буенча КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены, КПСС Үзәк Комитеты секретаре иптәш К. У. Черненко речь белән чыкты. Ул КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре итеп иптәш Ю. В. Андроповны сайлау турындагы тәкъдимне кертте.

Пленум КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре итеп бертавыштан иптәш Юрий Владимирович Андроповны сайлады.

Аннары Пленумда КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Ю. В. Андропов чыгыш ясады. Ул югары ышаныч күрсәтүе — үзен КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре постына сайлавы өчен Пленумга чын күңелдән рәхмәт белдерде.

Иптәш Ю. В. Андропов КПСС Үзәк Комитетын, Коммунистлар партиясен, КПССның XXVI съезды карарларында билгеләнгән коммунистик төзелеш программасын уңышлы үтәү, СССРның экономик һәм оборона куәтен тагын да ныгыту, совет халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү, тынычлыкны ныгыту бурычларын хәл итүдә, Л. И. Брежнев вакытында үткәрелеп килгән бөтен ленинчыл эчке һәм тышкы политиканы тормышка ашыруда дәвамчанлыкны тәэмин итү өчен үзенең бөтен көчен, белемен һәм тормыш тәҗрибәсен бирәчәгенә ышандырды.

Шуның белән Пленум үзенең эшен тәмамлады.

# ИПТӘШ Ю. В. АНДРОПОВ РЕЧЕ

Иптәшләр!

Партиябез һәм илебез, барлык совет халкы авыр югалту кичерә. Советлар Союзы Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте җитәкчесе, халыкара коммунистлар һәм эшчеләр хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, ялкынлы коммунист, совет халкының тугрылыклы улы Леонид Ильич Брежневның йөрәге тибүдән туктады.

Чорыбызның иң зур политик эшлеклесе безнең арабыздан китте. Иптәшебез һәм дустыбыз, олы җанлы һәм олы йөрәкле, сизгер һәм яхшы күңелле, ярдәмчел һәм тирәнтен гуманлы кеше безнең арадан китте. Эшкә чын күңелдән бирелгәнлек, үзенә һәм башкаларга карата килешмәүчән таләпчәнлек, җаваплы карарлар кабул иткәндә зирәк уяулык, тарихның текә борылышларында принципиальлек һәм кыюлык, кешеләргә даими ихтирам, сизгерлек һәм игътибар — партия һәм халык Леонид Ильичны менә шушы гүзәл сыйфатлары өчен югары бәяләделәр һәм яраттылар.

Леонид Ильичның якты истәлеген бер минут тынлык белән хөрмәтләвегезне сорыйм.

Леонид Ильич үз тормышының һәр көне Советлар Союзы Коммунистлар партиясе, бөтен Совет иле башкара торган эшләрдән аерылгысыз булуын әйткән иде. Бу чыннан да шулай булды.

Илне индустрияләштерү һәм авыл хуҗалыгын коллективлаштыру, Бөек Ватан сугышы һәм сугыштан соңгы торгызу еллары, чирәм җирләрне үзләштерү һәм космосны тикшерену — боларның барысы да совет халкының хезмәт һәм көрәш юлында бөек этаплар һәм шул ук вакытта коммунист Леонид Ильич Брежнев биографиясенең бөек этаплары.

Бөек социалистик бердәмлек илләренең куәте үсү һәм һәрьяклы хезмәттәшлеге тирәнәю, безнең чорда кешелек дөньясы алдында торган тарихи бурычларны хәл итүдә бөтен дөнья коммунистик хәрәкәтенең актив катнашуы, җир йөзендә барлык милли азатлык һәм социаль прогресс көчләренең теләктәшлеге ныгу Леонид Ильич исеме һәм аның эшләре белән аерылгысыз бәйләнгән. Леонид Ильич Брежнев илтифатлы кешелек дөньясы хәтерендә һәрвакыт тынычлык һәм халыкларның иминлеге өчен, кешелек дөньясы алдына килеп баскан бөтендөнья атом-төш сугышы куркынычын бетерү өчен эзлекле, ялкынлы һәм армый-талмый көрәшүче булып калыр.

Империалистлардан тынычлыкны ялварып алып булмаслыгын без яхшы беләбез. Аны бары тик Совет Кораллы көчләренең җиңелмәс куәтенә таянып кына саклап калырга мөмкин. Партия һәм дәүләт җитәкчесе буларак, СССР Оборона Советы Председателе буларак, Леонид Ильич илебез оборона сәләтенең хәзерге заман таләпләре дәрәҗәсендә булуына даими игътибар бирде.

Биредә, бу залда, Леонид Ильич унсигез ел буена даими җитәкчелек иткән партиябез штабына кергән кешеләр җыелды. Бердәм, коллектив эшне оештыруга, бу штабның ленинчыл дөрес курс алуына аның күпме көч һәм күңел җылысы салуын һәркайсыбыз белә. Бүген партиябез тормышын һәм эшчәнлеген характерлый торган сәламәт морал̧ь-политик атмосфера булдыруга Леонид Ильичның бәя биреп бетергесез өлеш кертүен һәркайсыбыз белә.

Партиябезнең марксизм-ленинизмны саклау буенча принципиаль көрәше, нык үскән социализм теориясен, коммунистик төзелешнең иң

актуаль бурычларын хәл итү юлларын эшләү Леонид Ильич исеме белән бәйләнгән. Аның бөтендөнья коммунистик хәрәкәттәге эшчәнлеге тугандаш партияләрнең, чит илләрдәге сыйныфташларыбызның, социализм өчен капитал изүенә каршы, бөек коммунистик идеалларның тантанасы өчен көрәштәшләребезнең хаклы рәвештә иң югары бәясенә лаек булды.

Леонид Ильич Брежневның гомере аның фикерләре, тырышлыгы КПССның XXVI съездында, Үзәк Комитетның аннан соңгы Пленумнарында билгеләнгән экономик, социаль һәм культура үсешенең гаять зур бурычларын хәл итүгә юнәлгән чакта өзелде. Бу бурычларны тормышка ашыру, партиябез һәм Совет дәүләтенең Леонид Ильич Брежнев җитәкчелегендә эшләнгән эчке һәм тышкы политик курсын эзлекле тормышка ашыру — безнең беренче дәрәҗәдәге бурычыбыз. Һәм бу безнең арадан киткән җитәкченең якты истәлеген иң яхшы хөрмәтләү булыр.

Безнең кайгыбыз зур. Без кичерә торган югалту авыр.

Бу шартларда һәркайсыбызның, һәр коммунистның бурычы сафларыбызны тагын да тыгызрак берләштерүдән, партия Үзәк Комитеты тирәсенә тагын да тыгызрак тупланудан, үз постыбызда, үз тормышыбызда совет халкы бәхете өчен, тынычлыкны ныгыту өчен, коммунизм тантанасы өчен мөмкин кадәр күбрәк эшләүдән гыйбарәт.

Совет халкы үзенең Коммунистлар партиясенә чын күңелдән ышана. Шунлыктан ышана, чөнки аның өчен совет кешеләренең иң кирәкле интересларыннан башка бернинди интерес та булмады һәм юк. Бу ышанычны аклау — коммунистик төзелеш юлыннан алга бару, социалистик Ватаныбызның тагын да чәчәк атуына ирешү дигән сүз.

Иптәшләр, безнең иң кыен чакларда безгә ярдәм иткән һәм ярдәм итә торган, иң катлаулы бурычларны хәл итәргә мөмкинлек бирә торган көчебез бар. Бу көч — партиябез сафларының бердәмлеге, бу көч — партиянең коллектив зирәклеге, аның коллектив җитәкчелеге, бу көч — партия һәм халыкның бердәмлеге.

Бүген безнең Пленум Леонид Ильич Брежневның истәлеген хөрмәтләү һәм ул үзенең бөтен гомерен биргән эшне дәвам иттерүне тәэмин итү өчен җыелды.

Пленум алдында Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Генеральный секретарен сайлау турындагы мәсьәләне хәл итү бурычы тора.

Иптәшләрнең бу мәсьәлә буенча фикер әйтүләрен сорыйм.

# ИПТӘШ К. У. ЧЕРНЕНКО РЕЧЕ

Кадерле иптәшләр!

Политбюро миңа Үзәк Комитетның шушы чираттан тыш Пленумында катнашучылар алдында чыгыш ясауны тапшырды.

Безнең Үзәк Комитетның чираттан тыш Пленумы чыннан да гадәттән тыш характерда бара. Ил һәм партия тирән кайгыда. Леонид Ильич Брежнев безнең арадан китте.

Совет халкы ике дистә елга якын партия һәм дәүләт башында торган, совет кешеләренең бәхете хакына, илебездә коммунизм төзү хакына үзенең бөтен көчен һәм гаять зур сәләтен биргән күренекле җитәкчесен югалтты. Без, кешелек дөньясы тынычлык, азатлык һәм социаль прогресс идеаллары өчен бөек, чын-чынлап армас-талмас көрәш-

чене югалтты, дип әйтә алабыз. Без, совет коммунистлары, социалистик илләрдәге туганнарыбыз, бөтендөнья коммунистик хәрәкәтендәге көрәштәшләребез Ленин эшен талантлы дәвам иттерүчене, безне хезмәт иләре интересларына чын күңелдән бирелгәнлеккә өйрәткән кешене югалттык.

Безнең югалтуның ачысын белдерергә сүзләр житми. Әмма бу кайгылы көннәрдә безнең барыбызга да Леонид Ильичның тормыш мәктәбе олы ярдәм булып хезмәт итә.

Леонид Ильич тулаем һәм бөтенләе белән җәмгыять интереслары, халык интереслары белән яшәү сәләтенә ия булды. Һәрвакыт, үсмер елларыннан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр шулай булды.

Әйбәт теләкләр генә буш аваз булуын Леонид Ильич яхшы белде. Дөрес фикерләр әйтү генә аз, аларны төгәл оештыру эше белән беркетергә, хезмәт ияләренең киң массаларына аңлаешлы һәм аларга барып житәрлек итәргә кирәк. Ул кешеләрне яратты. Ул кешеләргә ышана белде.

Леонид Ильич бик батыр кеше иде. Ул моны үзе беренче көненнән алып соңгы көненә кадәр булган Бөек Ватан сугышында гына исбат итеп калмады. Ул үзенең бөтен тормыш юлында батыр булып калды. Һәм ул һәр иптәшнең кыюлыгын, принципиальлеген, теләсә нинди сынауларда нык торуын югары, бик югары бәяләде.

Леонид Ильич белән янәшәдә булу, аны тыңлау, аның үткен акылын, тапкырлыгын, тормыш сөючәнлеген турыдан-туры тою — аның белән кулга-кул тотынып эшләү бәхете туры килгән барыбыз өчен дә яхшы мәктәп булды.

Леонид Ильич Брежнев безгә кыйммәтле мирас калдыра. Безнең 18 миллионлы партиябез бердәм һәм тупланган. Совет халкы партиянең зирәклегенә чын күңелдән ышана. Кадрларга таләпчәнлек һәм ихтирам, какшамас дисциплина һәм кыю, файдалы инициативаларны яклау, бюрократизмның теләсә нинди чагылышларына килешмәүчәнлек һәм массалар белән элемтәне үстерү турында, совет җәмгыятенең чын демократизмы турында даими кайгырту тормышыбыз нормасына әверелде.

Житәкчелекнең шушы стилен сакларга һәм үстерергә, Леонид Ильич үзенең сүзе һәм эше белән безгә васыять итеп калдырган бөтен нәрсәнең кадерен белергә — аның истәлеге алдында, партия һәм ил алдында бурычыбыз әнә шундый. Партиянең житәкче үзәге, аның Үзәк Комитеты, Леонид Ильичның хәлиткеч дәрәҗәдә катнашы белән төзелгән Политбюро моның шулай булачагына нык нигез булып хезмәт итә.

Политбюро исеменнән мин, безнең Пленум партиянең алга таба Ленин курсы белән нык барачагын бөтен ил алдында, бөтен дөнья алдында күрсәтер, дигән тирән ышаныч белдерергә телим. Бу ленинчыл курс хәзерге чорда КПССның XXIII—XXVI съездлары карарларында ачык һәм тулы чагылыш тапты. Партиябезнең эчке һәм тышкы политикасы — аны эшләүгә һәм тормышка ашыруга Леонид Ильич Брежнев гаять зур өлеш кертте — ышанычлы төстә, эзлекле һәм максатка омтылышлы итеп үткәреләчәк.

Халык бәхете һәм җир йөзендә тынычлыкны саклау безнең эшчәнлегебезнең юнәлеше булды, хәзер дә шулай һәм шулай булыр.

Безнең киңәйтелгән, һәрьяклап яхшы үлчәнгән социаль-экономик программабыз бар. Экономика экономияле булырга тиеш. Партиянең күрсәтмәсе шундый. Бу исә индустриаль һәм аграр секторларны яңа

техника белән коралландыруны, идарә итүне камилләштерүне һәм, әлбәттә, хезмәтне оештыруны яхшыртуны, аның җитештерүчәнлеген үстерүне аңлата. Шушы базада дәүләтебез экономикасы туктаусыз үсәчәк, халыкның тормыш дәрәҗәсе күтәреләчәк. Шушы ук базада илебезнең оборона сәләте ныгыячак.

Безнең сиксәненче еллар өчен киң, конкрет Тынычлык программабыз бар. Ул халыкның өмет-ышанычларына җавап бирә. Киеренкелекне йомшарту, коралсызлану, конфликтлы хәлләрне бетерү, атом-төш сугышы куркынычын юк итү — без үз алдыбызга куя торган бурычлар әнә шундый. Без үзебез өчен, дусларыбыз өчен, дөньядагы барлык халыклар өчен ышанычлы иминлек телибез.

Кадерле иптәшләр!

Леонид Ильичның үлеме белән безгә килгән югалтуны каплауның чиктән тыш кыен булуын безнең барыбыз да аңлыйдыр, мөгаен. Хәзер партиядә эшне коллектив төстә алып бару икеләтә, өчләтә мөһим. Барлык партия органнарында тату, бергәләп эшләү коммунистик төзелештә дә, халыкара мәйдандагы эшчәнлегебездә дә алга таба уңышларга ирешүне тәэмин итәр.

КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы, туган хәлне тикшереп, миңа Пленумга КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре итеп иптәш Юрий Владимирович Андроповны сайларга тәкъдим итүне тапшырды. Аның биографиясен сөйләп торуның кирәге юктыр, дип уйлыйм. Юрий Владимирович, партиядә һәм илдә фидакарь, Ленин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән коммунист буларак, Леонид Ильичның иң якын көрәштәше буларак яхшы мәгълүм.

Эчке һәм тышкы политика, идеология өлкәләрендә Юрий Владимировичның эшчәнлеге күп төрле. Ул комсомол җитәкчесе дә, зур партия работнигы да, дипломат та булды. Социалистик бердәмлекне ныгытуга, дәүләтебезнең иминлеген тәэмин итүгә ул күп хезмәт куйды.

Леонид Ильич аның марксистик-ленинчыл инанганлыгын, партиялелеген, киң карашлы булуын, гаҗәеп эшлеклелек һәм кешелеклелек сыйфатларын югары бәяләде. Политбюроның барлык членнары Юрий Владимирович җитәкчелектә Брежнев стилен, халык интереслары турында Брежневча кайгыртуны, кадрларга Брежневча карауны, агрессорларның казынуларына бөтен көч белән каршы торырга, тынычлыкны сакларга һәм ныгытырга әзер булуны яхшы кабул итте, дип саныйлар.

Юрий Владимировичка партиячел тыйнаклык, башка иптәшләрнең фикеренә ихтирам белән карау һәм, әйтергә мөмкин, бергәләп эшләүгә омтылу хас. Политбюро бертавыштан: Иптәш Андропов Үзәк Комитет ышанычына, партия ышанычына лаек, дип исәпли.

Кадерле иптәшләр! Леонид Ильичның якты истәлеге алдында башыбызны иеп, без үзебезнең иҗади эшебезне армый-талмый дәвам иттерәчәгебез турында тантаналы төстә вәгъдә бирәбез. Леонид Ильич эшләп өлгерә алмаган, аның җитәкчелегендә партия билгеләгән барлык эшләр эшләнер.



# ЮРИЙ ВЛАДИМИРОВИЧ АНДРОПОВ

Юрий Владимирович Андропов 1914 елның 15 июнендә Ставрополь краеның Нагутская станциясендә тимер юлчы семьясында туган. Югары белемле. 1939 елдан КПСС члены.

Уналты яшьлек комсомолец Ю. В. Андропов Төньяк Осетия АССР-ның Моздок шәһәрендә эшче булып эшли. Аннары аның хезмәт биографиясе Идел пароходчылыгы судноларында дәвам итә. Анда ул матрос булып эшли.

Ю. В. Андропов 1936 елдан — комсомол эшендә.

Ул Ярославль өлкәсенең Рыбинск шәһәрендә су транспорты техникумы комсомол оешмасының башка эшләрдән азат ителгән секретаре итеп сайлана. Тиздән аны Рыбинск шәһәрендә Володарский исемендәге суднолар верфендә ВЛКСМ Үзәк Комитеты комсоргы эшенә күтәрәләр. 1938 елда Ярославль өлкәсе комсомоллары Ю. В. Андроповны ВЛКСМның Ярославль өлкә комитетының беренче секретаре итеп сайлыйлар. 1940 елда Ю. В. Андропов Карелия ЛКСМ Үзәк Комитетының беренче секретаре итеп сайлана.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән Ю. В. Андропов — Карелиядә партизаннар хәрәкәтендә актив катнашучы. 1944 елда Петрозаводск шәһәрен фашист илбасарлардан азат иткәннән соң Ю. В. Андропов партия эшендә. Ул партиянең Петрозаводск шәһәр комитетының икенче секретаре, ә 1947 елда — Карелия Компартиясе Үзәк Комитетының икенче секретаре итеп сайлана.

1951 елда Ю. В. Андропов КПСС Үзәк Комитеты карары нигезендә КПСС Үзәк Комитеты аппаратына күчерелә һәм инспектор, аннары КПСС Үзәк Комитеты подотделы мөдире итеп билгеләнә.

1953 елда партия Ю. В. Андроповны дипломатия эшенә җибәрә. Ул берничә ел буе Венгрия Халык Республикасында СССРның гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе була.

1957 елда Ю. В. Андропов КПСС Үзәк Комитетының бүлек мөдире итеп билгеләнә.

Партиянең XXII һәм аннан соңгы съездларында Ю. В. Андропов КПСС Үзәк Комитеты члены итеп сайлана.

1962 елда Ю. В. Андропов КПСС Үзәк Комитеты секретаре итеп сайлана.

1967 елның маенда Ю. В. Андропов СССР Министрлар Советы каршындагы Дәүләт иминлеге комитеты председателе итеп билгеләнә. Шул ук елның июнендә ул КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы членлыгына кандидат итеп сайлана.

1982 елның маенда Ю. В. Андропов КПСС Үзәк Комитеты секретаре итеп сайлана.

1973 елның апреленнән Ю. В. Андропов — КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы члены.

Юрий Владимирович Андропов — күп чакырылыш СССР Верховный Советы депутаты.

Ю. В. Андропов партия кушуы буенча эшләгән барлык постларында бөек Ленин, партия эшенә бирелгәнлеген күрсәтте.

Ул партия карарларын тормышка ашыруга, коммунизм идеяләре тантанасы өчен көрәшкә үзенең бөтен көчен, белемен һәм тәҗрибәсен бирә.

Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләтенең күренекле эшлеклесе Ю. В. Андроповка Ватаныбыз алдындагы зур хезмәтләре өчен 1974 елда Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде. Ул дүрт тапкыр Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Кызыл Байрак орденнары, өч тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр белән бүләкләнде.

# КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫНДА

## КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫ «ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛЛАРНЫҢ КОММУНИСТИК ТӨЗЕЛЕШ ПРАКТИКАСЫ БЕЛӘН ИҖАДИ ЭЛЕМТӘЛӘРЕ ТУРЫНДА» КАРАР КАБУЛ ИТТЕ

СССР Язучылар союзы, аның матбугат органнары, диелә карарда, әдипләрнең халык тормышы белән, коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәләрен үстерү һәм тирәнәйтү буенча шактый эш башкаралар. Бу — әдәби көчләрне тагын да туплауга булыша, КПССның XXVI съезды куйган бурычларны үтәүдә язучыларның активрак катнашуына китерә. СССР Язучылар союзы журналларының әдәби процессны оештыру роле көчәя.

Карарда күрсәтелгәнчә, иптәш Л. И. Брежневның социализм төзү героикасын, совет кешеләренең бай рухи дөньясын, Ватаныбызның бөек эшләрен гүзәл төстә чагылдыручы истәлекләре китабы журналларда басылып чыгу илебезнең иҗтимагый тормышында мөһим вакыйга һәм әдәбиятыбыз өчен рухландыргыч үрнәк булды.

Журнал редакцияләре партия комитетлары һәм язучылар оешмалары ярдәмендә әдипләрнең промышленность предприятиеләре, зур төзелеш, колхоз һәм совхоз коллективлары белән, армия һәм флот сугышчылары белән иҗади дуслыгы тәэмин итела. Хезмәт иләре белән элемтә, әдәби постлар, халык хуҗалыгының мөһим объектларына шефлык, укучылар белән бергәләп социаль-экономик һәм рухи тормыш мәсьәләләрен тикшерү әдәбиятны хәзерге заман тематикасы белән баета, журналларда басылган материалларның чынбарлыкны чагылдыру дәрәҗәсен көчәйтә.

Хуҗалык итү өлкәсендәге уңай тәҗрибә турындагы, авылларны социаль үзгәртү проблемалары турындагы, әйләнә-тирә мохитны саклау турындагы мәкалә һәм очерклар укучыларда зур кызыксыну уята. Аларның кайберләре буенча партия һәм дәүләт органнары карарлар кабул иттеләр.

Шуның белән бергә, КПСС Үзәк Комитеты, әдәби журналларның эше яхшыртылырга тиеш, дип саный. Язучыларның иҗтимагый активлыгы, политик җитлеккәнлеге һәм профессиональ осталыгы үсү матур әдәбият матбугатына коммунизм төзелеше бурычларын хәл итүдә, халыкның культура ихтыяҗларын канәгатьләндерүдә тулырак катнашырга мөмкинлек бирә. Язучылар оешмалары, журнал редакцияләре сәләтле әдипләрне актуаль юнәлештәге әсәрләр язарга әлегә җитәрлек тартмыйлар. Совет кешеләренең яңа буыны рухы һәм вакыты белән үзләренә якын торган, әдәби ачыш итеп кабул ителерлек, кешеләрнең эшләренә тәэсир итәрлек, халык язмышын чагылдырырдай уңай геройга мохтаҗ.

Журналларның редколлегияләре, партия оешмалары һәм авторлар активы, диелә карарда, тагын да зуррак җаваплылык тоеп эшләргә тиешләр. Кайбер журналларда ватан тарихы, социалистик революция һәм коллективлаштыру вакыйгаларын тормыш чынлыгыннан җитди читләшкән рәвештә чагылдыручы әсәрләр басылып чыгу белән һич кенә дә килешеп булмый. Кайбер әсәрләрдә хәзерге заман турында уйдырма һәм

сай фикерләр әйтелә. Кайбер басмаларда редколлегияләр роле киметелә. Журнал җитәкчеләре авторларга карата һәрвакытта да тиешенчә таләпчәнлек күрсәтмиләр. Сәнгатьчә эшләнеше түбән булган, вак темалы әсәрләр байтак басыла.

Журнал битләрендә катлаулы материалны үзләштерә алмаган, дөньяга карашы буталчык булган, иҗтимагый күренешләрне тарихи, төгәл сыйнфый позицияләрдән чыгып бәяли алмаган авторларның әдәби-тарихи һәм әдәби-тәнкыйть эшләре басыла. Әсәрләргә бәя биргәндә, әдәби тәнкыйтькә кайвакыт ачыклык һм принципиальлек җитенкерәми.

КПСС Үзәк Комитеты СССР Язучылар союзына, әдәби журналларның җитәкчеләренә иҗат эшчәннәренең игътибарын һәм тырышлыгын, әдәби матбугатның сәнгать чараларын эчке һәм тышкы политиканың төп мәсьәләләренә, КПССның XXVI съезды карарлары нигезендә илне социаль-экономик үстерүнең хәлиткеч юнәлешләренә туплауга тәкъдим итте. Хезмәт коллективлары белән элемтәләрне камилләштерергә, моны бу эшнең төп максаты сәнгатьне актуаль тормышчан эчтәлек белән баету, хәзерге заман турында сәнгатьчә эшләнеше югары булган әсәрләр тудыру икәнен күздә тотып башкарырга.

Вакытлы матур әдәбият басмалары, диелә карарда, заман белән бердәм атлап барырга, совет җәмгыяте тормышындагы яңалыкны, алдынгы якларны күрергә һәм якларга, партиялелек һәм халыкчанлык принципларын тайпылышсыз кулланып эш итәргә бурычлы. Язучылар оешмалары, әдәби журналларның редколлегияләре КПССның экономиканы интенсивлаштыру, җитештерү мөнәсәбәтләрен камилләштерү, социалистик ярышны үстерү курсына бәйле темаларга язуны хупларга тиешләр. Совет экономикасын үстерү өлкәсендәге яңа бурычлар барлык иҗтимагый мөнәсәбәтләр белән, яңа кеше формалаштыру белән аерылгысыз бәйләнгән. Бу — иҗат өчен зур киңлекләр ача.

Карарда күрсәтелгәнчә, СССР Язучылар союзы һәм әдәби журнал редакцияләре иптәш Л. И. Брежнев КПСС Үзәк Комитетының май (1982 ел) Пленумында ясаган докладында куйган бурычларны үтәүдә, СССРның Азык-төлек программасын тормышка ашыруда иҗат работникларына үз урыннарын табарга һәм рольләрен билгеләргә булышырга тиешләр. Фән һәм алдынгы тәҗрибә казанышларын тизләтеп кертү нигезендә авыл хуҗалыгын үзгәртү әдипләрне авылда җитештерү һәм көнкүреш өлкәсендә яңа шартлар тудыруга бәйле чынбарлыкны сәнгать ягыннан үзләштерергә мәҗбүр итә. Яшьләрдә җиргә, табигатькә, авыл хезмәтенә мәхәббәт тәрбияләүдә әдәбият күп нәрсә эшли ала.

КПСС Үзәк Комитеты СССР Язучылар союзына, журнал редколлегияләренә һәм редакцияләренә, әдәби тәнкыйтькә социаль әһәмиятле проблематика өлкәсендә художестволы эзләнүләрне активрак якларга тәкъдим итте. Совет кешесенә лаеклы тормыш максатларын расларга, политикасызлыкны һәм кулланучылык психологиясен эзлекле рәвештә фаш итәргә.

Нәфис сүзнең, диелә документта, тәрбияви әһәмиятен күтәрү өчен, Ватанга, партия эшенә хезмәт итүне мактаучы югары патриотик яңгырашлы әсәрләр тудыру өчен барлык мөмкинлекләрне файдаланырга. Социалистик реализм сәнгате өчен советча яшәү рәвешен, коммунистик әхлак нормаларын, безнең кешеләр бәхете хакына намуслы хезмәт, интернационализм, эшебезнең тарихи хаклыгына инану кебек мораль кыйммәтләребезне раслаудан да мөһимрәк бурыч юк. Журналлар союздаш һәм автономияле республикаларның художество тәҗрибәсен тулырак чагылдырырга, тугандаш әдәбият әсәрләрен рус һәм СССРның башка халыклары теленә сыйфатлы итеп тәрҗемә итүгә игътибар бирергә, социалистик милләтләр культураларының якынлашуына һәм бер-берсен баетуына, күпмилләтле совет җәмгыятенең идея һәм политик яктан тупланууына, социалистик бердәмлек илләре халыкларының дуслыгын ныгытуга булышырга тиешләр.

СССР Язучылар союзы, аның матбугат органнары ашкынып кораллануны туктатуны, тынычлык һәм халыклар иминлеген яклап, атом-төш сугышы куркынычын бетерү таләбе белән чыгышлар ясауга совет әдипләрен, чит илләрнең прогрессив культура эшлеклеләрен киңрәк тартырга, хезмәт ияләрен совет халкының революцион казанышларын саклауга хәзерлек рухында тәрбияләргә тиешләр.

Нәфис сүз, диелә карарда, марксизм-ленинизм тантанасы өчен көрәштә, дөньядагы ике системаның идеология тартышында һәрвакыт үткен корал булды. Партия язучыларның халыкара эшчәнлегенә, аларның идея дошманнары белән һөҗүмчән бәхәс алып бару осталыгына, антикоммунизмга каршы көрәштә уйнаган актив роленә югары бәя бирә. Политик романның, публицистик фильм, драма һәм поэзиянең зур уңышы художество иҗатындагы бу юнәлешнең заман рухына туры килүен күрсәтә.

КПСС Үзәк Комитеты СССР Язучылар союзы, республика союзлары, журнал редколлегияләре игътибарын киләчәктә дә художество публицистикасын үстерү зарурлыгына юнәлтә. Яшь әдипләргә аеруча зур игътибар бирергә кирәк. Иҗади командировкалар, редакцияләр заданиесе буенча җаваплы материаллар әзерләү алар өчен җитди тормыш һәм һөнәр мәктәбенә әйләнүе ихтимал, яшьләр сәләтенә дөрес юнәлеш күрсәтергә кирәк.

КПСС Үзәк Комитеты карарында редакцияләр коллективлары эшендә журналларның башлангыч партия оешмалары ролен күтәрү зарурлыгы басым ясап әйтелә. Алар тематик планлаштыруга, басыла торган материалларның эчтәлегенә актив йогынты ясарга, редакция кадрларын сайлап алуда һәм тәрбияләүдә катнашырга, тапшырылган эш өчен югары җаваплылык хисе якларга, редакция коллективларында таләпчәнлек һәм үзара таләпчәнлекне җәелдерүгә булышырга тиешләр.

Союздаш республикалар компартияләре Үзәк Комитетларына, партиянең край һәм өлкә комитетларына, КПССның Мәскәү шәһәр комитетына матур әдәбият журналларының идея-иҗат эшчәнлегенә көндәлек игътибар бирергә тәкъдим ителде. Әдипләрнең шәһәр һәм авыл хезмәт ияләре белән дуслыгын хупларга, әдәби матбугат чыгышларына эшлекле тәстә колак салырга, журналларда басылган материалларны идеология эшендә активрак файдаланырга.

СССР Язучылар союзына, СССР Госкомиздатына СССР Госпланы һәм СССР финанс министрлыгы белән бергә журналларны басып чыгаруны, аларның полиграфик эшләнешен, тиражлау һәм тарату эшен тагын да яхшырту өчен материаль-техник базаны тагын да камилләштерү чараларын тормышка ашыру йөкләнде.

# СССРның төзелүенә 60 ел

## Зәки Нури

### Очрашсыннар җырда халыклар

Йөрәкләрне тәрҗемә ит, телем,
Илчесе бул якты фикернең!
Кавказ тавын, Украина җирен
Күз алдыма бүген китердең.

Ә иртәгә мине ерактагы
Дунай буйларына алып бар,—
Озын юллар тизрәк кыскарсын да,
Очрашсыннар җырда халыклар!

Кыргызларда инде булганым бар,
Төрекмән белән күптән серләштем...
Бергә атлап шигырь юлларыннан,
Куба белән Казан берләшсен.

Йөрәк сүзен, матур көлүләрне...—
Тәрҗемә ит, телем, барчасын.
Нинди рәхәт күреп йөрүләре
Планетаның рухи бакчасын!

Рус теле бар — һәммә телгә ачкыч,
Җанга сеңдер шуның тылсымын.
Дөнья гизеп күпме илләр ачтык!
Һәммәсеннән килде җыр шуның.

Килде җырлар Идел шавы сыман,
Яңгырадылар Тукай телендә.
Дуслар, дуслар! Әле шаулыйсы бар
Сезнең җырның бик күп күңелдә.

Салих Батыев,
Татарстан АССР Верховный
Советы Президиумы председателе

# БЕРДӘМ, ТАТУ ГАИЛӘДӘ

Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңгәннән соң ук Владимир Ильич Ленин: «Без Башкорт республикасына автономия бирдек. Без автономияле Татарстан республикасын төзергә тиешбез һәм барлык Көнчыгыш халыкларына карата шул ук политиканы дәвам иттерәбез...»— дигән иде. (В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 30 том, 321 бит.)

Юлбашчының сүзе эзлекле рәвештә тормышка ашырыла килде. 1922 елның ахырына Россия Федерациясе составындагы егермеләп республика һәм өлкә автономияле булды. Җиңүгә ирешкән Октябрь, социаль һәм милли богауларны өзеп ташлап, илдәге барлык халыкларны тарихи мөстәкыйль иҗат юлына бастырды.

Совет автономиясен төзүдә, аның формалашуында, максатларын һәм бурычларын билгеләүдә РКП(б)ның X съезды карарлары принципиаль әһәмияткә ия. Бу тарихи документларда, совет дәүләте булып оешканда, төрле халыкларның милли үзенчәлеге шартларына туры килерлек формаларын үстерү һәм ныгытуның зарури якларына аерым басым ясала: власть һәм хуҗалык органнарында, суд һәм администрациядә җирле халыкның гореф-гадәтләрен, психологиясен белүче, туган телдә эш итүче җитәкчеләр булдырырга; матбугат, мәктәпләр, театр һәм клублар, гомумән культура-агарту учреждениеләре үз эшләрен туган телдә алып барырга кирәклеге әйтелә.

Төп максат, туган телгә зур хөрмәт күрсәтеп, милли үзенчәлекләрне тирәннән өйрәнеп һәм аңлап, Совет автономиясе биргән хокуклардан файдаланып, халыкларның киң массасын караңгылыктан чыгару, экономиканы һәм культураны үстерү, Россиянең үзәгендәге һәм ерак читләрендәге районнарын социализм төзелешенә тарту иде.

Федерация эчендә автономияле совет милли дәүләтләрен оештыруның мәгънәсе, татар буржуаз милләтчеләре хыялланганча, милләтләрнең махсус аерылуында да, үз эченә йомылып яшәүче аерым хуҗалыклар булдыруда да, хәтта экономик һәм культура ягыннан артта калганлыкны гади рәвештә генә бетерүдә дә түгел иде. Без халыкларның Коммунистлар партиясе тарафыннан ныгытылган, Совет власте һәм пролетар интернационализм нигезендә туган бөек дуслыгына, экономик, политик һәм культура ягыннан үсешкә илтүче бердәмлегенә юл ярдык. Совет автономиясенең социалистик сыйфаты әнә шулар белән билгеләнә.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү һәм аның үсү юлы Коммунистлар партиясенең һәм Совет властеның милли политикасындагы иң якты сәхифәләрне тәшкил итә, Ленин теләкләренең тормышка ашуын раслаучы матур үрнәк булып тора.

1920 елның 27 маенда БҮБКы[1] һәм РСФСРның ХКСы[2] Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын төзү турында тарихи декрет чыгарды. Бер ай узгач, 25 июньдә, Казан Губерна башкарма комитеты үз вәкаләтләрен тантаналы рәвештә Татарстан АССРның вакытлы революцион комитетына тапшырды. Шул көн Татарстанның рәсми туган көне итеп билгеләнде.

Ул чактан башлап Совет Татарстаны СССР халыкларының бердәм, тату гаиләсендә данлы көрәш һәм җиңү юлын үтте. Ленинчыл милли политиканы, ягъни тигез хокуклылык, туганнарча дуслык һәм ярдәмләшү политикасын, эзлекле рәвештә тормышка ашыра барып, Татарстан нык үскән индустриягә, авыл хуҗалыгына, фән һәм культурага ия булган республикага әйләнде.

СССРның алга китешендә 1977 елда СССР Конституциясен, союздаш һәм автономияле республикаларның конституцияләрен кабул итү тарихи әһәмиятле вакыйга булып тора. Өлгереп җиткән социализм чорының Төп законнары Совет гомумхалык дәүләтендәге тирән демократизмны, тормышыбызның барлык милләтләр һәм халыклар өчен уртак булган социалистик сыйфатларын тагын да ныгытты, республикаларның хокукларын тагын да ышанычлырак итеп гарантияләде, ил алдындагы бурычларны хәл итүдә аларның ролен арттырды.

РСФСРның һәм Татарстан АССРның 1978 елда кабул ителгән Конституцияләре республикаларыбызның дәүләти-хокук статусын да ныгытты, аларның вәкаләт даирәсен киңәйтте. Безнең Конституция Татарстанның РСФСР эчендәге социалистик гомумхалык дәүләте булуыннан чыгып эш итә. Республиканың территориясе аның үз рөхсәтеннән башка үзгәртелә алмый. Ул үзенең эчке эшләрен мөстәкыйль рәвештә башкара. Татарстанның үз Конституциясен булдыру, РСФСР Верховный Советында закон чыгару тәкъдиме белән файдалану, шулай ук РСФСР һәм СССРга кагылышлы мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу хокукы бар. Безнең автономияле республикабыз үз территориясендә экономик һәм социаль алга китешне һәрьяклап тәэмин итә, үзендәге СССР һәм РСФСР карамагында булган предприятие һәм учреждениеләрнең дә эшчәнлегенә юнәлеш бирә, тикшереп, тиешле контрольне тәэмин итеп тора. Татарстан милли телдә эш итүче үз дәүләт аппаратын һәм иҗтимагый-политик учреждениеләрен тотарга хокуклы. Ул үз законнарының бозылмый саклануын тәэмин итә, үзенең гражданлык һәм дәүләт символларын булдыра ала.

Әмма шунысын да әйтергә кирәк: автономияле республика үз-үзенә бикләнеп яшәүче аерым дәүләт түгел, ул союздаш республиканың һәм Советлар Союзының составына керә. Бу сыйфат исә аның автономияле совет дәүләтенә хас төп үзенчәлеген билгели.

Совет автономиясе — милли мәнфәгатьләрне катгый төстә искә тоткан хәлдә кечкенә халыкларның зур милләтләр белән якынаюын тәэмин итүче милли дәүләт булып оешу формасы ул. Владимир Ильич Ленин С. Г. Шаумянга 1913 елның 6 декабрендә язган хатында һәм милли мәсьәләләргә кагылышлы башка хезмәтләрендә автономияләрнең чын асылын бик тирәннән ачып, аңлатып бирә. Милләтләрнең үз билгеләнү хокукын аерым дәүләт булып аерылып чыгу дәрәҗәсендә таныган хәлдә В. И. Ленин автономияләрнең төрле формаларын сыйдырган зур, бердәм дәүләтне яклый. «Без,— дип яза ул,— барлык өлешләр өчен автономия ягында, без — аерылып чыгу хокукы ягында (барысының да аерылып чыгуы ягында түгел!). Автономия — безнең демократик дәүләт төзү планы». (В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә. 19 том, 494 бит.)

---

[1] Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты.
[2] Халык Комиссарлары Советы.

В. И. Ленин, интернационалист булу өчен үз милләтең хакында уйлау гына җитми, дип өйрәтә, барлык милләтләрнең мәнфәгатен өстен күрергә, гомуми азатлык һәм тигез хокуклылыкны алга сөрергә кирәк. Кечкенә милләт вәкилләре милләтчелек ваклыкларының һәртөрле күренешләренә каршы кискен рәвештә өзлексез көрәшергә тиешләр. В. И. Ленин: «Мәсьәләне төптән уйлап җиткермәүче кешеләр изүче милләтләр социал-демократларының «аерылып чыгу ирегең» куәтләргә, ә изелгән милләтләр социал-демократларының «кушылу ирегеңн куәтләргә тиеш булуын «каршылыклы» дип табалар,— дип язды.— Ләкин аз гына уйлану да күрсәтә ки, интернационализмга һәм милләтләрнең кушылуына башка юл юк, ул максатка бара торган башка юл юк һәм булырга да мөмкин түгел» (В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 басмадан тәрҗемә, 22 том, 367 бит).

Л. И. Брежнев, милли мәсьәләнең марксистик-ленинчыл диалектик асылын, социаль һәм милли изелүләрдән тәмам котылып, алга китү өчен барлык шартларны тудырып, милләтләрнең һәрьяклап бер-берсенә якынаюына, берләшүенә ирешергә кирәк, дип аңлата. Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә Совет илендә яшәүче барлык милләтләр зур уңышларга ирештеләр. Бу фикерне РСФСРдагы уналты автономияле республиканың берсе булган Татарстан АССР мисалында дәлилләп тә күрсәтергә мөмкин.

Казан губернасы Октябрь революциясенә кадәр патша Россиясенең иң артта калган бер почмагы була. Аның халкы Казан, Уфа, Самара, Вятка, Сембер губерналарына таркатылган. Аның промышленносте, җан башына бүлеп исәпләгәндә, Россия промышленностеның уртача күләменнән дүрт тапкыр кимрәк продукция җитештергән. Предприятиеләр нигездә авыл һәм урман хуҗалыгы продуктларын эшкәрткәннәр, шәм, сабын, кәрзин кебек әйберләр ясаганнар. Казан эшчесенең хезмәт хакы Үзәк Россия эшчеләренекеннән 25 процентка кимрәк исәпләнгән.

Ярым ач яшәүче крестьяннарның хәле бигрәк тә авыр булган. Кайберәүләр, хәерчелектән котылырга тырышып, шәһәргә күчеп килгәннәр. Монда исә аларны авыл җирендәгегә караганда да рәхимсезрәк изү, кимсетүләр каршы алган.

Халыкның күпчелеге караңгылык, наданлыкта яшәп, биргән. Казан губернасы Россиянең Европа өлешендәге илле губернасы арасында уку-язуга өйрәнү буенча нибары 44 нче урында торган. Халыкның өчтән ике өлеше хәреф танымаган.

Бу кара көннәр мәңге кире кайтмаска бик еракта калды инде. Коммунистлар партиясе һәм Совет власте, ленинчыл милли политиканы эзлекле рәвештә гамәлгә кертә барып, илдәге барлык халыкларның тулы тигезхокуклылыгын, милләтләрнең үзбилгеләнү принцибын булдырдылар, барлык милләтләрнең һәм халыкларның моңарчы күрелмәгән экономик һәм культура үсешен тәэмин иттеләр.

Бүгенге Совет Татарстаны — нык үскән күп тармаклы индустриягә, заманча механикалаштырылган авыл хуҗалыгына, фән һәм культура үзәкләренә ия булган республика. Ул туган Ватанның, СССРның үсүе, ныгуы, алга баруына торган саен зуррак өлеш кертә.

Бүгенге Татарстан индустриясе промышленностьның йөздән артык тармагын берләштерә. Аларның күбесе, техника прогрессының иң соңгы ачышларына таянып, өр-яңа баштан булдырылды. Нефть индустриясе һәм нефть химиясе, машина һәм приборлар төзелеше, энергетика, электроника, автомобиль төзелеше...

Быелгы ел башына Татарстанда промышленность предприятиеләренең һәм берләшмәләренең саны 460 ка җитте. Шуларның 131 е — союз, 329 ы РСФСР карамагында, 107 предприятие исә берьюлы Татарстан һәм РСФСРга буйсына. Республика промышленность производствосының гомуми күләме, Казан губернасының 1913 елдагы җитештерүчәнлеге

белән чагыштырганда, 800 тапкырга арткан. Хәзер без ярты эш көнендә генә дә Казан губернасы ел буе җитештергән продукцияне эшләп чыгарабыз. Татарстан промышленносте продукциясе дөньяның 80 иленә озатыла.

Республика үзенең нефте белән бик урынлы горурлана ала. Безнең нефть промыселлары илгә ике миллиард тоннадан артык нефть бирделәр. Бер төбәктән шулкадәр мул байлык табу СССРда беренче тапкыр күзәтелә. Нефть промышленностена нигез салу, аны куәтле итү максатыннан чыгып, Татарстанга кирәкле техник һәм материаль ресурслар бирелде, фәнни көчләр, СССРның моңа кадәр нефть чыгарыла торган якларыннан белгечләр, эшчеләр җибәрелде. Татарстан нефтен чыгара башлауга бөтен ил бер булып катнашты: Урал бораулау җайланмалары ясады, Куйбышев, Волгоград, Пермь заводлары бораулар җибәреп торды, Азербайҗан ССРдан торбалар килде, Мәскәү, Ленинград, Уфа, Грозный безне промысел җиһазлары белән тәэмин итте. Илнең бердәм тырышлыгы, карусыз ярдәме Татарстанны илленче еллар уртасына нефть чыгару буенча СССРда беренче урынга бастырды. 1970 елда безнең нефтьчеләр елына йөз миллион тонна сыек ягулык җитештерә башладылар. Республика нефть промышленностеның үзәге булган Әлмәт җиреннән дөньяның иң зур магистраленнән саналган «Дуслык» нефть үткәргече юл алды. Татарстан бу уңышлары белән илдәге ягулык балансы структурасын яхшыртуга, аның чит илләрдәге сәүдә элемтәләрен киңәйтүгә, Советлар Союзының экономик җегәрен көчәйтүгә зур этәргеч ясады. Ватаныбыз Татарстан нефтьчеләренең фидакарьлегенә зур бәя биреп килә. «Татнефть» берләшмәсе, «Әлмәтнефть» идарәсе — Ленин орденнары белән, «Татнефтестрой» берләшмәсе — Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде, мең ярымлап нефтьче күкрәген дәүләт орденнары һәм медальләре бизи, унҗиде нефтьче Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды. Хәзер республикабыз нефтьчеләренең, интернациональ дуслыкка тугрылык саклап, Себер, Мангышлак, Белоруссия, Ухта, Удмуртия нефтьчеләренә туганнарча булышуын белеп тору исә безнең күңелләрдә иң куанычлы тойгыларны уята.

Нефть һәм газ җитештерелә башлау белән республикада нефть химиясе үсәргә мөмкинлек туды. Түбән Кама һәм Казан «Органик синтез» берләшмәләре химия промышленностебыз продукциясенең 28 процентка артуына китерде. Татарстан химиклары СССРда җитештерелә торган полиэтиленның — 31 процентын, дивинил һәм башка күп төрле химик продукциянең 28 процентын бирәләр. Түбән Камадагы нефть химиясе берләшмәсе аеруча куәтле, ул Татарстан химиясе һәм нефть химиясе башкара торган барлык эшнең 40 процентын үз җилкәсендә тота. Түбән Кама химиклары КПСС ҮК Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Леонид Ильич Брежневның ихлас күңелдән котлавына өч тапкыр лаек булдылар.

Ә Октябрь Революциясе орденлы «Органик синтез» берләшмәсе фенол, ацетон, этилен, полиэтилен һәм башка төр продукция җитештерүдә ил күләмендә иң зур предприятиеләрнең берсеннән санала. Аның продукциясе илнең 1400 предприятиесенә һәм 14 чит илгә озатыла. Бу бишьеллык азагына Татарстан химия предприятиеләре эшләп чыгару күләмен 1,7 мәртәбә арттырачаклар.

Татарстан илнең җылылык-энергетика базасын үстерүгә дә зур өлеш кертә. Без үткән бишьеллыкта гына да ГОЭЛРО планында каралган барлык электр станцияләре куәтенә тиң электр көчен сафка керттек. Бу урында гыйбрәтле бер чагыштыру китерергә мөмкин. Беренче бишьеллыкның беренче елында Татарстанда 20 млн. квт-сәгать электр энергиясе эшләнә иде, ә хәзер республика аны һәркөнне уртача 80 млн. квт-сәгать күләмендә бирә. Техник яктан иң мөкәммәл корылмалардан са-

налырга хаклы булган Түбән Кама ГЭСы — халык хуҗалыгы өчен аеруча әһәмиятле төзелеш. Проектта каралган бөтен куәтенә эшләргә тотынса, бу станция ел саен 2450 млн. квт-сәгать арзанлы энергия бирәчәк. Унберенче бишьеллыкта Татарстан җирендә атом электр станциясе дә салына башлады.

Машина төзелеше елдан-елга Татарстан индустриясенең әйдәүче тармагына әйләнә бара. Ватаныбыз автомобиль төзелешенең гигантыннан саналучы КамАЗ сафка басканнан соң, республиканың машина төзелеше бирә торган продукция икеләтә артты. КамАЗ елга 150 мең авыр йөк машинасы һәм 250 мең дизель двигателе җитештерә. Төзелешнең мондый темплары һәм бу дәрәҗә киң колачлылыгы ил өчен зур яңалык булды. Хәтта көнбатыш белгечләре дә Кама буенда соңгы ун ел эчендә башкарылган эшне «дөньяның яңа могҗизасы» дип таныдылар. Могҗизаның сере исә — совет кешеләренең үз авангарды, ягъни коммунистик ленинчыл партия тирәсенә нык тупланган булуында, Советлар Союзы халыкларының интернациональ дуслыгында һәм коммунизм төзү кебек якты максатның уртаклыгында иде. Капитал дөньясында моңа тиң могҗизаның булганы да, булачагы да юк, әлбәттә. Л. И. Брежнев КамАЗны төзүдә катнашкан каһарманнарга җибәргән котлау хатында: «Еллар үтәр, әмма совет кешеләре Кама буенда күрсәтелгән хезмәт батырлыгын горурлык хисе белән искә алырлар»,— дип язды. Татарстанның машина төзүчеләре СССР халык хуҗалыгына кирәкле төрледән-төрле продукция җитештерәләр. Арадан химия һәм тау промышленносте өчен ясалган җиһазларны, авиация двигательләрен, һава лайнерларын, вертолетларны, электрон исәпләү техникасын һәм медицина инструментларын аерым санап үтәргә мөмкин. Бу кыйммәтле машиналар барлык союздаш республикаларга җибәрелә.

Шуның белән бергә Татарстанның СССРдан, РСФСРдан зур күләмдә капитал һәм материаль-техник ресурслар алуын да әйтергә кирәк. Соңгы ике бишьеллыкта гына да республика халык хуҗалыгын үстерү ихтыяҗларына 22 млрд. сум акча бирелде. Бу аннан алдагы илле ел буе тотылган чыгымнар күләменә тигез. Совет власте елларында республикада 2000 гә якын предприятие, 31 шәһәр һәм эшче поселоклары, 30 млн. кв. метр торак, меңнәрчә мәктәпләр, больницалар һәм культура учреждениеләре салынды. 60 еллык яшәү дәверенең иң мөһим нәтиҗәсе итеп шуны билгеләргә кирәк, Татарстанның экономикасы — илдәге барлык халыкларның, милләтләрнең уртак мәнфәгатьләреннән, максатларыннан, экономик закончалыкларыннан барлыкка килгән тулы организмның бер кисәге ул. Гомумсоюз һәм РСФСРдагы олы эшләрдә үзеннән зур-зур өлешләр кертә килеп, Татарстан Ватан-ананың үсешенә, алга барышына өзлексез ярдәм итә.

КПССның фәнни нигезгә корылган аграр политикасы нәтиҗәсендә безнең Татарстан да күптармаклы авыл хуҗалыгын югары дәрәҗәдә механикалаштыруга иреште. 1934 елда ук авыл хуҗалыгындагы уңышлары өчен Татарстан АССР Ленин ордены белән бүләкләнде. Хуҗалыгыбызның бу өлкәсе кызу темплар белән үсүен дәвам иттерә. Унынчы бишьеллыкта авыл хуҗалыгы производствосы 14 процентка артты. Татарстан бөртекле ашлыклар һәм терлекчелек продуктлары җитештерүдә күренекле урыннарның берсен тота. Хуҗалыкларны специальләштерү, производствоны концентрацияләү бу юлда иң ышанычлы алым булып тора. Бездә хәзер ике йөзләп хуҗалыкара предприятиеләр һәм берләшмәләр бар. Мондый хуҗалыклардан республикада җитештерелә торган дуңгыз итенең — 25 проценты, йомырканың дүрттән өч өлеше алына, мөгезле эре терлекләрнең яртысыннан артыгын шуларда асрыйлар. Совет власте елларында авыл хуҗалыгы хезмәте тамырдан үзгәрде. Татар крестьяны, сука, урак, чалгы кебек эш коралларыннан арынып,

көчле механизмнарга күчте. Хәзер татар авылының һәр кешесе техниканың нинди дә булса бер төреннән файдаланмый калмый. Республика колхоз-совхозларында 60 меңнән артык механизатор исәпләнә. Мәгълүм ки, Татарстан җирләрен элек-электән корылык интектереп килгән. Табигатьнең кырыслыгын искә алып, без басуларны сугару системасын үзләштерәбез. Бу мәсьәләнең хәл ителүе республиканы табигать холыксызлыгыннан коткарачак һәм югары уңыш алуда нык ярдәм итәчәк.

Экономия өлкәсендәге күркәм үзгәрешләр Татарстандагы социаль үсешкә һәм культураның алга китүенә сәбәп булды. Хезмәт ияләренең тормыш шартлары яхшыра бара, шәһәр һәм авыллар матурлана, халыкның көнкүреше күзгә күренеп әйбәтләнә. Бу җәһәттән егерменче гасыр башында иҗат иткән күренекле татар язучысы Фатих Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» исемле фантастик хикәясен искә төшерик. Хикәянең төп герое гаҗәеп бер төш күрә. Төшендә ул моңарчы хыялында гына йөрткән искиткеч урында — татар клубында, имеш. Клубка хокук, медицина, математика, философия, экономика кебек фәннәрнең галимнәре, инженер-архитекторлар, композиторлар, рәссамнәр, язучылар — татар галимнәре, татарның культура һәм сәнгать әһелләре җыелган. Аларның әсәрләре хәтта чит илләрдә дә мәгълүм, имеш. Җитмеш ел элек мондый күренеш, чыннан да, бәры тик хыялда гына булырга мөмкин иде. «Вестник воспитания» журналының 1906 елда чыккан бер санында, Россиянең вак милләт вәкилләрен аң-белемле итү өчен, 4-5 мең ел вакыт кирәк дип язылган. 1905—1907 елгы революциягә кадәр татарларда вакытлы матбугат та, профессиональ театр да булмаган, ислам дине исә музыка, рәсем сәнгате белән шөгыльләнүне катгый рәвештә тыйган. Казандагы бөтен губернага бер саналган китапханәгә дә татарларны кертмәгәннәр. Патша власте вак милләт вәкилләрен югары уку йортларында укудан да тыя. Казан университетының Октябрь революциясенә кадәрге 113 еллык эшчәнлеге чорында анда татарлардан нибары 6 кеше укып чыккан.

Үткәндәге ул көннәр, Татарстанның бүгенге тормышы белән чагыштырып караганда, шомлы риваять кебек. Хәзер безнең республикада унике югары уку йорты, дүрт институтның филиалы, 57 махсус урта уку йорты, 2570 клуб һәм культура сарайлары, 1754 китапханә, 10 музей, 9 профессиональ театр, филармония, цирк бар. Алар барысы да хезмәт ияләре карамагына тапшырылган. Югары уку йортларыбызда һәм махсус урта уку йортларында 134 мең кеше белем ала. Аларның 45 проценттан артыгы — татарлар. Илнең халык хуҗалыгына ел саен Татарстанда белем алган 25 мең яшь һөнәр иясе озатыла. Мең кешегә туры килгән укымышлы белгечләр әзерләү буенча чагыштырып караганда Татарстан Франция, ГФР, Италия кебек алга киткән буржуаз илләрне дә артта калдырды.

Татарстандагы иҗади көчләр алты союзга берләшкән. Язучылар Союзында гына да 160 тан артык әдип исәпләнә. Татар әдәбияты СССР халыклары әдәбиятлары арасында үзенең лаеклы урынын тота. Язучыларыбызның замана әдәбияты таләпләренә тулысынча җавап бирүчән, югары осталык белән иҗат ителгән әсәрләрен СССР халыкларының 55 телендә һәм күп кенә чит илләрдә укыйлар.

Югарыда китерелгән мисаллар КПССның XXVI съездында алга сөрелгән «...һәр республиканың материаль һәм рухи потенциалын үстерә барырга, аңардан бөтен илнең гармоник рәвештә алга баруында файдаланырга» дигән төп курсын ачык төстә сурәтләп бирә. Безнең республиканың матурланганнан-матурлана баруы тар кысалы милли хуҗалык булдырырга омтылган, партия һәм халык тарафыннан кире кагылган солтангалиевчелекнең никадәрле реакцион идея булуын да фаш итте. Тормышыбызның күркәмлеге чит илләрдә әле бүген дә татар халкының үзәк властьлар тарафыннан «изелүе»нә, «тормыш дәрәҗәсе-

нең ифрат түбәнлеге»нә, «милләтнең бетүгә йөз тотуы»на офтанып яшәүче А. Беннигсен, К. Лакмон, А. Акыш, Т. Дәүләтшин кебек буржуаз милләтчеләрнең, ак эмигрантларның офтануына да туры җавап була ала.

Без төп көчебезнең Советлар Союзы халыкларының какшамас дуслыгында икәнен көн саен ныграк тоябыз. Ә илнең куәтен арттыру өчен исә Татарстан уллары һәм кызлары сәләтләрен кызганмыйлар. Алар, интернационализмның иң матур үрнәкләрен күрсәтеп, Магнитка, Березняки химкомбинаты, Сталинград трактор заводы төзелешләренә катнаштылар. Днепрогэс төзүчеләренең өчтән бер өлеше — Татарстан кешеләре иде.

Безнең дуслык Бөек Ватан сугышы елларында тагын да ныгый төште. Коммунизм төзү өчен барган бүгенге көрәштә бу гаҗәеп дуслык тагын да сафлана, яңа баскычка күтәрелә бара. Ил Казахстандагы 25 млн. гектар чирәм җирләрне үзләштергәндә дә, Татарстандагы һәм Себердәге нефть катламнарын айкаганда да, җир тетрәүдән хәрабә хәленә килгән Ташкентны аякка бастырганда да, БАМ, КамАЗ кебек гигант төзелешләрдә дә, РСФСРның кара туфраксыз җирләрен эшкәртүдә дә һәм башка бик күп очракларда безнең дуслык сынатмады. Бу эшләр СССР халыкларының тату, бердәм гаилә кебек яшәвенә һәйкәл булып тора.

Совет федерацияләренең һәм автономияләренең тормышчанлыгын тарих үзе дәлилләп күрсәтте. Даһи Ленинның «Бу федерация бөтенләй ирекле рәвештә, ялгансыз һәм богаусыз үсәр, һәм ул какшамаслык булыр»,— дигән сүзләре рас килде. (В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 26 том, 473 бит).

Тәҗрибә СССРда федератив төзелешнең төп сыйфатлары үзен аклавын күрсәтә. Совет федерациясе һәм автономиясенең тарихи миссиясе милли мәсьәләне хәл итүдә генә түгел. Нык алга киткән социализм шартларында дәүләт булып оешуның милли формалары СССР халыкларын коммунизм төзүдәге бурычларны хәл итүгә туплауда зур роль уйный. КПСС ҮКның «СССР төзелүнең 60 еллыгы турында»гы карарлары гаять зур теоретик һәм практик әһәмияткә ия. Анда, әле беренче тапкыр, федератив форманың «социалистик дәүләтнең акрынлап коммунистик үзидарәгә үстерелә баруына йөз тоткан тарихи дәвердә» дә сакланачагы турында әйтелә.

Ленинчыл Коммунистлар партиясе бөтен совет халкын, шул җөмләдән Татарстан хезмәт ияләрен дә, интернационализм рухында тәрбияләде һәм тәрбияли. КПССның XXVI съездында әйтелгән партия «социализмның бөтен табигатенә каршы килүчән шовинизмга яки милләтчелеккә, милләтчелекнең һәр төрле күренешләренә каршы көрәште һәм һәрчак кискен рәвештә көрәшәчәк,— дигән сүзләр безнең эшчәнлектә күрсәткеч булып тора.— Без милли үзенчәлекләрне ясалма төстә бетерүгә юнәлдерелгән тенденциягә каршы. Әмма аларны ясалма рәвештә сакларга тырышуның да һич нигә кирәге юк, дип саныйбыз».

Әмирхан Еники

# СОҢГЫ КИТАП

## ДӘҮЛӘКӘН

### Дим буйлары

Казаннан Дәүләкәнгә Бәләбәй аша да, Уфа аша да кайтып була. Бәләбәй аша шактый урау һәм мәшәкатьле: башта самолет белән Бөгелмәгә, Бөгелмәдән автобуста Бәләбәйгә, Бәләбәйдән инде поезд белән Дәүләкәнгә. Шулай да, мәшәкатенә карамастан, Бәләбәйне күрер өчен генә бу юл белән дә кайтып йөргәнем бар. Ләкин күбрәк, билгеле, Уфа аша йөрим.

Дәүләкәннән мин беренче мәртәбә ерактагы таш калага — бала чактан ук әлифба китабы белән бергә күңелгә кереп урнашкан мәшһүр Казанга 1925 елның августында чыгып киттем. Бу чакта миңа уналты яшь иде. Утыз икенче елга кадәр һәр җәйне атам йортына кайта идем. Соңгы кайтуым утыз дүртенче елның кышында булды. Бу вакытта инде атам-анам да Казанга күчеп килгәннәр иде. Шуннан соң мин егерме ел Дәүләкәнемә кайтмыйча тордым. Нәкъ егерме елдан соң, ягъни илле дүртенче елдан башлап, минем өзелгән юлым яңадан ялганып китте. Һәм шушы вакыттан алып, мин ике-өч ел саен диярлек, берничә көнгә генә булса да, Дәүләкәнгә кайткалый торам. 1969 елны кайтып, шундагы иске дус-ишләр белән алтмыш яшем тулу бәйрәмен дә үткәреп киттем. Аннан соң да кайтып йөрүем өзелмәде һәм моннан соң да, иншалла, өзелмәс дигән өметем бар әле.

Бер уйласаң, бу сәер дә тоелырга мөмкин. Җитмеш елдан артык гомеремнең бары унбиш елы гына Дәүләкән өлешенә тия бит, калганы исә гел читтә, еракта узды. Әмма ул унбиш ел минем гомерем башы — иң саф, иң самими, иң гөнаһсыз чагым. Нәкъ шушы чакта адәм баласында хыял канатлана, мәхәббәт кабына түгелме соң?!. Югыйсә, җитмештән узгач та кайтып йөрү нигә кирәк икән?..

Ярты гасыр эчендә Дәүләкән халкы алышынып бетте диярлек. 1926 елны анда сигез меңнән артыграк кеше яшәгән булса, 1975 елда инде егерме меңнән дә артып киткән. Димәк, яртысыннан күбесе —

---

«Соңгы китап»ның беренче өлеше журналның 1981 ел 10, 11 саннарында басылды.

мин киткәч үрчегән яки читтән килгән халык. Минем замандагы кешеләр юк, беткән яки берәм-сәрәм генә калган. Бик күп йортлар искерсә дә, үзгәрсә дә миңа таныш, кемнәр торганын да яхшы беләм, әмма ләкин күптән инде ул йортларда хуҗалары гына түгел, аларның токымнары да яшәмиләр. 1969 елны туган көнемне үткәрергә кайткач, бер табынлык иске дус-ишләрне җыя алган идем, ә хәзер анда мин белгән һәм мине белгән бары дүрт-биш кеше генә калды. Кыскасы, чын дөресен генә әйткәндә, Дәүләкән хәзер миңа үзе дә ят, халкы да ят. Кайткан чакларымда урамнары буйлап йөрим, әлеге ике-өч танышымда булам, районның берәр җитәкчесенә «визит вежливости» ясыйм; әлбәттә инде, Дим буена төшәм, үзем ишеп, ялгызым гына көймәдә йөрим, шул рәвешчә бер-ике көн әйләнәм-тулганам да, электричкага утырып, китеп тә барам. Минем бер кимчелегем бар: төрле җирләргә кереп, күренеп йөрергә, кыскасы, үземне афишировать итәргә бер дә яратмыйм. Дәүләкән яши, кайный, зур-зур эшләр башкара... Бу инде асылда нык үзгәргән, зурайган яңа шәһәр, әмма шушы яңа шәһәр аша мин әле үземә бик таныш иске Дәүләкәнне дә күрәм. Әйе, тарта мине Дәүләкәнем, тарта, туган авылым Каргалыга караганда да ныграк тарта! Ни өчен? — үзем дә аңламыйм. Бәлки бишектән алып үскән җирем, эчкән суым, йөргән сукмакларым шушында калганга күрәдер.

...Хәтерлим егерме елдан соң беренче мәртәбә кайтуымны... Июль ахыры, әллә август башы иде — Уфадан Дәүләкән станциясенә мин тәмам караңгы капкач килеп төштем. Якын туганнардан монда беркемебез дә юк, иске танышлардан кемнәр барын да ачык кына белмим — бу вакыт эчендә зур сугыш та үтеп китте, кешеләр язмышында нинди генә үзгәрешләр булмагандыр... Шуңа күрә мин тоттым да электән үк гостиница хезмәтен үтәүче, тимер юл каршындагы бер генә катлы таш йортка юнәлдем. Барып, хадимә хатынны уятып, үземә урын-койка алдым. Ләкин ятып йокларга һич тә теләгем юк иде, кечкенә чемоданымны калдырдым да кире чыгып киттем. Инде төн уртасы якынлашадыр, Дәүләкән өстендә тулган ай. Тулган айның томанлырак яктысы миңа бик таныш ул! Мондый төннәрдә нигәдер бик ямансу була торган иде... Әйтергә онытa язганмын, әле поездан төшеп, вокзал урамына чыккач та мин бик тәмле бер хуш ис сизгән идем. Менә яңадан шул урамга килеп кергәч, бу гаҗәеп таныш һәм тансык ис бөтенләй аңкып тора башлады. Хәйран калдым — айлы төндә, Дәүләкән урамында... алма исе!.. Әнис белән антоновка исе!.. Кайдан бу?.. Нигә шул хәтле көчле аңкый ул?.. Бервакытта да алма исе болай таралганын мин һич тә хәтерләмим, чөнки бу тирәдә алма бакчалары юк — элек тә юк иде, хәзер дә күренми алар... Дәүләкән җиләк-җимеш бакчаларына гомумән бик ярлы иде. Бигрәк тә татар, башкорт өлеше... Дөрес, ике бик зур алма бакчасы бар иде, шуларның берсе моннан ерак та түгел татар бае Кәримовларныкы, ләкин аның да гүләнья бакчасына әйләндерелгәнен ишеткән идем инде. Гүләнья бакчасында әнис алмагачлары хәзергә кадәр, ай-һай, сакланып торыр микән?!. Шулай гаҗәпләнеп иснәдем мин бу хуш исне, иснәдем, ләкин кайдан таралуын артык тикшереп тормадым, чөнки алма исеннән дә кадерлерәк икенче бер нәрсәне тизрәк барып күрәсем килә иде. Вокзал урамыннан Дәүләкәннең төп урамына чыктым да югары очка таба карап киттем. Урам тып-тын, бер кеше заты юк, өйләрдә утлар күптән сүнгән, тик аларның кара күләгәләре генә җиргә ап-ачык булып яткан. Барысы да бик таныш өйләр, үткәннәрне күргәндәй һәркайсына карап узам. Менә кирәк урынга килеп җиттем, менә каршысына туктадым — мин үскән безнең йортның дим... Егерме елдан соң менә каршысында басып торам. Нихәл, танысыңмы мине, дип дәшәсем килә... Төн уртасында килеп йөрүем өчен гаеп итмә, дисәсем килә... Түзмәдем шул, ялгыз, аулакта гына күрәсем килде сине!.. Ышан, сагынуым ашыктырып китерде!..

...Тордым шулай, тордым шикле кеше сыман аның каршысында басып, аннары теләр-теләмәс әкрен генә кузгалып киттем. Бу йортыбыз турында сүз алда күп булыр әле, тик хәзергә шуны гына әйтеп үтик: утыз икенче елның көзендә, Казанга күчәр алдыннан атакай аны ниндидер бер оешмага сатып киткән иде. Күрше тирәдә аерылыбрак торган йорт иде, чөнки ике катлы иде ул — аскысы жиргә кертебрәк — таштан, ә өске каты таза бүрәнәдән салынган иде. Һәммә жире бөтен, таза иде әле ул чакта. Ә хәзер күреп исем китте: йорт тәмам искергән, тузган, ничектер картаеп, боекланып киткән. Аскы катның штукатуры кубып беткән, өске катның бүрәнәләре арасыннан мүкләре иске бау кисәгедәй асылынып тора; урамга караган өч тәрәзәнең дә капкачлары каерылган, парадный ишеге бөтенләй юк, аны иске такталар белән каплап куйганнар; урам яктагы бакча рәшәткәсе дә юкка чыккан, үсеп утырган топольләрнең берсе дә калмаган, шунлыктандыр инде, йорт үзе дә өстен салдыргандай бик ялангач күренә.

Билгеле, мин икенче көнне дә йортыбызны күрергә килеп життем. Бу юлы ишегалдына да кереп, бөтен жирен ашыкмыйча гына карап чыктым. Үзгәрешләр зур иде. Ишегалды яклап та матур гына бакчабыз бар иде — ул юк, бакча кырында гына җәйге алачыгыбыз бар иде — ул юк, эчтәрәк зур тәгәрмәч чыгырлы коебыз бар иде — ул да юк. Бусы гаҗәбрәк, кое югалмаска тиеш иде, күрәсең, ишелеп төшкәндер дә, күмеп куйганнардыр.

Мин инде өйнең эченә дә керергә яхшысынмадым. Өске катында ике, аскысында бер квартирант тора икән. Шулардан ике хатынны күрдем. Ишегалдында бөтенләй ят бер кешенең каранып йөрүе аларны бик гаҗәпләндерде булса кирәк, миңа үземнең кем булуымны, ни өчен килүемне аңлатырга туры килде. Шунда ук хәлемә кереп, хәтта кызганган төсле дә булып, квартирларын да күреп чыгарга чакырдылар. Нигәдер мин аларның бу яхшылыклары белән файдаланырга кыймадым. (Тышындагы үзгәрешләрне күрү дә житәр, эчендәгесе... хыялымда сакланган килеш калсын дидем ахрысы.) Әзрәк сөйләшеп тә тордык, алар Дәүләкәнгә бездән соң килгән кешеләр икән, шуңа күрә безне белмиләр, аннары саубуллашып, капка сыман бер ачык урыннан чыгып киттем. Ләкин, шул ук көнне фотограф ияртеп килеп, йортыбызны урам яктан гына булса да төшертеп алдым. Һәм шуннан соң гына Дәүләкәндә мин белгән кешеләрдән кемнәр барын-югын урам буенча йөреп дигәндәй ачыкларга керештем. Хәер, тагын бер нәрсә шул ук көннең иртәсендә үк ачыкланды: бу — әлеге мине хәйранга калдырган «алма» исе... Кәримовлар бакчасы дигән идем бит әле, менә шул Кәримовлар ихатасы белән янәшә заманында ак кирпечтән салынган зур бер магазин бар иде. Һәм шушы магазинны, тагын ниндидер каралты-биналарны әйләндереп алган койма эчендә, хикмәте хода, балалар аяк киеме тегә торган фабрика корып җибәргәннәр икән. Инде әйтсәм әйтим, әлеге борынны ярып кергән «әнис исләре» шул фабрикадан таралган ниндидер җилемме, лакмы исе булып чыкты!.. Белгәч, ирексездән көлеп җибәрдем. Юк, чынлап та, хуш исле фабриканың Дәүләкәндә эшләп ятуы күңелле бер сюрприз булды бит әле минем өчен...

Хуш, кай тарафтарак соң ул минем Дәүләкәнем? Башкортстанда икәнен беләсез инде, Уфа белән Бәләбәй арасында. Дим елгасының урта агымында утыра ул. Уфадан кузгалып, Агыйдел күперен чыккач та поезд Дим буйлап китә. (Нәкъ шул күпердән чак кына өстәрәк Дим Агыйделгә килеп тә кушыла.) Тик поезд көнбатышка таба бара, ә Дим көнчыгышка карап ага. Бик матур, бик хозур урыннар. Димнең түбән агымы буе белән диярлек тоташ агачлык. Елга җәелеп үскән биек, юан тирәкләр арасыннан бормаланып ага, кайбер төшләрдә тимер юлына якын ук килә, янәшә бара, аннары тагын карт тирәкләр ышыгына китеп югала. Тик ара-тирә генә аның куе куләгәләрдән зәңгәрләнгән

өсте күренеп кала. Әнә шулай, Алкино станциясен узганчы, елга белән тимер юл, һәркайсы үз юнәлешендә, янәшә баралар, ә Чишмәгә җитәрәк инде Дим каршы яктагы ерак сыртларга таба аерылып китә. Алда исә аның чакрымнарга җәелгән киң, тип-тигез тугае ачыла...

Минем атакай Дим елгасын Башкортстандагы иң якты елга дип әйтә торган иде. Чөнки кояш чыгышына карап ага ул. Чынлап та Димнең өстендә, буеннан-буена, сыек рәшә сыманрак үзенә бер яктылык балкып тора. Моны бигрәк тә ерак сыртлар өстеннән караганда ачык күреп була. Әле дә хәтерлим, бала чакта Ташлыкүлдән кайтканда, Балкан тау итәкләрен узуга, бик ерактан ук юка гына аксыл ефәктәй нурлы томанга төренгән Дим буйлары ачылып күренә башлый иде... Ходаем, нинди киңлек, нинди җылы, якты иркенлек!— бу күренештән күзләр генә түгел, күңелләр дә ничектер кытыкланып, җилкенеп китә торган иде.

Уфа белән Дәүләкән арасын — туксан чакрым, ә Чишмәне нәкъ шуның уртасында диләр. (Хәер, минем чамалавыма караганда Чишмә Уфага якынрак булырга тиеш.) Менә шул Чишмәдән чыгып киткәч тә поездның сулъяк тәрәзәсеннән Дим үрендә күгелҗем томан эченнән бер тау күренә башлый. Бу — Ярыштау. Дәүләкән әнә шул тау каршысында инде. Ерактагы ялгыз тау ачылу белән, мин үземне Дәүләкәнгә кайтып җиткәндәй тоя башлыйм һәм вагон тәрәзәсеннән китмичә тик шуңа карап барам. (Хәлбуки, сәгатьтән артыграк барасы бар әле.) Бу — гадәтемә әйләнде дияргә ярый, чөнки Ярышның күренә башлавы минем өчен кавышу, ә күздән югалуы аерылышу билгесе ул... Чөнки Дәүләкәнгә җиткәнче Дим буенда Ярыштан башка дөнья өстенә ялгызы карап торган бүтән бер тау да юк. Бала чактан ук кайсы яктан гына кайтырга туры килсә дә, иң элек Ярыш ачыла, Ярыш озын юлдан ялыккан күңелләрне күтәреп җибәрә торган иде.

Ләкин шунысын да әйтергә кирәк: Дәүләкән нәкъ Ярыш каршында торса да, алар арасы шактый ук ерак әле: берсе Димнең сул ягында, ә икенчесе уң ягында, арада ике-өч чакрымга җәелгән тугай, тугай бетүгә — Көрмәнкәй тавы, һәм шушы озын тәбәнәк тауны менеп, дүрт-биш чакрым киткәч кенә Ярыштауның итәге башлана. Зур тау үзе дә ике катлы: иң элек, Димгә карап, озын сәкедәй бер тау сузыла, аннары шул «сәкенең» нәкъ уртасына каплап салган казан шикелле Ярыш үзе басып тора.

Мәһабәт, горур тау ул Ярыш! Теләсәң кай җиреннән аңа менеп тә булмый. Шулай да малай чагымда Дүртөйлегә караган ягыннан тырыша-тырыша түбәсенә менгәнем бар. Ул заманда аның турында төрле хикмәтләр дә сөйлиләр иде. Имештер, «ак патшага» каршы баш күтәргән башкортлар, Ярыш түбәсенә тупланып, шуннан карательләр отрядына каршы яман сугышканнар. Соңгы елларга чаклы анда уклар, ук башлары табыла торган булган имеш. Аннары тауның нәкъ түбәсендә ялгыз кабер дә бар, аны ниндидер бер батыр кабере диләр — димәк, Ярыш турындагы сүзләр бөтенләй ук нигезсез булмаска тиеш. Мин үзем бер нәрсәне яхшы хәтерлим: Ярыш түбәсеннән Ачлы күл ягындагы Балкан тавы ерактан күгәреп кенә күренеп тора иде. Аралары кимендә бер утыз-утыз биш чакрым булыр. Балкан да ялгыз тау, аның да үз легендасы бар (Зыятүләк белән Сусылу әкияте) — менә шул ике тау ике баһадир сыман бер-берсенә карап торалар да инде.

Әйе, гаҗәеп киңлек, иркенлек монда, таулар, елгалар, тугайлар, кырлар-яланнар барысы да атлар чабып җитмәстәй булып күренә. Бер кайтуымда райкомның икенче секретаре иптәш Халиков мине үзе белән авылларга алып чыгып киткән иде. Яңа гына урып-җыю башланган чак. Башта бер совхозга бардык. Анда игенне шундый зур мәйданнарда үстергәннәр ки, җирнең бер башыннан төшкән комбайн икенче башына җиткәндә инде күздән югала. Исем китте шуңа... Иң әшәке юлдан да

курыкмый торган «газик»та без күп җирләрне әйләндек. Иптәш Халиков белән сүзләр килешкән иде, коры, һавалы рәсмилек аңарда юк, гади, ачык күңелле, теләсә нәрсә турында рәхәтләнеп сөйләшеп була. Бер кулын сугышта өздергән, йөрәк тә таза түгел икән, ләкин яшь иде әле, дәртле кеше иде. Каргалыга да ул мине райком машинасында илтеп куйган иде. Әмма, ни кызганыч, икенче кайтуымда бу тынгысыз, авыр эштә янучы яшь кеше дөньяда юк иде инде. Чишмә районына, әнисе янына кайтып үлгән диделәр.

Халиков минем өчен яңа кеше иде, һәм, гомумән, район оешмаларында эшләүчеләрнең бик күбесе якын-тирә авыллардан яки бөтенләй читтән килгән шундый ук яңа кешеләр. Дәүләкәннең үз кешеләре, һәрхәлдә миңа танышлары бик аз иде. Бигрәк тә җитәкчеләр арасында... Хәер, Дәүләкәннең үзеннән чыккан Зубарев фамилияле кеше дә райкомның беренче секретаре булып шактый вакыт торган иде. Алтмыш яшем тулу көнен үткәрергә кайткач, ул мине бик әйбәт каршы алып, кабинетында безнең белән (Казаннан Илдар Юзеев, Уфадан Вәзих Исхаков «юбилярны» озата килгәннәр иде) әңгәмә уздырып, кирәк кешеләргә тиешле боерыкларны биреп һәм ахырдан минем мәҗлескә килеп, бераз гына утырып та киткән иде. (Борис Михайловичның бу кешелекле игътибарын әле дә онытканым юк.) Тик шунысы бар: без икебез дә дәүләкәнле булсак та, кызганычка каршы, ул — мине, мин аны белмим, чөнки ул мин авылдан чыгып киткәч кенә туып үскән кеше. Аталары да бездән еракта, Дәүләкән очында торган икән, хәер, без бер-беребез турында артык сорашмадык та — мин яхшысынмадым, ә ул үзенә кирәген болай да белгәндер дип уйлыйм.

Билгеле инде, мин беренче нәүбәттә үземә якыннарны, үз тиңнәремне күрергә дип кайта идем. Ләкин алар да күп түгел, кемне сорама — ул юк, кайсы киткән, кайсы үлгән, кайберләре сугыштан кайтмаган... Әйе, аз табылды малай чак дуслары!.. Хәзер исә шулардан бары ике генә кеше калды — Гомәр дә Әхтәм... Өченчесе Хәмит иде... Иң элек сүзем дә аның турында.

Хәмитне мин икенче кайтуымда ук эзләп таптым. Ул күптән инде Дим аръягындагы Иске Көрмәнкәйдә тора икән. Сугыштан кайткач өйләнгән, дүртме-бишме баласы бар, хатыны — түгәрәк йөзле, сөйкемле, тулы гына башкорт бичәсе, Сәгыйдә исемле. Өе авыл урамының иң очында, тау итәгендә үк, аңардан соң башка өй дә юк. Шактый искергән, чалышая да төшкән, түбәсенең бер башы такта, әчкәре башы салам. Бүрәнә араларын сылап, известь белән буяган. Ишегалдында балчык белән сылаган читән алачыгы һәм салам япкан читән абзары бар. Башка каралтысы юк. Кыскасы, ярлырак авыл кешесенең өе-ихатасы.

Хәмит белән без бер елгы — яшьтәшләр. Ул Дәүләкән мәзине Нәбиулла абзый улы иде. Без бер урамда үстек, аларның өйләре дә бездән өстәрәк, дүрт йорт аша гына иде. Атасы Нәбиулла абзый кара-көрән кеше, кечкенә кара сакаллы, тышкы кыяфәте белән бер дә дин әһеленә охшамаган иде. Һәм ул тормышта гади бер крестьян да иде, җәйге кызу эш өстендә чабатасын киеп, атын җигеп печәнгә дә, уракка да йөри иде. Үзенә күрә аты-туны, хуҗалыгы бар иде. Әмма төп эше, әлбәттә, мәзинлек итү, һәм халык өчен дә ул шулай — мәхәллә мәзине иде.

Ураза аенда без, малайлар, мәчет коймасы буена җыелып, аның кичке азан әйткәнен көтә идек. Ахшам тыңларга җыелу (кичке азанны шулай дип атый идек) үзе бер күңелле эш, ләкин мәзин абзыйның манарада күренгәнен көтеп алалмыйча зарыгып бетә идек. Ниһаять, башына ак чалма ураган мәзин абзый таш манара ишегеннән килеп чыга. Ләкин ул нигәдер ашыкмый әле, бераз кояш баешына карап тора, түш кесәсеннән сәгатен чыгарып, аңа да карап ала, бары шуннан соң гына, ике кулын колагына тидереп, манараны әкрен генә әйләнә-әйләнә, матур көр тавыш белән азан әйтә башлый. Без аның тамак төбен каймак

белән майлагандай көчле-йомшак яңгыраган тавышын ишетүгә, дәррәү урыныбыздан кубып, «Азан әйтелде, азан әйтелде!» дип кычкыра-кычкыра өйләребезгә чабабыз, ә өйдә инде авыз ачар өчен табынга бөтенесе әзерләнеп куелган була торган иде.

Мәзин абзый малайларын да бик иртә эшкә җикте. (Хәмиттән башка тагын Фәрид исемле улы бар иде.) Шуңадыр ахрысы, Хәмит эшсез йөргән урам малайлары арасында сирәк күренә иде. Безнең уеннарга да һәм төрле ямьле-ямьсез шуклыкларга да ул бер дә диярлек катнашмый иде. Аның каравы, Хәмит бик зәһәр балыкчы иде, бәрәңге бакчалары су буена төшә, тагарак шикелле генә көймәләре дә бар, һәм менә иртә таңнан басмага кем төшеп утырган, аръякта кармакларын күтәреп кем йөри дисәң, шул Хәмит була торган иде. Озын җепкә тезгән ак таран, чабак, кызыл канатларны да күп алып кайта — малайлар көнчелектән «ул балык догасын белә» дип әйтә торганнар иде... Менә шул сәбәпләр аркасында булса кирәк, миңа малай чакта Хәмит белән күп аралашырга да туры килмәде. Үзенә башка иде ул, безнең ише бушка урам таптаучы түгел иде.

Аннары тагын Дәүләкәндә иң беренче башлап тракторга утырган егет тә әнә шул Хәмит булды. Соңыннан үзенең сөйләвенә караганда, Дәүләкән МТСына яңа гына кайткан «фордзон» тракторына менеп утырган да, һичкем өйрәтмәстән, үзе белеп йөртә дә башлаган. Бәлки әзрәк арттырадыр да Хәмит дус, әмма ничек кенә булмасын, тракторны бик тиз «иярләп» ала һәм сугышка киткәнче аның өстеннән төшми дә... Ләкин мин эзләп тапканда, ул инде Кәрмәнкәй колхозында ат җигеп, төрле вак-төяк эшләрдә йөри иде. Бахыр, сугыштан бик нык яраланып кайткан. Җиң эчендә кулы булса да, ул бары тире белән сеңергә генә эләгеп тора икән. Госпитальдә врачлар кисик дисәләр дә, Хәмит кистермәгән, менә хәзер үзе үк, ат җиккәндә уң кулыма әзрәк ярдәме тия, дип куана. Сыкранмый, куана! Колхозда эшләүче фронтовикның бу куанычын аңларга була, минемчә.

Дәүләкәндә минем тагын бер якын дусым — Гомәр Зәйнуллин, Сафиулла абзый улы, безгә тагы да якынрак күршеләр — йортлары да урам аша гына иде. Кайткан саен мин иң элек Гомәргә барам, аны алып чыгып китәм, бөтен вакытымны диярлек аның белән бергә уздырам. Ул — Дәүләкәндә утырып калган иске танышларның иң якыны, коммунист, район һәм өлкә газеталарына язгалап торучы, кыскасы, миңа иң кирәк кеше. Аның белән сөйләшеп йөри-йөри мин күп нәрсәләрне искә төшереп, хәтеремдә яңартам.

Кәрмәнкәйдәге Хәмит дус янына да без гел Гомәр белән бергә бара идек. Күбрәк аргы якка чыгып, тугай сукмагыннан туры гына атлыйбыз, ләкин элегрәк, бер-ике тапкыр көймә белән дә бардык. Бормаланып аккан елга буйлап юл озынрак һәм агымга каршы ишүе дә авыррак, әмма аның каравы Димнең гаҗәеп матур җирләрен — текә кара яр буйлап сузылган әрәмәлекләрне, бөтен өсте ак, сары төнбоеклар белән түшәлгән тынын култыкларны, куе таллыклар күләгәсе каплаган тар ерымнарны күреп узасың. Бөтен әйләнәдә тынлык, яктылык, болыннан чапкан печәннең хуш исе килә. Атластай тыгыз-якты елга бөтерелеп-уймакланып тын гына ага, ә бераз алдарак тип-тигез су өстендә кинәт сикергән балыкның сырты ялтырап кала... Көймә белән барганда, Кәрмәнкәй юлы әнә шундый ул.

Малай чакта әллә ни күп аралашмаган Хәмит кордашымны менә хәзер килеп белдем һәм бик тиз ияләштем үзенә. Ул гомере буе җирдән аерылмаган гап-гади авыл кешесе булып чыкты. Атасы кебек төскә биткә көйгән сөт касмагыдай кара-көрән, тик гәүдәгә кайтыш, үтә ябык, чандыр... Елмаеп кына сөйләшә, алгы тешләре юк, көлгәндә авызын кызлар шикелле кулы белән каплый. Хәер, тартынучан димәс идем

мин аны, күргән-кичергәннәрен бер дә иренмичә сөйли, кәефе килсә, берәр озын көйгә карлыга төшкән тавышы белән сузып та җибәрә.

Тормышы да аның үтә гади, натуральный дип тә әйтергә мөмкин. Икмәк кенә колхоздан, калганы барысы да үзенеке. Балыкка йөрүне дә ташламаган икән.

Хатыны Сәгыйдә дә үзенә бик тиң килгән, чын авыл җиңгәсе: ачык, сүзгә юмарт, кунакчыл. Гәүдәгә ул Хәмиттән күп тазарак, әмма чебеш кебек ирен чын ихластан санлап, яратып тора булса кирәк — шулай сизелә.

Бер вакытны шулай ашап-эчеп утырганда Сәгыйдә Хәмитнең үз алдында ничек итеп аңа кияүгә чыгуын да сөйләп алды. Хәмит, хатынының сүзләрен җөпләгәндәй, ара-тирә көлгәләп, тыңлап кына утырды. Башта шуны әйтергә кирәк, Сәгыйдәнең беренче ире сугышта һәлак булган, аннары инәсе дә үлеп киткән, шулай итеп атасы белән икәү генә торып калганнар. Күпмедер вакыттан соң Хәмит кайта, боларга килеп йөри башлый, Сәгыйдәнең атасы белән дуслашып китә, еш кына сөйләшеп утыралар, эчкәләп тә алалар икән. Күрәсең, ялгыз солдат атай кешегә ошап киткән — көннәрдән бер көнне ул Сәгыйдәгә әйткән: «Кызым, һин, булмаһа, Хәмиткә сык!» — дигән... Сәгыйдә бераз уйлап торган да: «Юк, сыкмаем»,— дигән. «Ник?» — дип сораган атасы... Моңа каршы Сәгыйдә: «Һин дә эсәһең, ул да эсә, кәрәкмәй, сыкмаем»,— дип җавап биргән. Атай кеше шактый уйга калган. Аннары күпмедер вакыттан соң тагын иплән кенә әйткән: «Хәмиткә сыкһаң, эсүемде ташлайым»,— дигән. Моны ишеткәч, Сәгыйдә дә: «Ярай, уйлап карармын»— дип әйткән... Билгеле, аның үз күңелендә дә нидер булгандыр инде, чөнки озак та үтмичә, Хәмит бер килүендә боларда торып та калган.

— Шулай итеп, атайым димләве аркаһында ошо Акбирдин иптәшкә сыгып куйдым шул,— ди Сәгыйдә, сүзен очлап һәм Хәмитенә хәйләкәр генә күз атып: — Шөкер, ахырдан үкенергә туры килмәне, әйбәт кенә тороп киттек, бына биш бала үстерәбез инде,— ди.

— Ә барлыгы унны тапты,— ди Хәмит, Сәгыйдәнең аркасыннан кагып,— молотчина мңнем бичә ул тарафтан, тик сабыйларыбыз гына барысы да тормады. Ату, мать-герой буласы иде минем Сәгыйдәкәй!

Сәгыйдә оялуыннан бары кызарып кына куя һәм, ашыгып, тастымал белән битен сөртергә тотына.

Әнә шулай сөйләгән иде Хәмит бичәсе ничек итеп өйләнешүләрен. Гади авыл кешесе «ярату» сүзен гадәттә кулланырга яратмый, әмма ләкин ничегрәк итеп сөйләүләреннән алар арасындагы мәхәббәт хисен һәрхәлдә сизеп була. Аннары Хәмитнең сүз ахырында гына бичәсе белән мактанып куюы да яратышып торуының ачык бер дәлиле түгелмени?!

Моның кебек иркен, табигый сөйләшүләр алар өендә гадәткә кереп киткән иде инде. Дөрес, беренче мәртәбә барып чыккач, Хәмит бик гаҗәпләнеп, аптырап калды, хәтта азрак ятсынды да шикелле... Үзенең авыл очындагы иске генә өйдә гап-гади «мужик» булып яшәве өчен Казаннан кайткан язучы алдында, бәлки, беркадәр уңайсызлану да кичергәндер. Ләкин бу нәрсәләр барысы да бик тиз таралды, бетте, чөнки без бер урамда үскән күрше малайлары, һәм шушы нәрсә менә егерме биш елдан соң безне тагын якынайтты да куйды.

Килгән саен, безне бу өйдә бик теләп, куанып каршы алалар, хәзинәдә бары белән чын ихластан сыйлыйлар (билгеле, без үзебез дә буш кул белән килмибез). Хәмит шунда ук берәр тавыкны чалып Сәгыйдәсенә тоттыра. Сәгыйдә ашка чаклы чәй өлгертә, Хәмитнең тотып кайткан балыгы булса, шуны таба тутырып кыздырып китерә... Әмма әйтсәм әйтим сезгә, Казан балыкчылары: Дим балыгы кебек тәмле балыкны сез хәзер төшегездә дә күрә алмыйсыз. Бернинди хлор, нефть исетәме кермәгән чын, саф балыкны мин дә күптән оныткан идем инде.

Гаҗәеп икән ул, ашап кына туйгысыз икән! Димдә генә сакланса кирәк мондый борынгы чын балык, чөнки Димне хәзерге көндә Башкортстанның иң чиста елгасы диләр. (Һәрхәлдә югары һәм урта агымы.) Хәмит көлеп сөйли, безнең бу тирәгә дә килеп, нефть эзләп йөрделәр, бөтен балыкчылар әчләреннән «таба алмасалар гына ярар иде», дип теләп торды, ди. Нишлисең, балык белән балыкчының хәлен аңларга була!

Тик менә кымыз белән генә эшләр шәптән түгел икән, ә мин аны бик сагынып кайткан идем. Дөрес, Уфада әзрәк эчкәләргә туры килде, ләкин Дәүләкәндә кымыз юк — базарында да, ресторанында да юк... Һәм бу гаҗәп иде, чөнки Дим буе элек һәрвакытта үзенең кымызы белән дан тотып килде. Һәрбер башкорт авылында, һәр йортта диярлек бия бәйлиләр, кымыз ясый торганнар иде. Көрмәнкәйне инде әйткән дә юк, аның бичәләре, Арча хатыннары Казанга катык ташыган шикелле, Дәүләкәнгә кымызны китереп кенә торалар иде. Шулай ук ул авылда һәр җәен Уфа-Казаннардан килгән кымызчылар да күп була иде. (Гомумән, бу тирәдәге авылларга — Шәрипкә, Казанголга, Япарга — җәй саен кымызчылар килмичә калмый иде.) Дәүләкәннең үзендә дә бия бәйләүче, кымыз ясаучы башкортлар бар иде, шуларның берсе — безгә йорт аша гына күрше Арсланғәрәй агай ел да бия бәйләп, кымызчы да кертә торган иде.

Кымызны ул заманда сайлап эчә идек. Нинди авылдан, кайсы агайның яки җиңгәйнең кымызы бу — тәҗрибәле кешеләр шуны иң элек белергә тырышалар. Үзенә күрә, хикмәте булгандыр инде. Уфадан киткәндә Сәгыйт мәрхүм миңа, гадәтенчә шаяртып, син, Әмирхан дус, Дәүләкәнгә кайткач, кымызның председательгә дип калдырганын сорап эч, аларга һәрвакытта бары яхшысын гына калдыралар дигән иде. Яхшы кымыз, мәсәлән, кылганда йөргән биядән була диләр. Савып алгач, бия сөтен гөбедә күпме пешекләүнең дә әһәмияте бар икән. Яхшы кымыз артык кырку да, бик төче дә булмый, эчкәч тамак төбендә каймагы утырып кала, кикергәндә борыннан әчесе тәмле генә ярып чыга. Күп еллар узса да, әнә шулай сакланган хәтердә яхшы кымыз... Безнең үзебезгә аны бер агай Акколайдан китерә торган иде. Әйе, кайчандыр элек күп иде кымыз, ләкин ничаклы күп булса да, ул иң тансык эчемлек һәм кадерле сый булып санала иде.

Ә хәзер юк, беткән... Бер яктан бу хәлне аңларга да була. Билгеле ки, үткән сугышның коточкыч авырлыгы атларга да килде. (...Нилэр генә күрмәй ир-егеткәй менән ат башы, дип җырлый башкорт үзе дә.) Авылларда ат көче җитмәгәч, үгезләрне, хәтта сыерларны эшкә җиктеләр. Ә савым бияне авыр эшкә җигәргә ярамый бит, шулай булгач, кымызның бетеп, онытылып торуы гаҗәпмени?!

Ләкин мин кайтып йөри башлаган чакларда кымыз булырга тиеш иде инде (сугыш бетүгә дә ун еллап вакыт узды), кайбер авылларда бар, ясыйлар икән дип тә ишеткән идем, әмма стаканны яртылаш ак күбек белән тутырып, эчеп кенә җибәрергә туры килгәне юк әле...

Шулай да мин нәфесне котыртып торган бу салкын кымызга бер баттым батуын. Икенче кайтуымда булса кирәк, без Гомәр белән икәү көймәдә генә тагын Көрмәнкәйгә Хәмитне күрергә бардык. Гадәттәгечә Хәмит үзе дә, хатыны Сәгыйдә дә безне бик җылы, якты каршы алдылар. Исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сорашканнан соң тиз генә самавыр да куелды, учак та ягылды, ә Хәмит, «сезгә кымыз алып килим әле» дип, ашыга-ашыга ферма өенә китеп барды. Шактый ук югалып торды хуҗабыз, әмма бик борчылып, буш кул белән кайтып керде. Кемдер инде, ферма мөдиреме, завхоз тиешле кешеме, Хәмиткә кырт кисеп: «Председатель рөхсәтеннән башка бер шешә дә бирмим!» — дигән. Шуннан Хәмит председательне эзләп киткән — таба алмаган, яңадан әлеге кешегә килеп, төрлечә әйтеп, ялварып караган, әмма юк, һич кенә дә күндерә алмаган тегене... «Ерактан кайткан кунагым өчен дип ялвардым үзе-

нә,— ди Хәмит үрсәләнеп. — Тыңламады бит мөртәт, тотып ватасыңмыни ул сабакыны!» Ярый, хәерле булсын, дидек без, Хәмитне юатып, эчмәгән кымыз түгел, монда болай да сыең җитәрлек! Шуннан соң юмарт күңелле хуҗаларыбызның чәен эчтек, мәен дә эчтек, изү чишеп, тирләп, ашларын ашадык. Аннары кырга чыгып йөрдек, Көрмәнкәй тавына менеп, Дим буйларына карап утырдык. Көрмәнкәй тавының исеме бар икән — элек мин моны белми идем: Иван-сәй тавы, имеш! Ни өчен мондый сәер исем дип сорагач, Хәмит болай аңлатты: кайчандыр борынгы башкортлар шушы тау башында килешеп, күпмедер җирләрен русларга чәйгә алмашып биргәннәр; янәсе. Чынмы, ялганмы — хода белсен, әмма Иван-сәй тавының икенче ягында, Димнең бик матур борылып килгән җирендә кечкенә генә рус авылы әле дә бар, күренеп үк тора. Сүз уңаеннан шуны да әйтәсе килә: башкортлар элек читтән килгән халыкларга зур су буйларындагы җирләрен сатмаганнар һәм бирмәгәннәр. Мәсәлән, Димнең урта агымында бер татар авылы да юк, барысы да читтә, ләкин рус авыллары сирәк кенә булса да очрый. Ихтимал, алар Столыпин вакытында килеп, утырып калганнардыр...

...Кояш шактый авышкач, без, көймәбезгә утырып, агым түбәнenә җиңел генә ишә-ишә, әйләнә-юньдәге хозурлыкка сокланып карый-карый, Дәүләкәнебезгә кайтып киттек. Икенче көнне якшәмбе иде — базар көн икән. (Элек базар сишәмбе көнне була торган иде.) Онытмас борын шуны әйтим, бу кайтуымда инде мин яңа гостиницага төшкән идем. Шул базар мәйданы янында ук (дөресрәге, элекке Марҗа базары каршысында гына) ак кирпечтән салынган ике катлы озынча йорт, ике катында да тезелеп киткән номерлар, арада мөһимрәк кунаклар өчен бер урынлысы да бар — миңа мица да шундыен биргәннәр иде. Иртән торып, якындагы ашханәгә кереп, тамак ялгап чыккач, мин базарны да бер әйләнергә булдым. Хәзерге базар — ул элекке зур мәйданның урта бер җирен койма белән әйләндереп алган иркен генә урын — шунда кибетләр, ларeклар, ике озын гына такта лапас, берсендә ит-май, икенчесендә катык-сөт саталар. Базар шактый сүлпән иде, тирә-як авыллардан килгән халык та аз, һәм, әлбәттә, кымызның да исе дә юк иде... (Көрмәнкәй бичәләре дә хәзер кымыз урынына, көянтә башына элеп, бирегә катык-сөт кенә китерәләр икән.) Кыскасы, базарны мин бик тиз әйләнеп чыктым. Шуннан нишләргә?.. Кайткан саен бер эшем — ул да булса — Дәүләкән урамнарында таныш йортларны карап, үткәннәрне искә төшереп йөрү иде. Бүген дә мәнә шул гадәтемә буйсынып, тимер юл аръягына чыгып йөрергә булдым.

Тимер юл Дәүләкәнне урталай кисеп уза. Дим агымына карап әйткәндә, юлның уң ягында кайчандыр башкорт, татар, рус торса, сул ягында күбрәк немецлар тора иде. (Башкорт юк, татар бик аз, руслар да күп түгел.) Шуңа күрә ул якны без үскән чакларда «нимич ягы» дип йөртәләр иде. Ул якта таза, матур йортлар, матур бакчалар күп иде, урамнары да киң, туры һәм яшел чирәмле иде. Мин тимер юллары аша атлый-атлый шул якка — «нимич» ягына чыгып киттем... Чыккач та анда, юлларга каршы, немецлардан калган беркатлы таш йортта райком бинасы. Кинәт уема килде: туктале, мин әйтәм, кереп чыгыйм, секретарьлардан берәрсен очратып булмасмы?.. Урам ишектән кердем, эчкәре уздым, тынлык, берәү дә юк кебек, ләкин бар икән — беренче секретарьның приемный бүлмәсендә бер кыз бала машинкасын әкрен генә тыкылдатып утыра. «Керергә рөхсәтме?..»— дип сорадым. Кыз мине белә иде инде. Шулай да ул башта үзе кабинетка кереп чыкты, аннары миңа рөхсәт итте.

Ул елларда, ягъни илленче елларның ахырында, алтмышынчы елларның башында Дәүләкәннең беренче секретаре таза, киң җилкәле, ир уртасы кеше — иптәш Тартыков иде. (Соңыннан аны Уфага авыл хуҗалыгы министры итеп күчергәннәр дип ишеттем.) Иптәш Тартыков

безнең Татарстанда да күпмедер торып, эшләп киткән икән. Ул мине әйбәт каршы алган иде. Бу юлы да ачык йөз күрсәтте, өстәл артыннан торып кул бирде. Утырдык, сөйләшеп киттек. Сүз башы итеп дигәндәй, мин иптәш Тартыковның якшәмбе көнне дә райкомга килеп утыруына бераз гаҗәпләнү белдердем.

— Нишлисең, өйрәнелгән, гадәткә кергән,— диде ул, ике кулын җәеп.— Срочный эш булмаганда, бөтен аппаратка ял бирәм, ә үзем мена өйдә утыра алмыйм, киләм шушында — аулакка!..

Шулай башланып китте безнең әңгәмә. Сүз нәрсә турында? — билгеле инде, беренче секретарь белән перспектива — киләчәк турында. Иптәш Тартыков миңа шул хакта бик мавыктыргыч итеп сөйләгән иде. Күп еллар узганнан соң аның сөйләгәннәрен хәзер инде искә төшерә алмыйм, шулай да ике моменты ничектер хәтердә сакланып калган. Берсе — тугайларны сөреп, кукуруз чәчү мәсьәләсе иде. Мин бераз килешмичәрәк тугайлар печән бирә бит, элек Дим буйлары печән чүмәләләре белән чып-чуар була торган иде, дигәч, ул көлемсерәп, балага аңлаткандай, тугайда печән уңышы бик түбән булуын, кукурузның ике-өч мәртәбә күбрәк уңыш бирүен төшендерде. Билгеле, мин аңа ышандым, чөнки бу кукуруз үзләштерү «һөҗүме» башланган еллар иде.

Икенчесе — Дәүләкәннең үзе турында сөйләгәндә иптәш Тартыков якын киләчәктә тугызар катлы йортлар салыначагын әйтте. Моңа да мин шактый гаҗәпләндем, Дәүләкән кебек кечкенә шәһәргә андый биек йортлар нигә кирәк икән дип уйладым. (Уфаның үзендә дә тугызар катлылар ул чакта яңа гына салына башлаган иде.) Ләкин күңелемдәге шигемне әйтеп тормадым. Хикмәте бардыр, җитәкчеләр белмичә эшләмидер, дидем эчемнән генә, хәтта әле Дим өстенә карап тезелгән биек йортлар Дәүләкәнне бик матурлар дип сөенеп тә куйдым.

Минем — яхшымы, начармы — бер гадәтем бар: җитәкче кеше янына барсам, вакытын күп алмыйм дип борчыла башлыйм. Менә хәзер дә мин, сүземне чикләп, рәхмәтемне әйтеп, кузгалырга булдым. Иптәш Тартыков та артык кыстамады, ләкин кайчанрак китүем белән кызыксынды, тагын шулай кергәләргә кушты. Шул чакта, инде урыннарыбыздан торгач, минем ничектер тәвәккәлләп беренче секретарьга әйтәсем килде:

— Сез гаеп итмәгез инде,— дидем,— мин әле бер нәрсәгә аптырап торам.

— Әйтегез, нәрсә икән ул?

— Әллә ни зур нәрсә түгел, ләкин шулай да... — дидем мин, әз генә икеләнеп. — Эш шунда: Казанга кайткач, якын дуслар миннән Дим кымызын эчтеңме дип сораячаклар. Эчтем дисәм, ялганлау була — эчмәдем дисәм, ышанмаячаклар.

— Әлбәттә, ышанмаслар!

— Ләкин юк бит... Дәүләкәндә кымыз юк. Хәтта Көрмәнкәйдә дә булмады.

— Ник булмасын, бар, табабыз аны! — диде иптәш Тартыков катгый рәвештә һәм шунда ук телефон трубкасын алды. — Кем бу? Синме?.. Давай, тиз генә монда кил әле... Бер эш бар.

... Озак та үтмәде — озын буйлы бер егет кабинетка килеп тә керде. Бу райкомның өченче секретаре икән.

— Гараждан машинаны алып чык,— диде Тартыков аңа.— Менә иптәш Еникеевны утырт та Көрмәнкәйгә сыздыр. Безобразие, безгә кунакка кайтып, кымыз да эчмәй китсә, ояты кемгә?!. Абдуллиннан кәрзине белән алып бир!

— Була ул! — диде озын егет өлгер генә.

Шулай итеп, мәсьәлә бик оператив хәл ителде, һәм миңа кабатлап рәхмәт әйтүдән башка эш тә калмады. Ә бер биш-ун минуттан без киндер түбәле газик машинасында Көрмәнкәйгә китеп тә бардык. Элек,

мин малай чакта, Дим күпере Якорь буасыннан аз гына түбәндәрәк иде, ә хәзер шактый еракка күчкән икән. Шул сәбәпле күп кенә җир әйләнеп, урап барырга туры килде. Көрмәнкәйгә җиткәч, машина туп-туры выжлатып, авыл читендәге ялгыз кымыз өенә барып туктады. Егет машинадан төшүгә, өйдән эшләпәле бер агай килеп чыкты.

— Әзер кымызың бармы? — дип сорады егет аңардан бернинди керәш сүзсез.

Агай каушабрак калды:

— Ни бит, кем, иптәш, прсидәтелдән башка...

— Әйдәле! — диде егет, аның сүзен бүлеп һәм беләгеннән тотып, өйгә алып кереп тә китте. Мин мыштым гына үз урынымда утырып калдым.

Өч минут та үтмәгәндер, агай бер кәрзин кымызны көчәнә-көчәнә күтәреп чыкты да машинаның йомшак урындыгына әйбәтләп кенә куйды.

— Булды бу,— диде егет, рульгә утырып һәм, борыла төшеп, миннән сорады: — Инде кая, Дәүләкәнгәме?

— Юк, — дидем мин,— монда минем бер дустым бар, шуңа илтегез.

— Кем ул?

— Хәмит Акбирдин.

— Өен беләсезме?

— Беләм.

— Киттек, алайса!

Һәм күз ачып йомганчы Көрмәнкәйнең тип-тигез урамыннан Хәмит өенә барып та җиттек. Әйтәсе дә түгел, егет машинасын авыллар арасында виртуозларча йөртергә тәмам өйрәнеп беткән икән. Иң мөһиме — шома йөртә, бәла-казасыз, һәм мине дә туп урынына чөеп азапламады. Кымызны да кәрзине белән егет үзе өйгә кертте. Хәмит ишегалдында йөри иде, бу хәлне күреп, ул да шактый аптырап калды.

— Ничек булды әле бу?

— Булды инде,— мин әйтәм, — синең белән миңа райком күчтәнәче, беләсең килсә!

Егет шунда ук кире китмәкче иде, ләкин без аны җибәрмәдек. Кәрзиндә егерме шешә кымыз, ничек эчеп бетермәк кирәк?! Җыйнаулашып өйнең түр ягына кердек, утырыштык, Хәмит стаканнар китереп куйды, һәм без сагындырган тансык кымызны (һәрхәлдә минем өчен) тәмләп кенә эчә дә башладык. Кымыз әле яшь иде, шуңа күрә сүс бау белән бәйләнгән бөкесен чишеп ачканда, кинәт котырып китеп, атып маташмады, бары тик җаһәт кенә күтәрелеп, күбекләнеп, күпереп кенә стаканнарга тулды. Әмма, яшь булса да, эчәр өчен өлгергән иде инде. Әчкелтемрәк куәте борынны да ярып чыкты, ә каймагы тамак төбенә дә ягылып калды. Агиш мәрхүм әйтмешли, председательнең үзенә диебрәк хәзерләнгән булса кирәк.

...Беренче стаканнардан ук һәйбәт кымыз кузгаткан, инде онытыла да язган үткәннәрне искә төшерә башладык. Кайчандыр бу авылның һәр йортында диярлек бия бәйлиләр иде. Көрмәнкәй бит ул, тимер юлга якын булганга күрә, һәр җәй кымызчылар килеп тула торган шактый ук мәшһүр бер авыл иде. Килгән бер кымызчы, хәллерәк башкортның өен яки келәтен алып, ак киез җәйгән сәке өстендә мендәргә кырын таянып, көн саен хуҗаның кымызын эчә, алачыкта җиңгә пешергән яшь тәкә итен ашый, көн дә сөтен, маен, йомыркасын алып тора — кыскасы, пансионаттагы шикелле, бөтенесе бар, бөтенесе бер генә хуҗадан... (Тик чәй-шикәрдән башкасы.) Шул рәвешчә берәр ай хушланып, тазарып яткannan соң кымызчы әфәнде-хуҗага барысы өчен дә тиешле акчасын түләп, китеп бара, һәм еш кына алдагы җәйдә дә шул ук йортка яңадан килә торган иде...

Минем истә әле: монда бер җәйне Нәгыймә Таждарова белән Нури

Сакаев, Маһирә Мирвәлиева белән Шакир Шамильский кымыз эчеп яттылар. Шулай ук матур җәйләрнең берсендә Казаннан Галимҗан Нигъмәти һәм Гомәр Гали дә хатыннары белән бергә килгәннәр иде... Тагын бер онытылмас истәлек: 1924 елның җәендә булса кирәк, Көрмәнкәйдә — Мәҗит Гафури, ә Иске Шәриптә минем җизни Шәриф Сүнчәләй белән аның энесе Сәгыйт Сүнчәләй кымызда булдылар. Һәр атнада диярлек алар Дәүләкән базары көнне кирәк-яракларын алыр өчен безгә киләләр иде. Көрмәнкәйдән Мәҗит агай да, билгеле, килеп китә иде... Әле дә ачык хәтеремдә: таяк тоткан, юка гына гәүдәле, ак чырайлы, кара мыеклы Мәҗит агай аксый биребрәк, безнең капкадан ук: «Сәгыйт!» дип тавыш салып, килеп керә торган иде. Тавышын ишетүгә, өйдән я җизни, я Сәгыйт абый чыгып, аны каршы алалар иде. Минем әдәбият белән «җенләнә» башлаган чагым, шуңадыр инде Мәҗит Гафури, Сәгыйт Сүнчәләй кебек танылган шагыйрьләрнең безнең өйдә булуы яки кереп кенә чыгулары да минем өчен, билгеле, зур бер куанычлы вакыйгага булып кала иде [1].

Әнә шулай күңелле истәлекләргә бирелеп, тәмләп кенә дүрт-биш шешәне бушатканнан соң, райком егетенә рәхмәтебезне әйтеп, аны озатып җибәрдек. Мин исә кымызны эчеп бетерер өчен Хәмиттә калдым. Бу дуамал эчемлек юлда селкетеп йөрткәнне бер дә яратмый, аннары җәй кызуында аны озак сакларга да ярамый. Сәгыйдә килен бер уңлап шешәне шунда ук кар базына да төшереп куйды. Ә калган өч-дүрт шешәне алып, без Хәмит белән, Сәгыйдәнең ашы өлгергәнче, Дим аръягына чыгып килергә булдык. Аръяктагы тугайда, нәкъ Көрмәнкәй каршысында «Япраклы» дигән зур гына күл бар, кайчандыр без — Дәүләкән малайлары еш кына шул күлгә балыкка килә торган идек. Минем инде Япраклыда булмавыма, юләр әйтмешли, бер кырык ел бардыр — менә шуның ярында, малай чактагы шикелле кармак салып утырасым килеп китте. Моның өчен бөтен кирәк нәрсә Хәмиттә бар, абзар артындагы черегән тиреслектән калай савытка бераз суалчан казып алдык та аның буялмаган иске генә көймәсендә аръякка чыгып та киттек. Тугайның әле чабылмаган куе үләнен ерып, күл буена бардык, таллар ышыгыннан әйбәт кенә тыныч урын табып, кармакларны сүтеп, бисмилланы әйтеп дигәндәй, безне зарыгып көткән балыкларны ялыктырмас өчен тизрәк эшкә дә керештек. Ләкин ни хикмәттер, балыклар безнең кармакларга ташланырга ашыкмадылар. Моның сәбәбен Хәмит шунда ук әйтеп тә бирде, хәзер көн үзәге, балыкларның көн кызуыннан ялкауланып, тик кенә «ята» торган чаклары, диде. Шулай да ул үзе ничектер, ниндидер хәйләсен белеп, чибәр-чибәр генә кызыл канатларны тартып чыгаргалады. Гаҗәп, утырган җиреннән кузгалып та тормыйча, эләккән балыгын ике тез арасына ашыкмыйча чыгарып кына сала! Балык та канәгать кебек, артык тыпырчынмый да.

Әмма минем осталык та, сабырлык та житмәле — баштарак калкавычтан күземне алмыйча утырсам да һәм берничә тапкыр кармакны кинәт күтәреп җибәрсәм дә, балык, җимне ашап, су төбендә кала бирде. Көлә дә белә микән әллә ул минем ише балыкчыдан?! Аннары мин, онытылып китеп, кармактан бигрәк, күл әйләнәсен ешрак күзәтеп утырдым. Кырык ел аз вакыт түгел, бу вакыт эчендә Япраклы да күпмедер үзгәрергә тиеш иде кебек. Без, Дәүләкән малайлары, мәсәлән, балык тотарга күлнең әнә каршы ягына килә торган идек. Ул якның кара яр буйлары ачык, таллыклар, куе камышлыклар юк диярлек, йөреп-сайлап утырыр урыннар күп иде. Хәзер без утырган бу ягында әрәмәлек тә таллык, су читен ләм һәм төнбоек баскан була иде, кармак салыр өчен иплә урын табуы да бик читен иде. Ләкин Япраклы хәзер дә шул ук

[1] Быел Уфага баргач, Йосыф абзый Гәрәйдән ишеттем: бер җәйне Сәгыйт Рәмиев тә Көрмәнкәйдә кымыз эчеп яткан һәм шул чагында үзенең «Авыл» исемле мәшһүр шигырен язган икән. Ә. Е.

Япраклы икән, берниндн үзгәреш күрмим дияр лек. Хәер, ничәмә йөз еллар яшәгән күл өчен кырык ел нәрсә ул, кеше кулы тимәгәч, торган сакланып... Кырык ел гомер безне генә танымаслык дәрәҗәдә үзгәртеп бетерде. Бер уйласаң, кызганыч та инде без, кайчан гына әле яланаяк, күлмәк-ыштаннан гына шушы күл әйләнәсендә кармак күтәреп йөрүче малайлар идек, ә хәзер?.. Юк, кыска, бик кыска адәми затның гомере! Әмма шушы кыска гына гомерле адәмнең кодрәте чамадан ашты — мең ел гына түгел, миллион еллар сакланып килгән табигатьне соңгы егерме-утыз ел эчендә генә дә ничаклы үзгәртеп бетерде. Һәм бу үзгәрешләр Япраклы күлнең тирә-ягында да бар. Әнә, каршы яктагы киң тугайны аркылы бүлеп, дамба сузганнар... Ни өчен, нинди максат белән? Ишетүемә караганда, кайчандыр Дәүләкәннән Стәрлетамакка юл салырга уйлаганнар һәм бу дамбаны шуның өчен күтәргән булганнар. Ләкин соңыннан юл үткәрүне бу төштә кирәксез табып, эшне туктатканнар. Ә дамба калган, хәзер ул оборона нығытмасы шикелле бөтен тугайны ямьсезләп, күпме печән бирә торган болынны алып тора. Яки әнә Көрмәнкәй яклап Дәүләкән каршысындагы тугайда урман үстергәннәр. Бәлки кирәктер, файдагадыр бу урман? — белмим, әйтә алмыйм. Әмма болынлык мәйданы бик нык кимеп калган. Кыскасы, үзгәреш бар, бөтен җирдә бар ул. Тик, кызганычка каршы, кеше дигәнең, гомере кыска булганга күрәме, табигатьне үз кулы белән үзгәртүнең бөтен нәтиҗәсен генә яхшылап күрергә өлгерми — ул кадәресен инде шулай ук кыска гомерле балаларына уйларга һәм аңларга калдыра: кирәк булганмы бу, әллә юкмы?.. Гафу итегез, балык чиртмәгәч, ниләр генә килми күңелгә?!

...Ә шулай да эссе-бөркү, кояш каршыбызга борылды, кыздыра, мин яңадан таллар ышыгына күчебрәк утырдым. Юеш комга утырткан шешәне алып, әледән-әле кымызны эчәм, Хәмиткә дә салып бирәм, ләкин ул һаман «үзең эч!» ди—күбрәк миңа тисен, ди торгандыр инде. Шулай кысташып, әкрен генә сөйләшкәләп, бер-ике сәгать чамасы утыргач, балыкчым да урыныннан торды:

— Бер табалык булды, кузгалсак та ярый,— диде ул, кармагын урый башлап. — Сәгыйдәнең дә ашы өлгергәндер.

Мин дә, торып, кармагымны урадым. Хәмит, нечкә талчыбыктан шеш ясап, балыкларын шуңа тезде. Ахырда кузгалдык. «Хуш, Япраклым, хуш! Тагын килеп, ярларында утырырга язсын!» — дидем мин эчемнән генә һәм кулымдагы ипи кисәген угалап, өстә генә йөзгән вак балыкларга ташладым.

...Без кайтканда, Сәгыйдәнең ашы өлгергән, өстәлгә табын әзерләнгән иде. Ничә сынаганым бар: аның кулы аш-суга һәрвакытта юмарт, барысын да бик мул әзерли, үзе пешергән бодай икмәген дә ул зур телемнәр итеп ашъяулык уртасына өеп куя... Хәмит бер яртысын да чыгарды, аш хөрмәтенә анысын да берәр генә стопка күтәрдек. Шулай матур гына сыйланып һәм кунып, икенче көнне мин, һаман әле эчелеп бетмәгән 3-4 шешә кымызны алып, Дәүләкәнгә кайтып киттем. Бер тәүлек эчендә бер кәрзин кымызны бетереп карале — әйтергә генә ансат бу! Шуңа күрә дә онытылмас бер вакыйга булып калды ул минем өчен. Чөнки, соңыннан күпме кайтып йөрсәм дә, миңа инде андый муллыкны яңадан күрергә туры килмәде. Аннары Көрмәнкәйдә кымыз ясау бетерелгән, бу эшне тагы да арырак — Дүртөйлегә күчергәннәр дип ишеттем. Кыскасы, Дим буеның мәшһүр кымызын сагынып сөйләргә генә калды.

Әйе, мин кайткан саен Хәмит белән очрашмыйча китми идем. Хәмит үзе дә, хатыны Сәгыйдә дә — бик гади, бик садә кешеләр. Бернинди ясалмалык, кыланчыклык, хәйләкәрлек юк аларда... Көн итүләре дә саф авылча — икесе дә колхоз эшенә йөриләр, шуннан килгән белән генә яшиләр. Күзгә күренерлек байлыклары юк, әмма тамаклары тук —

бәрәңгесе, сөте-мае, кош-корты үзләренеке, барына канәгать булып, бала-чага үстереп, тыныч-тату гына тора бирәләр. Ничә кайтсам да, тормышлары һаман искечә, тик үзләре әкрен генә олыгая, балалары үсә бара, кайберләре инде читкә укырга китәргә дә өлгергәннәр иде.

1969 елның март башында Дәүләкәнгә туган көнемне үткәрергә кайткач, мин, билгеле, Көрмәнкәйдән Хәмит белән Сәгыйдәне дә мәҗлескә чакырткан идем. Ресторан залында оештырылган менә шул мәҗлескә алар миңа күчтәнәч итеп, бер бөтен каз күтәреп килгәннәр иде. Казанга чаклы ук алып кайттым мин ул кадерле күчтәнәчне!

Соңгы очрашуыбыз, ялгышмасам, 1975 елны булды шикелле. Бу явымсыз бик коры җәй иде. Үләннәр кибеп бетте, малга азык юк, сарыклар җир кимерә дип сөйләгәннәре хәтердә. Башта мин Бөгелмә аша Туймазыга бардым, Туймазыдан якын туганым Ләләнең «Жигули» машинасы мине Бүздәк аша Дәүләкәнгә илтте. Бу юлны үзем сайлаган булдым, чөнки Бүздәкне дә күреп, Ачылыкүл янынннан да узасым килгән иде. Туймазы — Уфа юлы бик шәп, киң, тигез асфальт, йөзеп кенә барасың. Әмма Бүздәктән Дәүләкәнгә борылгач, алтмыш километр чамасы юл бик алама булып чыкты. Шул хәтле ватык һәм тузанлы иде, әгәр каршыдан берәр машина үтеп китсә, соры калын болыт эченә чумгандай була идек. Барып җиткәч, чишенеп өскә утырган тузанны бәрәсуга кагарга туры килде.

Бер-ике көннән без Гомәр дустым белән, күчтәнәчкә гастрономнан анысын-монысын алып, Хәмитне күрер өчен җәяүләп кенә Көрмәнкәйгә киттек. Шулай ук эссе көн иде, җирдән дә кипкән үлән һәм кызган туфрак исе аңкып тора. Җәйнең болай коры килүенә борчылып сөйләшә-сөйләшә бара торгач, Көрмәнкәй очына килеп тә җиткәнбез.

...Сәгыйдә безне күптәнге дуслар итеп ачык йөз белән каршы алды, ләкин Хәмит үзе өйдә юк иде — күршедәге Дүртөйлегә киткән булган. (Колхоз идарәсен шунда күчергәннәр икән.) Хатыны өйгә керергә кыстаса да, без тышта, койма буендагы биек, куе агач күләгәсендә утырып, Хәмитне көтәргә булдык. Сәгыйдә шунда ук самавырын да куймакчы иде дә, тик без аңа бераз сабыр итәргә куштык. Шулай да Сәгыйдә борчыла һәм борчылуын яшереп тә тормый: «Эсеп кенә йөремәһә ярар ине»,— ди.

— Ә нишләп ул эчеп йөрергә тиеш әле? — дип сорыйбыз.

— Бында бөтәһе лә эсәләр,— ди Сәгыйдә. — Үткән байрам көнөндә эсә башлаганнар ине, әле дә туктагандары юк.

Ләкин без Сәгыйдәне тынычландырырга тырышабыз, Хәмит алай йөрмәс, ул инде яшь кеше түгел, дибез. Хатын үзе дә килешкәндәй була, кеше котыртмаса, үзе генә эчеп йөрми иде, ди, тик шулай да Көрмәнкәй кешеләренең бер эчә башласалар туктый белмәүләреннән зарлана. Сүз уңаеннан без малайлары турында сорыйбыз. Аның өч малае үсеп җиткән, олысы белән кечесе өйләнгәннәр дә инде, башка чыгып, аерым торалар икән. Яннарында хәзер ике кызы да бер малае.

— Малайзарым, шөкер, тәүфыйклы булып үстеләр,— ди Сәгыйдә.— Эсү менән дә шаярманылар...

Бигрәк тә уртанчы малаен мактый. Аның турында шундый кызык кына нәрсә дә сөйләп алды: ул, ягъни уртанчы малае, армиядә чакта Кремль сагында хезмәт иткән, безнең җитәкчеләрне үз күзе белән күргән... Егет яхшы хезмәт итүе беләнме, әллә булмаса холкы-фигыле беләнме, шундагы бер татар полковнигына бик ошаган, имеш. Шул тиклем ошаган ди, егетне армиядән бушагач та Мәскәүдә калырга кыстый башлаган полковник, хәтта кызымны сиңа бирәм, тора-бара квартир да алып бирермем, теләсәң әти-әниеңне дә китерерсең, дигән имеш. Егет шуларның барысын да хәбәр итеп, киңәш сорап, атасы белән инәсенә хат язган. Әмма Сәгыйдә моңа һич тә риза булырга теләмәгән: «Улым, балакаем, Мәскәүдә өйләнеп кала күрмә, үзебезгә — Көрмәнкәйгә кайт»

дип язып җибәргән. Һәм егет, Мәскәүне калдырып, үзенең Көрмәнкәенә кайткан, хәзер колхозда эшли икән, тик нигәдер өйләнергә теләми, ди Сәгыйдә.

Әнә шундый хикмәтле бер кыйсса!.. Без моңа ышандык, чөнки бу Сәгыйдә үзе генә уйлап чыгарырлык нәрсә түгел иде... Озак та үтми, Хәмит тә кайтып җитте. Куанышып күрештек, аннары өйгә кердек. Дустыбыз бер дә үзгәрмәгән, элеккечә ябык-какча, кара-көрән, каты-кара чәчендә бер чал бөртеге дә күренми диярлек, үзе исә бик шат, дәртле күренә. Ләкин эчкәнен сизмәдек (хәер, әзрәк кенә бар иде шикелле). Без сөйләшкән арада хатыны чәй дә өлгертте. Өстәлдә сөт, каймак, май, бер-ике дистә күкәй һәм өйдә пешкән бик тәмле бодай икмәге. Без китергән гастроном күчтәнәчләре дә шунда куелды, әмма ләкин Сәгыйдәнең куе, салкын каймагы белән хуш исле икмәгенә ни җитә, ходаем?! Өйләрендә зур яңалык — кечкенә өстәлдә кызыл тастымал япкан телевизор! Шактый ук кыйммәтле бу замана әйберсенә без игътибар итеп өлгергән идек инде.

— Көйләнде безнең эшләр, парин!.. Бичә белән икәү сәкедән генә карап ятабыз Уфа белән Мәскәүне,— ди Хәмит көлеп.

— Байлык керә башлаган өеңә, Хәмит! — дибез без дә шаяртып.

— Байлык ул түгел, байлык менә бу! — ди ул, икмәк сыныгын күрсәтеп. — Шушы булса, калганы табыла.

— Шөкер генә итәһе,— ди Сәгыйдә дә, иренә кушылып.— Авыр сактар үтте инде, малайдар үсеп етте, йәрдәмләшәләр, пинсиябез дә килеп тора, шөкөр генә итәһе!..

Чәйдән соң Дим аръягына чыгып килергә булдык. Киткәнче, Хәмит, бер тавыкны абзар ышыгында гына суеп, хатынына бирде. Аннары өчәүләп бәрәңге бакчасы буйлап кына Димгә таба атладык. Хәмитнең өе авылның иң читендә дип әйткән идем. Моннан инде сөзәк кенә тау итәге башлана. Кайчандыр кымызчыларның шунда чыгып, хуш исле җылы чирәмдә кызынып ята торган җирләре... Быел яңгырлар булмагач, тау итәге тәмам көеп беткән, атлаганда, көлгә баскандай, кайнар тузан бөркелеп кала.

Хәмитнең көймәсенә утырып, аръякка чыктык. Тугай буйлап киттек. Бу якта күлләр күп: теге бер килүдә кармак салып, кымыз эчеп утырган Япраклы күлнең аргы очына якынрак тагын бер кечкенә түп-түгәрәк күл бар — Алабога күле ди идек без аны. Кечкенә булса да бик тирән дип әйтәләр иде... Япраклының бирге очыннан ерак түгел зур гына күлне ни өчендер Сасык күл диләр иде. Ә моңардан ары, өскә табарак Үле Дим — бусы инде, елга агымын үзгәрткәч, күлгә әйләнеп калган борынгы Дим калдыгы. Ул шактый озын һәм тирән дә булса кирәк. Малай чакта без боларның барысына да еш кына килеп йөри идек, ә хәзер менә өч «бабай», кулларны артка куеп, салмак кына атлап барабыз.

Хәмит безне туры Сасык күлгә китерде. Монда аның салып куйган нәрәтәсе бар, шулай ук куе камышлык эчендә кечкенә генә каегы да тора икән. Менә шул каегына басып, ул, озын колга белән генә этә-этә күлгә кереп китте дә, нәрәтәсен күтәреп, балыкларын бушатканнан соң, нәрәтә казыкларын кире утыртып, камыш арасыннан шуып кына ярга чыкты. Безнең күреп исебез китте: каек төбендә бәләктәй калын-тыгыз кара балыклар тыпырдашып ята!.. Әз дә түгел, кимендә бер унбишләп булыр... Миңа, күптән инде тере балык күрмәгән кешегә, бу гүя бер могҗиза булып тоелды. Юк, чынлап та Хәмит дусның һаман да әле балыктан бәхете бар икән.

Шуннан соң инде без тугайда озак юанмадык. Балыкларны юеш капчыкка салып, кайтыр якка борылдык. Әйтергә кирәк, кара балык ул бик затлы балык, бик тәмле, бик симез, кылчыгы да бик әз, су төбендә генә ята ул, кармакка бөтенләй эләкми диярлек. Шуңа күрә аны

элек тә, Дим буйлары балыкка бик бай чакта да сирәк күрергә, сирәк ашарга туры килә иде.

Әлбәттә, без кайту белән, Сәгыйдә килен кара балыкны тиз генә чистартып, кыздырырга да тотынды (бу балыкны чистарту ансат — эчен ярып юасы гына). Ә Хәмит шул арада салкын катыкны кое суы белән туглап, безгә бик тәмле «өреле» әйрән эчерде, аннары ашыкмыйча гына табын әзерләргә керешә. Озакламый өстәлгә аш та, тавык та, таба тулы балык та килде. Кулларны угалап, алдан ук эчке бер канәгатьләнү татып утырыштык. Монда «тост» дигән нәрсә дә, макташып утыру да юк, хуҗалар кыстый, без ашыйбыз, күңелгә ни килсә, шуны сөйлибез, берәр мәзәктән көлешеп тә алабыз — барысы да бик гади дә бик табигый!.. Бүген дә әнә шулай, без килгәч кенә тәрәзә капкачлары ачылган салкынча иске генә өйдә изүләрне чишеп, ашап-эчеп, җәелеп, хозурланып утырдык. Тик иң ахырдан гына Хәмит дустыбыз ничектер бераз уйга калып, күңелсезләнеп киткән шикелле булды да үзе үк башлап, карлыга төшкән тавышы белән сузып кына бер җырлап та алды:

Җил җиләйдер лә бурайдыр,
Буразнага сылайдыр.
Карлар китеп, язлар килгәч,
Күңел ямансылайдыр.

Әйе, бик моңаеп җырлады ул бу сәер җырын, һәм без ирексездән гаҗәпләнә дә калдык.

— Язлар килгәч, күңел күтәрелә торгандыр бит, Хәмит?..

Хәмит, гаепле елмаеп, авыр гына сулап куйды:

— Шулаен шулай да... тик кайчагында нигәдер бик ямансу да булып китә шул. Дөньяның иң матур чагын әллә күреп була, әллә юк тагын...

— Куй, юкты һөйләп утырма! — диде Сәгыйдә дә ачулана төшеп.

— Бетте, карчык, бетте! — диде ул, бала шикелле йөзен аның аркасына яшереп. Бик аз гына авыр тынлык булып алды, ләкин без моңа игътибар итмәскә тырыштык. Берни булмагандай шунда ук сүзгә дә керештек, яңадан бер капкалап та алдык, Хәмит үзе дә бик тиз җанланды — кыскасы, мәҗлесебез элеккечә күңелле генә дәвам итә бирде.

...Чәйләр дә эчеп, кояш та шактый түбәнәйгәч, без кайтыр вакыт җиткәнен искә төшердек. Элек балыкка йөргән юллардан узар өчен Көрмәнкәй яклап кайтмыйча, Япраклы ягыннан әйләнеп, «пәриле» коесына да тиеп кайтырга булдык. Моның өчен Хәмит безне яңадан Дим аръягына алып чыгарга тиеш иде. Иң элек әле ул калган балыкларны көчләп дигәндәй сумкабызга салып бирде. «Минем нәрәтәгә көн дә кереп тора алар, ә боларын Гомәр бичәсе пешереп ашатсын!» диде... Ә көймәгә утыргач, туры гына аръякка чыгармыйча, башта безне Дим үренә таба алып китте. Иван-сәй тавының текә кызыл ярын узгач, анда Димнең киңәеп киткән, читләрендә оя-оя төнбоеклар үскән гаҗәеп матур бер җире бар икән — Хәмитнең менә шуны безгә күрсәтәсе килгән. Рәхмәт аңа моның өчен!.. Шуннан соң кире борылып, Көрмәнкәй турысына җиткәч, тугай ярына төштек. Хәмит безне шактый гына җир озата барды. Ахырда туктадык, «яңадан күрешкәнче» дип кулларны кыстык... Шул чакта Хәмит минем кулымны озаграк тотып, нигәдер кинәт кенә боекланып, туп-туры күземә карады. Һәм без ирексездән бер-беребезгә тартылып кочаклаштык. Беренче мәртәбә!.. Элек җиңел генә аерылыша идек, ә бу юлы нәрсәдер нидер әйтте кебек безнең күңелләргә... Бераз киткәч, мин артыма борылып карадым, Хәмит исә һаман шул урынында басып тора иде. Минем туктаганны күргәч, ул миңа таба килә башлады, мин дә аңа таба атладым, һәм без тагын сүзсез генә кочаклаштык... Әнә шулай аерылыштык без... Әйткәнемчә, бу 1975 елның явымсыз коры җәендә булды.

Хәмит белән без хатлар язышып тормадык, вәгъдәләр дә бирешмәдек, кайткан чагымда шушы очрашулар безгә бик җиткән иде, аеруча исән-сау күрешүебезгә ышанып аерылыша да торган идек. Аның үз дөньясы, минем үз дөньям, шул сәбәпле даими бәйләнеш тотуның кирәген дә тапмаганбыздыр ахрысы.

1978 елның июнь ахырында мин, вакытым бик тыгыз булуга карамастан, ике генә тәүлеккә тагын Дәүләкәнгә кайттым. Бернинди эшем йомышым юк иде, бары өйрәнелгән гадәт буенча гына, чөнки Уфага кайтсам, Дәүләкәнгә барып килмичә түзә алмыйм. Бу юлы ничектер шулай туры килде ки, кайтып төшүем белән мин элек күршебездә үскән, яшьтән үк таныш Рабиганы очраттым. Һәм менә күрешеп, танышбелешләрне сораша торгач, Рабига миңа, ниһаять, әйтте: Көрмәнкәйдәге Хәмит үзе дә, хатыны Сәгыйдә дә дөньяда юк бит инде...

— Тукта, ни дигән сүз бу? — дидем мин, аңлап бетермичә.

— Алар... үлделәр шул! — диде Рабига, миңа карамаска тырышып...

— Үлделәр?! Кайчан, ничек?..— Мин тәмам аптырадым да калдым, колакларыма ышанмый торам, чынмы, ялган түгелме бу? Юк, ялган түгел, ди Рабига, ышанмасаң, Көрмәнкәй бичәләреннән сораш, ди... Әмма минем аңыма һаман да әле барып җитми кебек, җитсә дә, һич кенә килешергә теләми кебек бу һич тә көтелмәгән гаять аяныч хәбәр белән...

Ләкин барыбер ышанырга да һәм килешергә дә туры килде. Әҗәл агач башыннан йөрми, диләр... Башта Хәмит үзе кыска гына авырып, үлеп киткән, аннары өч ай үтүгә, хатыны Сәгыйдә дә аның артыннан ияргән... Нинди авырудан икәнен ачык кына белә алмадым: Сәгыйдә, мәсәлән, кан басымы күтәрелүеннән зарлана торган иде, бәлки үлеменә шул сәбәп булгандыр. Сугыш инвалиды, сыңар куллы карт колхозчы Хәмитнең үлүе — бик гади вакыйга, ишеткәне — белгән, ишетмәгәне белми дә калган.

Минем үземә аларның бер-бер артлы диярлек үлеп китүләре бик вакытсыз да һәм бик мәгънәсез дә булып тоелды. Яшәргә тиешләр иде әле, яшәргә!.. Хаклары һәм гомерләре бар иде әле яшәргә!.. Тормышның әзрәк рәхәтен дә татып калырга!.. (Ә михнәтен алар әз күрмәгәннәр, билгеле.)

Юк, шулай да аңлавы читен бу дөньяны!.. Кеше үлә дә китә, гүя караңгы төндә бер генә минутка туктаган поездан төшеп кенә кала. Аның төшеп калганын юлдашлары иртән торгач кына беләләр. Ә поезд һаман бара да бара — алда һәркемне үз тукталышы көтә... Шундый микәнни кешенең гомер юлы да?!

Хәзер инде Көрмәнкәйгә юллар өзелде. Икесенең берсе юк... Әмма аларның... каберенә мин әле барачакмын!.. Дөрес, ишеткәч тә үк мин моны эшли алмадым — ни сәбәптер, шул чакта аягым тартмады. Буш, ятим йортка барып керүдән курыктыммы — үзем дә белмим. Ә икенче көнне инде миңа Дәүләкәннән китеп тә барырга туры килде. Ләкин соңгы кайтуым булмас әле бу, булмаска тиеш, сүземдә торуыма ышанам, тик баш кына сау булсын!

Сез беләсез инде, менә егерме биш елдан бирле мин бу тарафларга кайтып йөрим. Дәүләкән ул минем уемнан һәм күңелемнән бер дә чыкканы юк. Сәбәбен аңлап та бетерә алмыйм. Сугыштан соң беренче мәртәбә кайтуымны аңлыйм, ул чагында бик сагынган идем, күпме еллар үскән-яшәгән җиремне күрмичә торган идем... Кайтып төшү белән айлы төндә карап йөрдем — Дәүләкәнем кадимге Дәүләкән, бер дә үзгәрмәгән диярлек, шул ук урамнар, шул ук йортлар, тик алар шактый искергән, тузганнар иде. Һәм халкы бик үзгәргән иде, искеләр аз калган, мин белмәгән яңалар бик күбәйгән иде.

Әйтергә кирәк, Дәүләкән шул иске хәлендә үзгәрмичә алтмышынчы елларның ахырына хәтле диярлек торды яки, үзгәрсә дә, бик әз үзгәр-

де. Моның сәбәбен урындагы иптәшләр Дәүләкәндә эре промышленность юклыгы, аның һаман да икмәк бирә торган район үзәге булып кына калуы белән аңлаталар иде. Дөрес, Дәүләкәннең борыннан ук дан тотып килгән зур-зур тегермәннәре көне-төне эшлиләр, алар тартып чыгарган мәшһүр Дәүләкән оны илнең бөтен шәһәрләренә өзлексез китеп кенә тора — бу җәһәттән эшләр шәп бара иде булса кирәк. Һәм азмы-күпме үзгәрешләр дә шул тегермәннәр тирәсендә күренә: Якорь тегермәненә тимер юл веткасы кергән, шуннан ерак түгел комбикорма заводы төзелгән, ә элекке Гардер тегермәнләре янында ниндидер зурзур биналар салынган иде. Әйткәнемчә, тегермәннәр — Дәүләкәннең даны һәм горурлыгы.

Инде кечкенә шәһәрнең башка өлешенә килгәндә — үзгәрешләр юк диярлек. Барлык район оешмалары, шул исәптән райком белән райисполком да байлардан калган йортларда урнашкан иде. Хәтта озак кына вакыт Дәүләкәннең үз клубы да булмыйча торды. Кайчандыр безнең заманда спектакльләр куела торган ике катлы Бәлдәй йорты сугыштан соң нишләптер ишелеп төшкән (шулай диделәр миңа), ә аның урынына яңа бина салу төрле сәбәпләр аркасында елдан-ел кичектерелә килгән.

Әмма үзгәреш бер башланырга тиеш иде. Безнең заманда бер генә шәһәрчек тә нәкъ искечә сакланып кала алмый, иртәме-соңмы аңа да үзгәреш килә — килмичә хәле юк. Менә мин дә соңгы кайтуларымда (җитмешенче елларга кергәч) Дәүләкәннең шактый кызу үзгәрә башлаганын күрдем. Иң элек нәкъ үзәктәге иске йортларның һәммәсен дә сүткәннәр, алар урынына өч-дүрт катлы тартма йортлар салганнар, шунда ук райком белән райисполком өчен чибәр генә махсус биналар төзелгән, алар каршында иркен генә мәйдан калдырылган, чәчәкләр өчен зур-зур түтәлләр эшләнгән, агачлар утыртылган. Шул ук мәйданда, дөресрәге, элекке Марҗа базары түрендә ничәмә елга сузылган, зур культура сарае да, ниһаять, салынып беткән.

Шулай итеп, Дәүләкәннең базар белән янәшә үзәге кыска гына вакыт эчендә үзгәргән дә куйган. Миңа таныш йортлардан, Басыйр купецның ике катлы таш магазинын исәпләмәгәндә, берсе дә калмаган. Кызганып әйтүем түгел, ләкин кайберләре хәтердә озак сакланыр әле — мәсәлән, элекке «Туманный»!.. (Революциягә кадәр үк агачтан салынган кинотеатр.) Чөнки бу «Туманный»га малай чакта да, егет була башлагач та күп йөрдек, аннары минем үземнең аңа бәйләнгән кайбер истәлекләрем дә бар.

Дәүләкәннең читләрендә дә үзгәрешләр зур. Әле үзәккә тотынганчы ук читтәге буш урыннарга, мәсәлән, Вязмин бакчасы кырындагы тау битенә һәм элеватор артындагы ачык яланга күп квартиралы йортлар салына башлаган иде. Теге сүтелгән вак өйләрнең хуҗалары хәзер шуларда торалар да инде. Чын шәһәрчә... дияргә була. (Әгәр канализация дә үткәрелсә.) Кыскасы, минем Дәүләкәнем дә, башка җирләрдән соңга калыбрак булса да, үзгәрә һәм яңара. Мин моны кайткан саен күреп китәм. Кайчандыр, әле революциягә чаклы ук салынган Дәүләкән элеваторын бөтен республикада иң зурысы дип әйтәләр иде. Чынлап та, аның кебек зур, биек элеватор тагын кайда гына булды икән? — миңа, мәсәлән, күпме еллардан узсам да, күрергә туры килмәде... 1979 елның җәендә көн өстенә генә кайткач, минем бер күренешкә исем китте: иске элеватор янына кай арададыр тагын бер элеватор салып куйганнар. Зурлыгын әйт син аның! Галәмәт!.. Иске элеватор бәләкәй генә булып калган аның янында!.. Моны күргәч, шунда ук уйлап та куйдым: кирәк нәрсәне бездә бик тиз салалар икән. Һәм Дәүләкән элеккечә республиканың икмәкне иң күп җыя һәм саклый торган урыны да икән!

Хуш, болар барысы да, әлбәттә, бик әйбәт... Ләкин бит мин Дәүлә-

кэнгэ туган-үскэн туфрагым дип кайтам. Барысыннан элек миңа аның халкы якын һәм кадерле булырга тиештер бит инде. Җире-суы, кырлары-яланнары, тугайлары-күлләре, ниһаять, бормаланып аккан Димкәе кадерле булырга тиеш... Яшьлегем хатирәләре белән бәйләнгән урамнары, йортлары, мәктәп, клуб кебек урыннары миңа аеруча якынтансык булырга тиеш түгелме соң?.. Нәрсә калган шуларның барысыннан?.. Каршыда мәһабәт Ярыш тавы басып тора, якты Дим салмак кына ага, тугайда күлләр җәйрәп ята, кайткан саен мин аларга текә яр башыннан сокланып һәм уйланып карап торам, янә тагын Дим өстендә, хәтта ялгызым гына булса да, көймәдә йөрмичә калмыйм. Ләкин табигать үзе, никадәр генә бай, гүзәл булмасын, кешегә карата салкын, битараф бит ул — аның өчен синең кайтуың да, китүең дә барыбер түгелмени?!. Кеше кайта аңа, кеше сагына аны, чөнки кешенең үткәне шушында калган, шушында саклана... Минем өчен дә ул шулай, мин дә, кайтып, Дим ярына басу белән гүя үткәнемә күчәм, үткәнемне күрәм. Әйтик, кайчандыр без җомга көн саен егетләр-кызлар бер-ике көймәгә утырышып, гармун һәм мандолинага кушылып җырлый-җырлый Дим өстендә күңел ачып йөри торган идек. Сез беләсезме икән, су өстендә җыр-гармун тавышларының никадәр дәртле-матур яңгыраганын?!. Яр башында утырган картлар, карчыклар да сихерләнеп тыңлый торганнар иде... Әйе, кайчандыр иде бу, ә менә хәзер егерме биш ел буена кайтып-китеп йөрим, әмма Дим өстендә бер генә тапкыр да җыр, гармун тавышы ишеткәнем юк!.. Беткән, онытылган бу матур гадәт, ләкин аның каравы моторлы көймәләр ярларны ишә-ишә колак тондырып чабалар... Хәер, соңгы елларда җирле власть Димнең тынычлыгын саклау өчен аларны болай чабудан тыйган һәм бик дөрес эшләгән.

Әйе, үзгәрешләрнең төрлесе була — куандырганы да һәм уйландырганы да. 1969 елны кайткач, Илдар Юзеев һәм Вәзих Исхаков белән бергә Дәүләкәннең башкорт укучылары интернатында, аннары мин укыган татар мәктәбендә булган идек. Дәүләкән ул борыннан ук үзенә күрә бер мәгърифәт оясы иде. Революциягә чаклы ук инде анда зур мәдрәсә, ир һәм кыз балалар өчен аерым җәдит мәктәпләре бар иде, бу мәктәп-мәдрәсәләргә читтән дә килеп укый торганнар иде. Совет дәверендә исә монда педагогия училищесы һәм авыл хуҗалыгы техникумы яшәде, ә хәзерге вакытта республика күләмендәге механизаторлар мәктәбе эшләп ята. Яшьләргә урта белем бирү инде ул закон белән кертелгән чара. Ләкин ни гаҗәп, Дәүләкәндәге әлеге җитмеш-сиксән ел яшәп килгән минем мәктәбем хәзер инде юк.

Хуш, тагын нәрсә әйтәсем калды?.. Утырам һәм уйланам. Дәүләкән миннән еракта... Онытырга вакыт түгелме икән инде үзен? Беренче тапкыр бу кечкенә шәһәрдән чыгып китүемә дә ничәмә дистә еллар тулып узды. Шулай булгач, аның миннән ераклаша һәм ятлаша баруы бик табигыйдыр инде. Кайтып киткән саен мин бу хәлне ныграк тоям да түгелме соң?! Хәмит тә үлгәч, минем анда очрашып, сөйләшеп йөри торган бары ике кешем калды — Гомәр дә Әхтәм... Тагын сиксәнгә җиткән Муллагали абзый белән Зөләйха апа янына кереп, күрешеп чыгам. Башка юк, хәер, булса да, безнең аралар шулкадәр ераклашкан, очрашып күрешү кирәклеген алар да, мин дә тоймыйбыз... Әнә шулай үзгәрә икән авылдашлар арасындагы мөнәсәбәтләр дә!..

Әмма шуңа карамастан, минем Дәүләкәнне оныта алганым юк. Соңгы елларга кадәр ул гел искә төшә торды, һаман мине үзенә тартты. Һәм мин, форсат чыккан саен, я электричкада, я машинада чакырылмаган кунактай барам да төшәм: Әссәләмегаләйкем, без, менә тагын килеп

життек!.. Я, гаҗәп түгелме?.. Баштарак әле Дәүләкәнгә бөтенләй күчеп кайтмаска микән дип уйлап куйган чакларым да булды. Ләкин мин мондый теләкнең ялгышлыгын һәм кирәксезлеген бик тиз аңладым, чөнки кайчандыр үскән, яшәгән, ярты халкы диярлек таныш булган җирдә хәзер инде бер килмешәк төсле гомереңне ялгызлыкта үткәрүе һич тә кызыклы булмас иде.

...Юк, шулай да нәрсә тарта, нәрсә бәйли соң мине һаман да бу җиргә?.. Менә шуны бик аңлыйсым килә. Минем шикелле Дәүләкәндә үсеп-яшәп тә читкә китүчеләр аз түгел, Уфаның үзендә генә күпме алар. Ләкин шушы соңгы егерме ел эчендә берәрсенең кайтып күренгәне бармы? Юк бит... Хикмәт нәрсәдә соң?.. Әллә бик рәхәттә уздымы минем монда яшәгән чакларым?.. Һич тә алай түгел ич! Дәүләкәннең мине рәнҗеткән, елаткан чаклары да аз булмады — бигрәк тә үсеп егет булгач, ул миңа шактый газаплар китерде. Ләкин бик күптән булган хәлләр бит алар, онытырга да вакыттыр инде, начарын гына түгел, хәтта яхшысын да!.. Хәер, яхшысы онытылмый, әйтик, балачак, иртә яшьлекнең беренче өметләре, беренче татлы хыяллары, беренче мәхәббәт газабы — болары саклана, болары онытылмаячак. Әйе, искә төшкәндә сагындырган, уйландырган, үкендергән хатирәләр!.. Менә шул хатирәләр эзеннән, Мәҗнүн шикелле, йөрим ахрысы мин... Бүтәнчә ничек аңлатыйм?.. Әгәр шулай икән, димәк, ул хатирәләрнең үзләренә дә чират житте дигән сүз.



## Эткол

Башта тарихка бер күз салыйк. Ягъни Дәүләкәннең борынгырак чагына. Бу кирәк, чөнки тарих ул кешеләр язмышының сүз башы. Минем өчен дә ул шулай.

...Үткән гасырның ахырларында Дим елгасының сулъяк ярында янәшә диярлек ике башкорт авылы утырган — берсе Эткол, икенчесе Дәүләкән. Күчкенә булган алар, ихтимал, башкортлар әле мал куып, күчеп йөргән чакларда кышлау гына булганнардыр. Кышлауның нәрсә икәне аңлашылса кирәк. Бу — язын (язлауда), җәен (җәйләүдә), көзен (көзләүдә) мал йөртеп, кар төшкәч һәм суыклар башлангач, башкортларның кышлар өчен кайтып керә торган урыннары. Менә шул кышлаулар, тора-бара башкорт та утраклы тормышка күчкәч, авылга әйләнгән булырга тиештер.

Гадәттә күп кенә авыллар беренче килеп утырган кешенең исеме белән атап йөртелә. Дим буенда да андый авыллар шактый — якынтирәдәге Акколай, Ибрай, Кормәнкәй, Шәрип, Исмәгыйль, Казангол, Япарларны әнә шундыйлардан дип әйтә алабыз. Эткол да кеше яки ыру исеме белән бәйләнгән булырга тиеш, чөнки «кол»га беткән исемнәр башкортта күп очрый. Ә Дәүләкәннең инде турыдан-туры Дәүләтхан исеме белән бәйләнгән булуын үземнең дә ишеткәнем бар иде.

Якты Дим буйларында башкортлар, терлек күп асраганга күрә, мул печән бирә торган болыннарын үз кулларында саклаганнар. Аннары судагы балык, тугайдагы җәнлек кебек байлыкларга да үзләре генә хуҗа булганнар. Электән үк бу якларга килеп утырган татар авыллары булса да, алар Димнән шактый еракта, тирән чокырлы кечкенә инеш буйларына урнашканнар. (Мәсәлән, Аюхан, Чуенчы, Карамалы һәм башкалар.)

Әйе, кайчандыр чиксез иркен булган бу яклардагы башкорт җирләре — сөзәк кенә үрләр күтәрелгән, үрләр төшкән, бөтен әтрафта тирән тынлык хөкем сөргән, тик төпсез күктә ялгыз тургай тавышы гына чыңлап торган. Минем атакай мәрхүм дә: «Мин малай чакта Каргалы

белән Дәүләкән арасында бер генә авыл да юк иде, гомер бакый сука кермәгән ак кылганлы тоташ ялан гына иде» — дип сөйли торган иде... Әнә шулай булган ул малай чакта, ә мин малай чакта инде бу кырык чакрымлык арада өч-дүрт рус авылы һәм күпмедер немец хуторлары бар иде. Кайчан башлана, кайчан шулай бик тиз үзгәреп өлгерә соң бу күпме заман тын гына яткан иркен-буш җирләр?

1880 елны нәкъ Эткол кырыннан гына Самар — Уфа тимер юлы уздырыла. Бу Россия үзәгеннән башланган мәшһүр Себер тимер юлының дәвамы. Тора-бара ул Уралны, Себер далаларын, Тайга урманнарын, Саян тауларын да үтеп, Ерак Көнчыгышка хәтле барып җитә. Россия өчен бик кирәкле һәм бик әһәмиятле бу гаять озын юлны заманасына күрә шактый кызу салганнар. Халыкны эшкә авылы-авылы белән китергәннәр — хәтта кырык чакрымдагы Каргалы кешеләре дә атлары белән килеп җир казыганнар, балчык ташыганнар. Атакайның әйтүенә караганда, ул да яшь кенә малай көе, балчык ташучыларга ияреп, ат башында йөргән. Шуның өчен әле әзрәк кенә акча да төшергән.

Эткол кырында гына таштан яңа станция дә салына. Ләкин аңа Дәүләкән исемен биләр, күрәсең, бу исемне уңайрак һәм матуррак табалар. Русча ул «Давлеканово» дип атала.

Билгеле инде, Россия үзәгеннән килеп, Себергә чаклы узып киткән бу тимер юл моңарчы тын гына йокымсырап яткан Эткол-Дәүләкән җирләрен кинәт бик нык җанландырып һәм үзгәртеп җибәрә. Озак та үтми, яңа юл белән мондагы бәрәкәтле җирләргә төрле халык агылып килә башлый: руслар, хохоллар [1], немецлар һәм татарлар, әлбәттә... Күпмедер вакыттан соң, бары бер ел эчендә генә, Дәүләкән әтрафында егермеләп рус-хохол авыллары һәм немец хуторлары барлыкка килә. Әгәр Эткол белән Дәүләкәннең үз халкы тимер юл ачылганчы биш йөз чамасы булса, 1897 елда инде халык саны мең ярымнан артып китә. Бу урында шуны әйтергә кирәк, татарлар күбрәк Этколның үзенә аерым семьялар булып киләләр. Тимер юл ачылгач кына бу якларга килеп утырган татар авылын мин белмим, ишеткәнем дә юк. Мондагы татар авыллары барысы да диярлек бик күптән килеп калган иске авыллар иде.

Шулай итеп, кыска гына вакыт эчендә тирә-якта иген игү бик нык арта, ә Эткол үзе бик җанлы бер сәүдә итү һәм ашлык чыгару урынына әверелә. Бигрәк тә хутор булып утырган немецлар игенне зур мәйданнарда чәчә һәм үстерә башлыйлар. Шулай ук яңарак килгән руслар белән хохоллар да иген эшенә җиң сызганып керешәләр. Татарлар исә монда күптән игенчелек белән шөгыльләнгәннәр. Борын-борыннан мал асрап яшәгән башкортлар үзләре дә «бидайны» ашар өчен генә түгел, сатар өчен дә үстерергә тотынганнар. Кыскасы, икмәк төп байлыкка әверелә, икмәк барысына да җан өрә, бөтенесен хәрәкәткә китерә. Һәм бу якның моңарчы төрән кермәгән кара уылдыктай чирәм җирләре уңышны да ишеп биргән булырга тиеш. Бер генә мисал: 1908 елны Дәүләкән станциясеннән 2 миллион поттан артыграк ашлык озатыла, ә шул ук вакытта бөтен Уфа губернасыннан ул барлыгы 6 миллион пот чыгарыла. Димәк, зур губерна җитештергән игеннең кимендә 30-35 процентын бер Дәүләкән үзе генә биргән була [2].

Менә шушы бөтен әтрафтан агылып килә башлаган игеннән нинди табышлар алып булачагын бигрәк тә немецлар алданрак күрәләр һәм бу табышны үз кулларына эләктерер өчен зур өлгергәнлек тә күрсәтәләр. Берничә ел эчендә алар Дәүләкәндә зур-зур тегермәннәр салдыра: Гардер, Гауфлер, Войтер тегермәннәре, шулай ук Димне буып салган мәшһүр Якорь тегермәне әнә шундыйлардан. Боларның һәркайсы таш-

[1] Шул заманда украинлылар шулай аталган. Ә. Е.
[2] Бу мәгълүмат хәзер Дәүләкәндә чыга торган «Знамя» газетасыннан алынды.

тан, бишәр-алтышар катлы, биек кирпеч трубалары белән чын заводларны хәтерләтә. Дәүләкәнгә кайсы яктан гына килсәң дә, чиркәү, мәчетләрдән дә биегрәк булып, иң элек әнә шул мәһабәт тегермәннәр күренә. Һәм болар инде авыл агаеның берничә капчык бөртеген түгел, ә өзлексез кереп торган гәрәбәдәй бодайны тартып чыгара... Тартканы да биткә кершән итеп сөртерлек ап-ак он — крупчатка! Шул онны зәңгәр пичәтле махсус капчыкларга тутырып, вагон-вагон Мәскәүгә, Петербургка, башка зур шәһәрләргә һәм чит илләргә озаталар. Күрәсез, Дәүләкән оны үзенең югары сыйфаты белән дөнья базарына да чыга. Шуны да әйтеп үтик: 1910 елны Ростов шәһәрендә оештырылган күргәзмәдә Якорь тегермәне шул оны өчен зур көмеш медаль белән дә бүләкләнә.

Немецлардан кала Этколда руслар да зур тегермәннәр салдыра, шулай ук татар бае Үтәмишевлар да немецларныкыдай биш катлы тегермән салдырып җибәрә. Ялгышмасам, революциягә чаклы тегермәннәр саны бер унга җиткән иде шикелле. Ә моның нәтиҗәсе шул була: беренчедән, бу хәтле күп һәм машина көче белән эшләүче тегермәннәр игенне Дәүләкән әтрафыннан гына түгел, читтән — ерактан да үзләренә «суырып» дигәндәй китерә башлый, икенчедән, Дәүләкән инде бөртек җыеп озатучы гына булып калмыйча, асылда яхшы сортлы әзер он җибәреп торучыга әйләнә. Менә бу соңгысы Эткол-Дәүләкән тормышына зур үзгәрешләр кертә. Иң элек тегермәннәр үз тирәсенә күп кешеләрне эшкә тарта, ягъни монда яңа хезмәт иясе — эшчеләр катлавы барлыкка килә. Мин дә әле әзрәк хәтерлим, күпме грузчик-ломовойлар шул тегермәннәрнең оннарын көне-төне станциягә ташый торганнар иде. Һәм боларның күбесе башкорт агайлары иде. Билгеле, грузчиклардан башка монда, он тузанына батып, төрле эштә эшләүчеләр дә аз булмаган. Шулай ук төрле профессия кешеләре — мастерлар, механиклар, электриклар, конторщиклар да эшли бу тегермәннәр эчендә.

Игенне зур мәйданнарда чәчеп үстерә башлагач, авыл хуҗалыгы машиналарына һәм эш коралларына ихтыяҗ да бик нык арта. Тиз арада Этколда машина һәм кораллар белән сату итә торган фирмаларның бүлекләре бер-бер артлы ачыла башлый. Төрле урыннарда таштан зур-зур складлар салына. Боларның да хуҗалары бөтенесе диярлек немецлар: Эльворт, Бюлер, Ремпель, Зудерман, Кап; Гельфрих һәм башкалар. Бу складларга машиналар — төрле зурлыктагы молотилкалар, үзе ура, үзе көлтәсен дә бәйләп ташлый торган ургычлар, чәчкечләр, җилгәргечләр, чапкычлар, берничә төрәнле сабаннар, йөзле (дискалы) тырмалар, хәтта «Интернационал» дигән тракторлар да (шул заманда!) турыдан-туры Германиядән һәм Америкадан килеп тора. Шуңа күрәдер инде, революциягә чаклы ук Дәүләкән тирәләре авыл хуҗалыгы машиналары белән иң нык коралланган җирләрдән саналган. Бу материал да «Знамя» газетасыннан алынды.

...Әнә шундый үзгәреш!.. Әйтәләр, Эткол-Дәүләкәндә иллеләп иген җыю-салу амбарлары булган, дип... Гаҗәп түгел, чөнки бөтен әтрафтан көзен-кышын ашлык өзлексез агылып кереп торган. Бу ашлыкны җыеп озатучылар арасында (тегермән хуҗаларыннан кала) зур рус байларын күрәбез — болар — Лашков, Тимофеев, Костюриннар... Мин әле бер-ике яһүдне дә беләм (дөрес, НЭП вакытында) — аларның берсе Тяуш, икенчесе Свердлов иде... Ниһаять, революциягә чаклы ук Дәүләкәндә Уфа губернасындагы иң зур элеватор да салына.

Билгеле инде, мондый җирдә һәртөрле сәүдә-коммерция эшләре аеруча кызу үсә һәм җәелә башлый. Мәсәлән, 1914 елны Дәүләкән халкының утыз проценты тегеләй яки болай сәүдә эше белән бәйләнгән була. Зур шәһәрләрдәге шикелле, монда акча салу, акча алу өчен банк та ачыла. Монда «Зингер» дигән тегү машиналары белән сату итүче атаклы фирманың филиалы да урнаша. Немецлар сыра заводы да салдырып

җибәрәләр, шәп булган дилә аларның сырасы, губернаның төрле якларына китә торган булган. Польдяев дигән бер мордва бае монда таштан ике катлы итеп, ике зур йорт салдырган. Бу йортларны без Бәлдәй йорты дип атый идек. (Хуҗасының чын фамилиясен мин күптән түгел генә белдем.) Берсендә, тимер юлга карап торганында, гостиница белән ресторан булган икән. Икенчесе, базар мәйданына якыны, махсус клуб итеп салынган. Менә шуның сәхнәсендә унҗиде — унсигезенче елларда татарча спектакльләр куела торган иде. Аннары Марҗа базарына[1] каршы гына агачтан шулай ук махсус салынган кинотеатр да бар иде. Элек аның исеме Модерн булган, имеш. Этколда — Модерн!.. Ләкин без, татар малайлары, аны — «туманный» дип кенә йөртә идек. Тик шуны онытмагыз, болар барысы да Эткол дигән башкорт авылында — ул заманда әле ул волость үзеге дә булмаган шикелле. Чөнки безнең волость Казангол волосте дип аталган — бу инде Дим буендагы икенче бер башкорт авылы.

## «Купичлар»

Инде сәүдәнең үзенә килгәндә, бу тармакта күбрәк татарлар өлгерлек күрсәтәләр. Эткол базарының мәйданы зур иде, ул чиркәү янынкан башланып, Дәүләкән чокырына чаклы сузыла иде. Менә шул мәйданның уртарак бер җирендә ике-өч рәт тезелеп киткән таш кибетләр — барысы да диярлек татарларныкы... Араларында өч-дүрт яки биш-алты приказчик тоткан зур кибет хуҗалары да бар — болар Сафа купец, Басыйр купец (кибете таштан, ике катлы), Борһан купец, Шәймәрдән купец... Алар кулында кызыл мал, галантерея, бакалея сәүдәсе. (Шәймәрдән купец үзенең йорты белән янәшә махсус китап кибете дә ачкан иде.) Кечерәк сәүдәгәрләрдән Зариф, Гатаулла, Сафиулла, Габидулла (Гыйбаш) купецларны күрсәтергә мөмкин. Боларның сәүдәсе — галантерея яки бакалея, ләкин араларында җиләк-җимеш белән генә сату итүчеләр дә бар иде. (Мәсәлән, Гыйбаш махсус подвал да ачкан иде.) Шулай ук итчеләр һәм тире-яры җыючылар да, традиция буенча, торганы диярлек татарлар иде. Ләкин татарларның иң зур байлары — тегермән хуҗасы Үтәмишевләр белән җир-урман биләүче Нәбиулла Кәримов иде... Дөрес, сәүдә эшендә руслардан да зур купецлар булган, әйтик, Самсонов, Антимонов, Чигадаев, Решетников һәм тагын кемнәрдер — мин аларның барсын да белеп тә бетермим. Һәм гомумән читтән килгән халыкның күпчелеге руслар булганга күрә, монда алардан байлар гына түгел, төрле һөнәр ияләре дә, эшче-хезмәткәр дә башкаларга караганда күбрәк иде.

Инде яңадан татар «купичларына» килсәк, монда шундый бер кызык хәл күзгә ташлана. Иң элек — алар барсы да диярлек Казан ягыннан чыккан, тик башкорт җиренә килгәч кенә баеп киткән кешеләр. Мисалларын китерик һәм безнең күршебез Борһан абыйдан башлыйк. Ул Әлмәт ягы Өчмунча авылыннан, яшүсмер чагында ук атасы аны Самарга илтеп, шунда очраган бер дагстан баена малайлыкка биреп җибәргән. Күпмедер еллар ул ерак илдәге шул байда хезмәт иткән. Башта самавырчы малай гына булып йөргән, аннары әкренләп үскән, күтәрелгән, гадел хезмәт иткән, байга ярагән, тиенләп акча туплаган, ахырда хуҗасының фатихасын алып, азмы-күпме җыйган «капитал»ын учлап, башкорт якларына юл тоткан. Этколга килеп, яңарак кына уяна, җанлана башлаган бәрәкәтле җирдә үзенә бик әйбәт зәмин дә тапкан. Беренче герман сугышы алдыннан Борһанетдин Мөхәммәтҗанов Дәү-

[1] Төрле яшелчәләр белән сату итә торган урынны шулай атыйлар иде. Ә. Е.

ләкән «купичларының» иң билгелесе, биш-алты приказчик тотып, иң затлы товарлар белән генә сату итә торган зур таш магазин хуҗасы иде. Товарны да — кызыл мал белән галантереяне — ул Мәскәүдән, Петербургтан, Варшавадан гына китерткән, сатып алучылары да «затлы», дөресрәге, акчалы халык — чабаталы мужик аның магазинына керергә дә кыймаган, диләр. Әлбәттә, тиз арада бу рәвешчә күтәрелеп, баеп китәр өчен Борһан абзаң сәүдә эшенең нечкә серләрен бик яхшы белүче уңган, зирәк, тырыш кеше дә булырга тиештер инде. Шунсыз Өчмунча авылыннан малайлыкка чыгып киткән хәерче татар иң бәрәкәтле җирдә дә мантый алмас иде...

1918 елның җәе башында без Борһан абзыйларга күрше булып күчтек. Аларның ишегаллары бик иркен иде, яшел чирәм иде, һәм шул чирәмдә төрле төстәге чәчәкләр шикелле бик пөхтә киенгән балалар йөгерешеп уйнап йөриләр иде. Бу балалар бер дә урамга чыкмыйлар иде, мин дә аларга керергә һич тә кыймый идем (капкалары да һәрвакытта бикле була торган иде), исемнәрен дә белмим, бары койма ярыгыннан гына аларны бик кызыксынып күзәтә идем. Шул чакта ук инде араларыннан берсе — озын кара толымлы, нечкә кара кашлы, алсу-ак чырайлы өлкәнрәк кызлары минем игътибарымны үзенә бик нык җәлеп итә иткән иде. Соңыннан мин бу Һаҗәр исемле кызга үлә язып гашыйк та булдым.

...Борһан абзый үзе кечерәк буйлы, җыйнак кына бер кеше иде. Бик пөхтә һәм чиста киенеп йөри иде. Аз сүзле, тыныч, горур — шулайрак күренә иде ул миңа. Унсигезенче елның җәендә таш магазины эшләгән булса кирәк, чөнки минем күз алдында шундый бер күренеш бик ачык саклана: кичкырын урам уртасыннан Борһан абзый зур улы Галиулла белән, матурлап бәйләгән төргәкләр күтәреп, ашыкмыйча гына кайтып киләләр. Икесе дә бик шәптән киенгәннәр: Борһан абзыйның өстендә утыртма якалы озын кәзәки, башында каракүлдән кырпу бүрек, ә Галиулла өстендә бик килешле утырган тужурка белән чалбар, башында киң читле йомшак фетр эшләпә. Әйтергә кирәк, Галиулла төскә дә бик чибәр һәм аяк атлаулары да аның бик көяз иде. Ишегаллындагы вак балалар, аталарының кайтыр вакытын белеп, барысы да урамга йөгерешеп чыгалар, шаулап каршы алалар, әтиләре белән абыйларына тотынып, шунда ук кереп тә китәләр. Капка ябыла, аркылы агачын яңадан шылдырып куялар, шуннан бер мәлгә ишегалды да тынып кала.

Бер уңайдан Борһан абзыйның үзе турында өстәп шуны да әйтәсем килә: бу аз сүзле кеше Дәүләкән купецлары арасында бердәнбер балыкчы иде. (Купец балыкка вакыт әрәм итәме соң?!) Җомга көннәрендә кибетләр ябык чакта ул, озын кармакларын алып, берәр малаен ияртеп, көймәсе белән Дим үренә китә торган иде. Билгеле, аның бу һәвәслеге балыкны үзе тотып ашарга яратканнан гына булмагандыр инде. Төрлесен күргән кеше, бигрәк тә соңгы елларда күпне кичерергә туры килде аңа, бәлки тын гына бөтерелеп аккан Дим ярында утырып, ул үзенә җан тынычлыгы тапкандыр. Ә җан тынычлыгы кемгә генә кирәкми ул?!.

Хәзер икенче күршебез, бездән өстәрәк урам аша гына торган Гатаулла картка күчик. Ул хәзерге Арча районы Чиканас авылында туып, яшьли ятим калып үскән кеше. Үз авылында өйләнгәннән соң, яшь хатынын ияртеп, башкортякларына бәхет эзләп чыгып киткән. Чуенчы исемле зур татар авылыннан ерак түгел, Йосыф исемле бер байның утарында унбиш ел үзе дә, хатыны да ялчы булып хезмәт иткән. Димәк, бу очракта да бер үк язмыш: нужадан котылу өчен иленнән чыгып китү, кайдадыр еракта кемгәдер ялланып эшләү, искиткеч тырышлык, чыдамлык күрсәтә белү һәм шул рәвешчә байга ярап, үзенә юл ачу... Утарда унбиш ел тир түккәннән соң, Гатаулла карт (хәер, ул чакта әле ир уртасы) гасыр башында Этколга күчеп килә һәм шул ук Йосыф бай яр-

дәме белән сату итәргә тотына. Ләкин крестьян эшен дә ташлап бетерми: башкортлардан арендага җир алып иген дә игә, берничә баш ат, сыер, сарыклар да асрый. Бу вакытта инде аның бер-бер артлы үсеп килгән өч малае да була. Тырышкан табар, ташка кадак кагар дигәннәр бит. Бу акыллы мәкаль, әйтергә кирәк, картның үзенә дә, малайларына да бик тә туры килә. Күп тә үтми, Гатаулла абзый Эткол урамында чибәр генә йорт та торгыза, ишегалды буйлап таза каралтылар да эшләтә һәм базар мәйданында таштан кечерәк кенә кибет тә салдыра. Хәзер инде аны да «Гатаулла купич» дип кенә йөртәләр, хәлбуки, ишетүемә караганда, төп капитал Йосыф байныкы булган диләр иде. Ләкин ничек кенә булмасын, ярлы бер татарның «купичка» әйләнүе, әлбәттә, Дәүләкәндә сәүдә эшләренең нәкъ кыза башлаган чагына туры килүе белән аңлашылса кирәк. Билгеле, кеше үзе дә шуңа һичшиксез сәләтле булырга тиештер инде.

Яки менә Шәймәрдән Гайнетдиновны алыйк. Бу да башкорт җиренә Балык бистәсеннән кечкенә кабык арба тартып килгән кеше. Башта кургаштан ясалган алка, йөзек, беләзек кебек нәрсәләр сатып йөргән. Баегач, Этколның нәкъ уртасында асты таш, өсте бүрәнәдән таза йорт салдырган, йорты белән янәшә, шулай ук таштан, махсус китап кибете дә ачкан. Кибетнең ишеге сырлы тимер калайдан — шылдырып кына югары күтәрелә торган иде. Бу йорт белән кибет фоторәсеме Казанның «Заман» календаренда реклама рәвешендә басылып та чыккан булган. Календарь битендәге бу рекламаны күптән түгел мин үзем дә күрдем: чибәрләп эшләнгән рус капканың бер ягында ике катлы яшел йорт, икенче ягында тимер ишекле таш кибет. Ә йорт белән кибет арасында тройка костюм, кара кәләпүш кигән, кулларын чалбар кесәсенә тыккан Шәймәрдән абзаң үзе басып тора. Казан каласының атаклы бер бае диярсең!

Ләкин Шәймәрдән агайның төп сәүдәсе базар мәйданындагы икенче таш магазинында иде — анда өч-дүрт приказчик кызыл мал һәм галантерея белән сату итteләр. Әнә шулай баеп киткән Шәймәрдән Гайнетдинов та, ягъни ул да — шактый «түбәннән күтәрелгән» купич!.. Әмма гомере кыскарак булды бу купичның, 1918 елны Уфада тифтан үлеп киткән, бичара. Шуңа күрә мин аны юньләп хәтерләмим дә диярлек.

Ә менә кайчандыр аның приказчигы булган Минһаҗ абзыйны мин инде бик яхшы беләм. Ул атакайның якын дусты иде, озак еллар башта Дәүләкәндә, соңра Казанда бергә аралашып гомер иттеләр.

Минем кулыма Минһаҗ абзыйның үзе турында язып калдырган истәлеге кергән иде. Шактый кызыклы язма. Тик мин ул язмадан үземә кирәк кадәресен генә чүпләп алырга мәҗбүрмен.

Болай башлана: Минһаҗетдин Шәрәфетдин улы Әминов элекке Мамадыш өязе Бучырма авылында дөньяга килгән. Атасы авылның атсыз-тунсыз бер фәкыйре, бары ике имана җир биләгән, көзен-кышын шахтага китеп эшләгән. 1891 елны каты ачлык килгәч, Шәрәфетдин агай, җиде яшьлек Минһаҗетдинне җитәкләп, башкорт ягына чыгып китә. Ниятләре — Стәрлетамакка барып җитү, чөнки анда Ильяс исемле күз күргән авылдашлары яши икән. Уфага хәтле бара торган пароходның дүртенче классына да утырырлык акчалары булмагач, болар алты йөз чакрым араны җәяүләп кенә үтәләр. Әмма кечкенә Минһаҗетдин еш кына арый, атасы аны җилкәсенә атландырып та баргалый, берәр атлы куып җитсә, шуңа да утыртып җибәргәли. Ат хуҗасы, берничә чакрым киткәч, малайны төшереп калдыра — Минһаҗетдин юл буенда елый-елый атасын көтеп ала... Әнә шулай салкын кара көздә бик җәфа чигеп, арып-ачыгып, кайбер авылларны узганда хәер дә сорашкалап, ахырда болар Стәрлетамакка барып җитәләр.

Ул елларда бу кечкенә өяз шәһәренең иң зур байлары Үтәмишев-

лэр булган — Шэрэфетдин агай, бераз хэл алганнан соң, энэ шул байларга дворник булып эшкэ керэ. Үтэмишевлэрнең ятим балалар өчен ачкан мэктэплэре дэ бар икэн — атасына ияреп килгэн кечкенэ Минһажетдинне менэ шунда урнаштыралар. Икенче елны Шэрэфетдин агай Бучырмадан хатыны белэн дүрт баласын да Стэрлетамакка китертэ. Котыйчык шикелле кечкенэ фатирда укмашып, өелешеп дигэндэй, тора башлыйлар. Минһажетдиннең энисе Бибифатыйма җиңги дэ шул ук Үтэмишевлардэ көнозын эшлэп йөри, бер апасы да байның киявлэренэ асрау булып керэ — шулай итеп, болар, ниһаять, авыр нужадан чыгалар. Һэрхэлдэ тамаклары тук.

Еллар уза. Кечкенэ Минһажетдин ятимнэр мэктэбеннэн соң берничэ ел русча да укып йөри. Ул заманда Стэрледэ татар балаларын русча укыта торган башлангыч мэктэп тэ булган икэн. Лэкин инде малайны уникe яше тулар-тулмас эшкэ дэ җигэлэр. Ул да Үтэмишевлэрдэ чэй төрүче булып эшли, аңа эле аена бер сум хезмэт хакы да түлилэр.

Үтэмишевлэрнең сэүдэ эшлэре бик киң жэелгэн була: ашлык та жыеп озаталар, чэй-шикэр сэүдэсе дэ алар кулында, керосин, тоз, ташкүмер белэн дэ сату итэлэр, шуның өстенэ Уралның төрле завод-рудникларында һэм Элшэй, Ыслак, Дәүлэкэн кебек базарлы авылларда кибетлэр дэ тоталар... Бөтен җирдэ махсус куелган кешелэр эшли, э Үтэмеш бай үзе шуларны карап, тикшереп кенэ йөри.

Шэрэфетдин агайның бик тырыш, гадел кеше икэнен күреп, бай хужа аны үзенэ даими кучер итеп куя. Яна кучер аллы-артлы итеп яхшы атлар җигелгэн ябык чанада (повозкада) байны элеге «точкаларга» йөртеп кенэ тора. Эмма кышның бик яман суыгында Шэрэфетдин агай кулларын өшетэ, озак төзэлэ алмыйча җэфалана, ахырда ике кулының да урта бармакларын кисэлэр. Бэхетсезлек житэклэшеп йөри дилэр. Шул чагында асраудагы кызы да, өстенэ самавыр аударып, бик каты пешэ һэм бик озак авырый. Шулай да бай аларны ташламый. Шэрэфетдин агайны читтэге «точкаларның» эле берсенэ, эле икенчесенэ төрле эшкэ җибэргэлэп тора. Эмма сэламэтлеген бер сындырган кеше, күрэсең, мантый алмый инде. Шэрэфетдин агай да чынлап авырый башлагач, 1901 елны семьясын алып, үзенең Бучырмасына кайтып китэ һэм шул ук елны туган-үскэн җирендэ вафат та була. Э Минһажетдин Стэрледэ кала. Аңа инде унҗиде яшь, үз көнен үзе күрергэ тиеш. Үтэмишевлар аны Дәүлэкэндэге тоз, керосин, ташкүмер складына «баш» итеп җибэрэлэр. Хезмэт хакы аена ун сум — Минһажетдин шуның алты сумын авылга энисенэ җибэреп тора. Атасы кебек тырыш, гадел булганга күрэ, байлар ел саен аның хезмэт хакын бер-ике сумга арттыралар, ул да ел саен энисенэ акчаны арттырып җибэрэ, чөнки дүрт ятим анда, энисе кулында, кош балалары шикелле көтеп кенэ торалар.

Тагын берничэ ел үтеп китэ. Минһажетдиннең каралыр вакыты да житэ. Моның өчен ул туган авылына кайта, лэкин шуле гаилэнең бердэнбер тэрбиячесе булганга күрэ аңа льгота («күк билет») чыга. Солдаттан котылгач, бер унайдан егет, Чокырча авылының Гамилэ исемле кызына өйлэнеп, яшь кэлэше белэн яңадан Дәүлэкэнгэ китэ.

Минһажетдин инде үзен сэүдэ эшендэ таныткан кеше, аны Дәүлэкэн купецлары үзлэренэ чакырып кына торалар. Үтэмишевлэрнең һаман да бер урыннан икенче урынга күчереп йөртүлэре бик туйдыргандыр ахрысы, ул тота да элеге югарыда телгэ алынган Шэймэрдэн купецка приказчик булып күчэ. Фатир — байдан, хезмэт хакы да аена егерме биш сум...

Шик юк, Минһаж абзый кайчан да булса үзе дэ «купичлыкка» чыгарга хыялланган булырга тиеш. Ул заманда бу һэрбер өлгер, уңган приказчикның хыялы иде. Эмма лэкин Минһаж абзыйның «сэүдэгэрлек мэктэбе» артык озакка сузыла, нужадан чыгып, мая туплап, үзенэ «эш

башлаганчы» ул арада 1917 нче елның революциясе дә килеп җитә. Билгеле инде, язмышның бу борылышы өчен аңа соңыннан бары сөенергә генә туры килгәндер. Бигрәк тә балаларына!

Шулай да нэп вакытында Минһаҗ абзый һәм аның үзе кебек элеккеге приказчиклардан алты кеше «Алга» исеме белән ширкәт төзеп, Басыйр купец магазинында бер биш-алты ел гөрләтеп сату итеп калдылар. Шуннан соң инде хосусый сәүдә эшләре сүнде, бетте, һәм Минһаҗ абзый да үзенең асылына кайтты. Ягъни яңадан хезмәт кешесенә әйләнеп, калган гомерен төрле урыннарда эшләп уздырды.

Минһаҗ абзыйның үзе язып калдырган бу тарихы Казан якларыннан «бәхет» эзләп чыгып киткән ярлы татар өчен бик характерлы дип әйтәсем килә. Дәүләкән купецларыннан кемне генә алма, аның тарихы әнә шулай башлана. Дөрес, кайберләре иртәрәк уңышка ирешә, баеп та өлгерә, ә кайберләре өлгерә дә алмыйча кала. Билгеле, уңыш дигән нәрсә күп сәбәпләргә, мәсәлән, кайчан килүенә, ниндирәк җиргә килеп эләгүенә һәм кешенең үз сыйфатларына да бәйләнгән булырга тиеш. Шул ук Үтәмишевләр дә бит хәзерге Балтач районы Мәчкәрә авылыннан, ә Уфа миллионерлары Нәзировлар исә — Казан арты Битаман авылыннан чыккан кешеләр. Әмма болар башка, болар инде җәеннең бик эреләре!

Дәүләкән «купецлары» турында шушы китерелгән мисаллар да бәлки җитәр иде. Ләкин мин тагын ике кеше язмышы турында язмыйча үтә алмыйм — калдыруы кызганыч!

Аларның берсе Сафиулла Зәйнуллин. Бу инде Башкортстанның үзендә (хәзерге Туймазы районы, Арысланбәк авылында) туган кеше. Сигез яшендә ятим калгач, аны Уфага китереп, Хәкимов дигән байга тәрбиягә бирәләр. Хәкимов — Уфаның иң зур байларыннан, заманында шәһәр үзәгендәге куш манаралы мәчетне дә шушы бай салдыра. Бу кеше турында шундый кызыклы бер риваять тә ишеткәнем бар: имеш, ул үзе дә кайчандыр яшь чагында көтүче булган диләр. Ахырда ничектер баеп киткәч, үзенең шул иске чабаталары белән озын чыбыркысын намаз бүлмәсендә чөйдә генә элеп тоткан; карт намаз укыганда, шулар: «Масайма, безне киеп һәм сөйрәп йөргән чакларыңны онытма!» дигән төсле гел аның күз алдында торган, имеш! Булыр да!

Сафиулла шушы байда үсеп, егет булгач солдатка алына һәм сигез ел Польша җирләрендә хезмәт итеп кайта... Кайткач, бай аны Нәфисә исемле Малмыж кызына өйләндереп, кулына күпмедер акча биреп, Дәүләкәнгә җибәрә. Башта Сафиулла Уфа баеның малы белән сату итә, аннары тора-бара кибет тә, товар да аның үзенә күчә. (Сәүдәсе — бакалея.) Озак та үтми, Эткол уртасында башкорттан җир алып, зур гына йорт та, таза каралтылар да салдырып җибәрә. Шулай итеп, Дәүләкәндә Сафиулла дигән тагын бер «купич» пәйда була.

Кыскасы, бер үк язмыш кичергән, бер үк юл үткән татар сәүдәгәре, әмма кеше буларак ул бөтенесеннән дә бик нык аерылып тора иде. Тышкы кыяфәте белән үк — биленә зинар буып, яланбаш йөри торган иде. (Татар сәүдәгәрендә моны күрмәссең.) «Кызыл купич» дисәм арттырып җибәрү булыр, һәрхәлдә прогрессив карашлы, заманга иярүче бер кеше иде ул. Динне танымады, мәчеткә йөрмәде, күршесе Искәндәр ахунны да гел тәнкыйтьләп кенә торды, диләр белгән кешеләр. Корьән укыту мәҗлесләренә дә бер вакытта да йөрмәгән һәм үзе дә андый мәҗлесләр үткәрмәгән. Ике улы — Барый һәм Гомәрне дә — ул дин сабагына йөртмәде, ә иң зур кызы Рәкыя апаны гимназиягә биреп укытты. (Татар кызларыннан бары икәү генә — Басыйр купецның Газизәсе белән шушы Рәкыя апа гына бездә гимназисткалар иде.) Калган балалары инде совет мәктәбендә укыдылар.

Ике революция (февраль белән Октябрь) арасында Сафиулла аб-

зый еш кына митингларда ялкынлы нотыклар да сөйләгән. Билгеле, патша төшерүне хуплап, хөрриятне яклап!.. Әйткәнемчә, заман барышын тиз сизә торган кеше булган ул. Моны аның соңгы бер кыю гамәле дә ачык күрсәтте.

НЭП дигән нәрсә бетеп, «бөек борылыш» чоры башлангач, ягъни 1929 елны Сафиулла абзый Дәүләкәннең элекке приказчикларыннан «Урал» исемендә колхоз сыман кечкенә бер артель оештыра. Волость оешмалары бу артельгә унике чакрымдагы Конягин хуторы ягыннан күпмедер җир дә кисеп бирәләр. Утызынчы елны Сафиулла абзый, Дәүләкәндәге йортын сатып, яңа җиргә күчә, үзенә кечерәк бер өй салып керә, калган акчасына артель өчен өч ат һәм кайбер машиналар да сатып ала. Шунда ул, колхозның җитәкчесе дә һәм көтүчесе дә булып дигәндәй, бик тырышып эшләп маташа. Әмма колхоз бик бәләкәй, бик зәгыйфь була, бер дә мантый алмый, чөнки элекке приказчикларның җир эшенә дәртләре һәм сәләтләре юк диярлек, «колхозга» язылган 12 кешенең дә бары алтысы гына яңа урынга күчеп утыра. Калганнары Дәүләкәннән килеп-китеп кенә йөриләр. Шул рәвешчә бер-ике ел эшләп азапланганнан соң бу «Урал» ахырда якындагы «Урта тау» колхозына кушыла. Сафиулла абзый менә шул колхозда гади колхозчы булып, 1938 елга хәтле эшли һәм, авырый башлагач, Уфага — зур кызы Рәкыя янына күчеп килә. Ә 1940 елны инде ул рактан үлеп тә китә. Шулай итеп, бу тынгысыз «купич» та ахыргы гомерендә, үзенең чын асылына кайтып, дөньядан үтә.

Дәүләкәндәге әлеге бердәнбер диярлек дустым Гомәр шушы Сафиулла абзыйның улы инде — һәм атасының бу гыйбрәтле тарихын да миңа ул сөйләгән иде.

Дәүләкән байларыннан икенче бер «хикмәтле» кеше — Нәбиулла Кәримов. Билгеле, читтән килгән татар, ләкин кайсы яктан — ул кадәресен белә алмадым. Сорашыр кеше дә калмаган. Мин үскәндә, Нәбиулла Кәримов үзе юк иде инде, ләкин йорт җирләре саклана иде әле. Дәүләкәндәге ике зур алма бакчасының берсе менә шул Кәримовныкы иде. Мәйданы бер-ике дисәтинә чамасы булыр. Бакча эчендә үзе яшәгән матур гына агач өе бар иде. Соңыннан бу өйдә үлгән байның җитеп килгән ике улы (Гали белән Гомәр) һәм аларга туган тиешле Исмәгыйль исемле бер чатанрак абзый зур бакчаның хуҗасы да, каравылчысы да булып торды. (Чатан булса да, алма урларга кергән малайларны сүләндәй[1] бик капыл эләктереп ала иде.) Аннары шул ук бакча белән янәшәдәге иркен ихатада бик озын итеп салынган ике катлы агач йорты һәм таш магазины да бар иде. Озын йортның буеннан-буена ачык терраса сузылган, бик күп ишекләр менә шул террасага чыга, һәр ишек үзенә аерым бер фатир, һәм һәркайсында фатирчылар тора иде. Аскы катының базар мәйданына караган башында чәйханә иде шикелле — шулай хәтеремдә калган. Янә тагын Имәнлек ягында аның зур гына урманы да булган — аны «Кәримов урманы» дип йөртәләр дә иде. Кыскасы, байлыкның төрлесен биләгән Нәбиулла Кәримов. Әмма ничек баеп киткән соң бу каяндыр Эткол авылына килеп чыккан кеше?.. Безнең атайлар сөйли торган иде, имеш, ул картада бик оста уйнаган һәм күз буу (ягъни гипноз) дигән хикмәтне яхшы белгән, дип. Мәсәлән, үзенә мәҗлескә җыйган мулла һәм картларның «күзләрен буып», аларның кәвеш-каталарын суда йөзеп йөргән үрдәкләр итеп күрсәтә икән. Кунаклар астыбызга су керә дип хәтта урыннарыннан сикереп торалар, имеш. Инде Нәбиулланың баеп китүе дә әнә шул сәләтләре (бигрәк тә картада отуы) аркасында булган диләр. Һәрхәлдә, буш кеше булмаган бу абзый!.. Җиләк-җимеш үстерүнең нәрсә икәнен белмәгән бер җирдә шундый зур бакча үстерүе үзе генә дә ул кешенең һәр тор-

---

[1] Селәүсен (рысь).

ле сәләткә ия булуын күрсәтсә кирәк. Тик менә әҗәлдән котылу чарасын гына таба алмаган.

Шулай итеп, күргәнебезчә, Дәүләкән купецларының барысы да диярлек Казан ягыннан килгән һәм бик түбәннән чыккан кешеләр. Ягъни аларның берсе дә потомственный сәүдәгәр түгел иде. Тагы да ачыграк әйтсәк, яңа урында яңа гына туган купецлар! Моның сәбәбен дә күрдек: Эткол дигән башкорт авылы кырыннан Себер тимер юлы уза, кечкенә авыл бик тиз арада җанлы бер сәүдә урынына әверелә, һәм соңга калмыйча килеп җиткән өлгер, булдыклы абзыйлар конъюнктурадан оста гына файдаланып, кыска гына вакыт эчендә күтәрелеп-баеп та китәләр. Әлбәттә, һәрбер читтән килүче монда «алтын тапкан икән», дип уйлау хата булыр иде. Юк, алтын җирдә аунап ятмый ул, бик сирәк кешегә генә очрый, шул сәбәпле читтән килүчеләрнең күбесе яңа байларда я приказчик, я хезмәтче булып эшләргә мәҗбүр иде. Аннары төрле һөнәр иясе — тимерче, тегүче, итекче, мич чыгаручы, пима басучы, извозчикларны алсак, болар инде асылда туграк җир, күбрәк эш эзләп килгән үзенә аерым бер «кәсепчеләр» иде.

Алар турында да сүз булыр әле, ә хәзергә купецлар турындагысын бетерәсем килә. Хикмәт шунда ки, бу төркемнең «эшчәнлек» дәвере шактый кыска булып чыкты, чөнки Дәүләкәндәге сәүдә-коммерция эшләре үзе дә бик кыска гомерле булды. Бары егерме-егерме биш ел гына... Октябрь революциясе килеп җиткәндә, татар купецларының күбесе кырык биш-илле яшьләр тирәсендә генә булгандыр (арада иң «карты» Гатаулла бабай — ул гына илледән узган). Билгеле, революция аларның эшен өзде, тамырларын кисте, ләкин бөтенләй үк аяктан екмады. Кибет-малларыннан аерылсалар да, йортларыннан аерылмадылар — искечә тора бирделәр. Ә менә балаларының язмышы бөтенләй икенче эздән китте, һәм без монда да шактый гыйбрәтле хәлләр күрәбез.

*

* *

...Яңадан Борһан абзыйдан башлыйк, булмаса. Аның балалары күп — ялгышмасам, өч улы, биш кызы бар иде. Күрше-тирә белән дә артык аралашмыйча, ничектер бикләнебрәк тыныч кына яшәгән шушы гаилә кинәт кенә таркала башлый. Иң элек әле революция алдыннан гына Борһан абзыйның җәмәгате Фатыйма абыстай үлеп китә. Бу инде таркалуның башы дигән сүз. Сигез бала, иң кечесенә ике-өч яшь кенә булгандыр, караучысыз һәм саклаучысыз кала. Шуннан соң озак та үтми, гражданнар сугышы башлангач, әлеге атасына ияреп магазинга йөри торган бик чибәр, бик көяз уллары Галиулла тота да, кызылларга язылып, фронтка китә. Моны миңа соңгы очрашуда энеләре әйтте, хәлбуки мин үзем күптән инде Галиулланы кызыллар мобилизовать иткән дип ишеткән идем. Ләкин кайсылай гына булса да, моны егетнең бәхетеннән санарга кирәк, чөнки кызыллардан соң Дәүләкәннең күп кенә яшьләрен аклар җыеп ала. Боларның барысы да диярлек Колчак армиясендә югалып бетә, ә менә Галиулла үзе дә югалмый, киләчәген дә югалтмый.

Аннары шул ук җәйне Борһан абзыйның зур кызы Заһидә апа үзләренә фатирга куелган бер кызыл кавалеристка — янып торган җирән чәчле мишәр егетенә ияреп китеп бара. Бу инде «мисле» булмаган, гадәттән тыш вакыйга! Шушы вакыйгадан соң Борһан абзый үзе дә, вак балаларын алып, Уфага китеп тора. Сугышлар бераз тынгач, ул балаларын кире Дәүләкәнгә кайтарып куя, ләкин үзе ни өчендер яңадан Уфага китә. (Бәлки хәтәр-хәвефтән сакланыр өчендер.) Шулай итеп бер заман бу гаиләдә зурлардан берәү дә калмый, җыен ыбыр-чыбыр

бала-чага, иң олысы Гайшә апага унбиш-уналты яшьләр булыр, менә шул кыз инде атасы кайтканчы гаилә башы булып тора да. Бу авыр елларны алар ничек үткәргәннәрдер дә, ничек көн иткәннәрдер — хәзергә кадәр төшенә алганым юк. Тик бер нәрсәне беләм, Борһан абзыйның элек һәрвакытта ябык капкасы хәзер һәркемгә ачык, без, күрше малайлары, теләсәк кайчан кереп йөрибез, хәтта әле еш кына хуҗасыз йортта «аулак өй» дә ясый торган идек. Аларда бүлмәләр күп, без шуның берсенә җыелып, төрле уеннар уйнап, кич үткәрә идек. Әйтергә кирәк, моңарчы сирәк аралашкан «купич» кызлары Әминә белән Хава да, уллары Зәкәрия белән Яхъя да бик ачык күңелле, уйнарга-шаярырга ярата торган тиндәшләр булып чыктылар. Тик минем күңелне гел үзенә тартып торган Һаҗәр турында гына алай әйтүе дөрес булмас, ул шактый горур кыз иде, ә бәлки миңа карата гына шулай булгандыр.

Берме-икеме ел үткәч, Борһан абзый Уфадан Хәдичә исемле чибәр, сөйкемле генә абыстайны балалары янына алып кайтты, үзенә никахлы хатын, балаларына, үги булса да, ана. (Әмма бик әйбәт ана булды дип сөйлиләр Борһан абзый балалары.) Иш янына куш дигәндәй, абыстайга ияреп, Хәким исемле минем чамадагы улы да килгән иде. Гаилә яңадан бер кыек астына җыела, бергә оеша, искечә үк булмаса да матур, тыныч кына тора да башлый. Тагын күпмедер вакыттан соң Гайшә апаны гомерен Сафа байда ялчылыкта уздырган Кәфи карт малае Хәйретдин абзыйга кияүгә бирәләр. Бик ярлы кешенең баласы булса да, Хәйретдин абзый элекке «купич»ка кайсыдыр яклары белән ошаган булса кирәк, чөнки озак та үтми алар бергәләп кибет ачып, шәп кенә сату итәргә дә керешәләр. Ләкин, әйткәнебезчә, нэп дигән «иркенлек» бик кыска булып кала, тиздән «бөек борылыш» игълан ителә, һәм Борһан абзыйның сәүдәсе ябыла, семьясы да инде бөтенләйгә тарала. Аңарчы әле, 1927 нче елның җәендә, мине саргайткан Һаҗәр Дәүләкәнгә ни өчендер килеп чыккан Низам исемле Ыслак егетенә тагылып китә дә бара. Ни булган бу Борһан кызларына?!.. Кешесе, хәерсез, кайдан табылып тора?! Әйткәннәр иде, ул егет бик «зәһәр комсомол» дип, күп еллар узгач, миңа аның белән очрашырга да туры килде, ләкин бусы инде башка бабтан... Читкә тайпылмас өчен Борһан абзый балаларыннан ерак китмик әле. Хуш, кайсыннан башлап дәвам итәргә?.. Булмаса, иң элек зурларын — Галиулла белән Заһидә апаны искә төшерик. Галиулланың Кызыл армия сафына алынуын егет өчен бәхет дип юраган идек. Чынлап та ул шулай булып чыга да: Галиулла армия сафында партиягә керә, хәрби хезмәттән бушагач совет органнарында эшли, республиканың Учалы районында РИК председателе дә булып тора. Яхшы ук грамоталы, зиһенле егет үсә-үсә ахырда Башкортстан үзәк башкарма комитеты секретариатының мөдире, аннары Совнарком каршындагы дини эшләр идарәсенең җитәкчесе булуга чаклы барып җитә. Ватан сугышы башлангач, ирекле рәвештә фронтка китә һәм 1943 елны каты сугышларның берсендә хәбәрсез югала. Күпме алар, хәбәрсез югалучылар?! Ә менә аның улы Ирек көнчыгыш Сахалинда нефть берләшмәсенең начальнигы булып эшли икән. Моны миңа Галиулланың энеләре әйтте. Шулай ук энеләренең әйтүенә караганда, Галиулла сәхнә әсәрләре дә язгалаган, кайберләре исә вакытында уйналган да икән. (Бу кадәресе миңа билгеле түгел иде.)

Шулай ук гражданнар сугышы вакытында кызыл кавалерист — мишәр егетенә ияреп киткән Заһидә апа дүртме-бишме елдан соң көтмәгәндә генә атасы йортына кайтып керә. Нык үзгәргән. Теге вакыттагы сылу туташ хәзер сулган гөлгә охшабрак калган иде. Бу юлы аны икенче бер мишәр абзые ерактан, каяндыр Пенза-Рузаевка якларыннан үз аты белән, арбасына утыртып, Дәүләкәнгә алып кайта. Билал исемле бу абзый теге кавалерист кебек шәмдәй төз, таза егет түгел иде инде. Яшькә дә шактый олы, өс-башы да иске, йөз-чырае да чытык (няген-

битен каты сары төк баскан), әмма ул яхшы күңелле, намуслы кеше булган булырга тиеш. Каядыр еракта адашып калган Заһидә апаны бәхетсезлектән йолып, ничәмә йөз чакрым җирдән атасы йортына китерүе шуны расласа кирәк. Бала газиз, Борһан абзый күпме хәсрәт чиктергән кызын да, мужик кыяфәтле бу килбәтсез киявен дә кабул итә, йортыннан аларга урын да бирә. Әмма кияве аның сәүдә эшләренә бөтенләй катышмый, һәрбер мишәр шикелле ул да ат ярата һәм бөтен көнен шул аты белән нидер эшләп йөри. (Станция тирәсендә йөк ташый иде шикелле.)

Утызынчы елларның башында бабасы йортыннан чыгып китәргә туры килгәч, Билал кияү Дәүләкән очында үзенә кечерәк бер өй корып кергә. Шул өйдә Заһидә апа белән икәвесе бергәләп картайганчы тыныч кына яшиләр. Балалар үстерәләр. Шул ук утызынчы елларның башында Борһан абзый үлгәч, аның салкын гәүдәсен ләхеткә куючы да шушы кияве була. Балаларыннан берсе дә бу вакытта юк, таралышып беткән булганнар.

Кайда алар? Кайсы якларга очтылар икән бу оясы туздырылган «чәүкә» балалары? Мине бигрәк тә күршедә бергә уйнап-үскән, инде егет булып өлгергән Зәкәрия белән Яхъя язмышы кызыксындыра иде. Ләкин аралар ерак, Дәүләкән белән элемтә күптән өзелгән, кайтып йөрү түгел, һичкем белән хат та алышканым юк. Аннары ил эчендә төрле хәлләр булып узды, тормышта бик зур үзгәрешләр булды, ул арада Бөек Ватан сугышы да башланды. Бу вакытта бертуганнар да еш кына бер-берсен югалтып тордылар... Бары тик сугыштан соң илленче елларның урталарында гына мин башта Яхъяны, аннары Зәкәрияне, ниһаять, Уфада очраттым. Бу вакытта Яхъя шәһәр үзәгендәге бер ашханәдә мөдир иде. Әле сугышка чаклы ук бик чибәр Уфа кызына өйләнгән булган, хәзер инде бишме-алтымы баласы да бар икән. Билгеле, Ватан сугышында да булган, яраланган, күп кенә орден һәм медальләр белән бүләкләнгән, званиесе — гвардия майоры!..

Зәкәрия «тарихы» минем өчен тагы да көтелмәгәнчәрәк булып чыкты: атасы кебек бәләкәйрәк буйлы, юка гына гәүдәле бу егет хәрби самолетта очучы-штурман булган икән лабаса!.. Дөрес, ул фронтта булуын булмаган, ләкин ике төрле авиация мәктәбен бик уңышлы тәмамлаганнан соң, бөтен сугыш дәвамында үзе, инструктор буларак, авиация өчен штурманнар хәзерләгән... 1957 елны гына отставкага чыга, Уфага кайта, өйләнә, квартир ала, хәзерге көндә әйбәт пенсия белән матур гына торып ята... Зәкәрия дә, Яхъя да — коммунистлар. (Һәм хатыннары да аларның бертуганнар икән.) Менә шулай. Алма агачыннан ерак төшми диләрме? Хәер, бу очракта «алмалар» агачтан шактый ерак тәгәрәгәннәр. Әмма сорты шул ук бит! Кайчандыр Өчмунча авылыннан малайлыкка биреп җибәрелгән, соңыннан Этколга килеп баеп киткән Борһан «купич» улларының язмышы әнә шундый.

Яки менә каршыдагы күршебез Гатаулла бабай улларын алыйк. Мин аларның иң олысы Габдрахман абзый белән иң кечесе Хәбибрахманны яхшы беләм. Калган ике улын һәм ике кызын белмим диярлек, чөнки мин үсеп, кешеләрне ныграк таный башлаганда, алар юк иде инде. Ике улының берсе гражданнар сугышы вакытында, икенчесе берничә ел соңрак тәмам егет булып җиткәч кенә тифтан үлгәннәр. Шулай ук кызлары да иртә киткән бу дөньядан... Хәбибрахманның әйтүенә караганда, алар барысы да укырга бик сәләтле булганнар.

...Иң өлкәне Габдрахман абзый, ничек дим, идеалист бер кеше иде. Ул иң яхшы мәгънәдәге мөгаллим, һәм аның өчен мөгаллим булудан да изгерәк, кирәклерәк бүтән эш дөньяда гүя юк та иде. Шуңадыр инде ул атасының сәүдә эшләренә бер вакытта да катнашмады. Бөтен хыялы һәм максаты аның татар, башкорт халкын агарту — шушы эшкә бөтен

тәне-жаны белән бирелгән гаҗәп бер кеше иде. «Укыгыз, туганнар, укыгыз!» — еш кына кабатлый торган сүзе дә әнә шул иде.

Мин дә аңарда бер-ике кыш укыган идем. Ул зур борынлы, тирән утырган зур соры күзле, нык, таза бәдәнле, урта буйлы җыйнак кына кеше иде. Дүрт сәгать укыта икән — дүрт сәгать гел аяк өстендә, бер генә минут та утырып тору юк. Әмма ничек укыта диген?! Тәмам онытылып, ялкынланып, чын артистларча!.. Бигрәк тә әдәбият дәресен. Иң яраткан шагыйре, әлбәттә, Тукай иде. Тукайның «Пар ат»ын яки «Тәләнче»сен яттан шундый сөйләп җибәрә ки, без хәтта тынлап бетергәч тә, авызларыбызны ябарга онытa идек. Һәм бездән дә шулай көчле-матур итеп, ноктасын ноктага туры китереп, яттан сөйләтергә тырыша... Аннары табигать дәресләрен дә ул бик яратып укыта иде. Шәкертләрне көзен яки җәй башында кырга алып чыгып, үләннәр һәм чәчәкләр белән таныштырып йөри — безнең өчен иң күңелле дәрес тә шушы була торган иде.

Бу урында тагын бер яңалыкны искә төшерү артык булмас: Дәүләкән башкортлары, шулай ук татарлары да яшелчә үстерүнең нәрсә икәнен белмиләр иде. Яшел суганны да алар Марҗа базарыннан барып алалар иде. Һәм менә шул мөселманнарга Дәүләкән туфрагында яшелчәне беренче үстереп күрсәтүче дә Габдрахман абзый булды. Аның каткат өндәве аркасында күрше-тирә татарлар, шулай ук кайбер башкорт агайлары да, ишек алларын киртәләп, суган, кишер, кыяр, кабак кебек нәрсәләр утырта башладылар. Ә 1921 елгы ачлыктан соң инде бу эш үзеннән-үзе көчәеп китте. Дәүләкән җире шәп, ни чәчсәң дә, котырып үсә — бездәге көнбагыш та кабак төше хәтле була торган иде.

Беренче хатыны тифтән вафат булгач, Габдрахман абзый безнең Каргалы кызы Мәрзия апага өйләнде. Мәрзия апа үзе дә мөгаллимә — Мөхәммәтша тегүче өенең кечкенә бер бүлмәсендә фатирда тора. Туйлары да шушы йортта булырга тиеш иде. Без, бер төркем малайлар, туй килгәнен күрергә дип Мөхәммәтша абзыйның капкасы төбенә җыелдык. Кышкы шактый салкын айлы төн иде, өйнең урамга караган өч тәрәзәсендә дә утлар яна, ак пәрдәләр тартылган, ләкин өйнең эчендә дә, тышында да мондый чакта була торган хәрәкәт, ыгы-зыгы бер дә сизелми. Без күпме көтсәк тә, кыңгыраулы пар атларда туй килгәнен күрмәдек. Тик шактый вакыт үткәч, бер генә ат җиккән эчле чанада Габдрахман абзый ялгыз үзе генә килеп җитте. Кемдер капканы ачып аны ишегалдына уздырды. Шуның белән барсы да бетте, тынды.... Без дә салкын тын урамда бераз биешеп тордык та әкренләп өйләребезгә таралыштык. Туйларны күргән бар иде — андагы кызык, шаушу, җыр-музыка!.. Әмма боларның берсен дә безнең үтә тыйнак мөгаллимебез әллә белмәгән, әллә инде кирәк дип тапмаган.

Туйдан соң «яшьләр» Гатаулла бабайның ишек алды түрендәге иске өендә бергә тора һәм бергәләп укытып та йөри башладылар. Аларның бәхете әнә шул эшләрендә иде, башкасын алар гүя тели дә, көтә дә белмиләр иде. Хәер, бер бик көчле теләкләре булган аларның — уку, уку, һәм уку!.. Менә шушы теләк белән алар, шактый олы яшьтә булуларына карамастан, икәүләп утызынчы елны Уфага, Учительләр институтына укырга киталәр. Авыр еллар, ике балалары бар, ничек укыганнардыр да ничек яшәгәннәрдер, хода белсен?! Ә укуны бетергәч, янадан шул ук иске, изге эшкә — Габдрахман абзый Уфаның бер башлангыч мәктәбендә мөдир, Мәрзия апа исә шунда ук рус теленнән гади укытучы. Бу эштә инде аларның гомерлеккә «чәчләре — чәчкә бәйләнгән!»

Илленче елларның уртасында беренче мәртәбә Уфага кайткач, мин Габдрахман абзыйны электән үк таныш урамнарның берсендә, баракка охшаган озын агач йорттан эзләп таптым. Бераз гаҗәпләнеп, әмма бик сөенеп каршы алды ул мине... Миңа да гаҗәпләнергә туры килде:

авыр еллар Габдрахман абзыйга да тирән эзен салып узган икән. Анналары үсеп җиткән ике улының Шамил исемле зуррагы фаҗигале рәвештә үлгән дип тә ишеткән идем. Әйе, хөрмәтле укытучым шактый ук картайган да, суырылган да, йөзе дә саргайган, күзләре дә эчкәрәк бата төшкән, ләкин үзе әүвәлгечә дәртле сөйләшә, елмая, сораша, әмма үз хәсрәте турында ник бер сүз әйтсен!.. Минем әдәбиятта яңадан күренә башлаган чагым иде, шуны белгәч, чын ихластан куанды ул... Без сөйләшеп утырган бүлмә бик тыгыз иде. Унике квадрат метрда дүрт кеше —үзе, Мәрзия апа, өйләнгән улы белән яшь киленнәре торалар. Ике караваТ (берсенә чаршау корылган), уртада өстәл, урындыклар, ишекнең бер ягында савыт-сабалар өстәле, икенче ягында киемнәр элгече, кыскасы, борылыр урын да юк. Мондый шартларда тору өчен нинди сабырлык кирәк!.. Уллары Искәндәр урман хуҗалыгы институтын уңышлы тәмамлаган яшь белгеч. Ул, билгеле, квартир алу хәстәре артыннан йөри башлый. Шул арада Габдрахман абзый да авырып китә... Аны күбрәк килене карый — килен үзе врач булу өстенә, бик кече җанлы, бик итәгатьле кыз булып чыга. Шактый көч һәм вакыт сарыф итеп йөргәннән соң аларга, ниһаять, өч бүлмәле квартир бирергә булалар. Шул чагында Габдрахман абзый улына әйткән:

— Искәндәр улым, әллә сабыр итеп торабызмы? Подвалларда торучылар да бар бит әле, алардан элек яңаны алу безгә килешмәс!— дигән.

Соңыннан моны ишеткәч, минем дә ачынып әйтәсем килде: Их, мөгаллим, мөгаллим, шул хәтле дә изге җан булырга ярыймы соң?!. Куй, я кешеләрнең ачуын китерерсең...

Яңа квартирга күчкәч, Габдрахман абзый бер генә ел торып калган. Белмим, бу кыска гына вакыт эчендә ул иркенрәк квартирда торуның рәхәтен әзрәк татый алды микән, әллә булмаса һаман да шул «подвалларда яшәүчеләр»дән тартынып-оялып дөньядан китеп барды микән?!.

Ә менә Мәрзия апа Габдрахман абзыйга караганда озын гомерле булды. Улы белән килене тәрбиясендә кадер-хөрмәттә яшәп, ул сиксән биш яшенә җиткәч дөнья куйды... Әйе, яхшылар да, начарлар да иртәме-соңмы бу дөньядан китәләр. Начары, кеше буларак, шунда ук онытыла, ә яхшысы гомер буена диярлек онытылмый. Ә аның кайбер сыйфатларын балаларында да күрсәң, кешеләргә ничектер ышаныч арта, тормыш үзе дә яктырак, рәхимлерәк булып күренә башлый. Быел Уфага кайтып, Искәндәр белән очрашкач, мин әнә шундый бик әйбәт, тансык, кадерле бер хис кичердем.

Гатаулла бабайның иң кече улы Хәбибрахман — миннән өч яшькә олырак. Габдрахман абзый белән Хәбибрахман арасында туган балаларның үсеп, тәмам егет һәм туташ булып җиткәч кенә үлеп китүләрен әйткән идем инде... Ул заманда ике төрле чир — чахотка белән тиф яшьләрне аеруча кырды. Картның да ике улын тиф, ике кызын чахотка алып китте. Бер сабыйны югалту да хәзер ата-ана өчен зур фаҗига, ә тап-таза егетләр белән буй җиткән кызларны югалтуның хәсрәтен ничек кенә күтәрергә мөмкин икән?! Әйе, искиткеч чыдам булган ул чакта картларның йөрәге!..

Хәбибрахман үзе дә бала чактан ук тазалыкка туймады. Аның бер аягында сөяк туберкулезы иде, шуның белән ул берничә ел азапланды, берничә мәртәбә озак-озак кына больницада да ятып чыкты. Малай чагында аңа чабып, уйнап йөрергә күп туры килмәде. Хәлбуки, әйтүенә караганда, чабарга бик яраткан. Безнең уйнаганны да ул капка төбенә чыгып, култык таякларына таянып, баганага сөялеп, читтән генә бик кызыксынып карап тора иде. Менә шул авыруы аркасында, гәрчә урам аша гына торсак та, мин Хәбибрахманның малай чагын юньләп белми дә, күрми дә калдым. Тик бер тапкыр Дәүләкән читендәге больницага кемнәргәдер ияреп аның хәлен белергә баруымны гына әзрәк хәтерлим.

Әмма аның караве, без икебез дә 1925 елны Казанга барып, шунда очрашкач, бик якынаеп, дуслашып киттек. Һәм бу дуслык гомеребез буена һич сүрелмичә, өзелмичә дәвам итте. Һәм хәзер дә шулай дәвам итә!

Больницада яткан чагында аның аягын кисмәкче дә булганнар, ләкин ул кисәргә бирмәгән аягын. «Үләсең!» — дигәннәр аңа. «Үз аягым белән үләм»— дигән ул... Торып-торып шуңа исе китә һәм куана Хәбибрахман хәзер дә: «Миңа бит унике генә яшь иде, ничек акылларым җиткән!»— ди. Аяк әкренләп булса да төзәлә, тик Хәбибрахман әзрәк аксый торган булып кына кала. Җитмеш биш яшьлек картым рәхәтләнеп йөрү генә түгел, дәрте килсә, яшь ханымнарның беленнән алып, танцевать та итеп җибәрә.

Хәбибрахман бала чактан ук укырга гаять сәләтле булган икән. Еллап авыруына карамастан, ул үзлегеннән укуын дәвам иттерә, ә аягына баскач, Бәләбәйгә барып, ике ел эчендә урта мәктәпне бетереп кайта. Егерме бишенче елны Казанга барып, университетның медицина факультетына укырга да керә. Имтиханнарын да җиңел генә бирә. Шулай итеп, моңарчы рәсемнәрдә генә күрергә туры килгән мәһабәт колонналы ак бинаның озын коридорында сары кайры тун, төпле пималар кигән, азрак кына шадра бер Эткол егете аксый-туксый укып йөри башлый. Әмма бу уку аңа, әйтергә кирәк, чын куаныч белән бергә зур газап та китерә. Ятимнең авызы ашка тисә, борыны бозга тия диләрме, шуның шикелле, тырышып кына укып йөргәндә, аның сәламәтлеге янадан начарлана: әлеге чахотка дигән әшәке хәтәр авыру үпкәләренә күчә — менә шул авыруы белән көрәшә-көрәшә укый ул... Соңгы курска җиткәндә инде ул кан төкерә, хәле бик мөшкел иде. Бу чакта без аның белән Кирпично-заводской урамында, чокыр төбендәге бер йортта икәү бергә тордык. «Кем-кемне алдан бетерә инде, мин медфакнымы, әллә чахотка минеме?» — ди иде Хәбибрахман еш кына, көләргә тырышып. Менә шушы хәлендә дә ул дәүләт имтиханнарын уңышлы тапшырып, медфакны бетереп чыкты һәм чыгу белән артык беркөн дә тормыйча Кырымга китеп тә барды. Бу утызынчы ел җәенең кояшлы бер иртәсе иде, иске чемоданын һәм каеш белән бугап медицина китапларын күтәрешеп, мин аны Казан вокзалында озатып калдым. Хәерле юл, хәерле сәгатьтә!..

Аның бар өмете Кырымда иде. Шунда эшләргә дә, шунда сәламәтләнергә дә тиеш иде ул. Ләкин китүенә берничә ай үтте микән, Кырымнан кайткан бер таныш миңа очрап, Хәбибрахманның авыр хәлдә больницага кереп ятуын сөйләп торды. Дөрес, ул үзе аны күрмәгән, ләкин кемнәндер шулай дип ишеткән. Мин моңа, билгеле, ышана калдым һәм Хәбибрахман белән бергә укыган, шул сәбәпле аның хәлен яхшы белгән кайбер иптәшләренә тизрәк хәбәр дә иттем. Уйлаштык-киңәштек тә, үзара акча җыеп, Хәбибрахманга җибәрергә булдык. Башка ярдәм итәрлек чарабыз юк иде. Хәбибрахман исә Кырымнан миңа нинди санаторийда эшли башлавын язган иде инде. Шул сәбәпле акчаны җыючы да, җибәрүче дә мин булдым. Ләкин, нишләптер, озак кына хәбәр булмыйча торды, күңелгә төрле шикләр килә башлады — акчабыз барып җитмәдеме, әллә инде... соңга калдымы?.. Шулай ни уйларга белмичә хәвефләнеп торган чакта, ниһаять, егетебездән хат килеп төште. Бик күп рәхмәт әйткән, сезнең кебек дуслар булуына бик сөендем дигән, ләкин юкка борчылгансыз, минем больницага кергәнем юк, әйбәт кенә эшләп ятам, сәламәтлегем дә ул хәтле үк начар түгел, Кырым һавасының шифасын да әкренләп сизә башладым инде дип язган.

Җыеп җибәргән акчабыз күпме генә булгандыр инде, әмма Хәбибрахман аны гомере буена диярлек онытмады. Ә Кырымга китеп, ул бик дөрес эшләгән икән, Кырым аны чынлап та аякка бастырды. Авыруын да җиңде, бәхетен дә шунда тапты.

1937 нче елны инде Хәбибрахман үзе миңа ярдәм кулын сузды. Әзербәйҗанның бер районында ярты ел эшләгәннән соң, минем Бакуга килеп, кая барырга, нишләргә белмичә аптырап йөргән чагым иде. Хәбибрахманга кыскача гына хат яздым. Озак та үтми аңардан чакырып җавап та һәм юллык акча да килде. Безнең җиде ел инде күрешкәнебез юк иде. Хатын белән баланы Казанга озаттым да үзем Кырымга китеп бардым. Башта поезд белән Севастопольгә, аннан кечкенә пароходта Ялтага, Ялтадан җәяүләп кенә Кориез дигән җиргә... Уналты чакрымлык бу араны һич тә таныш булмаган бик әйләнчек юлдан бер дә адашмыйча мин җиңел генә барып та життем. (Яшь чак шул!) Хәбибрахманның исе китте, ник хәбәр итмәдең дип тиргәп тә алды. «Эмка» машинасында гына каршы алмакчы булган икән ул мине...

Яшь чаклар өчен җиде ел аз вакыт түгел. Бу вакыт эчендә Хәбибрахман сәламәтлеген ныгыткан, таза ирләр төсе кергән үзенә, азрак шадра йөзе дә тулыланып, шомарып киткән һәм — иң мөһиме — бик матур яшь кенә кырым кызына өйләнгән, инде ике баласы да бар икән. Әмма мине тагын да гаҗәпләндергәне һәм сөендергәне — ул, баксаң, фиркасыз көенә Үзәк Комитет карамагындагы иң шәп санаторийның баш врачы да булып өлгергән!.. (Кырымга барып йөрүчеләр бу санаторийны белергә тиешләр — ул Кориез дигән җирдә, «Тау кояшы» дип атала иде.) Хикмәт нәрсәдә? Хикмәт шунда ки, Хәбибрахман, Гатаулла карт малае, шактый тиз арада үзен яхшы, төпле врач итеп кенә түгел, санаторий эшен бик оста оештыручы тырыш, чын житәкче итеп тә таныта. Шуңа күрә дә ул житмеш яшенә чаклы бөтен гомерен төрле җирдәге зур санаторийларда гел баш врач булып уздырды. (Билгеле, Кырымда чакта ук партиягә дә керде.) Бары сугыш вакытында гына семьясы белән Татарстанга кайтып, Арчадагы немец әсирләре госпиталенең начальнигы булып торды. Врач эше кешене, аның кем генә булуына карамастан, дәвалау, үлемнән коткару — шуңа ул врачлык дипломын алган чакта ук ант иткән. Терелеп, аякка басып, сугыш беткәч иленә җибәрелгән немец солдатлары хәрби гимнастерка өстеннән ак халат кигән, көне-төне алар өчен аксый-туксый чапкан, тырышкан бу татар начальнигын һәм аның кул астында эшләүче врачларны, шәфкать туташларын бәлки хәзер дә рәхмәт укый-укый исләренә төшерә торганнардыр. Әгәр кеше булсалар, әлбәттә!

Әзрәк читкә тайпылдым шикелле. Хуш, мин бит әле Кырымда, Хәбибрахманның кунагы... Санаториесенең ремонтка ябылган чагы икән, ял итүчеләр юк, миңа ул бик чибәр бинадан бик шәп җиһазлы иркен бер бүлмә бирде, шушында рәхәтләнеп тор, ял ит, диде. Үзе ул ремонт эшләре белән төрле якка гел йөреп тора иде. Ләкин күрә: миңа аңардан башка бер дә күңелле түгел, шуннан соң кая гына барса да, ул мине үзеннән калдырмас булды. Ул елларда машиналар күп түгел иде әле, шулай да Хәбибрахманның персональ машинасы бар иде. Утырабыз да китәбез. Монда юллар әйләнмәле дә борылмалы. Бер якта киерелеп яткан зәңгәр диңгез, икенче якта текә-текә кыя-таулар... Күп йөретте Хәбибрахман мине, Кырымның бөтен матур җирләрен күрсәтеп чыкты. Әмма бу йөрүләрнең минем өчен иң әһәмиятлесе — Галимҗан Ибраһимовны күреп китү булды. Авыру әдипне Хәбибрахман бер-ике тапкыр үз санаториесына алып, дәвалаган-караган, шуның аркасында алар арасында бик әйбәт якын мөнәсәбәт тә урнашып калган. Ялтага барган саен Хәбибрахман, әдип янына кереп, хәлен белеп чыга торган иде. Минем китәр вакыт якынлашкач, ул мине дә кыстый-кыстый Галимҗан ага янына алып керде. Бу турыда мин «Әдипнең терелеп кайтуы» дигән мәкаләмдә язган идем инде, шул сәбәпле янадан кабатланасым килми, тик шуны гына әйтергә тиешмен ки, олы әдип белән күрешү-сөйләшү һәм аның шул чактагы кыяфәте минем хәтердә гомерлеккә диярлек сакланып калды. Күңел түрендәге бер хәзинә дияр

идем мин моны... Хәбибрахман мине ике айга якын җибәрмичә үзендә тотты, төрле очрашулар да (мәсәлән, Такташның беренче хатыны Гөлчирә Хәмзина белән) аз булмады, ләкин боларны искә төшерә башласам, бик читкә кереп китәрмен дип куркам. Сүз Дәүләкәннән ерак китмәскә тиеш.

Әйткәнемчә, Хәбибрахман бөтен гомерен санаторийларда эшләп уздырды. Соңгы бер егерме елын Мәскәү партия комитеты санаториясенең баш врачы булып Звенигородта эшләде — бары житмеш яшенә житкәндә генә пенсиягә чыга алды. Бу санаторийның бинасы да иске заманның бер бай аристократыннан калган, зур парк эчендәге ак колонналы бик шәп сарай. Бирегә килеп ял итүчеләр дә карт большевиклар белән югары урындагы работниклар — үзенә аерым бер контингент дияргә була. Егерме ел буена шушы «контингент»ка ярар өчен баш врачның нindirәк кеше булырга тиешлеген сөйләп тору артык, минемчә. Әмма шунысы гыйбрәтле, бу зур санаторийда ул — бердәнбер татар, ләкин бөтенесе аңа түбәнчелек белән «Хәбиб Гатауллович» дип кенә торалар. Шушы үзе генә дә кешенең эштәге авторитетын гына түгел, аның кайбер башка якларын да аңлатса кирәк.

Хәзерге вакытта Хәбибрахман Гатаулла улы Ибраһимов РСФСРның атказанган врачы, шул ук санаторийдан ерак түгел, яшел калкулык өстендәге үзенең агач йортында тыныч кына картлык көннәрен уздыра. Сәбрия ханым белән алар икәү дүрт бала (өчесе кыз, берсе ул) үстереп, укытып, һәркайсына югары белем биреп кеше иттеләр. Дәүләкән егете белән Кырым кызыннан туган бу балалар таза-нык һәм үткен-кыю булып чыктылар.

Хәбибрахман белән минем дуслык, күргәнегезчә, бик борыннан килә. Бу дуслык һәрвакытта бик саф, бик җылы булды, аңа бервакытта да әз генә дә кер-тап төшмәде. Мәскәүгә яки Малеевкага барсам, без очрашмыйча калмыйбыз: я мин аның янына барып чыгам, я ул үзе минем янга килә. Серләребез килешә, сөйләшеп туймыйбыз — өч көн тоташтан сөйләшсәк тә, сүзебез бетмәс кебек. Ул миңа бик әйбәт киңәшләр бирә, аеруча сәламәтлекне ничек итеп саклау турында, тик мин, юньсез, аның әйткәннәрен үти генә белмим... Хәбибрахман ул гомумән бик ярдәмчел, агасы Габдрахман абзый кебек, шулай ук атасы кебек тә дип өстисем килә. Гадәттә без бит купецта кешелек сыйфаты күрергә өйрәнмәгәнбез, әмма шушы Гатаулла «купич» егерме беренче елның коточкыч ачлыгында менә нинди изгелек эшли: инде тәмам үлем чигенә килеп җиткән тол хатын Лотфия җиңгине ике малае белән үзенең йортына кертеп җылы урын бирә, ризык бирә. Ике малайның олысы, Фәтхелислам, кечесе Миңнеислам, аталары грузчик Мансур агай 1918 нче елны тифтән үлгән. Лотфия җиңги бик юаш, бик тыйнак бер хатын иде бичара! Хәерчелек баштан ашкан, җөйләре сүтек ике мендәрдән һәм сәләмә юрганнан башка һич нирләре юк — менә шуларны Гатаулла карт ач үлемнән коткарып кала.

Фәтхелислам да, Миңнеислам да минем бергә үскән дусларым иде. Һәм, билгеле инде, алар соңыннан кем булып, нинди дәрәҗәгә ирешсәләр дә Гатаулла бабайларын бер вакытта да онытмадылар. Чөнки кемгә бурычлы булуларын бик яхшы аңлыйлар иде.

Купецларның Гатаулла карт кебек ярлылыктан байлыкка ирешкәннәре рәхим-шәфкатьтән бер дә мәхрүм түгелләр иде — мин моның мисалларын ишетеп тә, күреп тә беләм. Аннары кеше нинди сынаулар аша үтә һәм ничек үтә — шуны да онытмаска кирәк. Ә Гатаулла карт сынауларның бик авырлары аша үтә. Башта ятимлек, хәерчелек, унбиш ел ялчылыкта тору, инде хәлләнеп, ныгып, баеп алгач кына зур югалтулар кичерү; бөтенесен бергә татыган, күтәрешкән җәмәгате Фатыйма абыстай 1919 елны тифтән вафат була, җитеп беткән улы һәм кызлары бер-

бер артлы үлеп китә. Бүтән берәү булса, мондый югалтулардан соң бәлки үзе дә сынар, егылыр иде. Әмма карт сынмый, егылмый. Янадан әйбәт кенә бер тол хатынга өйләнә, аңардан тагын ике кыз туа, һәм шуларны да ул кеше иткәнче тәрбияләп үстерә... Утызынчы елларның башында аны йортыннан чыгаралар, ләкин карт бүтәннәр шикелле Дәүләкәнне ташлап китми. Хәбибрахман ярдәме белән үзенә кечкенә бер өй алып, шунда тора башлый. Төнге каравылчы булып эшкә керә, көндезләрен «Заготконтора»ның атларын карый. Эш-хезмәт — аның стихиясе, күргән, татыган ул аны, шул сәбәпле «купичлыктан» кире кара эшкә күчү аның өчен зур бәхетсезлектән саналмаган... Хатыны Рокыя апай да тегү артелендә эшли, «ударница» дип аны газетага да мактап язалар. Шулай яшиләр алар. Карт сиксән биш яшенә хәтле эшли, аннан пенсия ала башлый. Туксаннан да узып китә ул! 1937 елны мин аны Кырымда күргәндә (Хәбибрахман янына кунакка килгән чагы), аңа җитмеш җиде яшь иде. Кечерәк буйлы җыйнак кына карт, иңбашлары әзрәк салынкы, кара-көрән муенында аркылы-торкылы сызыклар, шуңадыр ахрысы, ул бөтен торыш-килбәте белән каты агач тамырын хәтерләтә иде. Хәбибрахманның әйтүенә караганда, бабай бәлки йөзгә дә җиткән булыр иде, ләкин бәхетсезлегенә каршы, кышкы томанлы көннәрнең берсендә ул тимер юлы аша чыкканда поездга тапталып һәлак була... Чиканастан бәхет эзләп чыгып киткән ярлы татарның язмышы әнә шулай тәгәлләнә.

Әйтергә кирәк, Дәүләкәннең нәкъ уртасыннан узган тимер юлда моның ише фаҗигале үлемнәр ара-тирә һаман булгалап тора икән, чөнки бу юлда хәрәкәт гаять көчле, озын авыр составлар биш-ун минут саен диярлек зур тизлек белән бер-бер артлы үтеп кенә торалар. Кайткан чакларда мин моны үзем дә күреп, бик курыкканым бар. Дөрес, сугыштан соң шактый вакыт узгач, юллар аша биек тимер күпер салдылар, ләкин адәм дигәнең, күпергә менеп-төшеп йөрисе килмичә, хәтәр җирдән туры гына үтеп китәргә ярата... һәм кайчагында авыр составның ажгырып килеп чыкканын сизми дә кала...

Сүз моңарчы татар «купичларының» балалары турында барды. Алар күп һәм барысы турында язып торуның, минемчә, кирәге дә юк. Шуңа күрә мин мисал өчен үземә бик яхшы таныш булган ике күршебезнең уллары белән генә чикләндем.

Җепнең очын югалтмас өчен бераз артка чигенергә кирәктер, ахрысы... Сүз нәрсә турында иде?.. Эткол — Дәүләкәннең тарихы, аның ничек итеп үсеп-күтәрелеп китүе, анда яшәүчеләрнең кайдан килгән нинди халык булуы турында иде. Шушы уңай белән мин менә Дәүләкән купецлары турында шактый озын итеп сөйләдем. Чөнки болар миңа яхшы таныш, күбесе күршеләр, бергә аралашып яшәгән кешеләр. Аннары килеп, татар халкының кая гына барсаң да очрый торган бу төркем кешеләренең язмышы шактый гыйбрәтле, моңарчы безнең мемуар әдәбиятында юньләп чагылганы да юк, шул сәбәпле алар турында белгәннәремне язып калдыру бер дә язык булмас дип санадым. Ләкин укучыларга минем бу язганнарым бер генә яклы булып тоелмасын өчен әйтәсем килә: һәр җирдәге шикелле үк Дәүләкәндә дә сәүдәгәрләргә караганда хезмәт ияләре, әлбәттә, берничә тапкыр күбрәк иде. Һәм ярлылар да байларга караганда һичшиксез күбрәк иде. Бер урамда яшәдек, күршеләр булып тордык, уллары һәм кызлары белән бергә укыдык, бергә уйнап үстек. Алар турында хәзергә сүз бармый икән, моның сәбәбе бер генә: мин үскәндә яшәгән хезмәт иясенең язмышында зигзаглар булмады. Революциядән соң аның язмышы бары яхшыга таба үзгәрде. Балаларына укырга, үсәргә, күтәрелергә — рәхим ит! — юллар ачык иде. Бу инде күп тапкырлар кабатланган хакыйкать. Ә китап, үзегез беләсез, күп кабатлауны яратмый, шуңа күрә гаепләштән булмасын!..

Дәүләкәннең янә бер кызыклы ягы — шушы авылга да охшамаган, кала да булып танылмаган, әмма бик җанлы сәүдә үзәгенә әверелгән җирдә күп төрле милләт халкы яши иде. Башта әйткәнебезчә, аларны бирегә әлеге Себер тимер юлы төрле яктан тартып китергән. Төп халкы башкорт, аннары татар, рус, немец, яһүд, чуваш, тагын берәм-сәрәм һәртөрле милләт кешесе — хәтта монда үз йорты белән торучы чеган дә һәм Кавказ якларыннан килеп чыккан самавырлар ямаучы чиркәс тә бар иде. Чегәннең эше-кәсебе нәрсә булгандыр, белмим, ләкин бездән артык ерак та түгел, урамга буй салынган шактый чибәр яшел йортын яхшы хәтерлим. Һәр елны бу чегән кар китеп, кырлар яшәргәч тә, ике атын киндер көймәле зур арбасына җигеп, шуңа әллә ни хәтле төеннәрен һәм бер оя бала-чагасын төяп, каядыр читтә йөрүче үз чегәннәре янына чыгып китә, бөтен җәен шулар белән бергә бер таборда уздыра, тик салкын көз җиткәч кенә яңадан үз йортына кайтып керә торган иде.

Сан ягыннан халыкның күпчелеге мин үскәндә руслар иде. Алардан кала башкорт белән татарлар, аннары немецлар һәм башкалар китә. Башта, әлбәттә, төп халык күпчелек тәшкил иткән. Ләкин читтән килүчеләр арта барган саен милли состав бик тиз үзгәрә. Кызганычка каршы, бу хактагы иске мәгълүматларны мин таба алмадым.

Дәүләкән (дөресрәге, Эткол) арта-зурая башлаганда, бу халыклар бер-берсеннән аерылыбрак утырганнар. Мәсәлән, Этколның буеннан-буена сузылган иң төп, иң озын урамында тоташтан диярлек башкортлар белән татарлар яши иде. Шул ук урамның бары югары очында гына күбрәк руслар тора. Янә тимер юлына караган чиркәү урамы — тоташы белән русныкы. Вокзал тирәсендә, Дәүләкән чокыры буендагы урамнарда да руслар күпчелек, ә менә «выгон» дигән җирдә инде руслар гына иде.

Немецларга килсәк, болар инде тимер юлның аръягында үзләренә аерым бер төбәк булып утыралар иде. Шуңа күрә бу төбәкне «нимеч ягы» дип кенә йөртә идек. Алар ягына барып чыксаң, бөтенләй икенче бер бистәгә килеп кергәндәй буласың. Монда урамнар киң, яшел чирәм, йортлары да, каралтылары да ак кирпечтән таза-матур, һәркайсында җиләк-җимеш бакчасы, ишегалларында оя-оя төрле эре чәчәкләр үсеп утыра. Бөтен җирдә тәртип, чисталык. Мин хәтта малай башым белән аларның бер йортына тәмам гашыйк та булган идем. Йорт без Чагыл тавына үтеп йөри торган урам өстендә иде. Аның бик матур чардагы да һәм вак кына пыяла өлгеләрдән торган верандасы да бар. Үзе ул ап-ак йорт, әмма нечкә бизәкләр белән сырлап эшләнгән карнизләре, тәрәзә башлары, веранда рамнары барысы да ачык сарыга буялган, шунлыктан бөтен йорт ничектер бик җиңел дә, бик нәфис тә булып күренә иде. Җитмәсә әле веранда каршындагы бакча уртасында су атып тора торган түгәрәк фонтаны да бар. Мин бу йорт янында узып кына китә алмый идем, мин туктап аңа карап торырга ярата идем, һәм үскәч, хәлемнән килсә, мин дә шушындый йорт салдырырмын әле дип хыяллана да торган идем. Билгеле, кысыр хыял иде бу, әмма матур йортларга соклану миндә шул чактан ук сакланып калмады микән?! Чөнки кай илгә, кайсы шәһәргә генә барып чыксам да, иң элек аның йортларын карап йөрү минем гомерлек гадәтемә керде дияргә ярый. Матур йорт, матур йортта матур тормыш һәм матур кешеләрне күрәсе килү — бу бит чынлап та бик мавыктыргыч!

Илленче елларның урталарында Дәүләкәнгә кайтып йөри башлагач, кайчандыр мине шул хәтле сокландырган бу йортны күреп исем китте. Аны май заводына әйләндергәннәр. Янәшәсенә таштан аран шикелле

нәрсә салып, шуның белән тоташтырганнар. Стенасын ватып, ишек уйганнар. Челтәр өлгеле верандасы юк, элекке бизәкләренең берни дә калмаган. Кыскасы, нәфис кыз шикелле йорт тәмам өтелгән, бер карчык кыяфәтенә кергән. Әйләнәсендә бидон төяп килгән арбалар, машиналар — койма буйлары, ишегалды тапталып, чүпләнеп беткән... Акылым җитмәде минем бу күренешкә... Май заводы, әлбәттә, бик кирәкле нәрсә, ләкин аның өчен Дәүләкәндә бу йорттан башка да тазарак, гадирәк берәр бина табылмас идемени? Күрәсең, гүзәллек белән нәфәсатне саклау турында уйлап караучы да булмагандыр... Материаль ихтыяҗга матурлык киртә була аламыни?! Билгеле, юк.

Немец малайларын бик усал дип әйтә торганнар иде. Урамнарына барып чыккан чит малайларны гел тукмап җибәрәләр, имеш. Ләкин без үскәндә алар ягыннан күпме үтеп йөрсәк тә, «нимеч» малайлары белән бер вакытта да очрашырга да, бәрелешергә дә туры килмәде. Гомумән, очрамыйлар иде, кайда алар, нишлиләр — ходай белсен! Тик ике катлы ак кирпеч мәктәпләре яныннан узганда, шуның иркен ихатасында бик пөхтә киенгән немеч балаларының артык шауламыйча гына таган атынуларын яки куышып уйнауларын күреп китә идек. Зурлары, күрәсең, тегермәндә яки хуторда эштә булганнардыр инде. Алар безнең кебек бушка урам таптамыйлар иде.

Әйе, немецлар башка халык иде. Иң зур тегермәннәрнең хуҗалары — алар, төрле сәүдә фирмаларының хуҗалары — алар, хутор биләп, зур мәйданнарда иген игүчеләр дә алар иде. Революциягә кадәр ул шулай булган, революциядән соң байлары кая киткәндер — ул кадәресен белмим. Әмма калганнары һаман әле үзләренә аерым бер төбәк булып яшиләр, гыйбадәтханәләре дә, мәктәпләре дә аерым — бары үзләре өчен генә. Башка халык белән аралашу, йөрешү юк иде бугай. (Билгеле, эш, алыш-биреш мөнәсәбәтеннән башка.) Һәм гаҗәп хәл: шушы «өстен» милләтнең бер чибәре белән миңа шулай да бераз гына «гулять» итеп алырга туры килде.

Читкә чыгыбрак булса да, мин бу вакыйганы сөйлим әле — бер төрләндереп алу зарар итмәс, югыйсә сизәм: «хикәятнамәм» бик коры бара кебек.

Бу «роман» дип әйтик инде, мин егет булып, Казаннан Дәүләкәнгә кайтып йөргән чакларда, ягъни 1927—28 елларда булып алды. Кыз Лида исемле иде. Әгәр ул «нимеч ягында» торса, билгеле, бернинди очрашу да, танышу да булмаган булыр иде. Ләкин аның әтиләре татар-башкорт ягында, тагын да төгәлрәк әйткәндә «Якорь» тегермәне янында торалар иде. Ә «Якорь» тегермәне — ул немецлар Димне буып салдырган иң зур, иң мәшһүр тегермәннәрнең берсе. Ихтимал, Лиданың әтисе заманында тегермән хуҗаларының берсе булгандыр, әмма совет вакытында инде ул шунда белгеч — мастер буларак эшли иде. Торган йортлары да аларның бик шәп таш йорт. Янә килеп, шул ук тегермән территориясендә безнең Гөлсем исемле бер «артисткабыз» — назлы гына кызыбыз да тора иде. Һәм шунда ук «кызыл почмак» дип аталган зур гына бүрәнә йорт та бар — без татар яшьләре менә шул йортка җыелыш-мазарга баргалыйбыз. Билгеле, ул чакта әле безнең арада бернинди немец кызы да, рус кызы да булмый торган иде. Ләкин шулай да теге Лида дигән «нимеч» чибәре безнең килеп-китеп йөргәнне һаман күргәли икән. Һәм, ни сәбәптер, шул чакта аның күзе миңа төшкән. Гөлсемнән, кызыксынып, бу егетегез кем дип сораган, аннары бер дә кыенсынып тормыйча үзе белән таныштырырга да кушкан. Шулай итеп, Гөлсем безне таныштырды.

Хуш, шуннан соң ни булды? Бик яхшы хәтерлим: иң беренче эш итеп без, Лида теләге белән, Димдә өчәүләп көймәдә йөрдек. Мин ашыкмыйча ишләп кенә ишәм, Лида каршымда утыра, ә Гөлсем көймәнең иң түрендә, гүя безгә игътибар итмәгән булып, авыз эченнән әкрен

генә нидер көйләп бара. Ул безнең җыр яратучан бер моңлы кызыбыз иде. Лиданың өстендә ак ефәктән юка гына кофта, кара юбка, аягында нәрсә иде — хәтерләмим. Күзләрем — гел аның йөзендә. Әйтергә кирәк, ул бер дә немец кызларына охшамаган иде. Немец кызлары бит гадәттә я аксыл, я җирән чәчле булалар, ә бу нәкъ чегән кызыдай чем кара чәчле, нечкә кара кашлы, кара энҗедәй кечерәк кенә күзле, әмма йөзе сөттәй ап-ак һәм бик чиста да иде. Әлбәттә, ул бик матур, бик нәфис кыз иде — биле дә чегәннәрнекедәй нечкә, күкрәкләре дә тулы гына. Хәтта колагындагы алкалары да чегән кызларыныкы шикелле зур түгәрәк алкалар иде. Мондый сылу белән минем әле беренче танышуым, шуңа күрә миңа аның алдында үземне «тота белү» бер дә җиңел түгел. Бигрәк тә русча тел зәгыйфьлеге мине бик «изә» иде. Лида, шуны сизгәндәй, күбрәк үзе җанланып нидер сөйләнә, ә мин тырышып-тырышып ишүемне генә беләм. Биргән сорауларына да баш кагып, «да», «нет» белән генә чикләнәм.

...Кызларымны мин «Кара яр» ерымы аша Димнең үренә алып чыктым. Бераз бара төшкәч, анда елганың киңәеп киткән бик матур урыны бар иде. Күпме генә килеп йөргән урын булмасын, әмма матурлык ул күргән саен барыбер сокландыра. Кызларым да бик куандылар, мин ишүдән туктадым, көймәне агым ихтыярына куйдым. Тирәягыбызга каранып, сокланып, рәхәт татып утырабыз. Көймә әкрен генә яр читенә якынлашкач, Лида яңа гына ачылган ап-ак эре төнбоек чәчәкләрен озын саплары белән бергә судан суырып-суырып алды. Төнбоек чәчәкләре суда чакта бик матурлар, әмма өзгәч, алар бик тиз шиңәләр... Кыскасы, без көймәдә бик күңелле йөреп кайттык.

Шуннан соң?.. Шуннан соң без тагын берничә тапкыр очраштык, кичен читтәге буш урамнарда йөрдек, айлы төндә берәрсенең капка төбендәге куләгә караңгылаган эскәмиясендә иңне-иңгә терәбрәк утырдык. Минем бәхеттән кызым шат күңелле иде. Сөйләнә, көлә, шаярта, кыскасы, бер дә «скучать» итми иде. һәм миңа да инде аның көенә җайлашып, үземне беркадәр хөр тотарга, көләргә, хәтта, сүзен табып, көлдереп тә алырга туры килә. Дөрес, башта ук бер нәрсә минем өчен бик ачык иде: бу очрашып йөрүләрнең җитди төс алуы, бик тирәнгә кереп китүе һич тә мөмкин түгел. Аерма бик зур. Асылда Лида өчен бер татар егете белән «йөреп карау» ул кызыклы мавыгу гына булырга тиеш иде. Мин моны ничектер сизә идем һәм үземне аңа һич тә тиң кеше итеп санамый идем. Шуның өстенә әле мин үзебезнең егетләр һәм кызлардан да шактый уңайсызланам. Белә калсалар, берәүләре: «Әмир әнә кем белән чиерттерә икән, малай!» — дип көләчәкләр, ә икенчеләре, ихтимал, каты гына хөкем дә итәрләр иде. Ул елларда үтә актив комсомоллар берәр егет белән кызның, коллективтан аерылып, ялгыз йөрүләрен бер дә яратмыйлар иде.

Әмма кыз әйбәт, кыз матур, кыз яратырлык иде, ләкин инде минем тиздән китәр вакытым да килеп җитте. һәм шул чагында немец кызы тагын бер көтелмәгән кыюлык күрсәтте: бик киенеп, көязләнеп, җитмәсә сеңелесен дә ияртеп, ул мине озатыр өчен вокзалга килде. Берәүдән дә — озата төшкән атам-анамнан да, якын дусларымнан да һич тартынып тормыйча, аларны шактый хәйранга калдырып, минем белән килеп күреште, бик мөлаем итеп хәерле юл теләде, кулындагы бердәнбер куе кызыл чәчәген дә миңа сузды: «Казанга барып җиткәнче ташламагыз!» — диде. Поезд кузгалып киткәндә дә ул минем якыннарым арасында, булачак кәләшем шикелле, кечкенә ак кулъяулыгын селкиселки озатып калды. Мин белә алмаган, мине бик гаҗәпләндергән әнә шундый кыз иде ул Лида!

Икенче елны кайтсам, туташым кияүгә чыккан икән ләбаса! Шулай диделәр дусларым миңа... Кайчан, кемгә?.. Кемгә булсын, бер немец егетенә, билгеле... Бу хәбәр күңелемне бик тырнады тырнавын, әмма

артык гаҗәпләндермәде. Ләкин болай ук тиз булыр дип һич тә көтмәгән идем. Әле чибәр-сылу кыз белән тагын матур гына йөреп калырмын дигән өметем бар иде. Мин бит инде бер яшькә булса да олаеп, үсә төшеп, шәһәрчә әйбәтләнеп (сүзгә дә бераз остарып) кайткан идем. Кызлар белән бик йөрисе килгән чак, алай гына түгел, үземә «яр табу» турында уйлана, эзләнә дә башлаган чак, ләкин ни хикмәттер, миңа уңышсызлык артыннан уңышсызлык килә дә тора. Кече яшьтән үк мине күпме саргайткан Һаҗәр дә былтыр ук бер Ыслак егетенә иярде дә китте, инде менә үзе башлап миңа күз аткан кызым да тоткан да үзенең «нимеченә» чыгып куйган. Их, ышан син бу кызларга!

...Шулай да без очраштык. Бик тын, җылы бер төн иде. Танырдай кеше күзенә күренмәс өчен без башкорт Дәүләкәненең иң читтәге аулак урамында озак кына йөрдек. Кемнеңдер коймасы буендагы косаркыга (печән чапкычка) туры килеп, шуның калай идәненә утырып та тордык. Лида кияүгә чыгуын бик җиңел аңлатты: «Вакыт җитте, шуңа күрә чыктым»,— диде. Мин: «Нигә мине көтмәдең?» дигән булдым. «Ә син көтәргә куштыңмы соң?» диде ул, шелтә белдергәндәй итеп. Әйе, хак сүзгә җавап юк!.. Ләкин кузгалыр алыннан Лида үзе миңа сарылып, кайнар сулап: «Әйдә, һич югы бер үп мине!» диде. Бу безнең иң беренче һәм иң соңгы бик дәртле, әмма гөнаһсыз үбешүебез булды. Шуннан соң мин тиле бәрән орлыгы ашаган малай кебек кыек-мыек атлап, бәхет дигән нәрсәне нинди җиңел табып та һәм югалтып та була икән дигән уйдан хәйран калып үзебезнең очка кайтып киттем.

Икенче көнне без, татар яшьләре, Бәлдәй йортына репетициягә җыелган идек. Шул чакта кемдер кереп миңа: «Әмир, сине тышта көтәләр»,— дип әйтте. Кемнәр дип сорагач, серле генә итеп, чыккач күрерсең, диде. Мин бераз аптырап, ләкин аны-моны уйламыйча чыксам, клуб ишеге төбендә өч егет басып тора. Бик яхшы киенгән таза егетләр. Берсе — ак чырайлы, саргылт чәчлесе — буйга да озынрак, күкрәкҗилкәгә дә киңрәк... Мин шунда ук аларның немец егетләре икәнен сизеп алдым. Әлбәттә, яхшы ният белән килмәгән болар дип уйладым, эчемә салкын курку да йөгерде, ләкин кире борылып кереп китмәдем. Озын буйлысы миңа беравык туп-туры карап торганнан соң, кырыс кына сорады: «Ты Амир?» — «Да, я Амир!» [1] — дидем мин... Шуннан соң ни булды? Шуннан соң берни дә булмады. Егетләр тагын бераз миңа карап тордылар да, артык бер хәрәкәт тә ясамыйча, борылып киттеләр дә бардылар. Мин бу эшкә бик гаҗәпләнеп, баскан урынымда торып калдым. Өч егетнең озын буйлысы һичшиксез Лида кияве булырга тиеш иде бит... Берниндн янау юк, кул күтәрү юк, ни өчен генә ике иптәшен ияртеп килде икән ул?! Хәер, мин моның серен тиз аңладым: аңа мине күреп, танып китү кирәк булган — менә ни өчен килгән ул!.. Һәм мин дә моны хәтәр бер кисәтү дип аңларга тиеш идем. Әйе, хәзергә алар миңа тимәделәр — чөнки көпә-көндез клуб алдында кеше кыйнап китү — үзе куркыныч эш, әмма бер күреп, танып киткәч, моның өчен башка уңай җае чыкмасмыни?!

Кыскасы, шушы вакыйгадан соң Лида белән очрашу бетте, өзелде. Икебез өчен дә ул кирәкми һәм ярамый иде. Лида өчен бигрәк тә... Дөрес, бу «өзелешү» минем күңелдә үкенү хисе катыш ниндидер бер ямьсез юшкын да калдырды, әмма нишләмәк кирәк?! «Романның» ахыры башыннан ук билгеле иде инде.

Ләкин Лида белән очрашулар бетсә дә, соңыннан миңа аның хакында кайбер нәрсәләр ишетергә туры килде. Иң элек мондый бер хәл: шул ук 1928—29 елларда булса кирәк, хутор биләүче һәм Дәүләкәннең үзендә торучы күп кенә немец семьялары дәүләт органнарының рөхсәте белән Германиягә яки Америкага күчеп китә башладылар. Шул чак-

[1] Дәүләкәндә бөтен яшьләр мине «Әмир» дип кенә йөртәләр иде ул чакта.

та Лиданың кияве дә ата-анасы белән бергә океан аръягына китеп бара. Ә Лида йөкле булганга күрә эти-әниләрендә (алар беркая да китмиләр) калып тора. Кияве исә аны соңрак кайтып алырга тиеш була. Ләкин инде ул яңадан безнең якларга кайта алмаган, чөнки бер киткәч, кире кайтулары мөмкин булмаган, күрәсең. Шул рәвешчә Лида Дәүләкәндә бөтенләйгә торып кала. Кем белә, бәлки үзенең дә китәсе килмәгәндер. Дим буйлары аның да туып-үскән җире, эти-әнисе янында, баласы да бар, әллә кайдагы билгесез илгә чыгып китү нигә кирәк аңа?.. Хәер, белеп әйтүем түгел, миңа бит боларның берсен дә аның үзеннән ишетергә туры килмәде.

Еллар узды, күп нәрсәләр еракта калды — онытылды, кемнең генә тормышында нинди генә үзгәрешләр булмады. Әмма шулай да язмыш дигәнең тагын бер мәртәбә Лиданы минем исемә төшерде.

...Хәтерлисездер, бу язманың башында мин үземнең алма исе аңкып торган айлы төндә Дәүләкәнгә кайтып төшүемне язган идем. Күпме еллар узгач, беренче кайтуым... Мин төн уртасында таныш урамнар буйлап йөрдем, үзебезнең йортны барып карадым, ә икенче көнне иртән базар янындагы ашханәгә ашарга кердем. Ашханәнең мөдире миңа бик якын кеше — тимерче Миңлегалим бабай кызы Мәһирә булып чыкты. Без кече яшьтән үк бер-беребезне беләбез, күршеләр булып тордык, озак еллар бергә аралашып, бергә йөреп үстек... Ләкин ашханәдә беренче мәртәбә очрашкач Мәһирә мине танымады. Йөземә карап торып та таный алмады. Тик исемемне әйткәч кенә исе-акылы китте. Димәк, чирек гасыр эчендә без никадәр үзгәргәнбез икән (хәер, мин үзем Мәһирәне күрү белән үк танудым). Әмма хикмәт шунда ки, безнең бер өстәлдә бик җанланып, шатланып сөйләшүебезне ашлар бирә торган тәрәзәдән янә бер хатын карап торган. Ул хатын Лида булган!.. Шушы ашханәнең повары икән ул. Ләкин мин аны күрмәдем, беренче керүемдә дә, соңыннан атна буена кереп, ашап чыккан чакларымда да күрмәдем. Билгеле инде, аның шушында, әнә кухня эчендә генә булу ихтималы минем башыма да килмәде. Килүе мөмкин дә түгел иде. Ә ул мине күргән,— күргән һәм таныган! Ләкин мин чыгып киткәч, Мәһирәгә бик нык кисәтеп әйткән, зинһар өчен, минем монда икәнемне аңа әйтә күрмәгез, дигән һәм Мәһирә миңа әйтмәде, һәм мин берни белмичә китеп тә бардым. Гүя урман эчендә янәшә генә узган кешене күрмичә үткән шикелле — ни үкенеч!.. Бары тик икенче тапкыр кайтуымда гына Мәһирә миңа бу хәлне көлеп сөйләде. Әмма бу вакытта Лида Дәүләкәндә юк иде инде, каядыр Украинага, кияүдәге кызы янына киткән булып чыкты. Әйе, язмаса язмый икән ул! Мәһирә сөйләгәннәрдән миңа бик ямансу булып китте, теге вакытта Лиданы миннән яшергәне өчен үзенә хәтерем дә калды. Шул чакта әйткән булса, мин Лиданың үзенә сиздермичә генә аңа карый алган булыр идем. Ләкин соңыннан инде, тынычлана төшкәч миндә: «Ә бәлки Лида күренмичә дөрес тә эшләгәндер» дигән уй туды. Һичшиксез, ул да үзгәргәндер, нык үзгәргәндер, ә хатын-кыз үзенең никадәр үзгәргәнен бик яхшы белеп тора ул. Инде менә күрмәгәч, ерак яшьлектәге гүзәл-сылу немец кызы, Дим читендәге нәфис ак төнбоек чәчәгедәй, минем хыялымда һаман да әле саклана...

Ярый, миңа бер юаныч, ә укучыга азрак ял биргән бу сагышлы истәлектән инде кире төп мәсьәләгә кайтыйк. Сүз бит Дәүләкәндә яшәүче төрле милләтләр турында бара иде. Әйткәнемчә, мин үскән елларда халыкның күпчелеге руслар иде. Байлары да күбрәк, һәм алар татар купецларына караганда байлык җәһәтеннән күп өстен, көчлерәк тә булганнар (бигрәк тә ашлык җыеп озатучылары). Зур, таза йортлар, ишегалды буйлап сузылган амбарлар, тотып тыя алмаслык шәп аргамаклар аларда иде. Әле революциядән соң масленица бәйрәмендә аларның киң-тирән кашовкаларга тәңкәле сбруйлар белән җигелгән тройка

яки пар атта урам буйлап буран уйната-уйната чапканнарын минем үземә дә күрергә туры килгән иде. Рус байлары арасында бик каралары, бик усаллары да булган (мәсәлән, Костюриннар турында шулай дип сөйлиләр иде), ләкин андыйлары гражданнар сугышы вакытында аклар белән сызганнар булса кирәк. Һәрхәлдә, мин аларны күреп белмим, бары ишетеп кенә беләм.

Шулай ук русның хезмәт иясе дә байларына караганда күбрәк иде. Болар тегермәннәрдә һәм тимер юлда эшләүчеләр, төрле хезмәткәрләр белән вак һөнәрчеләр... Янә килеп, күпмедер интеллигенциясе дә бар иде: гимназия укытучылары, врачлар, конторщиклар әнә шундыйлардан. Кыскасы, төрле милләт халкы җыелган Дәүләкәндә руслар күбрәк тә, өстенрәк тә, һәр җәһәттән алдынрак та иде. Шуңа күрәдер инде, монда унҗиденче елның революция вакыйгаларына иң актив катнашучылар да башлыча алар булган. Совет властен контрреволюциядән яклар өчен кораллы отрядны да алар оештырган. Дәүләкән Советының беренче председателе итеп Николай Кириченко дигән кеше сайланган. Гражданнар сугышы башланып киткәч, Дәүләкән аша да сугыш өермәсе узган, берничә тапкыр кулдан-кулга да күчкән ул, һәм, билгеле инде, бу каты, канлы көрәштә корбаннар да аз булмаган. Вокзалдан ерак түгел, кечкенә бакча эчендә алар күмелгән туганнар кабере бүген дә бик әйбәт сакланып тора. Кыскасы, революция вакыйгаларына катнашкан рус иптәшләрнең корбан киткәннәре дә һәм исән калганнары да мәгълүм — аларның берсе дә онытылмаган. Район газетасы «Знамя» битләрендә төрле бәйрәмнәр уңае белән алар турында истәлекләр дә басылып чыккалый. Бу — гүзәл эш. 1981 елның июнь аенда райкомның элеккеге беренче секретаре иптәш Тартыковның Дәүләкән тарихын яктырткан һәм берничә номерга сузылган шактый бай материалы басылган иде. Бу материалда да без шул ук революция каһарманнарын күрәбез. Революция вакыйгаларыннан бер халык та читтә торып калмады. Билгеле, һәр халыктан агы да, кызылы да, хәтта яшеле дә булды диярлек. Дөрес, мин үзем күрдем, беләм дип шаһитлек итә алмыйм, чөнки ул чакта 7-8 яшьлек малай гына идем әле. Малай чак өчен бер елның да аермасы бик зур. Мәсәлән, унҗиденче елны бик томанлы гына хәтерләсәм, унсигезенче елны инде шактый ук ачык искә төшерә алам. Шулай да Дәүләкәндәге революция вакыйгаларына катнашкан берничә татар кешесе миңа да мәгълүм — кайсын ишетеп, кайсын үзем күреп беләм. Шуларның берсе Нәбиулла Кәримов кияве Закир Мөхәмматҗанов. Күпереп торган кара мыеклы, тулы ак йөзле бу мәһабәт чибәр кеше унсигезенче елның җәендә Советка икмәк җыяр өчен продотряд белән авылларга чыгып китә. Отряд зур булмый — бары биш-алты кешелек кенә... Мәсәй дигән шактый эчкәре бер типтәр авылына баргач, җыенга (сходка) чакырылган халык, кулаклар коткысына бирелеп, боларның барысын да кыйнап үтерәләр. Котырган, кайнаган халык эчендә алар, күрәсең, коралларын ходка җибәрергә дә өлгерә алмыйча калалар. Дәүләкәнгә хәбәр килеп житә, һәм шунда ук яхшы коралланган зуррак отряд Мәсәйгә барып, канлы җинаятьне башлап җибәрүчеләрне чүплә, җыеп та ала. «Канга кан!» — дошманга хөкем ул чакта бары шулай гына булган. Үтерелгән продотрядчыларның гәүдәләрен Дәүләкәнгә алып кайтып, вокзал янындагы әлеге туганнар каберенә бик зурлап күмәләр. Тик шулардан Закир Мөхәмматҗановны нигәдер аерып, шәригать кушканча җеназалап, мөселман зиратына җирлиләр. Бәлки шуңа күрә дә аның исеме онытылып, әлеге истәлекләргә керми дә торгандыр?! (Дәүләкәннең ул зираты күптән бетерелде, аның өстенә урам-урам йортлар салынды).

Революция вакыйгаларына якыннан катнашкан икенче бер кеше — бу Борһан купец приказчигы Кәрим Сабиров. Митингларда еш кына сөйләгән, әйбәт оратор булган, диләр. Ләкин шуңардан башка ул та-

гын кем булган, нәрсә эшләгән — бу кадәресен тәгаен генә белеп әйтүчене мин таба алмадым. Хәзерге истәлекләрдә аның исеме дә юк. Хәлбуки, кайбер танышларымның әйтүенә караганда, Кәрим Сабиров егерменче елларның башында волисполком председателе булып торган икән. Бу инде, әгәр дөрес булса, Дәүләкәндә беренче урындагы кеше дигән сүз. Әмма ни өчен «онытылган» соң ул? Бәлки моңа аның фаҗигале үлеме сәбәптер?.. Елын ачык кына хәтерләмим, һәрхалдә җәй көне булган эш. Кәрим абзый Дим буендагы Казангол авылына барып чыга. Төшкән кешесендә (аны Исхак мулла дип сөйләгәннәр иде) ашап-эчкәннән соң, хуҗаның атын җигеп, болынга китәләр. Күе үлән ат корсагына җиткән болын юлында күпмедер вакыт хозурланып йөргәч, бер җирдә туктап, түгәрәк «табын» итеп кенә печән чабалар, шуны кочак-кочак җыеп, арбаларына төйиләр дә кире борылалар. Кайтканда Кәрим абзый дилбегәне үзе тота. Ләкин күрәчәгенәдер инде, башкортның шактый чыгымчы аты ишегалдына килеп кергәндә генә нәрсәдәндер өркеп китеп, арба күчәрен капка баганасына эләктерә дә боларны йөге-ние белән аударып та җибәрә. Хуҗа читкә сикереп өлгерә, ә дилбегә тоткан Кәрим абзый үткен чалгы өстенә эче белән килеп төшә. Аны шунда ук арбага салып Дәүләкән больницасына китерәләр, ләкин кызганычка каршы, врачлар берни дә эшли алмыйлар, чөнки Кәрим абзыйның ярасы бик тирән булып чыга, һәм озак та тормыйча ул шунда җан да бирә. Яшь иде әле Кәрим абзый, күп булса, утыз биш-ләр тирәсендә генә булгандыр. Миңнекамал исемле бик сөйкемле хатыны һәм миннән күпмегәдер яшьрәк Суфия исемле чибәр генә кызы торып калды. Соңрак мин аларга барып та йөрдем. Аларда бер вакытны Хәлил Наилский дигән артист торды — менә шуның янына баргалый идем мин... Бу хакта чираты җиткәч сүз булачак әле.

Дәүләкәндәге революция вакыйгаларына күпмедер катнашы булган татар кешеләреннән мин монда мисал өчен үзем белгән ике генә исемне телгә алдым. Әгәр казына-тикшерә башласаң, аларны шактый табып булачак. Ләкин бу инде күп вакыт сорый торган үзенә аерым бер эш. Мин исә бары үзем күргән-белгәннәр белән чикләнергә мәҗбүрмен. Шулай да әйтәсем килә: Дәүләкәнгә җыелган төрле милләт халкы, диннәре, телләре төрле булуга карамастан, бер үк җирдә бергә аралашып яшәгәннәр. Хезмәт, сәүдә, алыш-биреш, кыскасы, тормыш үзе аларны даими бәйләнештә тоткан. Дөрес, патша вакытында милли тигезлек булмаган, һәм бу хәл алар арасындагы мөнәсәбәтләрдә дә чагылмыйча калмаган. Русның шовинист байлары, чиновниклары, стражниклары, динчеләре, татар, башкортны еш кына кыерсытканнар, алдаганнар, хәтта мәсхәрәләгәннәр дә. Кайчандыр элек әнә шулай булган... Инде минем балалык хәтеремдә менә мондый бер күренеш саклана: яз башы, бик якты кояшлы көн, Эткол урамыннан мәчеткә таба сафларга тезелгән шактый халык байраклар күтәреп, эреп боткадай саргайган карны ера-ера, узып бара. Иң алдан яхшы киемле ниндидер таза кешеләр белән бергә кама тун өстеннән яшел чапан кигән, башына кызыл түбәле ак чалма ураган очлы сакаллы безнең мулла бабай да салмак кына атлый. Ә сафларның ике ягыннан күзләре тонган малайлар көтүе бата-чума йөгерә. Менә шундый бер тамашаны мин авызымны ачып, үзебезнең капка төбеннән карап калдым. Нинди тамаша икәнен, әлбәттә, аңламадым, тик шул ук көнне бик дәртләнеп кайтып кергән атакайдан: «Патшаны төшергәннәр ләбаса!» дигән сүзне ишеттем. Халыкның нәмаешка [1] чыгуы әнә шул уңай белән булган икән.

Ә менә Октябрь вакыйгалары безнең Дәүләкәндә ничегрәк узганын бер дә хәтерләмим. Кеше атлый алмаслык пычрак, салкын көз булган-

[1] Демонстрацияне ул елларда «нәмаеш» дип язалар иде. Ә. Е.

га күрәдерме, халыкның урамга чыгып, байраклар күтәреп йөргәнен дә белмим — күрмәдем. Әмма ләкин, бу чын революция Дәүләкәнгә әнә шулай сизелмичәрәк килсә дә, аның әһәмияте һәм нәтиҗәсе гаять зур булган икән. Дустым Хәбибрахман әйтә (ул миннән өч яшькә олырак): «Октябрь көннәрендә без иң элек милли изелүдән котылуыбызны сиздек — менә шуның шатлыгы бүген дә әле минем хәтеремдә саклана!» — ди. Ә бит Октябрь революциясе милли азатлык белән бергә хезмәт ияләренә иҗтимагый азатлык та китерде. Бәс шулай булгач, бу азатлык өчен көрәштән Дәүләкәннең татары һәм башкорты читтә торып кала аламы соң?! Әлбәттә, юк!

Ярый, яңадан үзем күргәннәргә кайтыйм әле. Хуш, мин үскәндә — ягъни егерменче елларның башында — малайлар арасындагы «милли мөнәсәбәтләр» ничегрәк иде соң?.. Дөресен генә әйткәндә, бик үк татудан түгел иде. Мәктәпләр аерым, укулар аерым, бергә аралашып йөрү, уйнаулар да юк иде. Рус малайлары күбрәк чиркәү урамында һәм Эткол урамының югары очында торсалар, без инде шушы урамның мәчеткә якын өлешен һәм түбән очын «биләп» тора идек. Тел киртәсе дә көчле иде әле, татарча гына укыгач, русча белүебез «кәлә-мәлә»дән узмый иде. Аннары борыннан сакланып калган «милли дошманлык» та (хәзергечә әйтсәк, антогонизм да) үзен сиздергәләгәндер, күрәсең. Мәсәлән, без руслар очына барып чыксак, аларның малайлары еш кына безгә һөҗүм итәләр, инде берәр рус малае безнең тирәгә килеп чыкса, без дә аның да «өстен каккаламыйча» җибәрми идек. Гадәттә һәр якның берәр бик кыю, усал малае була — шул башласа гына бүтәннәр дә «дошман»га ташлана. Безнең якта иң кыю, иң көчле-батыр малай Арыслангәрәй агай улы Таһир иде. Үзе ул сугышырга атлыгып та тормый кебек, әмма инде бер тотынса, арысландай сугыша иде. Шулай да малайларның кайберләре катнашырга курка, бүтәннәр тәпәләшкәнне читтән генә карап тора — һәм соңыннан каршы як, ни хикмәттер, күбрәк әнә шундый «битарафларны» эләктереп алып, үчен кайтара торган иде. Ә Таһирга ялгыз очраса да тимиләр, киресенчә, еректан ук аңа «А, Тагирка!»,— дип хөрмәт белән дәшәләр. Әйе, гаҗәеп бер малай иде Таһир!.. Аңарда, ничек дим, искиткеч тән сәләте бар иде, ягъни ул корыч чыбыктай теләсә ничек бөгелә-сыгыла, үзе гаять җиңел, житез һәм көчле дә иде. Комачтан (Димнең Эткол турындагы култыгы) атларын, бияләрен эчереп менгәндә ул иң кызу-усал кола айгырның сыртына аягүрә генә басып кайта иде. Әгәр без үскәндә яшьләрне спортка тарту булса, Таһир һичшиксез башкортның берәр төрле чемпионы булган булыр иде. Югала торган егет түгел иде ул! Тик менә бер-ике ел элек кенә Таһир үлгән диган хәбәрне ишеттем. Ләкин нигәдер күңелем ышанып бетмәде минем бу хәбәргә...

Ә безнең малай чактагы «милли тәпәләшүләргә» килгәндә, ул искедән йогып калган шаукым, комсомол эшләре көчәйгәч, пионерлар хәрәкәте дә тугач, әкренләп бетте дияргә ярый. Хәер, бу вакытта инде мин Дәүләкәннән киткән идем.

Хуш, тагын нәрсә?.. Әнә тимер юл буендагы калкулык өстендә бик матур зур ак чиркәү тора, күршесендә генә комташтан салынган ике катлы гимназия. Менә шул гимназиягә рус балаларының барып-кайтып йөрүләрен мин әзрәк хәтерлим әле. Малайларның өстендә ике яклап җиз төймә тезелгән күк шинель, аркаларында иңнәре аша каешлап кигән тартма сыман күн букча, ә кызлары тар билле, киң итәкле бишмәттән (хәзергечә әйтсәк, пальтодан), муеннарына кара мехтан тегелгән кечкенә муфта диган нәрсә асып, кулларын шуңа гына тыгып йөриләр. Бу гимназия укучылары әллә инде торганы бай балалары гына иде — барысы да бер төсле, барысы да матур, көязләр. Бигрәк тә кызлары бик сылу-матур... Без — татар шәкертләре — бик чуар идек, кемдә билле бишмәт, кемдә каеры тун; аякларда я пима, я ката

(хәтта чабата да), тик бау белән аскан киндер букчалар гына бер төслерәк иде.

Аннары гимназия укучылары Димнең киң бер җирендә (Водокачка турысында) бозны кардан арчып, шунда ботинкаларына беркетелгән чын тимераякта шуалар иде. Көяз егетләрнең сылу кызларны билләреннән алып, бер үк җайга тигез-килешле генә чайкала биреп, кызу-шома гына шууларын без инде яр башыннан исебез китеп карап тора идек. Ни сәбәптер, татар малайлары арасында тимераякта шуучылар юк дәрәҗәсендә сирәк иде. Тик кайберәүләр генә конькига охшатып юнган агач астына калын тимер чыбык сузып, шуны калын бау белән пимага боргычлап бәйләп, чана юлында шуып азапланалар иде. Мин чын конькины хәтта «купич» малайларында да күрмәдем. Аның каравы, без текә яр башыннан үрәчәсез чаналарда җил уйнатып шуа торган идек. Узыша-узыша — кем ераккарак оча!..

Янә килеп, русларның бәйрәмнәре бик кызыклы була торган иде. Иң элек һәр бәйрәмдә чиркәү чаңнары авыл өстендә өзлексез яңгырап тора. Һәм бу иң калыныннан алып, иң нечкәләренә хәтле алмаш-тилмәш яки бөтенесе бергә яңгыраган чиркәү чаңында нииндидер бер тылсым бар кебек иде. Хәтта минә минем вәсвәсәдән бик курыккан күңелдә дә ул чаң авазлары тантаналы да һәм ямансу да сәер бер тойгы уята иде. Шуңадыр ахры, мин яшьтән үк чиркәү чаңнарын ирексездән шомланып, әмма яратып тыңлый торган идем.

Ләкин хәтердә иң нык сакланганы — бу кыш үзәгендә була торган русның крещенье бәйрәме. Каты суыклар вакыты, Дим инде бер аршын чамасы каткан да була. Иң элек әнә шул каты бозны суы чыкканчы чабып, Дим өстенә зур бер тәре ясыйлар. Тәренең аяк очында түгәрәк бәке уялар. Чиркәүдән иконалар, хоругвьлар, тагын әллә ниләр күтәреп чыккан халык һәм поплар Иордан тыкырыгы буйлап боз өстенә төшәләр. Шуннан соң озак та үтми, пар ат җиккән тирән кошевкада зур толыпка төреп салган көрәк сакаллы бер русны боздагы тәре янына китерәләр. Шыр ялангач рус бабайны, толып эченнән чыгарып, бер кулына элмәкләп бау кидерәләр дә тәре очындагы әлеге түгәрәк бәкегә өч тапкыр чумдырып алалар. Салкын судан тартып чыгаргач та аңа стакан тутырып аракы бирәләр, шунда ук яңадан чанага салып, зур калын толыпка (дохага) әйбәтләп урыйлар. Өстенә тагын бер толып ташлыйлар, шуннан соң парат аны каядыр чаптырып алып та китә.

Бу тамашаны мин берничә кыш рәттән үз күзем белән күрдем. Дәүләкән бәләкәй җир, чиркәү дә бездән ерак түгел, шул сәбәпле рус бәйрәмнәрен гел генә күреп үстек. Русның зур бәйрәмнәре — масленица, пасха, троица — барысы да бик җанлы, кызыклы була торган иде. Әмма иң кызыклысы әнә шул шәрә картны чатнама суыкта бәкегә батырып алу иде — без малай-шалай, катып-туңып бетсәк тә, бу тамашаны күрмичә китми идек.

Инде сүз ахырында мондый бер вакыйганы да искә төшереп үтик булмаса. Вакытында Дәүләканне озак шаулаткан шактый хикмәтле нәрсә ул! Эш болай: безнең урамда, Зариф абзыйларның ишегалдындагы бәләкәй өйләрендә Хәдичә исемле диндар гына бер тол карчык ике кызы белән тора иде. Ә Миһран исемле аның житкән улы Меделанский дигән зур бер рус баенда кучер булып эшли. Меделанский читкә ашлык җыеп озатучы, шул сәбәпле ул еш кына Мәскәүгә яки Петербургка китеп торгалый икән. Монда, йорт саклап, бик тулы да бик алсу яшь хатыны кала. Яшь хатынның күз алдында көн саен кара сфәк мыеклы, яшь имәндәй таза егет ваемсыз гына эшләп йөри. Һәм ялгызлыктан интеккән хатын егеткә карап җан тынычлыгын җуя башлый. Егет тә тыштан гына ваемсыз икән, ә эченнән аның да хыялы ак калачтай хатында, имеш! Ситуация, үзегез дә күрәсез, шактый хәвефле. Әмма нәфес дигәнең коточкыч нәрсә бит ул!.. Кемнең генә аны

жиңә алганы бар?!. Озын сүзнең кыскасы, күпмедер вакыттан соң алар арасында яшерен «мәхәббәт» тә башлана. Кайнар мәхәббәт көннән-көн тирәнәя, тирәнәйгән саен ачыла да бара, ниһаять, халык теленә дә керә, һәм бу инде аларны шактый ук читен бер хәлгә дә куя. Ахырда хатын егеткә әйтә: «Болай ярамый бит, фаш булып беттек, безгә хәзер венчаться итәргә кирәк, мин иремне ташлыйм, ә син безнең дингә күчәргә тиешсең!» ди. Егет, йомры баш, тиз генә чамалап ала — бу бикәчкә ияреп байлык та киләчәк бит, һәм артык икеләнеп тормыйча гына риза да була. Шулай итеп, Меделанский үзе читтә чакта безнең Миһранны Дәүләкән чиркәвендә бик тантаналы рәвештә чукындырып та куялар. Исемен дә ансат кына Миронга әйләндерәләр һәм шуннан соң «православный» Миронны православный Мария белән «венчать» та итәләр. Бу эшнең чиркәү таләп иткән кагыйдәләре нинди булгандыр — вакыйганы сөйләүчеләр белмиләр. Әмма Миһранның чукынуы да, рус хатынына өйләнүе дә дөрес, булган эш.

...Бер заманны карт бай Меделанский Дәүләкәнгә кайтып төшә, ләкин өендәге хәлләрне белгәч, көне-сәгате белән кире Петербургка китеп тә бара. Әйтәләр, байның пайтәхеттә үз сөяркәсе булган, диләр. Бәлки дөрестер дә, чөнки мондагы йорт-җирен һәм хатынын алай җиңел генә ташлап китмәс иде. Әмма ничек кенә булмасын, чукынган татар рус баеның хатынына да, йортына да, мал-мөлкәтенә дә полный хуҗа булып кала, хәтта Меделанский дигән фамилияне дә үзенә ала. (Мирон Меделанский! — начар түгел бит?!) Дәүләкән күләмендә бу шаккаттыргыч бер вакыйга була, шау-шуы да аның берничә айга сузыла.

Ә Хәдичә карчык ничек соң, ул, бичара, ни хәлдә? Башта ул һич тә ышанмый, ә ышангач, чак җаныннан аерылмый. Улы (Миһран) килгәч, карчык сыгылып төшеп сорый икән:

— Әй, улым, улым, чынлап та чукындыңмыни?

— Пока гына,— дип әйтә икән Миһран, гармушкалы итекләре белән идән буйлап шыгыр-шыгыр йөри-йөри.

— Ни дигән сүзең ул?

— Ну, вакытлы гына.

— Вакытлы гына буламыни?

— Була, инәй, кирәккәч була!

Һәм карчык бу сүзләрдән ничектер тынычлана төшә, күршеләренә дә: «Миһранның иманы эчендә, тыштан гына ул урыс булып йөри» дип сөйләнеп, үзен-үзе юата да икән.

Ә көннәрдән бер көнне Миһран атлас-ефәкләргә төренгән, хушбуй исләре аңкып торган ястыктай тулы-йомшак «киленне» әнисенә күрсәтергә дә алып килә. Җитмәсә әле татарча дәшәргә дә өйрәткән.

— Дорогая инай! — ди икән «килен», кечкенә карчыкка бик ягымлы елмаеп.

«Инай» сүзе халык арасында да тарала. Әгәр марҗа киленне күрсәләр, «әнә инай килә» дип көләләр икән.

Әнә шундый вакыйга булып ала Дәүләкән «каласында». Революция алдыннан була бу эш, ә менә революциядән соң Мирон Меделанский ни эшләгән, байдан калган йортын, хатынын нишләткән, кая куйган — шуны миңа ачык кына белеп әйтүче булмады. Хәер, байлык өчен чукынучылар аз югалдымыни ул заманда?!

Инде бик озынга киткән бу бүлекне Дәүләкәннең төп халкы башкортлар турында язып тәгәллисе килә. Моңа мин бик теләп керешәм, чөнки башкортны яхшы ук беләм дип әйтә алам. Рәттән утырган өч күршебезнең икесе башкорт иде. Үнда Миңнегәрәй агай (аңа хәтле Сылубикә җиңгәй), сул ягыбызда Борһан купец аша гына Арыслангәрәй агай йорты. Миңнегәрәй агай белән исә бер ишегалдында торып, бер капкадан йөрдек... Хәтерләсәгез, «Каргалы» өлешендә дә мин безнең бабайларның борыннан ук башкортлар белән аралашып һәм йөре-

шеп яшәүләрен язган идем. Дәүләкәндә инде бу читтән торып аралашу гына түгел, ә бер үк җирдә бер халык булып диярлек яшәүгә әйләнгән иде. Дин бер, тел бик якын[1], бер үк мәчеткә йөриләр, бер үк мәктәпләрдә укыйбыз. Аерма юк иде дип әйтергә җыенмыйм, аерма — исемнәрендә үк, хәтта каршылыклар да юк түгел, әмма Дәүләкән шартларында бу ике халык бер-берсе белән бик тыгыз бәйләнгән иде.

Әле башта ук язып үткәнемчә, бу тирәләрдән Себер тимер юлы узганчыга хәтле Эткол белән Дәүләкәндә башкортлар үзләре генә яшәгәннәр. Күп итеп мал асраганнар, умарта тотканнар, җәнлек аулаганнар, кирәк кадәр генә иген дә игкәннәр. Шулай ук тирә-яктагы зур базарларга һәм ярминкәләргә йөреп, алыш-биреш тә иткәннәр. Ләкин нигездә зур үзгәрешләр кичермичә борынгычарак бер көе генә яши биргәннәр. Инде авыллары кырыннан гына үткәрелгән тимер юлы, паровоз гудоклары тын даланы сискәндереп уяткандай, моңарчы үз җаена салмак кына аккан башкортлар тормышын да бик нык үзгәртеп җибәрә. Иң элек, күргәнебезчә, яңа юл белән Эткол-Дәүләкәнгә төрле халык ябырылып килә башлый, шулар аркасында хуҗалык, сәүдә эшләре шактый кызу җәелә-көчәя, кыскасы, Эткол дигән бәләкәй генә башкорт авылында кинәт капиталистик мөнәсәбәтләр үсеп, куәтләнеп китә. Билгеле инде, бу мөнәсәбәтләр, төрле якка сузылган спрут кулларыдай, башкортларны да үз «кочагына» тартып ала. Беренче нәүбәттә без моны нәрсәдә күрәбез? Шуны онытмыйк: мондагы җир-суларга башкорт хуҗа, димәк, Дәүләкәнгә кем генә килмәсен, нәрсә генә эшләргә уйламасын, ул иң элек башкорттан җир сатып алырга тиеш булган. Шунсыз бер казык та кага алмаган. Шулай ук Дәүләкән әтрафындагы яңа рус авыллары да һәм немец хуторлары да башкорттан алган җиргә килеп утырган. Шул рәвешчә, башкорт үзенең иркен җирләрен азлап та һәм күпләп тә саткан яки арендага биреп торган. Бу җир сатуалу эшләре ул чакта бик кызу барган булырга тиеш, чөнки халык арасында ул турыда һәр төрле көлке һәм аянычь сүзләр күп сөйләнә иде (әйтик, кемдер кемнедер алдаган, кемдер кем беләндер судлашкан һ. б.). Миңа калса, бу әле Дәүләкән тарихының ныклап өйрәнелмәгән бер сәхифәсе.

Аннары килеп, Этколның үзендә үк зур базар ачыла. Тора-бара ярминкәсе дә була башлый. Тирә-яктагы башкортлар еракка китмичә, шушы базарга аяклы малын да, тире-ярысын да, итен-маен да чыгара. Базар стихиясе бик гаҗәп бит ул — бөтенесен дә үзенә тартып китерә... Тагын иң мөһиме — Дәүләкән ашлык җыеп озату урынына әверелгәч һәм зур-зур тегермәннәр дә эшли башлагач, башкортлар да иген игүне арттыралар, «бидайны» инде алар да товар итеп, йөге-йөге белән китереп саталар. Башкорт кулында тагын бер байлык — ул да булса печән. Дим буе болыннарына алар үзләре генә хуҗа иде. Болынны башкорт бик саклый, үлән әзрәк күтәрелгәч тә чабынга терлек кертми һәм кешедән дә таптатмый иде. Чабар вакыт якынлашкач, алар атналар буенча ат менеп яки җәяүләп әллә ничә чакырымнарга җәелгән болынны күзәтеп-карап кына йөриләр. Шушы уңай белән көлеп мондый бер кызык та сөйлиләр иде. Имеш, башкорт агае болында бер русны тотып алган да, яман ачуланып, аңа әйткән, янәсе:

Ләштер-ләштер атлаеш, засим бесән таптаеш?
Иты наша ялан бит, колак төпкә салам бит!

Эш колак төпкә хәтле үк барып җитмәгәндер инде, әмма әйтергә кирәк, печән ул башкорт өчен ишле малына бердәнбер азык та һәм шактый табыш китерә торган байлык та. Шуңа күрә дә терлектән дә, кешедән дә таптатмыйча саклаган ул аны. Печән чабу башкортларның уракка караганда да иң зур, иң кирәкле эш өсте — бөтен авылы, бөтен

[1] Дим буе башкортларының теле хәзерге башкорт әдәби теленнән шактый ук аерыла. Ә. Е.

хатын-кызы һәм бала-чагасы болынга чыга иде. Ирләр, торналардай тезелешеп, куе, тыгыз үләнне чаш та чош чабалар, хатын-кызлар берике көн җилләгән покосларны чүмәләгә өяләр, егетләр, үсмер таза малайлар тагы да кибә төшкән чүмәләне ат белән кибәнгә тарттыралар, һәм менә бер заман Дим тугае оста агайлар куйган очлы башлы-түгәрәк кибәннәр белән чуп-чуар була иде. Ә көзен-кышын Дәүләкән базарында шул хуш исле «бесәнне» бары тик башкортлар гына сата да иде.

Хәер, башкортның тагын кымыз дигән бик әйбәт бер байлыгы бар бит әле. Ихтимал, элек үзләре генә эчкәндә кымыз әллә ни зур байлыктан да саналмагандыр, әмма ләкин Дим буйлап тимер юл узгач, бия сөте чын бер табыш чыганагына әйләнә. Чөнки мәшһүр елганың көмештәй саф суы, чәчәкле-хуш исле болыны-яланы, каймактай йомшак һавасы, көннәр буе тигез генә кыздырган кояшы, шуның өстенә һәр төрле азыкның муллыгы һәм арзанлыгы үпкәсенә сихәт эзләүчеләрне бу тирәләргә күпләп тарта башлый. Кымызчылар диләр аларны. Ансат туры юл булгач, алар Уфадан гына түгел, Казаннан, Самарадан, Мәскәүдән, хәтта Петербургтан да Дим буйлап тезелгән башкорт авылларына киләләр. Иптәш Тартыковның язуына караганда, кымызчылар керткән һәрбер йорт хуҗасы җәенә 100 сумлап акча алып кала торган булган. Ә ул заман өчен бу — шактый ук зур табыш.

Димәк, яңа юл белән вагоннарга төялеп башкортларга да байлык килгән?.. Юк, ашыкмыйк әле... Әлбәттә, тимер юл — прогресс, алга китеш, үзгәрткән, җанландырып җибәргән ул җирле халыкның да тормышын, ләкин барысына да бер тигез байлык белән бәхет китергән дип уйлау зур хата булыр иде. Гомумән, байлык беркайчан да кешеләргә тигез бирелмәгән, башкортларда да борын-борыннан ук бае да, ярлысы да булган, ә тимер юлы аркасында җанланып киткән алыш-биреш эшләре (икенче төрле әйтсәк, капиталистик мөнәсәбәтләр) ул аерманы отыры тирәнәйткән генә. Дөрес, күп җир-су биләүче, күп мал асраучы башкортлар булган. Ләкин мин үскәндә алар да бик сирәк калганнар иде инде. Дәүләкәннең иң бай башкорты Дәүләткилде агай иде, диләр. Эткол урамының урта бер җиренә салынган иң шәп, иң матур чардаклы йорт та аныкы иде. 1919—1920 елны булса кирәк, бу йортның зур як башында бер кыш сабак та укыган идек. Яландай ишегалды, зур-зур абзарлар, тимер ишекле таш амбар — бер сүз белән генә әйткәндә, аныкы кебек йорт-җир татар «купич»ларында да бик сирәк иде.

Кем булган, ничек баеган ул, Дәүләткилде агай?

Таш магазин да ачмаган, сату да итмәгән, әмма, күрәсең, элек-электән үк җиргә-суга бай булгандыр инде. Ләкин иң мөһиме — ул волостной старшина булып торган кеше, ихтимал, шушы урыны аңа дәүләт китергәндер дә. Хәер, моны тәгаен белеп әйтүче юк, хәзер инде сорашыр кеше дә калмаган, хәтта балалары да белми торгандыр, чөнки күп сулар акты ул заманнардан соң. Дәүләткилде агай үзе дә һәм бичәсе дә революциягә чаклы ук, барысын да калдырып, бу фани дөньядан киткәннәр (әйтергә кирәк, бик яшьрәдәй чакларында). Алардан калган Рокыя исемле кыз белән Локманхәким исемле малайны атайларының инәсе Фәрхи карчык карап, тәрбияләп үстерде.

Локманхәкимне мин яхшы беләм, бер урамда үстек, ятимлеге ничектер йөзенә чыккан тыйнак-юаш кына бер малай кебек иде. Егерменче елларның ахырында ул Дәүләкәннән китә, кая китә, нишләп йөри — белүче юк. Тик күпмедер вакыттан соң бер хәбәр шулай да безнең колакларга килеп ишетелә: Локманхәким паровозда кочегар булып йөри икән, Дәүләкән станциясендә аны күреп калучылар булган, имеш. Булыр, ник булмасын?! Дәүләткилде малаена да кайдадыр эшләргә, дөньяда яшәргә кирәк ләбаса!.. Һәм соңыннан аның кочегар булып йөрүе дөрес тә булып чыкты.

Күп еллар узгач, без — олы яшьтәге ике агай, ниһаять, Уфада очраштык. Очрашуыбыз Дәүләкән «егетләренең» берсендә, күңелле генә бер мәҗлестә булды. Каршымда кечерәк буйлы, кап-кара чәчле, арык кына бер кеше утыра һәм мин аңа бик гаҗәпләнеп карыйм — шушымы кайчандыр минем белән бергә уйнап үскән Локманхәким?.. Ул бит тулы-түгәрәк кенә битле малай иде, гәүдәгә дә таза булмакчы иде — еллар, еллар әнә ничек үзгәртә икән кешене!.. Әмма иң гаҗәбе бу түгел әле. Минем хәтердә сакланган малай чагындагы ятимлек, нәүмизлек, мескенлекнең аңарда эзе дә калмаган. Хәзер ул үзен бик иркен, бәйсез тотучы, гаять җор, тапкыр сүзле, мәзәкчән бер кеше иде. Бөтен мәҗлес дәвамында кунакларны үз авызына каратып, өзлексез көлдереп утырды... Кем син, Локманхәким? — дип сорау кирәкми дә иде, дәүләт-байлык белән бәйләнгән үкенечле ачы язмыш күптән онытылган, ә хәзергесеннән исә ул мотлака канәгать! Мин башкача уйлый алмадым.

Дәүләкәндә икенче таза тормышлы башкорт безнең якын күршебез Арыслангәрәй агай иде. НЭП елларында аның өч-дүрт аты, бер кола айгыры, тагын күпмедер колын-тайлары бар иде. Ялгышмасам, ике бия бәйли иде, икеме-өчме сыер савалар иде. Тагын сарыклары, бәрәннәре... Хәер, кем санаган аларын?! Йорты урамга буй, кара-каршы салынган такта түбәле гадәти генә бер йорт. (Хәзерге механизаторларның йортларына җитми, һәрхәлдә). Кара-каршы өйнең уртасында иркен генә өйалды, ишегеннән кергәч сул кулда зур гөбе тора, бияне саугач та сөтен шул гөбегә кертеп салалар. (Чын булса, бияне көненә биш тапкыр савалар икән). Һәм кергән-чыккан һәрбер кеше, бала-чагага хәтле, гөбедәге кымызны пешкәк белән бер-ике тапкыр гына булса да болгатып ала. Хәтта чит кеше керсә дә, юл уңаеннан болгатмыйча узмый. Моны пешекләү диләр. Әнә шулай өзлексез пешекләп торсаң гына кымыз тизрәк тә һәм шәбрәк тә булып өлгерә икән. Шуңа күрәдер инде, хәзерге башкорт өйләреннән аермалы буларак, Арыслангәрәй агай өеннән җәйнең эссе көннәрендә әчкелтем тәмле кымыз исе килеп тора торган иде.

Арыслангәрәй агай үзе дә эре, таза, нык кеше иде. Һәм табигате белән дә ул ачык, көр күңелле, шаян-шат бер кеше дә иде дип өстисем килә. Шуңа күрәдерме, без малай-шалай, хәрти генә кешедән курыксак та, бу пәһлевандай дәү кешедән бер дә курыкмый идек. Чөнки ул — бөркет, без — чебен, ә бөркет себен тотмый, диләр башкортлар.

Ул бер вакытта да капка-койма буендагы сукмактан йөрмәс, бары урам уртасындагы ат юлыннан гына йөрер иде. Әгәр кызмачарак та булса, җилән чабуларын җилбәгәй җибәреп, бүреген күз өстенә төшереп, урамга сыймагандай шаулап, гайрәт орып, өенә кайта торган иде. Юлында очраган яшь бичәләргә шаяртып сүз катмыйча узмый ул, ә уйнап йөрүче малайларга туктап карап тора да ни өчендер бармак янап китә иде.

Шуның өстенә, Арыслангәрәй агай бик маһир аучы да иде. Беренче кар төшү белән ул киң күкрәкле, нечкә билле кола айгырын иярләп, озын саплы чукмарын биленә кыстырып, эчләре эчкә кереп беткән ике бурзаен ияртеп, бүре сугарга чыгып китә торган иде. Мин аның бүрене ничек итеп сугып алуын күптән инде «Бөреледә нилэр бар» исемле очеркымда язган да идем, шуңа күрә биредә янадан кабатлап тормыйм. Кыскасы, агаебыз чыккан саен берәр бүрене ат койрыгына тагып алып кайта, тиресен тунап, озын колгага элеп, капкасына беркетеп куя — бу дан билгесе! Үткән-сүткәннәр авызларын ачып: «Һи, Арыслангәрәй тагын бүре суккан ләбаса!» — дип исләре китеп узалар, ә безнең ише малайлар күшегеп, ачыгып бетсәләр дә, капка төбен ташлап китә алмыйлар — тере бүренең үзен күргәндәй алар тәмам дөньяларын онытalar. Монда нилэр генә сөйләнми дә, нинди генә бәхәсләр купмый иде шул чакта!

Арыслангәрәй агай улы Таһирны да ундүрт-унбиш яшеннән үк үзе белән бергә ауга йөртә башлады. Таһир, әйткәнемчә, бүре сугарлык көчле, гайрәтле малай иде. Һәртөрле уенда, көрәштә, йөгерешүдә ул иң беренче — аны җиңгән яки узган бүтән малай безнең арада юк иде. Шуның өстенә ул бит Арыслангәрәй агайның җыен кызлары арасында бердәнбер төпчек улы, атасының куанычы һәм мактанычы, шуңа күрәдер инде бәлки, Таһир шактый гарьчел малай да иде. Дөрес, үзе башлап тиктомалга берәүгә дә тими иде, әмма инде берәрсе аз гына аның ачуын китерсә, кинәт кызарып, шунда ук салып та җибәрә иде.

Без йорт аша гына күрше идек, бөтен малайлык чорыбыз Димдә, тугайда, урамда, мәктәптә бергә үтте. Егерме бишенче елны мин Казанга китеп бардым, ләкин һәр җәйне Дәүләкәнгә кайта торган идем. Бу инде безнең малайлыктан чыгып, егет булып килгән чагыбыз. Сагынышып очрашкач, тагын бергә йөрүләр, сөйләшүләр, күңел ачулар — хәзер инде, билгеле, мыек төрткән егетләрчә! Таһир кечкенә гармунда чибәр генә уйнарга да өйрәнгән, өстендә әйбәт тужурка, аягында күн итек, кызлар белән дә шаяргалый башлаган икән инде. Кыскасы, Дәүләкәннең бер шәп егете булмакчы иде, әмма ләкин кырыс заман аның язмышын тота да үзенчә хәл итә... Шуннан соң инде без очраша алмадык.

Әйтергә кирәк, Дәүләкән башкортларыннан Себергә бүтән җибәрелүче булмады да шикелле. Һәрхәлдә ишетергә туры килмәде. Миңа калса, Дәүләкәндә баеп киткән башкортларга караганда бөлгәннәре күбрәк иде кебек... (Монда сүз башлыча Этколның үзендә торучы башкортлар турында бара, ә төп Дәүләкән ул гади бер авыл — андагы башкортларны мин бик аз беләм.) Әмма бөлгенлек аларга революциягә чаклы ук килгән, чөнки кинәт башланган яңа шартларга күбесе тиз генә яраклаша алмаган. Җирен саткан, малын саткан, ә менә акчасын саклый белмәгән ахрысы. Этколь кырыннан гына үткән тимер юл белән бит һәртөрле күз кызыктырырлык товар гына түгел, «ак патшаның» аракысы да килгән, сыраны да Дәүләкәннең үзендә үк ясый башлаганнар. Шулай итеп, күрәсең, акчасын оборотка кертә белмәгән. Мәсәлән, Дәүләкәндә кибет ачып, сату иткән бер генә башкортны да мин белмим, юк иде бугай.

Хуш, ә бөлгенлеккә төшкәннәрен кайдан, нәрсәдән күреп була?.. Әйтик, менә яландай ишегалды, чыбык-чабык белән генә япкан читән абзарлар, абзар артында киртәләгән иркен утар — димәк, кайчандыр монда ишле мал кышлаган. Ә хәзер терлек юк, абзарлар буш, утар да буш, анда ята-ята череп, туфракка әйләнә язган тирес кенә... Шушының ише «хуҗалыклар» безнең урамда ук бар иде. Ерак китмичә, мисал өчен, бездән урам аша гына торган Солтанай агай йортын алыйк. Янәшә ике йорт, берсе калай, икенчесе такта белән япкан — димәк, бу хуҗа кайчандыр таза тормышлы булган. 1918 елны без аларга күрше булып күчкәндә, Солтанай агай үзе юк иде инде, Тимергали исемле энесен аклар алып киткәннәр, ул шуннан кайтмады. Кызыл түбәле йортта Солтанайның бичәсе ике улы белән тора (такта түбәлесен, бәләкәй генә ишек алды белән бергә, ачлык елы алдыннан Хәсән исемле бер вак сәүдәгәргә сатканнар иде). Тол хатын һәм ике үсеп килгән малай чибәр генә йортта калсалар да, шактый фәкыйрьлектә яшәделәр. Аларның инде бер сыердан башка бүтән терлекләре юк иде (бәлки, бернилә сарыклары булгандыр). Ә бит ихаталарының зурлыгына караганда, атлар, сыерлар, сарыклар кайчандыр монда аз тормагандыр... Күрәсең, Солтанай агай бу фани дөньядан аерылганда, барлык малын «очлап» бетерергә өлгергән инде. Эчкән кешенең, кем әйтмешли, малы да бетә, үзе дә бетә.

Ике малайның берсе — Мөхәммәтгали, икенчесе Муллагали исемле иде. Мөхәммәтгалинең бер аягы гарип, чатанлап йөри иде. (Исереп

кайткан атасы моның бик кечкенә сабый чагында ялгыш аягына утырган дип сөйлиләр иде.) Шуңа күрәме инде, ул бик нечкә күңелле, юаш кына бер малай иде. Безнең урам уеннарына юньләп катнашмый да, күбрәк ялгызы гына кармак күтәреп, Дим буенда йөрергә ярата иде. Балыктан бәхете бар иде аның... Күрше-тирә малайлары әле яңа торып кына чыккан булалар, ә Мөхәммәтгали инде тал чыбыкка тезгән чабакларын, тараннарын күтәреп, яр буеннан чатанлый-чатанлый менеп тә килә. Тагын бер яшерен хикмәте — ул да булса, безнең бу тыйнаксүзсез иптәшебез күптән инде шигырь язу белән дә мавыккан икән. Әйтергә кирәк, уеннан башканы белмәгән малайлар арасында утырып шигырь язу бик сирәк очрый торган хәл иде, булса да болай кызык өчен юри шаярып кына, чөнки чынлап шигырь язу ул гадәти кеше эше түгел, аның өчен син я Тукай, я Гафури булырга тиешсең. (Мәктәптә безнең иң күп укыган һәм ятлаган шагыйрьләребез.) Ә Мөхәммәтгали менә юри түгел, чынлап язган, күңелендә аның шигърият чишмәсе ачылган, шуңардан моңсу-боек җанына үзенчә юаныч та тапкан. Хәлбуки, минем дә, ниндидер бер яшерен кодрәткә буйсынып, кыяр-кыймас кына «каләм тибрәтә» башлаган чагым иде. Һәм шушы уртак «серебез» аркасында без аның белән шактый якынаеп, дуслашып та киткән идек.

Минем күңелдә якты бер хатирә саклана. 1926 елның җәендә Фәтхелислам белән икәү Казаннан ялга кайткач, Мөхәммәтгалине дә ияртеп без, Дәүләкәндә элек бергә укыган иптәшебез Гобәйдулла чакыруы буенча, «Мәрвәр утары»на кунакка барырга булдык. (Мәрвәр — Гобәйдулланың атасы, утар хуҗасы.) Ләкин безнең уналты-унсигез чакрымдагы утарга җигеп барырга атыбыз да һәм арбабыз да юк иде. Шулай да Мөхәммәтгали, йөри торгач, кемнәндер ат тапты, ә мин ерак түгел күршебез Рәхимҗан «купич»тан, ялынып-ялварып дигәндәй, аның рессорлы тарантасын алып тордым. Шулай итеп, без өч шәкерт биек тарантаска бәләкәй генә атны җигеп, җәйнең матур бер иртәсендә юлга да чыгып киттек. Башта егетләрчә бик кызу гына бармакчы идек, ләкин тискәре-ялкау атыбыз безне тыңламыйча күбрәк атлап кына барды. Яратмады ахрысы «купич»ның биек тарантасын?! Без инде, кеше аты булгач, аны артык чыбыркыларга да кыймадык. Әмма барыбер озын юлыбызны күңелле-хозур гына үтеп, көн төшлектән авышканда, «Мәрвәр» утары»на барып та җиттек.

Утар хәйран калырлык матур җирдә иде. Бөтен тирә-ягы ерактан ук сөзәк кенә түбәнәеп килгән шау чәчәкле тигез ялан. Утарның озын киртәләр белән генә әйләндереп алган ихатасындагы калай түбәле зур гына йортны да, иркен салынган каралтыларны да гүя шушы бер дә тапталмаган чирәм өстенә китереп кенә утырткannaр — бөтен җирендә чәчәк тә үлән генә... Ә түбәндә куе әрәмәлек арасыннан кечкенә инеш бормаланып агып ята. Инешне кичеп чыгуга, шактый биек, текә тау күтәрелә. Бу ялгыз тау, аның тирәсендә инеш ярыннан башка бер генә калкулык та юк. Тауларга мин һәрвакытта соклана торган идем, әмма ялгыз тауларның бик борыннан саклап килгән, бары үзләре генә белгән тирән серләре бар кебек, шуңадыр ахрысы, алар күңелдә ирексездән үзенә бер кызыксыну — соклану уята... Әнә тауның нәкъ түбәсендә таза-юан бер агач та (имән булса кирәк) сакта торгандай үсеп утыра. Юк, чынлап та хәйран матур, күңелле, сөйкемле бу утарның бөтен әтрафы! (Шушы утар күренешен мин бик күп еллардан соң «Гөләндәм туташ хатирәсе»ндә дә чагылдырырга тырышкан идем.)

Гобәйдулла дус безне үзенчә бик куанып каршы алды, бәләкәй атыбызны да көлә-көлә тугарышты. Ул һәрвакыт шулай муенын сузыбрак, башын аз гына калтыратып көләргә ярата торган иде, мәрхүм! Атны тугарып, абзар ышыгына бәйләгәч, без әле рессорлы тарантасыбыз янында юл хәлләрен бераз сөйләнгәләп тордык. Аннары Гобәйдулла үзе генә өенә кереп китте. Беренче мәртәбә татар утарына кунакка

килгәнгә күрәдерме, без ниндидер бер ятсыну тоеп, кыенсыныбрак калган идек. Ни булыр,ниләр күрербез, хуҗалар безгә ничек карарлар дигән шөбһәле уйлар иде безнең һәркайсыбызда. Озак та үтми, Гобәйдулла чыгып: «Әйдәгез, егетләр, өйгә керик!» дип, безне чакырды. Яшел чирәмдә генә комганнан кулларны югалап, рәшәткә башына элгән озын сөлге белән сөртенеп, өс-башның да тузанын бераз сыпыргалаштырып, Гобәйдулла артыннан өйнең түрьягына уздык. Шәһәрчә диярлек бай гына җиһазлы иркен зал, урта бер җирдәрәк ак эскәтер япкан зур өстәл, аңа каршы стена буенда яшел бәрхет тышлы озын диван, ә калган өч ягында биек артлы венский урындыклар. Дустыбыз йомшак диванга утырырга тәкъдим итеп караса да, без инде каты урындыкларны үзебез өчен «уңайрак» күрдек. Утырыштык. Залда берәү дә юк. Өстәлгә инде чәй әсбаплары куелган. Төрле ризык-сыйларны Гобәйдулла чаршау корылган бүлмә ишегеннән үзе барып ала. Аңа шул ишектән ике туташ бөтен нәрсәне биреп тора. Чаршау ачылганда гына күренеп киткән бу туташлар бик матурлар кебек иде. Ләкин ни кызганыч, аларның күренгәләве безнең өчен бик тансык, бик кадерле, әмма вакытсыз өзелгән үкенечле бер төш шикелле генә булып калды. Кемнәр алар, ни өчен Гобәйдулла аларны залга чакырмады, безгә күрсәтмәде— без моны һич тә аңлый алмадык. Күрәсең, бу йортта әле борынгы тәртипләр нык саклана.

...Ниһаять, өстәлгә ялт иткән сырлы ак самавыр да килеп утырды. Шулай дүртәү генә утырып һәм күңелле генә итеп чәй эчәргә керештек. Хуш исле кытай чәен чынаякларга Гобәйдулла үзе ясап, куе сөт өстен дә агач кашык белән үзе салып, безгә бирә торды. Дөрес, мондый матур кызлары булган бай йортта әдәп белән, чаманы белеп кенә сыйланырга кирәклеген онытмасак та, без юл килеп ачыкканга күрә өстәлдәге һәртөрле тәмле камыр ашларын ирексездән шактый ук урдык бугай. Тик Мөхәммәтгали генә гадәтенчә тыйнакланып утырды — сизгәнегез бардыр бәлки, нечкә күңелле гарибрәк кешеләрнең бер сыйфаты инде бу...

Чәйдән соң без инеш буена төшеп киттек. Ике янәшә бүрәнә генә салынган тар басмадан сай инешне үтеп, әрәмәлек арасында карагат, бөрлегән өзеп капкалагач, әлеге биек тауга юри иң текә җиреннән үрмәли-үрмәли менә башладык. Еш кына аяк таеп китә, түбән шуып та киткәлибез, шулай да бер-беребезгә кул бирә-бирә ахырда менеп җиттек. Тау башындагы ялгыз агач чынлап та бик мәһабәт таза имән иде, ләкин без аның куе үләнле, күләгәле төбенә утырмадык. (Гобәйдулла монда кара елан булгалый, диде.) Без күгелҗем сыек томан эченә китеп, әкрен генә эреп югалган ялан-кырларга карап, тауның сирәк кенә үләнле нәкъ текә кашына утырдык. Моннан ачылган манзара гаҗәеп иде, серле һәм тылсымлы иде. Без ул вакытта барыбыз да шигырь яза идек, хәтта мин дә... Ә табигать бит ул шигърият сарае, шигъриятне табигатьтән һич тә аерып булмый торгандыр инде... Билгеле инде, тау кашына утырып, каршыбыздагы манзарадан сихерләнгәндәй аз гына тын калып торганнан соң, безнең күңел һәм сүзләребез үзеннән-үзе шигырьгә күчте. Гобәйдулла шактый шомарган «шагыйрь» иде инде, күбрәк «һөҗү» (сатирик шигырьләр) яза торган иде. Яттан укуны да ул башлады. Тыңладык, көлдек тә, үзебезчә фикерләребезне дә әйткән булдык. Аннары Мөхәммәтгалидән үтендек. Ул, аз гына уйланып торганнан соң аягүрә басып, шунда ук җитдиләнеп, безне дә онычкандай, каядыр еракларга төбәлеп, ашыкмыйча гына үзенең берничә шигырен укыды. Без, башларыбызны каера төшеп, бик кызыксынып, хәтта беркадәр көнләшеп тә аны тыңладык. Әйбәт иде аның шигырьләре, гади генә язылган кебек, әмма бик үтемле иде... Инде миңа чират, ләкин Мөхәммәтгали артыннан минем нигәдер укып торасым килмәде, тик дуслар

бәйләнеп кыстаганга күрә генә тар кәгазьгә язган нииндидер бер әйберемне шунда укыган булдым [1].

Билгеле, тау башында укылган шигырьләрнең бер юлы да хәтердә сакланып калмаган — һәм бу гаҗәп тә түгел. Күпме еллар узып китте ул чаклардан соң?! Яшьлек белән картлык арасы кошлар да очып җитә алмаслык ара ул! Әмма шулай да менә хәзер әйтәсем килә: әгәр Мөхәммәтгали, үкенечкә каршы, бу дөньяны вакытсыз ташлап китмәсә, тора-бара аңардан бәлки чын бер башкорт шагыйре дә чыккан булыр иде. Инде шагыйрь чыкмаса, берәр төрле белем иясе булып китәр иде, чөнки ул, әйткәнемчә, укырга сәләтле, акыллы егет иде. Тик бичараны гариплеге һәм артык йомшак табигате харап итте булса кирәк.

...Кояш та җир читенә әкрен генә, тыныч кына якынлашып бара икән инде... Түбәндә күз җитмәс киңлекләр, ялан-басу төрләренә китеп югалган тар гына юллар, соры тузан бөтерелми бу юлларда, бөтен әтраф тын, саф, пакь — юк, белмәгәнбез ул чакта без моның чын кадерен, чын бәясен!.. Табигатькә без бик күнеккән идек, бик сирәк аңа соклана торган идек, хәзер генә ул сыкранып ах-вах иткән булабыз... Ахырда кузгалдык, шуа-шуа таудан төштек, инешнең салкын суында битләребезне чылатып алдык. Кайткач тагын дүртәү генә кечкенә ашка утырдык. Бая хыялларыбызны котыртып өлгергән туташлар бу юлы да безгә күренмәделәр. (Гобәйдулланың әтисен дә күрмәдек, өйдә юк икән — Чуенчы базарына киткән.) Шулай итеп, монда Гобәйдулла үзе генә хуҗа иде, үзе генә каршы алды, үзе генә әйбәтләп сыйлады һәм озатып та җибәрде. Әнә шулай узды безнең татар утарында бердәнбер кичебез. Икенче көнне иртәнге чәйдән соң без инде рессорлы зур тарантаска җиккән бәләкәй атыбызда Дәүләкәнгә таба тырт-тырт кайтып бара идек.

Солтанай агайның икенче улы Муллагали исә бөтенләй башка «тип» иде. Яшькә минем чамада булыр, ләкин миңа аның белән бик аз аралашырга туры килде. Мәктәпкә йөрүен дә ачык кына хәтерләмим — йөрсә дә бер-ике кыш кына йөргәндер. Урам аша гына торуларына карамастан, Муллагалине юньләп күреп тә булмый. Безнең уеннарга да бөтенләй диярлек катнашмый. Кыскасы, аның укуда да, уенда да кайгысы булмады шикелле. Сәбәп нәрсәдә? Ә сәбәп — башкорт малае өчен бик табигый да бик гади: аңа бик каты «ат җене» кагылган иде, бар белгәне тик ат, ат, ат кына!.. Атлар кайда — Муллагали шунда, башка җирдән аны эзләмә дә! Хәлбуки, аларның үз атлары юк иде. Шуңа күрә Муллагали көн саен диярлек Арыслангәрәй агай ишегалдында, көн буе шуларның атлары тирәсендә чуала иде. Билгеле, аны куучы юк, атлар бар җирдә малай кешенең чуалуы бик табигый нәрсә, аңа юньләп игътибар да итмиләр. Шуның өстенә ул әле кул арасына керергә, үзенчә нидер эшләргә дә тырыша. Әйтик, хуҗаның үз улы Таһир, урамнан керәсе килмәгәндә (уеннан аерылуы җәл), Муллагали еш кына кола айгырга атланып бияләрне, тайларны Комачка сугарырга төшереп менгезә. Бусы инде аның өчен үзе бер бәйрәм! Һәм иң мөһиме, атлар аны таныйлар, аны үз итәләр — бу инде куаныч кына түгел, чын горурлык та!.. Әнә шулай үтә кеше ишегалдында, кеше маллары тирәсендә малайның көннәре.

1921 елның рәхимсез каты ачлыгы үтеп киткәч, ничектер шактый тиз арада илгә муллык килде. Моны Ленин керткән нэп нәтиҗәсе диделәр. Нәкъ шул елларда безнең Муллагали дә, ниһаять, атлы булу бәхетенә иреште. Бу вакытта ул ныгып өлгергән уналты-унҗиде яшьлек таза егет иде инде. Һәм шушы яшеннән йөк ташучы булып эшли дә башлады. Егет максатына иреште дияргә ярый — ат бар, атай заманыннан калган кабык арба бар, капчык күтәрергә таза арка да бар—

[1] Буй киселгән тар кәгазьгә баскычлап шигырь язуны мин Казанда күреп кайткан идем инде. Ә. Е.

тагын ни кирәк?! Иң мөһиме — ул хәзер үз атын җигеп йөри, үзе «хуҗа». Атка гына түгел, агасына да, инәсенә дә, чөнки акчаны да хәзер ул таба! Һәм без, «урам таптаучылар», аңа инде көнләшеп тә карый идек.

Менә бу безгә күрше бөлгән башкорт Солтанай агай малайларының язмышы. Әмма андыйлар Дәүләкәндә аз түгел иде. Алар инде онытылып та беткән. Тик шуны әйтергә кирәк: тегермәннәрдән тимер юлга йөк ташучыларның бик күбесе, Муллагали шикелле, бер атлы башкорт агайлары иде. Язгы-көзге пычракларда казылмалы юллардан бичара атларның көянтәдәй бөгелеп, өзелердәй булып йөк тартканнарын миңа күп күрергә туры килде. Алар сыртына төшкән чыбыркыны ходай үзе башка җан иясенә күрсәтмәсен. Ни хикмәттер, токымы шундыйга күрәме, башкорт аты, әйтик, немец яки хохол атларына караганда, бәдәнгә кечерәк тә, арыграк та, әмма инде чыдамлыгына исең-акылың китәр! Чамасыз авыр эш өстенә ул бахырга, минемчә, ашату-карау да җитми иде. Мәсәлән, хуҗасы базар каршындагы чәйнигә «җылынып» чыгар өчен кереп китә, ә аты аның җиргә ташлаган бүрек хәтле генә печәнгә башын иеп, күзен йомып, тора да тора. Көн буе да тора ала ул шул хәлендә!

...Ниләр күрмәй ир-егеткәй башы менән ат башы — дип җырлый башкорт үзе дә. Сүз монда йөк ташучы грузчик агай һәм аның үзенә караганда да ныграк интеккән аты турында барды. Әмма сез беләсез инде, кеше язмышы да, ат язмышы да бер төсле генә була алмый. Миңа, мәсәлән, шул ук башкортларның җыеннардан-җыеннарга йөреп даны таралган сөлектәй чабышкы атларын да, киң тугайларда бияләр көтүен куалап, саклап йөртүче, һичкемне үзенә якын җибәрми торган бик зәһәр өер айгырларын да күрергә туры килде. Әйе, алар гәүдәгә зур түгел. Ләкин инде гаять җиңел сөякле, бик чая-тынгысыз атлар иде, мәхлуклар!

Ләкин шулай да, җепнең очын югалтмыйк әле. Мин Дәүләкәндә бай башкортларга караганда бөлгәннәре күбрәк иде дидем. Моны элек, революциягә чаклы ук булган хәл дип аңларга кирәк. Тимер юлы салынгач, Эткол-Дәүләкәндә кинәт «котырып» киткән капитализм шартларында берәүләр баеган, берәүләр бөлгән, ягъни кайчандыр билгәән байлыгын югалткан. Бу ул заман өчен табигый күренеш, тик аны бер яклы гына аңламаска кирәк: Этколда таза тормышлы башкортлар да аз түгел иде.

Менә миндә борынгы бер фото-открытка саклана. Дәүләкәндә чыгарылган, иске читенә «бия саву» дип тә язылган. Фоторәсемдә җәйге башкорт ишегалдының бер почмагы күрсәтелгән. Артта терлекләр утарына чыга торган җил капка, аңа тоташып киткән биек кенә читән койма. Менә шул җил капкадан бирерәк ике агай басып тора. Шунын берсе — озын куллы, озын буйлысы, кыяфәтенә караганда, һичшиксез хуҗа булырга тиеш: башында яңа кара түбәтәй, өстендә ак күлмәк, кара камзул, кара чалбар, аягында — кәвешләр. Аңардан чак кына уңдарак башына ак яулык ураган, өстенә әдрәс камзул кигән бичә чүгәләп, муенына озын корык салган ап-ак бияне савып тора. Икенче ак бияне кемдер ялыннан тотып (рәсемдә аның куллары гына күренә), саудырырга чиратын көтә. Менә шушы ике ак бия арасында хуҗаның малае — яше, чама белән, унике-унөчтә булыр. Башында тасмалы яңа эшләпә, өстендә бер очтан ябык якалы кара пинҗәк белән кара чалбар, аягында күн итекләр. Күренә ки, бу фотога һичшиксез бай тормышлы чын башкорт гаиләсе һәм өлешчән аның хуҗалыгы да төшерелгән. Әйтәсе дә түгел, бик колоритный фото!.. Тагын шунысы кызык, рәсемдәге озын таза башкортны минем атакай мәрхүм таныды: «Бу яңа Көрмәнкәйдән Мостафа агай!» диде. (Яңа Көрмәнкәй Эткол очындагы кечкенә генә авыл. Арада бер сай чокыр гына иде. Хәзер бу авыл юк. Ә Дим аръягындагысы Иске Көрмәнкәй дип йөртелә.)

Мостафа агай шикелле бай башкортлар якын-тирә авылларның һәркайсында диярлек булган ул заманда, кайберләрен мин дә әле күреп белә идем. Әйтик, Иске Көрмәнкәйдән Локман агайны, Акколайдан Гани агайны — бу соңгысы Дәүләкән базарына тәпән-тәпән бал төяп китерә торган иде. Нәкъ теге фотодагы шикелле, аның да шәптән киенгән малае базар саен атасына ияреп килә иде. Атасы бал сатканда, малай арба башында ак калач ашап яки көнбагыш ярып, аякларын селкеп утыра иде. Тик күпмегә сузылгандыр малайның бу бәхетле чаклары?!

Кыскасы, матди тигезсезлек — бик борыннан килгән нәрсә ул, бөтен халыклар өчен дә уртак күренеш, шуңа күрә дә алар сыйныфларга бүленгән, сыйныфлар исә гомер бакый үзара көрәшеп яшәгән — болар күптән мәгълүм хакыйкатьләр. Ләкин укучыда, табигый рәвештә, икенче бер сорау туарга мөмкин: хуш, ә бу күп милләтле Дәүләкәндә татар-башкорт мөнәсәбәтләре ничек иде?

Әйе, ул мөнәсәбәтләр турында мин үзем дә еш кына уйланам, һәм билгеле, ачык сорауга туры җавап бирергә дә кирәктер инде. Хәзер менә Дәүләкәндәге тормышыбызны искә төшереп әйтәсем килә: мөнәсәбәтләр һичшиксез якын, тату, әйбәт иде. Безнең, мәсәлән, башкортлардан дуслашып йөрешкән һәм туганлашкан кешеләребез дә бар иде. Минем инәйнең бертуган сеңелесе Кәримә түтакайның Өммегөлсем исемле дәү кызын Шәрип авылының Котлыяр мулла улы Миңнемөхәммәткә туйлап кияүгә бирделәр. Башкорт йоласы буенча, Миңнемөхәммәт җизни бер ел чамасы кияүләп йөрде, бары шуннан соң гына Өммегөлсем апабызны Ташлыкүлдән Шәрипкә килен итеп төшерде. (Бу ике авыл арасы бер 50 чакрым булыр). Инде Дәүләкәннең үзендә татарга өйләнү яки башкортка чыгу гадәти бер күренеш иде.

Әлбәттә, бу икесе — ике халык. Татары — татар, башкорты — башкорт, моны яшерү дә, моңардан качу да юк иде. һәркайсының үз халкы үзенә туган анасы кебек, һәркайсы шул халыкның исемен үз исемедәй гомере буена саклап йөрткән. Ихтимал, бик сирәк очракларда гына аерым кеше ниндидер фани исәплләрдән чыгып, «исемен» үзгәрткәндер, ләкин миңа андый хәлне Дәүләкәннең үзендә ишетергә туры килмәде. Бердәнбер фәүкылгадә вакыйга — ул да булса Миһран вакыйгасы булды. Бу хакта югарыда язган идек инде.

Билгеле ки, татар белән башкортны якын иткән сәбәпләр күп иде: дин — бер, тел — бер диярлек, тарихи язмышларда да уртаклык зур. һәр ике халык бөек Октябрь революциясенә чаклы хокуксыз булган, патша самодержавиесе тарафыннан каты изелгән. Бөек Тукай патшаның үзенә турыдан-туры мөрәҗәгать итеп:

> Уртак Ватанда халкыбыз шактый ук,
> Шушы халыкныңмы хокукка хаккы юк?! —

дигән, һич тә икеләнмичә! Халык шагыйре әнә шундый була ул!

Ә башкортларның ике йөз ел дәвамында (XVII—XVIII гасырда) «ак патшага» каршы өзлексез баш күтәрүләре әнә шул хокук, тигезлек, гаделлек өчен кан кою түгел идемени?!. Бу баш күтәрүләрнең бик күбесенә татарлар да катнашкан. Димәк, уртак язмыш ике халыкка да бер-берсенә якын торырга, терәк-таяныч булырга кушкан.

Кечкенә Дәүләкәндә дә без әнә шул борыннан килгән язмышлар бәйләнешен тоеп яшәдек дияр идем мин. Хәтта кайбер очракларда читләшүгә охшаш нәрсә булуга да карамастан... Ни дисәң дә, татар Дәүләкән җиренә читтән килгән, димәк, аңа «килмешәк» дип карарга да була, ул моны үзе дә сизә һәм вакыт-вакыт башкорттан да ишеткәли иде. Әмма татар — колонизатор түгел, аны башкорт җиренә патша хөкүмәте күчереп утыртмаган. Күрдегез инде, ул бу якларга бәләкәй арба тартып, җәяүләп килгән — авыр нужадан һәм золымнан котылу

өчен аның башка юлы да булмаган. Тарих үзе аны шулай югалмаска, бетмәскә өйрәткән. Аннары килүчеләр барысы да сәүдәгәр булып киткән икән, дип уйлау да хата булыр иде. Юк, килүчеләрнең күпчелеге хезмәт иясе — тимерче, кием тегүче, пима басучы, приказчик, извозчик, укытучы һәм тегермәннәрдә эшләүчеләр иде. Кыскасы, татар-башкорт арасы тормышның үзендә бик күп җепләр белән бәйләнгән таза, нык мөнәсәбәтләрдән гыйбарәт иде.

Мин үскәндә, Дәүләкән имамы Искәндәр ахун — башкорт, ә мәзине Нәбиулла абзый татар иде. Мәчет каршында урам аша гына иркен ихата эчендә ике йорт — берсе гади бүрәнәдән, икенчесе — зуррагы, такта белән тышлап, сарыга буялган. Болар мәдрәсә — Искәндәр ахун мәдрәсәсе дияләр иде. Кечерәгендә иптидаи (башлангыч), ә зуррагында рөшти (урта) сыйныфлар укый. Рөштидә укучыларның күбесе Дим буе башкорт авылларыннан килгән яшьләр — укулары да, торулары да шул сары мәдрәсәдә иде. (Бу мәдрәсә хәлләре турында мин кайчандыр «Корьән Хафиз» исемле хикәядә язган да идем.)

Менә без дә, ягъни минем яшьтәге татар һәм башкорт малайлары, башта бер-ике кыш ахун мәдрәсәсендә, аннары инде гел совет мәктәбендә бергә укыдык. Укулар, билгеле, татар телендә иде. Чөнки ул заманда бөтен дәреслекләр һәм әдәбият китаплары бары татар телендә генә чыга иде. Шулай ук укытучыларның барысы да татарлар иде. Гомумән, уку-укыту эшләре Дәүләкәндә күптән — сәүдә эшләре җанланып киткәч тә — башланган булырга тиеш. Революциягә чаклы ук анда кызлар мәктәбе дә булган. Махсус салынган йорты Эткколның иске зираты кырында иде. (Бу зират, Эткол зурайгач, авыл уртасында торып калды.) Кызлар мәктәбе өчен дә укытучыларны читтән чакырганнар. Шулай ук анда Искәндәр ахунның үз кызы Гайшә апа да укыткан. Гайшә апа бик сылу чибәр кыз иде, соңыннан, егерменче елларның башында, Таһиров дигән бер башкорт юристы килеп, өйләнеп, аны Уфага алып китте. Кияүне баш мәхкәмәдә (судта) эшләүче зур кеше дип сөйләделәр белгән кешеләр.

Дәүләкәндә шулай ук үзенә аерым татар китапханәсе дә бар иде. Заманына күрә шактый бай китапханә булгандыр, ахрысы, чөнки мин, мәсәлән, ул чактагы бик күп татар китапларын шуннан ташып укыдым. Укырга яратучы өлкәннәр дә, малайлар һәм кызлар да шул китапханәгә йөриләр иде. Аннары сәүдәгәр өйләрендә, бигрәк тә приказчикларда, элегрәк чыккан газета-журналлар да саклана иде әле. «Ялтйолт», «Ак юл», «Сөембикә», «Аң» һәм «Шура» журналларын мин башлап Дәүләкәннең үзендә күрдем, кайберләрен сорап алып укыштыргаладым да. Янә тагын әби, бабай булган өйләрдә шулай ук «Тутинамә», «Бакырган», «Бәдәвам», «Буз егет», «Каһарман катыйль» кебек укыла-укыла тузып беткән борынгы китаплар да табыла иде. Бик ялварып кына шуларны да миңа кулга төшерергә һәм аңлый алганнарын укып карарга да туры килде. Инде ачлык елы үтеп, тормышлар бераз рәткә кергәч, Уфадан, Казаннан һәм Мәскәүдән татар телендәге совет газета-журналлары да килә башлады. Болары безнең өчен, әйтсәң дә түгел, бик яңа, бик кызыклы иде, без аларны кулдан-кулга йөртеп укый торган идек. Минем үземә Уфада чыккан «Белем» журналы һәм Мәскәүдән килгән «Кечкенә иптәшләр» бик ошаган иде.

Әйе, безнең өчен ана телендә уку — күңел ихтыяҗына әйләнгән, гадәткә кергән бер эш. Телне безгә нык өйрәткәннәр, уку, язу, сөйләү — саф үзебезчә, һәм бу тел башкорт яшьләре өчен дә бердәнбер укый-яза торган тел иде. Сары мәдрәсәдә ятып укыган башкорт шәкертләре (егетләре) шушы телдә китапча югары слуп[1] белән, сүзләрнең

---

[1] Слуп — стиль.

дә иң матурларын гына сайлап, кәгазь читенә буяулы каләм белән чәчәкләр ясап, хәтта каләм тоткан бармакларын да төшереп, танышасы килгән кызларына хатлар язалар иде.

Аннары ул чакта укучы малайлар һәм кызлар арасында «Ядкарь дәфтәре» тоту дигән нәрсә дә бар иде. Шул дәфтәрне бер-берсенә биреп, ядкарь яздыралар иде. Минем дә булган андый дәфтәрем. Искереп бетсә дә, ул дәфтәр 1921 елдан бирле һаман әле миндә сакланып ятkан. Бергә укыган күп кенә малайлар һәм кызлар шуның битләренә үзләренең ядкарьләрен язганнар: күбесе миңа «иптәшем» дигән, «шәригем» дигән, ләкин арада «Әмирхан әфәндегә» дип куйганнары да бар. (Уникé яшьлек малайга!) Димәк, иске гадәтләр онытылып бетмәгән әле ул чакта.

Шул дәфтәрдәге ядкарьләр арасыннан берсен генә монда китерәсем килә. Кыска гына ул һәм бик матур кул белән язылган:

*Тәзкирәм!*
*Нәрсә языйм синең альбумыңа,*
*Матур язарга белмимен.*
*Сезнең бәхетле булуыңызны*
*Ихлас күңел илә телимен.*

*Сезнең кыйммәтле альбумыңызны былчыратканым өчен гафу утенәм.*

*апаңыз: Г. Ишаева.* $19\frac{27}{I}21$

Моны язучы әлеге үзе дә кызлар мәктәбендә укыткан Гайшә апа. Билгеле, мин дәфтәремне аңа бирмәгән идем, ә үзем белән бергә укучы энесе Исмәгыйльгә биреп торган идем. (Исмәгыйль миңа ядкарь итеп, Тукайның «Танса» шигырен күчереп язган.) Күрәсең, шул чакта күзенә чалынган дәфтәргә Гайшә апа да үзенең «Тәзкирә»сен язып куйган. Чын башкорт кызының саф татарча язуы берәүне дә гаҗәпләндермәсен. Чөнки бу — ул заман өчен табигый күренеш, чөнки элек-электән үк башкортның муллалары, мәзиннәре дә, соңрак мөгаллим-мөгаллимәләре дә төрле өяз һәм шәһәрләрдәге татар мәдрәсәләрен яки мәктәпләрен бетереп чыккан кешеләр. Хакыйкатьне яшерүдән мәгънә юк, тик моны дөрес аңларга кирәк. Мәсәлән, борын авылда күршедән ут алып чыгу гадәте булган. Утны соскы белән алып чыккан, учагына яккан, өен җылыткан — күршесенә рәхмәтен әйтергә дә онытмаган. Аң-белем бирүне дә мин шул ут биреп торуга охшатыр идем. Татар халкының учагында мәгърифәт уты иң авыр заманнарда да сүнеп бетмәгән, калын көл астында да әкрен генә көйрәп яткан ул, ә тора-бара, Россиядә азатлык хәрәкәте көчәйгәч, яңадан кабынып, ялкынланып киткән. Менә шул утны ул ихтыяҗы төшеп килгән кардәш халыкларга да биргән. Ә башкорт халкына аеруча, чөнки ул — терәлеп торган күрше, аңардан инде кызганып тору булмаган. Хәзер менә башкорт халкының үзендә аң-белем, культура, сәнгать: утлары дөрләп яна. Бу Ленин милли сәясәтенең иң гүзәл, иң куанычлы бер нәтиҗәсе. Моңа татар халкы да ихлас күңелдән куана — ничек кенә булмасын, аның да бит башкорт культурасына һәм сәнгатенә керткән зур өлеше бар. Әйдә, татулык-бердәмлек ватанында шулай аралашып яшәгән бу ике кардәш халыкның дуслыгы моннан соң да отыры ныгый барсын, белем, культура учаклары якты, тигез янсын — чөнки дуслыкның төп нигезләреннән берсе һәм иң мөһиме тигезлек! Һәр эштә, һәр җәһәттән!

*
* *

Әйе, Дәүләкән күп кенә милләтләрне үзенә җыйган шәһәр сыманрак зур бер авыл иде. Ләкин минем үземә бу милләтләр арасында иңгәли дә булса зур, җитди каршылыклар яшәп килүен күрергә туры килмә-

де. Чөнки мин үскәндә инде революция булган, совет власте урнашкан, милли тигезсезлекләр бетерелгән иде. Дәүләкәндә дә яңа заман, яңа тормыш башланды. Әмма бу яңа заманның нәп дигән кыска гына бер чоры булып алды. Сугышлар бетеп, ачлык елы да үтеп киткәч, кыска гына вакыт эчендә Дәүләкәнгә төрле яктан әүвәлгечә иген күпләп килә башлады, тегермәннәр эшләргә тотынды, базарлар җанланып китте, кибетләр-магазиннар ачылды, элекке сәүдәгәрләр генә түгел, һич уйламаган кешеләр дә җиң сызганып сату итәргә керешә, кыскасы, үткән тормышның күп кенә якларын шушы чорда тагын бер тапкыр күреп калырга туры килде. Минем әле үсмер чагым, яңа житлегеп килгән чагым иде, шуңа да карамастан, бу хикмәтле вакыт минем хәтердә шактый нык утырып калды. Әмма шундый кинәт җанланып киткән «иске» тормыш озакка бармас, тиз бетәр кебек иде,— нигә, ни өчен — белмим, әйтә алмыйм. Һәрхәлдә дөньяның тиздән башка якка үзгәрәчәген мин акылым белән түгел, ничектер йөрәгем белән сизә идем кебек... Шуның нәтиҗәсендә булса кирәк, миндә бик иртә уйлану, борчылу, эзләнү туа башлады. Шул ук вакытта күңелнең бу борчылу-ашкынулары, ә кайчагында газаплы кичерешләре, яшь өстәлә барган саен, отыры көчәя, тирәнәя дә бара иде. Кемгә генә таныш түгел яшьлекнең андый кичерешләре?! Минем өлешемә исә алар күбрәк тә төште. Менә ни өчен мин нәпның иң кызган чагында, уналты яшемнән үк Дәүләкәнне калдырып чыгып та киттем. Ләкин боларның барысын да миңа бу китапның соңгы өлешендә язарга туры киләчәк.

*
* *

1981 нче елның җәендә мин, бәлки соңгы тапкыр, Иске Көрмәнкәй авылында булдым. Хәтерләсәгез, Көрмәнкәйдә торучы Хәмит дустымның һәм аның бичәсе Сәгыйдәнең кыска гына вакыт эчендә үлеп китүләрен, ләкин кызганычка каршы, аларның каберләренә бара алмавымны башта ук язган идем инде. Бу юлы Дәүләкәнгә кайтуым да бары бер теләк — шул дусларымның каберләрен зыярәт кылу өчен генә иде.

Безне, ягъни мине һәм Уфадан бер-ике көнгә генә кайткан минем бик борынгы якын кешем Маһраны, «Салават» колхозының машинасы Көрмәнкәйдән килеп алды. Машинаны Райбашкарма комитеты председателе Равилов иптәш чакырткан булган. Алырга килүчеләр колхозның баш агрономы белән партоешма секретаре иде. Озак юанмыйча утырдык та киттек. Башта туп-туры Хәмит өенә барып туктадык. Менә ул, кайткан саен күпме сыйланып, күпме сөйләшеп утырган иске генә өй... Әмма хәзер анда торучы юк икән инде, ул ташландык — буш, аны тиздән сүтәргә тиешләр. Шулай ук Сәгыйдәнең безгә ашлар пешергән, балыклар кыздырган читән алачыгын да бөтенләй сүтеп ташлаганнар. Шулай итеп, хуҗалары белән бергә аларның гомер иткән җылы почмаклары да киткән яки китергә тора бу фани дөньядан!..

Аның караны, Хәмитнең кече улы шушында ук, капканың уң ягында гына зур таза йорт салдырып ята. Урам башын өлгерткән дә инде, тик эчке башы гына салынып бетмәгән әле... Егетне атасы кебек бик тырыш, уңган диделәр безгә, ләкин үзен күрә алмадык, эштә булып калды. Ә хатынын күрдек, һәм миңа бераз гаҗәп тә тоелды: ул әле түгәрәк йөзеннән балалык чырае да китеп бетмәгән бик яшь кенә, бик сөйкемле башкорт кызы иде, ләкин инде ике бала анасы, берсе кулында — Алсу исемле икән. Аталарыннан калган нигездә әнә шулай яңа, яшь тормыш таза үсентедәй күтәрелеп килә. Әйе, бу да бик табигый хәл, бик табигый күренеш!

Аннары каберлеккә киттек. Яшь кенә килен дә, баласын күтәреп,

безгә иярде. Хәмит өе авылның иң читендә иде, аны узгач та бик сөзәк кенә Көрмәнкәй тавы башлана. Кечкенә каберлек менә шул тауның итәгеннән бераз өстәрәк, калку урында, авыл очыннан бер ике йөз метрда гына булыр. Барып житү белән, каберләрен күрдек: икесе дә янәшә генә, Хәмитнеке аз гына өстәрәк, икесенә дә гади генә ак таш куелган, тар гына рәшәткә тотылган. Ташларына уелган сүзләрне укыдым: Хәмит 1976 елның ноябренда, ә Сәгыйдә 1977 елның мартында үлгәннәр... Аралары бик якын шул, бары өч кенә ай... Ашыккан Сәгыйдә Хәмите янына... Әмма уңайлы урында яталар — югарыда. Моннан гомер иткән өйләре — ишегаллары әнә генә, Дим дә якыннан гына уза, печән өстендә икәүләп йөргән болыннары, Сәгыйдәнең карагат, бөрлегән җыйган әрәмәлекләре, Хәмитнең балык тоткан күлләре, хәтта аның әнә туып-үскән Дәүләкәне дә барысы да ап-ачык күренеп тора. Ерак китмәгәнсез сез үзегезне чорнаган дөньядан — авылдашларыгызга, балаларыгызга, менә бу кечкенә оныкларыгызга тыныч кына карап ятасыз. Сез, тир түгеп, шушы җирне сугарган бик гади, бик самими кешеләр идегез — иң элек сезгә төшсен бу җирдә яшәүчеләрнең рәхмәте дә! Хушыгыз, дусларым, хушыгыз! — дидем мин эчемнән генә...

Ике кабер янында һәркайсыбыз эчтән генә үзебезнекен уйлап, бераз басып торганнан соң без әкрен генә кузгалдык. Калкулыктан төшеп, «Жигули»га утыргач, егетләр безне Ярыштауга алып киттеләр. Вакыт тыгызрак тыгызын, ләкин мин каршы килмәдем. Мондый форсаттан файдаланмыйча ярамый иде, әлбәттә. Кайткан саен каршы алган, киткән саен озатып калган тавым бит ул минем!

Ярыштауның Дим буена озын сәкедәй карап торган беренче катына безне машина үзе алып менде. Хәзер без аның каплап куйган казандай иң биек икенче каты янында басып торабыз. Бусы инде Ярыштауның үзе!.. Егетләр миңа әйтәләр: «Әйдә, агай, түбәсенә дә менik» — диләр.— «Менәргә... ничек итеп?» — «Туп-туры җәяүләп кенә!» — диләр егетләрем. Мин ирексездән көлеп, башымны чайкыйм: «Ай-һай, миннән булыр микән, егетләр?!» «Булыр, булыр, курыкмагыз, үзебез җитәкләп мендерербез!» — дип кыстыйлар һаман мине... «Биеклеге күпме соң?»... «Итәгеннән алып өч йөз илле метрлар чамасы, яртысын пачти мендек инде»,— диләр... Эчемнән генә уйлыйм: «Алай күп тә калмаган икән, ләкин мин бит Матбугат йортының дүртенче катына да туктамыйча менеп җитә алмыйм хәзер. Күпме булыр ул, унбиш-егерме метр, ә бу йөз илле метрдан да ким булмас. Минем өчен бик күп шул. Җитмәсә, «Бишбүләк»тә ике көн кунак булып, кайтып килгән чак... Йөрәк күтәрә алыр микән?.. Әмма менә алганда кызык та булыр иде... Ярышка мин унике-унөч яшьләремдә бер менгән идем, хәзер миңа җитмеш өченче яшь... йөрәктә стенокардия... Тәвәккәлләргәме-юкмы?..» Һәм мин тәвәккәлләргә булдым. Әнә миннән өч яшькә олырак Маһирә карчык та менәбез дип тора... Киттек менеп... Ашыкмаска тырышам, аякларны җиргә нык терәп, салмак кына атлыйм. Бер генә тапкыр туктап тын алдым, егетләргә кулымны да биреп тормадым... Ниһаять, менеп җиттек... Йөрәккә колак салам: юк, кысуы да, авыртуы да сизелми... Бик гаҗәп иде бу минем өчен... Хикмәт нәрсәдә?.. Хәер, тиз сиздем мин моның серен: һава, һава, һавада бөтен хикмәт!.. Шундый саф, шундый коры, шундый җиңел мондагы тау, дала, кылганлы сәхрә һавасы!.. Киерелеп, бавырларга үтәрлек итеп сулыйм, юк, туеп булырлык түгел — мондый һава имгәнмәгән йөрәкне йөз ел яшәтер!..

Тау башыннан ачылган ерак, күксел, чиксез киңлекләргә туйганчы бер карарга өлгермәдек, тагы да гаҗәбрәк икенче бер күренешнең шаһиты булдык. Тау түбәсенә, аның да текәрәк ягыннан, таякка таянган бер карчыкның, тар чалбар кигән унике-унөч яшьлек кыз балага тотынып, менеп җиткәнен күреп алдык. Кайдан, нинди карчык бу?.. Мин, янына барып, сорашмакчы булдым, әмма ул дөм сукыр һәм чукрак

булып чыкты. Кыз баладан әбиең ничә яшьтә дип сорадым, кыз — сиксән жиде яшендә диде. Бик аптырап, шушы яшендә ничек итеп һәм ни өчен менә ул дип сорагач, кыз әбисенең шушындагы кабергә коръән укыр өчен менүен аңлатты. Әйе, минем малай чактан ук исемдә калган ялгыз кабер монда тора икән, тик ул инде җир белән тигезләнеп беткән, урта бер җире уелган да, ләкин кемдер аны, кыска гына казыклар кагып, тимерчыбык белән генә булса да уратып куйган... Карчыкның бу кабергә беренче генә менүе түгел, күрәсең, ул кыз ярдәменнән башка туп-туры кабер янына барды да, иң элек аның өстенә вак таңкәләр ташлады, аннары чирәмгә аякларын сузып утырып, кулларын тезләренә куеп, авыз эченнән генә коръәнен укый башлады. Без барыбыз да бер мәлгә тынып калдык, ләкин, кеше изге гамәлен үтәгән җирдә болай казык шикелле басып торуны килештермичә, бераәм-берәм кузгалып, шыпырт кына түбән төшеп киттек.

Тик менә карчыкның кем булуын ачык кына белмичә китүе кызганыч иде. Үзе чукрак, үзе сукыр карчык миңа ничектер бер хикмәт иясе булып тоелды... Янымдагы егетләрдән сорап карадым, ләкин алар да бик аз белә икән: Дүртиледә, картаеп пенсиягә чыккан улында тора, җитәкләп менгән кыз — оныгының баласы, ә карчык, чын булса, китап укый-укый сукырайган имеш, диләр. Шуннан артыгын мин белә алмадым. Кызганыч!.. Уйламаганда гына хикмәтле кешеләр очрап куя, ләкин без һәрвакыт, әлеге каһәр суккан ашыгу аркасында, аларны күрмичә узабыз да китәбез. Шулай да егетләремә әйтүне кирәк таптым: сез ул карчыкны яхшырак белергә тырышыгыз әле... Кем каберенә йөри ул, кемне зиярәт кыла? Бер батыр кабере дип, минем дә малай чакта ук ишеткәнем бар иде. Билгесез гади бер кешене генә Ярыш түбәсенә мендереп күммәсләр. Бәлки картлардан тагы да белүче бардыр... Ә ул каберне рәтләп, баш очына таш та куйдырсагыз, бик күркәм бер эш булыр иде бу, дидем.

Егетләрем минем белән килешкән кебек булдылар.

Әмма мин бүгенге сәфәремнән ифрат та канәгатьмен. Иң элек күптән күңелемдә йөргән теләгемне үти алдым — Хәмит белән Сәгыйдәне үземчә зиярәт кылдым. Аннары менә алтмыш елдан соң икенче мәртәбә Ярыштау башына мендем, дөньяны күрдем, дөньяның бик борыннан килә торган, тик без генә оныткан серләрен сизгәндәй булдым. Әйе, үзең өчен чын канәгатьләнү кичергән мондый онытылмас көннәр безнең гомердә бик сирәк була ул.

Кайтышлый Дүртиле очында, Димнән якында гына нефть чыгаручы ике качалканың ашыкмыйча гына бер җайга селкенеп торуларын күрдем. «Димкәем, сиңа да чират җиттемени», дип уздым мин бу качалкалар яныннан. Ә алар, гүя түбәнчелек белән баш ия-ия, «Хәерле юл сезгә, онытып бетермәгез безнең бәрәкәтле Дим буйларын!» дигәндәй, мине озатып калдылар.

*Икенче өлеш тәмам.*

## Рәдиф Гатауллин

# АЛТЫН КОШ КАУРЫЕ

## Иң матур ил — балачак

*Мостай Кәримгә*

Нинди кыска син, Балачак!
Күз ачып йомган арада
Яктың ялмап алачак,
Аннары китеп барачак...
Юк, мәңгегә калачак!

Шундый озын син, Балачак:
Ил-йортта изге учак,
Туган тел, әнкәң догасы,
Акйолдыз сөюе — барсы
Дөньяга озатып калачак,
Юлдаш булып барачак.—
Утлардан алып чыгачак:
Язмышлардан да узмыш бар,
Син якласаң, Балачак!

Иң матур ил — син, Балачак!
Шагыйрь булсак, без мәңгегә
Шушы илдә калачак.
Аңа тугры булсак кына
Без хыялга көч алачак,
Кеше дип аталачак.

...Гомер, гомер! Үзең дә син
Дәвам иткән Балачак,
Озын-озак балачак!

## Парижда, Булонь урманында

Саумы, Булонь, мәшһүр урман!
Хәтерлимсең, синдә булган
Минем ерак бабаларым:
Кардәш башкорт җайдаклары,

Мишәр, типтәр солдатлары
Наполеонны җиңеп килеп,
Ялга туктап синдә торган.
Ат утлаткан, җырын сузган.
Хәтерлимсең шуны, урман?!

(Бу турыда шигырендә
Миңа кадәр искә алган
Башкорттан Муса Гали дә...
Аннан урлап язмадым да,
Тик көнләштем: синдә, Булонь,
Миннән элегрәк ул булган!)

Урман, гайяр бабамнарның
Рухына мин — тугры углан.
«Тарих язган ташлар»ына
Кайда да битараф булмам.
Антым калсын синдә, Булонь!

## Исемем турында

Исемем — Рәдиф: рифма артында сүзләр,
Запас җайдак, юлдаш, иярчен —
Мәгънәләрем күпме! Җырым ләкин
Ай, Кояшка минем иярсен...

Юлдаш икән, ил юлында булсын,
Кем яратмас хаклык юлдашын?!
Һәрбер Рәдиф — алмаш бәхет булсын,
Усаллыкка запас булмасын!

Исемем — Рәдиф, газәл шигырьләрдә
Торсын тотып рифма коймасын,
Шигырь төзеклеген. Тик мәгънәгә
Каршы булган койма кормасын.
Шигърияттә делец-эрсез затның
Яласына очрап куймасын!

Исемем — Рәдиф... Нечкә җырым кылын
Тетрәндереп чорым кагылсын.
Бу гасырда, тәндә җан барында,
Ничек чыңламыйсың, янмыйсың?!.
Исемем — Рәдиф... Шигырьдән сүз. Ә бу —
Шигырь җаны өчен азмы соң?!

●

Хәзер яшермисез: ул чак
безне бит... яраткансыз!
Безнең шатлыкларга җанда
сез яңгыраш тапкансыз —
икеләнүсез, ышанып,
хәтта безнең ялгышларга
кушылгансыз, янгансыз.
Тик горур булгансыз: хисне
бик эчтә саклагансыз.
Әйе, сез яраткансыз!

Без шашып сөйгән ярлардан
(күңләштегезме алардан?)
сизгеррәк булгансыз:
үзегез турында онытып,
безгә уңыш теләгәнсез —
теләк теләп торгансыз.
Сез көткәнчә үк булмадык,—
барыбер сүрелмәгәнсез —
һаман тугры калгансыз.
Безне гел күреп торгансыз,
һәм... күренми баргансыз.

Хәзер аңлыйм, соң булса да:
Бәхетебез булгансыз,
тугрылыклы дуслар, сез!
...Еллар, ник тиз узгансыз?!

●

Мин тагын күкләрдә! Тагын
Әмеренә алтын Кошның —
Хыялның теләп буйсынам! —
Югары омтылышым.
Гаебем табарга ашыкма,
Аңларга тырыш, дустым!

Мин тагын йөрәк иркендә;
Салкынын җиңдем кышның —
Аек фикернең: гашыйк мин!
Бәхет бирәләмме үзем? —
Синдә шул сорау, дустым!

Йөгәнсез түгел нәфсем, бел,
Китмәгән исем-һушым:
Садә яшьлеккә табынам! —
Битәрләп, «Шашынма», димә,
«Сабыр бул!» димә, дустым!

Мин тагын кабындым хистә!
Хатымны алтын кошның
Каурые белән язам, күр:
Җанымны эшкә куштым!
Тагын җиде кат күктә мин:
Үземә ышанам! Аңла бу
«Гаебем»не... Күтәр, дустым!

●

Кер әле тагын, Тамара,
Йөгереп, хат-хәбәр белән...
— Быел да бәхет китердем,
Онытмый сөеклең, диген,
Менә, күр: аннан килгән!
Кер әле, быелгы язның
Җылысы азрак бугай.
Казаннан хәбәр килмәсә,
Җанымда газап бугай.
Беләм дә: миңа язудан
Ул күптән азат бугай.

Язарга «вакыты юк» бәлки,
Сагына яшерен генә...
Ә шулай да онытылып,
Бер телеграмма җибәрсә —
Гүяки... яшьлегенә?!

Кер тагын, Тамара, җаным,
Кеше бәхетеннән янып,
Балкыган йөзең белән
Хәтерләт... бәхетемнең язын!
Ә хәбәр булмас... Беләм.

●

Ничек килдең шушы чынлыкка син? —
— Табулардан югалтулар күбрәк...
Хыялларны бәлки онытасы? —
Егерме ел ләса әзли йөрәк...
Тагын күпме аңа югалтасы?!

Тын авылдан юлга чыккан йөрәк!
Табудан, бел, күбрәк югалтулар...
Булды дуслар кулы, юатулар...

Вакытлыча булыр юанулар,
Күз яшеңне эчкә яшер тизрәк!

Егерме ел син юлдасың, йөрәк.
— Югалтулар артындадыр табу?!
Табу хакынадыр бит югалту?!
Юкса, юатулар нигә кирәк?
Кырыс хакыйкатькә өйрән, йөрәк!

Син юлдасың, йөрәк, мәңгелеккә!
Юк, егалмый сине югалтулар.
Сыгылсаң да, син сынмассың, йөрәк:
Җирдә Тынычлану-юану бар.
Табулардан югалтулар күбрәк...
Син табарсың ләкин, ышан, йөрәк!

•

Шундый без тутырдык тустаганны,
түбәләмә иттек стаканны;
чын пиала-савыт, касә алдык —
кайнап торган сөю хисе салдык!
Салдык чыңлап торган бәллүрләргә,
путалланган мөгез, көрәгәгә...
Хистән тулды чынаяклар, җамаяклар,
алтын, агач, балчык — бар аяклар!
Бәхет бәйрәменә дуслар без чакырдык:
Читтән генә үзебез карап тордык...

Тик сөюдән иде безнең яну, кызу...
Мөмкин түгел дидек ул ут узу!
Уза икән... Авыр хәзер хатирәсе!
Мәҗлесләрнең гүя иртәгәсе —
Үкенечкә калса яшьлек, күңелең — буш.
Әй син, Язмыш!
Безне тагын бер очраштыр, күрештер син,
тустаганның бир тулысын — бары бирсен,
икебезгә бер савыттан эчәргә куш:
уртак ялкын, сөю тулы ул касәне
инде кулдан без төшермәс идек аны...
...Ялыктырдың, артык тыныч, хиссез тормыш!

•

*Шагыйрь «дус»ка*

Без кем Зур Сәнгать каршында?
Гүя Аполлон[1] алдында,
һәммәбез кече бугай...

Ә бит Парнас[2] итәгендә
очрашкан идек яшьлектә,
дуслашкан идек шулай.

---

[1] Апполлон — сәнгать алласы.
[2] Парнас — тау исеме, шагыйрьләр яши торган урын.

Бүген, «нык күтәрелдек» дип,
ахры, алданган көндә
«Кем биегрәк менгән соң?» — дип,
бәхәстә ярышмыйбызмы —
бер түмгәк түбәсендә?!
Һәр сәгать, һәр көне чорның
хезмәткә чакырганда,
фидакарь җаннар, янып, чын
көрәшкә атылганда,
Тукай, Такташ, Җәлил рухы
Биеккә әйдәгәндә,—

вак, тар хисләр йөгең белән,
мавыгып тик үзең белән
кая барасың, бәндә?!
Мин изге бу тау янында
(син үзең, Аполлон алла,
вөҗданны-җанны уят!)
тиргәдем үземне бүген
(борчылма, юк, сине түгел!),
ялгышларымны уйлап.
Син, беләм, бу хәлдән өстен:
тыңдәшсез мөтәдәһига
нигә ул тәүбә-оят?!

## Җавап

*Синең ялгашыңа юк тиясем,*
*Чәбә! дип әйткәнем юк, ник өрәсең?*

Дәрдмәнд

Мөтәдәһилык шәп... Шәп, уйласаң,
«Талантлы укучы малай» да:

Оят җуеп, шөһрәт яулар өчен
Керми Иблис белән ул пайга.

Ул хыянәт итми мәхәббәткә,
Ул табынмый — файда эзләп! — потка:
Алмаштырмый чынны ялганга!

Алыш-биреше юк мәкер белән,
Әшнә түгел һәр ялагайга.

«Көрәшче мин» диеп, делецлыкны
Тәкъдим итми ул ил-базарга.

Макиавелли [1] тәгълиматын белми,
Карьеризм чит-ят аңарга!

Тартмый аны кемдер иман сатып
Салган сарай — җиз дә, калай да...

Алай да —
Мин баш иям шигърияттә шундый
Үзе булып калган малайга!

[1] Макиавелли — итальян язучысы.

# Гариф Галиев

# ИСТӘ, ҺАМАН ДА ИСТӘ...

**хикәя**



Безнең күршебез Шәйхевәли абзыйның өч малае һәм бер кызы бар иде. Малайлардан иң зурысы Габделхак исемле, аннан кечеләре Шәйхелбастам, икенчесе Габделбастам, ә кызлары Гөлсем исемле.

Әниләребезнең һәм кендек әбиебезнең сөйләүләре буенча без Гөлсем белән бер көнне туганбыз. Ул төнне ай бик якты булган. Мин кендек әбиебезнең: «Бу айның унбише тулган көзге төн иде. Җиз поднос кебек тулган түгәрәк ай сезнең кое сиртмәгез турына менеп җиткәч, җирдән ниндидер хәбәр көткән кебек, кузгала алмыйча, шактый вакыт түбән карап торды. Ә инде Гөлсем белән сез туып тавыш биргәч, тынычланды да, болытлар арасыннан ялтырап үтә-үтә, яңадан үз юлыннан тәгәри башлады», дип ярым шаярып, ярым чынлап сөйләгәнен әле дә хәтерлим. Менә шуннан соң инде өйдәгеләр, авылыбызның буеннан-буена тын гына агып яткан инешкә барып, бернichә чиләк «таң суы» дип йөртелә торган саф су алып кайтып җылытканнар да, шуның белән безне сак кына коендырганнар. Ә инде бернichә көн үткәч, безнең икебезне дә бабай мунчасына алып барып юындырганнар.

Шулай итеп, без Гөлсем белән берүк вакытта туганбыз, берүк вакытта мунча кергәнбез. Хәтта берүк көнне безгә имчәк каптырганнар һәм без яши башлаганбыз. Тора-бара, үрмәләп булса да, тәпи йөрергә маташканбыздыр...

Без дөньяга ныклап аяк басарга шулай әзерләнгән вакытта Гөлсем әтисен дә, минекен дә япон сугышына алганнар. Шул яуда минем әти бер диңгез портында үлеп калган, ә Шәйхевәли абзый исә, ниндидер бер шәфкатьле язмыш аркасында, исән-сау хәлендә өенә кайта алган.

Шул еллардан алып Шәйхевәли абзыйлар белән безнең әниләр, ике йорт бер йорт кебек булып, бик нык аралашып яши башлаганнар. Мин дә сабый чактан ук Шәйхевәли абзыйларга ияләшкәнмен. Әниемнең шул елларны искә алып сөйләвенә караганда, мин Бастамнар, Гөлсемнәр белән гел бергә уйнаганмын, дүртенче малай булып гел бергә аларның ашъяулыгы янына утырганмын. Мин ул чакларны, өзек-өзек кенә булса да, үзем дә хәтерлим. Җәй көннәрендә Шәйхевәли абзыйларның ямь-яшел бәбкә үләне белән капланган ишегалдындагы кар базына якын гына бер урынга җәелгән бик зур ашъяулык тирәсенә тезелеп, кызгылт агач табактан катык каткан борчак ашы ашап утыруыбыз бүген дә күз алдымда. Аннары шунысы күз алдымнан китми, Шәйхевәли абзый җәй һәм көз айларында басуга эшкә йөргәндә һәр-

кайчан ике ат җигә иде. Бер арбага ул тырмалы чалгылар, тырмасыз чалгылар, яшел саплы ураклар, имән ләгәннәр, басуда чәй кайнатканда төтен белән ысланып, кап-кара тәскә кергән чиләкләр төяп үзе генә утыра иде. Икенче арбага исә, чүлмәкләр кебек, без тезелеп утырабыз, һәм Гөлсем дә безнең белән бергә була иде. Ләкин безнең бу тезелешеп, тәртипле утырып баруларыбыз бик тиз «бозыла» һәм без үзара бөерләребезгә, кабыргаларыбызга төртешә-төртешә шаяра башлыйбыз. Вакыт-вакыт арбадан сикереп төшәбез, янадан сикереп менәбез. Атны Габделхак абзый әйдәп бара. Ул безгә һичбер каты сүз әйтми. Бик юаш табигатьле, кыз балалар кебек инсафлы, безне беркайчан да ачуланмый торган бу Габделхак абзыйны без үзебез дә бөтен җаныбыз белән якын итә идек. Ул нәрсә кушса, без шуны үтибез. Кыскасы, урак өсләрен, көлтә ташу чорларын бик көтеп ала идек. Әгәр яшел саплы кәкре урак та тоттыралар икән, бу безнең өчен бик зур ышаныч, безне кеше рәтенә кертү, ягъни санга санау иде. Ә инде олылар урак тотарга иртәрәк дигән фикер белән үзләре урып бәйләгән көлтәләрне өчәр-өчәр итеп, башларын бергә туры китереп өюне безгә кушалар икән, бу эшне шатлыгыбыздан сикерешә-сикерешә башкара идек. Өлкәннәр урып бәйләгән көлтәләр белән кичкә таба җир өсте чуарлана һәм без, шушы көлтә өемнәрен тезүдә үзебезнең дә катнашыбыз барлыгын аңлап, яланаяк килеш камыл өстеннән йөгерешә-йөгерешә йөри идек. Бу сап-сары камыллар безнең аякларыбызны аз гына да чәнчемиләр, алар гүяки безгә шәфкатьлелек белән ничектер йомшыйлар кебек тоела иде.

Ә инде кояш тау артына кереп яшеренгәч, без арбаларыбызга утырабыз һәм Шәйхевәли абзыйдан откан: «Бәләкәй генә бөкере, бөтен кырны бетерде» дигән табышмакны кат-кат әйтә-әйтә авылга кайта торган юлга чыгабыз. Бу такмак безгә бик охшый иде. Чөнки шушы зур җирдәге игенне урып бетергән «бәләкәй генә бөкере»нең яшел саплы урак икәнлеген без яхшы төшенә идек. Бәләкәй булсак та, без дә шушы урак кебек бик зур эшләрне башкара алуыбыз белән күңелебездән масая да идек. Кичләрен басудан авылга кайткач та дүртәр-бишәр нигрә көлтә төялгән фурманнардан аерылмый идек. Әлеге кар базы янындагы кичке аштан соң көлтәсе бушатылмаган шушы фурманнарга менеп, шул сап-сары һәм бик хуш исле көлтәләр арасында йокыга тала идек.

Бастамнар, Гөлсемнәр белән безнең болай аралашуыбыз шулкадәр табигый бер гадәткә кергән иде ки, без иртән тору белән бер-беребезне күреп, хәл-әхвәлебезне белмичә яши алмый башладык. Аеруча мин. Көн туу белән иң элек аларга барып керә идем. Әлбәттә, Бастамнар үзләре дә безгә еш керәләр, ә менә Гөлсем сирәк була, ул бер йомышсыз керергә ничектер уңайсызлана иде шикелле. Ә инде еллар үтеп, чәчләрен туздырып, яланаяк йөрүләрен ташлагач, ягъни инде үсмер кыз булгач, ул безгә нинди дә булса йомышсыз бөтенләй диярлек керми торган булды. Ләкин мине уй-исәпкә калдырган бу хәл озакка сузылмады, ул безгә керүнең җаен тапты. Бу менә ничек хәл ителде. Аларның үзләренең дә бик әйбәт коелары булса да, ул беркөнне җилкәсенә көянтә-чиләкләр асып, көтмәгәндә безнең коедан су алырга керде. Аны күрү белән минем әнием йомшак кына тавыш белән сорап куйды:

— Балакаем, Гөлсем, коегызга әллә күсе-фәлән төштеме?

Гөлсем сузып кына җавап кайтарды:

— Ю-ук, төшмәде. Безнең әни, аларның коеларының суы йомшак, шуңа күрә чәйләре әйбәт чыга, тәмле дә була, дип сезнең суыгызны мактый. Ә үзебезнең коеның суы артык каты, ди. Безгә чәй суын Мөхәммәтвәгыйзләр коесыннан ала торган итәргә кирәк, ди. Шуның өчен мин сезгә су алырга кердем.

Гөлсемнең бу җавабын ишетү белән әниемнең йөзе янадан ачылып китте. Мин әниемнең иреннәрендә ниндидер бер әйтелеп бетмәгән, ях-

шы сүз ишеткәннән соң була торган хәйләкәр елмаю сызыкларын күреп алдым. Ул Гөлсемгә тагы да йомшаграк, тагы да мөлаемрәк тавыш белән:

— Ал, кызым, ал, тик безнең коебыз бик тирән, хәер, көчең җитми башласа, әнә, Мөхәммәтвәгыйз бар, ул тартып бирер!— диде миңа карап.

Бу сүзләрне ишеткәч, мин бик тә шатландым. Димәк, безнең икебезне әниләреоез дә ярата...

Башымда моңарчы әле мин аңламаган ниндидер бер ят һәм яңа уй туган кебек булды. Йөрәгемнең тибүе ешайганын, күңелемдә яңа бер хиснең гүяки сизелер-сизелмәс кенә оулып уяна башлавын белдем.

Бу — Гөлсем беренче тапкыр безнең кое суын алырга керүе иде. Берүк вакытта бу аның бик күп тапкырлар керәчәген һәм һәркайчан минем аны көтеп алачагымны алдан хәбәр итүе иде.

Белмим, мин аның кергәнен көтә идемме, әллә минем ишегалдында йөргәнемне күреп, ул үзе туры китереп керә идеме, моны өзеп әйтә алмыйм. Ничек кенә булмасын, ул безнең коедан су алып чыгарга кергәндә без гел бер-беребез белән очраша идек. Мин аның җиңнәре сызганган беләкләре белән югары үреләүреләкое чиләген тартып төшерүен, аннары су белән күздәй тулган имән чиләкне коедан тартып чыгарып, аның суын әллә нинди матур парчалар төшерелгән үз чиләгенә тутыруын үз-үземне онытып карап тора идем. Ләкин имән чиләктәге су аның чиләгенә сыймый, чит-читләреннән ташып түгелә иде. Бу вакытларда минем күңелемә дә нәрсәдер шушы су кебек ташып тула, һәм гүяки ул да түгелә кебек иде. Мин сылу гәүдәсе белән бөгеләсыгыла, янып-пешеп су алучы Гөлсемгә карап хәйран калам һәм күңелемне ниндидер бер моңсу куаныч биләп ала иде. Шул чиләкләргә сыймый калган суларга минем йөрәгемдә урын бар икәнлеген аңа әйтмәкче булам. Гүяки аңа «Гөлсем!» дип дәшмәкче булам. Ләкин аның да, үземнең дә әле бәләкәй икәнебезне исемә төшерәм дә үземнәнүзем оялам. Яныбызда безне карап торучы әниләребез юкмы, дип икеләнеп калам. Беләм, ул да минем кебек сәер хәлдә бугай. Чөнки үзе чиләгенә су тутыра, ә үзе күз кырыйлары белән миңа карый. Әллә кое чиләгендәге су аның чиләгенә чыннан да сыймыймы, әллә ул минем карап торганымны күреп каушап кала да суы читкә түгелә?!

Гөлсем су тулы чиләкләрен үзе кебек сыгылып торган матур көянтәсенә эләктереп җилкәсенә күтәргәндә мин аңа ничек булса да булышырга телим. Ләкин кыюлыгым җитми, җөрьәт итә алмыйм. Әлеге дә баягы үземнән-үзем ничектер оялам һәм тыелып калам. Ә үземне тиргәп алам: юләр син, малай була торып шуңа ярдәм итмисең, дим. Үзем дә сизмәстән, аңа таба берничә адым атлыйм. Ләкин мин килеп җиткәнче, ул үзенең житен чәчәге кебек зәп-зәңгәр күзләре белән миңа бик матур карап ала да кое яныннан кузгала. Үзенең сылу гәүдәсе һәм ягымлы хәрәкәтләре белән бөтен ишек алдыбызны тутырып, шундагы барлык җан ияләрен гүяки үзенә каратып капкага таба атлый. Ул атлаганда чиләкләрендә сулар чайкала, шуны күреп минем күңелемдәге үзем дә рәтләп аңламый торган әллә нәрсәләр чайкала... Ниһаять, ул болай да бик киң капкага көчкә сыеп, борыла-борыла чыгып китә. Ләкин бөтен матурлыгы, бөтен тулылыгы әле һаман ишек алдыннан чыгып китмәгән кебек тоела миңа.

Ул беркайчан да тик тормый. Мин нәрсә дә булса эшләгәнен күреп аңа кызыга идем. Җәй көннәрендә абыйлары белән кыр эшләренә йөри. Иртә-кич сыер савар алдыннан җылы су белән аларның җиленнәрен юа, бозауларын имезеп, мунчаклап бәйдә тота. Кыскасы, әнисенә һәркайчан ярдәм итә иде.

Мин аның он иләү, токмач кисү, бияләй бәйләү, сүс талку кебек хатын-кызлар эшен кай арада өйрәнгәнен ачык әйтә алмыйм. Чөнки

аның әнисе кушкан бу яки теге эштән, белмәгәнлекне сәбәп итеп, баш тартканын ишеткәнем дә, күргәнем дә булмады. Ул кулыннан килердәй күп эшне, әнисе кушканны да көтмичә, үзе башкара иде. Нинди генә катлаулы, берүк вакытта зур осталыкны таләп итә торган нинди эшне башламасын, аның кулы шуңа ябышып тора иде. Әйтик, икмәк пешерү өчен он иләгән чакта, әгәр игътибар белән карап торсаң, юка гына кысалы бу иләк аның кулында түгел, ә бармак очларында, һавада үзеннән-үзе җай гына тирбәлеп тора кебек күренә иде. Ә инде токмач кисә башлый икән, аның кулындагы озын пычак та күзгә күренми, ә җеп кебек нәзек токмачлар аның бармаклары арасыннан түгел, ә кайдандыр, үзләреннән-үзләре килеп чыгалар да куна тактасына үзләреннән-үзләре тезеләләр иде.

Аның бу кадәр эшчәнлеген һәм осталыгын күреп, еш кына эчемнән «мин нәрсә эшли беләм соң?» — дип үземнән-үзем риза булмыйча кимсенеп куям, мин дә ниндидер берәр файдалы эшкә тотыныйм әле, дигән теләк туа һәм Гөлсемнең эшләгәнен озак карап торырга уңайсызлана башлый идем.

Шул искиткеч осталыгыннан булса кирәк, аның теге яки бу эшне кайчан башкарганын белми дә кала идем. Бу безнең инде балалыктан аерылып, балигъ булу алды еллары, ягъни үндүртне тутырып, унбишкә чыккан чагыбыз иде. Шул елны «әбиләр чуагы» дип йөртелгән көннәрнең берендә мин читән аркылы Гөлсемнәрнең ишек алдында казык башына элеп куелган бер пар ак перчатка күрдем. Гөлсем дә шунда иде. Ул казык башындагы перчаткаларны алды да, эчке якларын әйләндереп, яңадан шунда ук элде. Аннары сызганган җиңле беләкләрен селти-селти өйләренә таба атлады. Мин аңа дәшмичә кала алмадым:

— Гөлсем, нишлисең? — дип сораган булдым.

— Кул эше өйрәнәм, яхшыга кияргә үземә бәрән йонынннан гына перчатка бәйләдем, шуны сабын суында юдым да кибәргә элдем,— диде һәм гадәттәгечә гәүдәсен уйната-уйната өйләренә кереп тә китте. Перчатканы кай арада бәйләгән диген? Мин аны көн саен берничә тапкыр очратам бит, шул эшен күргәнем юк иде, дип аптырап калдым. Башкарган һәр эше Гөлсем өчен иң кирәкле бер бизәк һәм шул бизәкләр аны тагы да матурайталар, күңелне үзенә тагы да ныграк тарталар иде.

Чынлап та, аның карлыгач канаты кебек кара кашларына, уймак кебек кенә авызының читләрендәге кынадай куе кызыл иреннәренә һәм алсу колак яфракларына карап туеп булмый иде. Әгәр шушыларның бер генәсе булмаса да, аның матурлыгы тулы булмас иде. Табигать аны хатын-кызлар өлешенә тигән бер генә нәрсәдән дә мәхрүм итмәгән, барысын да биргән. Һәм шушыларның бөтенесен дә тупас карашлардан саклау өчен әйтерсең, икесе ике якка таралып, күпереп торган чем-кара толымлы иткән. Вакыт-вакыт ул үзенең шушы озын толымнарын җилкәләре аркылы күкрәгенә әйләндереп сала, вакыт-вакыт яңадан артка кайтарып шулар белән нечкә билле аркасын каплый иде.

Акыл ирешмәслек шушы матурлыкларны Гөлсем бик оста саклый да белә, ул беркайчан да артык кычкырып сөйләшмәс, өлкәннәр белән исәнләшмичә узмас, үзеннән кечеләрне бервакытта да кимсетмәс, иптәшләрен мәсхәрәүләрдән дә бик ерак торыр, кирәк чакта һәр җан иясенә ярдәм итәргә әзер булыр. Болар аның канына сеңгән гадәтләр. Шуңа күрәдер инде беркайчан да, арабыздан беркем дә аңа караңгы чырай күрсәтми, аңа каты кагылмый иде. Чөнки үзен-үзе тота белүе, хатын-кызларга гына хас әдәпле, шәфкатьле булуы белән Гөлсем безнең бөтенебезне дә буйсындыра иде.

Кайчан гына күрмә, ул җиңнәрен сызганган, биленә кар кебек апак алъяпкыч бәйләгән була иде. Мин аның әле яңа гына калкып килгән күкрәген каплаган, чит-читләре бөрмәләп тегелгән шушы алъяпкы-

чын күргәч тә, аптырап кала идем һәм аннан көнләшә идем. Валлаһи, шушы алъяпкыч та мине көнләштерә иде. Чөнки җилкәләренә, кулбашларына һәм күкрәгендәге калкулыкларга сыланып, ябышып торган бу алъяпкыч, җансыз булса да, миңа караганда мең тапкыр бәхетле иде кебек.

Ул безнең кое суының йомшаклыгын сылтау итеп безгә кергән кебек, мин дә юк йомышны бар итеп аларга бик еш керә башладым. Һәм кергән саен үземнең йөрәгем түрендә икенче бер йөрәк барлыгын, шуның тибүен сизгәндәй булам, шуның көннән-көн көчәя баруын сизә идем.

Шулай бер керүемдә мин аларның солы җирендәге чүп үләннәрен утарга барырга хәзерләнгән чакларына туры килдем. Ул көнне Шәйхевәли абзый олы малае белән тегермәнгә киткән икән, шунлыктан без утауга җәяү киттек. Солы җиренә житү белән аякларыбызны чишеп, анда-санда күренгән билчәннәрне утарга керештек. Эш озакка бармады, хәтта тамак та ялгарга туры килмәде. Без кайтырга кузгалдык. Шул вакыт Гөлсем безгә карап:

— Бер килгән килеш, кайтышлый әрәмәлеккә кереп мәтрүшкә дә җыеп чыгыйк инде, әнигә бик кирәк ул,— диде.

Без риза булдык. Әрәмәлеккә килеп керү белән, мәтрүшкә эзләп, төрлебез төрле яккааралдык. Гөлсем белән миңа ничектер янәшә йөрергә туры килде.

Менә шулай без Гөлсем белән тау араларындагы әрәмәлектә мәтрүшкә җыеп йөргәндә ниндидер сәбәп белән оясыннан егылып төшкән бер кечкенә, әле яңа гына йон чыга башлаган, сыек-сары борынлы былбыл баласына тап булдык. Шул чак Гөлсем болай да гел тал чыбыгы кебек уйнаклап торган гәүдәсе белән җиргә иелде һәм әлеге былбыл баласына озак кына карап торды:

— Вагыйз, бу бәләкәч әле яңа гына егылып төшкән бугай, аның әле иреннәре дә кипмәгән, бик юеш,— диде һәм, кошчыкны иппләп кенә алып, сул кулының учына салды.

Гөлсемнең кеп-кечкенә һәм бик йомшак учын былбыл баласы үзенә оя дип санагандай, шул минутта ук ниндидер бер хәрәкәт ясап алды. Мин бер Гөлсемнән, бер былбыл баласыннан күзләремне ала алмыйча, вакыт-вакыт икесенә берьюлы карап гаҗәпләнеп тордым. Болар икесе дә былбыл балалары кебек тоелды миңа. Аларда күзгә күренми торган бер сабыйлык, нәфислек һәм берничек тә аңлата алмаслык матурлык күрдем мин. Шул матурлык каршында тез чүгәсем, зәңгәр күккә карап кемгәдер дәшәсем, нәрсәдер әйтәсем килде. Әле көпә-көндез булса да, бу минутларда безнең өстебезгә гүяки йолдызлар коелган кебек булды. Шул йолдызлар белән бергә Гөлсемгә һәм аның кечкенә учындагы былбыл баласына карап, әллә нинди бер хәлдә калдым. Сыңар кул учына сыярлык бик бәләкәй былбыл баласы белән Гөлсем икесе бергә минем йөрәгемә кереп урнаштылар. Шуларга тәэсирләнеп карап торганда, тик үзенә генә хас йомшак тавыш белән Гөлсем миңа дәште:

— Вагыйз, бу бәләкәчнең оясы әнә теге яфракка күмелеп утырган агач ботагында бугай, син аны үз оясына меңгереп куй инде, — диде.

Ул ымлап күрсәткән агачны мин шунда ук күреп алдым һәм:

— Әйдә, Гөлсем, мин ботакларга тотынып югарыга менәрмен, ә син үрелеп былбыл баласын миңа бирерсең,— дидем.

Без агач төбенә килеп бастык. Мин ботакларга тотына-тотына өскәрәк күтәрелдем һәм шунда кош оясын күрдем дә Гөлсемгә таба түбәнгәрәк төштем:

— Бир бәләкәч былбылны!— дидем.

Ул:

— Кулыңны артык кысып тотма, Вагыйз, имгәнә күрмәсен былбылкай,— диде.

Кошчыкны бик зур саклык белән кулыма алып оясына куйдым да жиргә төштем.

— Менә әйбәт булды, Вагыйз,— диде Гөлсем.

Аның шулай дию булды — яфраклар арасыннан гаҗәп матур сайраган кош тавышы ишетелде. Бу әлеге бәләкәчнең әнисе иде бугай. Күрәсең, ул шатлыгыннан сайрап җибәргәндер инде. Без Гөлсем белән шулай уйладык һәм мәтрүшкә эзләвебезне дәвам иттек.

...Нәкъ менә шул җәйне, күп тә үтмәде, көтмәгәндә малайлар белән кызлар арасында килеп чыккан бер вакыйга аркасында Гөлсем уңайсыз хәлдә калды һәм миңа аны шуңардан коткарырга туры килде. Бу менә ничек булды.

Безнең авылның буеннан-буена агып узган инеш берничә урында кинәт кенә борылмалар ясап үтә иде. Шул борылмалы урыннарның берсендә малайлар, икенчесендә үсмер кызлар су коеналар. Көннәр бик кызу тора иде. Ул көнне авылдагы барлык бала-чага иртәдән кичкә кадәр инеш буенда булды. Барыбыз да су коенабыз. Көн шул кадәр кызу ки, ярга чыгып чүгәләп бераз гына утырасың да яңадан суга чумасың. Кызлар да шулай. Менә берчакны алар арасында кинәт шау-шу купты. Алар, ашыга-ашыга судан чыгып, нишләргә белмичә күлмәкләрен-күкрәкчәләрен эзли башладылар. Ләкин күпме эзләсәләр дә таба алмыйлар. Баксаң, аларның барлык киемнәрен кемнәрдер каядыр яшергән икән. Кием-салымнарын таба алмагач, кызлар яңадан суга керәләр, шунда ук яңадан ярга чыгалар да күлмәкләрен тагын эзлиләр. Ләкин тагын табылмый. Араларыннан берсе башкаларына карап:

— Әле генә яр буеннан теге янчек борынлы Гәйсә узып китте. Ул бик астыртын малай. Мөгаен, безнең күлмәкләребезне шул суга салып агызгандыр,— ди.

Кызлар елаша башлый. Бөтенесе дә шәрә бит, ничек кайтмак кирәк? Тагы инешкә төшеп, башларын гына судан чыгарып, яр кырыенда үзара шаулашалар. Бу шактый вакыт шулай дәвам итте. Ниһаять, бу эзләүгә без малайлар да килеп кушылдык һәм ындыр читәне буена яшереп, өстен ботак-сатаклар белән каплап куелган бер өем күлмәкләр, күкрәкчәләр, яулыклар таптык. Кызлар шатлыкларыннан нишләргә белмәде. Ләкин Гөлсем ничаклы гына эзләсә дә, үз күлмәген табалмады. Яшереп куелган өемдә юк иде ул. Аптырагач, иптәш кызлары үз яулыкларын, күкрәкчәләрен биреп, аны юатырга тотындылар һәм безгә:

— Малайлар, сез ник шаккатып калдыгыз, табып бирегез Гөлсемнең күлмәкләрен!— дип кычкыра башладылар.

Бу тавышны ишетү белән, әлбәттә, иң элек мин аякка бастым һәм иптәшләремә:

— Әйдәгез, малайлар, таллыкка! Шунда яшергәннәрдер бәлки?— дип аваз салдым. Арабыздан бер малай моны хуплады:

— Шунда булмыйча кайда булсын, әйдә, киттек, малайлар!

Таллыкка кереп, ешкынлыкка атлый башлауга Гәйсәне очраттык. Ул гадәттә безгә катнашмый, гел берүзе генә йөри һәм, чыннан да, бик тешләк һәм астыртын малай иде. Күрү белән, алдан сүз берләшкән кебек, җыйнаулашып аны камап алдык:

— Гөлсем киемен кая яшердең, хәзер үк китереп бир!— дип бугазыннан ук барып тоттым мин.

Тавышка кызлар җыела башлады. Мин аның саен Гәйсәне җилтерәтәм:

— Хәзер үк алдыбызга китереп куй!

Малайлар куәтлиләр: Башсыз калырга теләмәсәң, хәзер үк китереп бир!

Гәйсә бер агарды, бер кызарды. Күренеп тора, курка калды. Түбәнгә, аяк очларына карап, үзен акларга теләгәндәй, юаш кына тавыш белән:

— Мин бит аны юри генә, шаярып кына яшергән идем,— диде.

Бу сүзләрдән мин яңадан кабынып киттем:

— Ә ник Гөлсемнекен генә аерым яшердең? — дип якасыннан алдым.

— Гөлсемнеке бит ул. Шуңа күрә аерым яшердем...

— Ни өчен?

— Ул бит борынын бик югары чөеп йөри. «Эзләбрәк алсын әле» дип юри еракка куйган идем. Бөтенегез дә минем өскә ябырылып килерсез, дип кем уйлаган аны,— диде ул, борынын тарта-тарта. Башта шулай ык-мык итсә дә, кинәт башын күтәреп безгә карады да калтыранган тавыш белән:

— Әйдәгез, бергә барып алыйк. Тик миңа тимәгез,— диде.

Без аның артыннан куе таллыкка атладык. Күп булса унбиш-егерме адым атлаганбыздыр, Гәйсә әйтеп куйды:

— Сезнең ул Гөлсемегез очраган саен мине күрмәмешкә салышып үтә. Үзен бик эре тота. Ачуым килгән иде, эзли-эзли интексен әле дип еракарак яшергән идем,— диде.— Әнә, ботак очы төйнәлгән талны күрәсезме? Шуның янындагы әрекмән астында,— диде Гәйсә.

Әйтелгән урынга килеп җиттек. Ындыр табагы хәтле бу урынны бик зур һәм бик калын яфраклы әрекмән каплап алган иде. Араларына күлмәкләр, күкрәкчәләр генә яшерү түгел, кеше кертеп яткырсаң да күренмәслек иде. Гәйсә берничә төп әрекмәннең яфракларын уңга-сулга авыштыргалады да, шулар арасыннан ыклап төрелгән зәңгәр күлмәк алып, безгә сузды: «Мәгез!»

Мин малайлар арасыннан атылып чыктым да Гәйсә кулындагы күлмәккә сузылдым:

— Малайлар, мин киттем, анда, яр буенда Гөлсем шәрә утыра торгандыр!— дип инешкә таба чаптым. Аякларым тигән җиргә тиде, тимәгән җиргә тимәде, әйтерсең, кош булып очтым!..

Таллыктан чыгып кара бөрчекле зәңгәр күлмәкне болгый-болгый үзләренә таба йөгергәнемне инеш буендагы кызлар бик тиз күреп алдылар һәм бер-бер артлы Гөлсемгә кычкырдылар:

— Киемеңне тапканнар!

— Вагыйз тапкан, Вагыйз, ул тапмый калмас!

Яннарына мин килеп җиткәндә, Гөлсем судан башын чыгарган килеш көтә иде. Шул арада бүтән малайлар да килеп җитте. Берничә адым гына арттарак Гәйсә дә бар иде.

Гөлсемнең күлмәк-яулыкларын аның турына, яр буена куйдым. Ул үзе суда килеш миңа гаҗәеп бер йомшак тавыш белән:

— Гәйсәгә тимә син, Вагыйз!— диде.

Сүзләре миңа әллә кайлардан, бик ераклардан ишетелгән кебек тоелды: «Гәйсәгә тимә син, Вагыйз!». Гөлсемгә нәрсә дияргә дә белмәдем һәм малайлар янына кире атладым. Ләкин алар арасында Гәйсә юк иде. Күрәсең, ул безнең белән бергә кайтырга я уңайсызланган, я курыкккандыр. Без — кызлар да, малайлар да бергә, инешнең бик тар һәм бик тирән урынындагы басмага таба атлаган гына идек, бер баланы тыны-көне бетеп, кычкыра-кычкыра безгә таба йөгереп килгәнен күрдек. Ул:

— Гәйсә абый басмадан чыкканда аягы таеп суга төште, аны упкын суырды!— дип кычкырды.

Шуны кабатлый-кабатлый, әлеге малай янибызга килеп җитүгә, Гөлсем миңа кычкырды:

— Вагыйз, тизрәк коткар!

Мин Гөлсемнең Гәйсәгә карата болай шәфкатьле, мәрхәмәтле булуын ничектер тиз генә аңлап җитә алмадым һәм басмага таба атылдым. Суга сикереп төшү белән упкын уртасыннан чыга алмыйча бер батып, бер калкып газапланган Гәйсәне сыңар кулым белән эләктереп алдым да бар көчем белән ярга өстерәдем. Ләкин кайнап, бөтерелеп торган куркыныч бу упкын безнең икебезне дә кинәт төпкә тарта башлады. Авызларыбызга су тулды. Без быкырдый-быкырдый аска — җәһәннәмгә киткән кебек булдык. Тагы калкып чыктык. Һәм бусында мин, тагын бар көчемне җыеп, ярга таба соңгы тапкыр омтылдым. Шул вакыт колак төбемдә Гөлсемнең баягы тавышы яңадан ишетелгәндәй булды:

— Вагыйз, Гәйсәне тизрәк коткар!

Бу тавыш көзән җыера башлаган аякларымны яңадан хәрәкәткә китерде, авызыма тулган суларны бөркеп чыгара-чыгара Гәйсәне сөйрәп тагы берничә тапкыр омтылуга хәтәр упкыннан ычкынуыбыз булды.

Яр буена килеп җитәр-җитмәстән, кызлар һәм малайлар безне күтәреп җиргә чыгардылар. Берничә минуттан инде минем сулу алуым ачылды. Ә Гәйсәнең хәле мөшкел иде. Ләкин бу фаҗигане ишеткән өлкәннәр һәм Гәйсәнең әтисе килеп җиткәч, алар суга батканнарга ярдәм итүнең барлык чараларын күреп, аны да аңына китерделәр.

Гәйсәнең әтисе Миңнулла абый бу авыр хәбәрне басудан кайтышлый ишеткән булган һәм ул монда җигүле ат белән килгән иде. Гәйсәне арбага сузып салып, яр буеннан кузгалып киткәндә, ул малайларга һәм кызларга карап, әчке кичереш белән:

— Кемнең чын дус икәнлеге бәлагә очраганда беленә ул, балалар! Гәйсәне упкыннан тартып алганыгыз өчен барыгызга да рәхмәт. Ә сиңа, Вагыйз туган, беренче булып Гәйсәгә ярдәм кулы сузуың өчен аеруча зур рәхмәт. Һәркайчан шулай булыгыз, бер-берегез өчен утка да, суга да керегез, куркак булмагыз! — диде.

Алар тыкрыктан менеп киткәч, мин әчемнән үземә-үзем сорау биреп, аптырабрак калдым, ничек болай булды соң әле бу? Мин бит Гөлсемнең күлмәкләрен яшергәне өчен әле бая гына аның якасыннан алган идем. Гөлсем аның суга батканлыгын ишетү белән миңа кычкырды: «Вагыйз, тизрәк коткар Гәйсәне», диде бит. «Әгәр Гөлсем шулай димәсә, мин, белмим, Гәйсәне коткару өчен суга ташланыр идемме икән?» — дип уйлап алдым һәм кинәт иптәшләремә: «Гәйсәне упкыннан Гөлсем тартып алды!» — дип кычкырасым килде һәм шулай дип кычкырдым да. Ләкин шунда ук Гөлсем тавышын ишеттем:

— Юк, мин генә түгел, без бөтенебез бергә тартып алдык!

Гәйсә икенче көнне үк аякка басты.

Шулай итеп бу фаҗигале вакыйганың ахыры аяныч булмады булуын. Әмма шул елның көзендә язмыш безнең яшь җаннарны икенче зур кайгыга дучар итте.

Инде көз җитеп, басулар игеннәрдән бушап калды, ындыр башлары икe көлтә белән очланган кибәннәр белән тулды, бәрәңге алулар тәмамланды, талку алдыннан киндер көлтәләрен суга салып йомшарту вакытлары җитте. Көзге ачы җилләр искән чакларда чайкала-чайкала утырган агачлардан сап-сары яфраклар коела башлады. Ә җил аеруча көчәйгән көннәрне саргайганнары гына түгел, ямь-яшел яфраклар да коелгалады. Көзнең салкын һәм ачы җилләре аларны әйләндерә-әйләндерә йөртәләр дә, ниһаять, киң инеш өстенә илтеп салалар. Инеш исә бу яфракларны без белмәгән-күрмәгән якларга агызып алып китә иде.

Безнең иң якын дустыбыз Гөлсемнең дә язмышы — нәкъ менә шул яшьләй өзелгән яфраклар язмышы кебек булды. Әле генә телгә алынган җилле-давыллы, салкын көзге көннәрнең берсендә без, Бастамнар белән бер арбага утырып, урманга чыбык-чабык алып кайтырга киткән

идек. Шул көнне Гөлсем әнисе белән күп итеп кер юган һәм шул кер-ләрен чайкарга инеш буена төшкән. Ул, җиңнәрен һәм балакларын сызганган килеш суга кереп, шактый вакыт керләр чайкаган һәм көтмәгәндә карлы-бозлы яңгыр астында калган. Тирләп-пешкән килеш бар-лык керләрен күтәреп, тәмам хәлдән таеп өйләренә кайта алган һәм шунда ук түшәккә ауган. Без урманнан кайтып кергәндә, ул бик авыр сулап ята иде. Иртәгесен дә урыныннан тора алмады. Ике тәүлек бер нәрсә капмыйча, көчкә сулу алып бик авыр хәлдә ятты да өченче тәү-лек киткәндә кичен җан тәслим кылды...

Без Бастамнар белән тәмам аптырашта калдык. Башларыбыз түбән иелде, тамакларыбызга нәрсәдер тыгылган кебек булды, бер-беребезгә ничек дәшәргә дә белмәдек, аптырап калдык. Бөтен авыл өстен кара болыт каплагандай булды. Ул төн өйгә кереп-чыгып, йокысыз үтте. Икенче көнне төш вакытында гәүдәсен зиратка алып киттеләр. Анда без дә бардык. Бик сәер тынлыкта мәет ләхеткә төшерелде. Аннары, кабер өстенә туфрак өеп, аның башына язулы ак таш утырттылар. Шул арада без, малайлар, өлкәннәр алдан ук әйтеп куйганча, якындагы чирәмлектән ямь-яшел кәсләр кисеп алып килдек. Олылар кабер өстен шул кәсләр белән каплады лар да, күз яшьләрен сөртә-сөртә, зират кап-касына таба кузгалдылар. Без алар артыннан атладык. Без капкадан чыкканда, сибәләп кенә яңгыр явып үтте. Өлкәннәр арасыннан бер ба-бай әкрен генә:

— Яшь җанның вакытсыз гүр иясе булуына без генә түгел, күк тә җылый әнә,— диде.

Шуннан соң күпме җилләр исте, күпме сулар акты, күпме еллар үтте инде. Безнең гаҗәеп мөлаем йөзле, йомшак күңелле, бик инсафлы һәм мәрхәмәтле Гөлсемебез гомеребез буйларына онытылмады. Ул истә, һаман да истә...

## Рифгать Закиров

### Күпер чыкканда

Агым булып гөрләп килеп керә
Ярсу поезд тимер күпергә,
Вагоннары уза тезелеп кенә,
Ялгангандай гомер гомергә.

Ә аръякка чыгып җитәр-җитмәс
Ыргыла ул искән җил кебек.
Озак чыңлый күпер, поезд үткәч,
Тартылуы җиткән кыл кебек.

...Күпер-терәк бул син миңа, чорым,
Йөгем булсын күбрәк, саллырак:
Гасырларга ишетелсен җырым
Синең аша күкрәп — яңгырап!

### Төннәр буе мине йокы алмый...

Кеше күңелен көндез ачык күрәм,—
Ни күрсәм дә җиңел кичерәм;
Төнлә барысын искә төшерәм дә
Хакыйкатькә аннан төшенәм.

Төннәр буе мине йокы алмый:
Нинди генә уйлар уйлатмый!..
Көндез аек, төнлә уяу намус,
Шулар ахры, мине йоклатмый.

### Кайтаваз

Торам тыңлап: юмартлыкка — юмарт...
Тик алдаша бугай кайтаваз:
«Бушбугаз!» дип, мин кычкырдым уйнап,
Ә ул җавап бирде: — Яз!.. Яз!.. Я-а-з!..

Кабат сынап оран салдым чынлап:
— Әйт, гомерем азмы, күпме? — дип.

Тау-ташларны урап кайтты чыңлап:
— Күп, к-ү-ү-п, к-ү-ү-ү-п!..

— Әти кайда-а-а-у?..— дип кычкыргач исә,
Кинәт кенә дөнья тын калды...
Тау көрсенеп тирән тын алды да,
Җанны үксетерлек моң калды...

●

Үзгәргән дә сыман, юк та сыман
Үзәндәге күксел-юка томан...
Күктә гизгән үтә аксыл болыт
Канат җилпи гүя аккош булып.

Әллә рәшә, әллә көмеш канат
Тау битләрен сыйпый кабат-кабат.
Үлән тибри үрдә ымсындырып,
Үткән гомерләрне юксындырып.

Ямьле, матур көннәр искә төшә...
Бу көнем дә гөлгә тиң, югыйсә!
Һаман моңга гашыйк күңел генә
Тынгы табар төсле түгел менә.

Хәйран заман!.. Тик мин нигә һаман
Елап-көлеп җиңеләеп калам,
Табигатьнең керсез кочагына
Авырайган башны куйсам гына?..

## Эдуард Мостафин

### Уйлан, кеше

●

Саллар саллап маташканбыз —
Кораблар да төзеп булган.
Инештә чыпырдаганбыз —
Диңгездә дә йөзеп булган.

Агач атларда «чапканбыз»,—
Чаптар атлар биеп торган.
(Без уйнап йөргән арада
Кошлар яңа оя корган).

Сабый булып кыланганбыз,
Күптән ирләр икәнбез бит:
Зәңгәр хыял илләреннән
Ташлы ярга җиткәнбез бит —
җилкәнбез бит!

Бала чактан ниләр алдык
Ирләр булып баскан ярга? —
(Теге ярдан монда килеп
Кош күкәен урлый карга).
Яланаяк басып барам
Мең ел элек төшкән карга.

●

Мич җылысы гына җитми җанга,
Синнән килгән җылы кирәк миңа!
Салкыннарда туңмас өчен
Нинди дога була, өйрәт миңа:

Өйрәт мине күңел хәрлегенә —
Сүзләр көчсез, килеп кайгы кочса.
— Очу — бәхет,— дисең. Син кошларны күзәт
Көзге сары күктә алар очса.

Намус дигән төшенчәне беләм,
Әмма төше аның — җан түрендә.
Өйрәт миңа: ничек саклыйм — аның
Төшен даулап — хәшәрәтләр үрелгәндә.

Өйрәт мине, кулга кашык тотып
Ботка ашый алалмаган «мин»не.
...Син өйрәткән мәлдә күпме акыл
Йолдыз булып җирдән күккә менде.

Яраланган ерткыч явызлана гына —
Үтермәстәй булгач нигә кизәнергә.
Аучы булып түгел, яңа елда куйган
Чыршы булып иде сиңа бизәнергә.

Бер ерткычтай күреп яраладың мине,
Сиңа үчем сөю булып арта бары.
Яңа елда чыршы сокланырлык иде.
Бүген кышның акты менә соңгы кары.

Күкрәп кара әле язгы аваз булып,—
Нинди илаһилык, күпме моң бар анда!
Мин бер поши баласыдай килеп
Ул авазга кушылырмын салкын таңда...

Ярам тирәнәйгән саен — мин бәйлерәк
Була барам синең кырыс ихтыярга.
Яраланган ерткыч кан эчендә
Ярсуыннан улый башка ярда.

Ерткычмы мин, поши баласымы? Ә син,
Син шуларның кайсын яраладың икән.
Әллә аваз биргән бала поши җанын
Ерткыч тешләреннән араладың микән?
Яраладың микән?

●

Уйга батып калган кеше,
Ни тапкан да ни югалткан
Җир белән күк арасында?
Кояш баткан, Ай калыккан.

Чалкан ятып болыт йөзә,
Дулкын сөзә сөзәк ярны.
Йолдызлар янган мизгелдән
Серлерәк бер мизгел булмы?!

Барын күздән кичерә ул,
Барын барлап, үлчәп карый.
Уйга баткан чакларда да
Кеше тау ишкәндәй арый.

Уйларында йолдыз алып
Сөйгәненә бүләк итә,
Уйларында яланаяк
Балачакка кайтып китә.

Кеше уйда болытларны
Дулкын белән кавыштыра.
Тик һәрвакыт колагында
Кисәткәндәй тавыш тора:

Туйма, кеше, уйла, кеше!
Тик онытма үзеңне дә.
Ни югалттың? Эзләп кара —
Ятмый микән үзәнендә».

Кеше, уйларыннан айнып,
Салмак кына китә атлап.
Күктән төшкән болытлардай,
Тайлар йөри үлән утлап.

## Әмир Мәхмүдов

### Мизгелләр

●

Сөйкемле зат,
Син булганда минем янда,
Алтын нурда җиһан сарае.

Поезд китә...
Нурлар сүнә алтын офыкларда,
Күк гөмбәзе кала караеп...
Зур дөньяны сыйдыралган күңелем
бер мизгелгә кала сагаеп...

Поезд китә... сезнең якка.
Бәхет аккошлары очып үтә,
Әйткән сыман:
— Мәхәббәттән үлмә саргаеп...

...Бушап калдың, җиһан сарае!

### Гитара

Күктә кушыла җисемнәр,
Якыная аралар.
Нечкә билле чибәр кебек
Моңая гитаралар.

— Җирдә мәхәббәт патша!— дип,
Җырлата гитаралар.
Гыйшык утын кабындыра,
Елата гитаралар.

Йолдызлар мәллә коела
Гитара кылларына.
Йөрәкләренә тынгы юк,
Йокламый кызлар гына:
— Синең арттан җир читенә
Китәм,— дип,— җырла гына.

Төнге каланы йоклатмый
Бер таныш тавыш кына:
Таныш түгел йөрәкләрне
Гитара таныштыра,
Гитара кавыштыра!

●

Каеннарның барысы да зифа түгел.
Даруларның һәммәсе дә шифа түгел.

Нәни агач та тамырын суза тирән.
Йомшак җиргә дә кайвакыт керми тәрән.

Яраланган кош та күктә горур оча.
Арыслан да алышканда тирләп пешә.

Кыю чәчкә үсеп чыга кыя ташка.
Кул җитмәслеген белсәм дә,
Тотам, дип, һаман үреләм
Мин кояшка.

●

Җиргә атылган бөркеттәй
Зәңгәр таулар кочагына
Бер атыласы иде!
Кинәт тотылган кояштай
Сөйгәнеңнең кочагында
Бер онытыласы иде...

Яңа туган ак ай кебек
Бер яңарасы иде.
Безнең яшьлек мәхәббәте
Күктәге яшеннәр булып
Бер ялтырасын иде,—
Дөньядагы дәрьяларның,
Шарлавыкларның җырында
Гел яңгырасын иде!

................

К. Фасеев,
философия фәннәре докторы

# КИЛӘЧӘГЕ ТАГЫН ДА МАТУРРАК

Кайсы өлкәне генә алма, совет халкы үзенең данлы авангарды — даһи Ленин төзегән Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә дөньякүләм-тарихи казанышлар яулады. Шулардан берсе — әлбәттә, хезмәт кешесенең бөеклеген раслаучы һәм аны тагын да югарырак күтәрә торган яңача яшәү рәвеше. Бу хакта партиянең XXV съездында бик төгәл әйтелде: «Чын коллективизм һәм иптәшлек атмосферасы, илебезнең барлык милләтләре һәм халыкларының көн саен ныгый баручы тупланганлыгы һәм дуслыгы, безне көчле, нык итә торган әхлак сафлыгы — яшәү рәвешебезнең якты сыйфатлары әнә шундый, социализмның чынбарлыгыбыз җанына һәм канына сеңгән бөек казанышлары әнә шундый». КПССның шуннан соңгы XXVI съездында да социалистик яшәү рәвешен камиллəштерү мәсьәләсенә бик зур игътибар бирелде.

Яшәү рәвеше — гаять киң төшенчә. Аңарда кешеләрнең эше, холык-фигыле, үзүзләрен тотышы да, ихтыяҗы һәм бер-берләре белән мөнәсәбәте дә чагылыш таба. Кешенең экономик, социаль-политик һәм рухи сфералардагы эшчәнлеге дә шушы төшенчә белән билгеләнә. Әлбәттә, һәр кешенең үзенә генә хас характерга, сәләт һәм ихтыяҗларга ия булган аерым шәхес икәнлеген дә күздә тотарга кирәк. Шул ук вакытта кешеләр билгеле бер җәмгыятьтә яшиләр һәм шушы җәмгыятьтәге яшәешкә, яшәү рәвешенә җайлашалар. Ул гына да түгел, һәр кеше ниндидер бер милләт яки халык вәкиле булганлыктан, аның тормышында милли үзенчәлекне күрмәү мөмкин түгел. Шулай итеп, яшәү рәвеше бер яктан — гомумсоциаль, ә икенче яктан милли күренеш булып тора.

Социалистик яшәү рәвеше барыннан да элек интернационализм рухы белән сугарылган. Башкалардан ул нәкъ шушы сыйфаты белән аерыла. Аның тамырлары тирән тарих катламнарына барып тоташа. Кешелек үсеше алга киткән саен, иҗтимагый тормыш интернациональләшә бара.

Тарихи котылгысыз закончалык бу. Ләкин буржуаз җәмгыятьтә моны танырга теләмиләр. Киресенчә, аны — интернациональләшү процессын — ничек тә тоткарлап калырга тырышалар. Милләтнең өстенлек итүче эксплуататор даирәләре хезмәт ияләренең сыйнфый аңын томалау максаты белән алар тормышындагы һәр милли күренешне куертып һәм күпертеп күрсәтәләр, төрле милләт һәм расалар арасында берберләренә карата нәфрәт, күрәлмаучылык хисе уяталар, дошманлык уты кабызалар. В. И. Ленин бик төгәл әйтеп биргәнчә, ниндидер бер «милләтне тәшкил итүче сыйныфлар арасындагы каршылыкларны ясалма рәвештә читләтеп үтүгә корылган» «гармоник бөтенлекле милләт» (В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 2 том, 213 бит) төшенчәсе ярдәмендә буржуазия кабиләчелек, милли һәм дини конфликтлар китереп чыгара, канкойгыч сугыш учагы кабыза, хезмәт халкының игътибарын төп социаль проблемалардан читкә юнәлтә. Шулай итеп, ул массаларны социаль һәм милли иректән мәхрүм итә, аларның яшәү рәвешен имгәтә. Эксплуататор сыйныфлар үткәреп килә торган расачылык, геноцидлык, колониаль изү политикасы нәкъ менә шушы нигезгә корылган.

Җәмгыять үсеше яки кешеләрнең көнкүреше, үз-үзләрен тотышы һәм әхлакый сыйфаты иң элек сыйнфый-социаль каршылыклар белән билгеләнә. Бу каршылыклар-

ны ясалма рәвештә кабартылган милли ызгыш-талашлар да яшереп кала алмыйлар, алар торган саен ныграк өскә калкалар һәм хезмәт кешеләренең яшәү рәвеше формалашуда хәлиткеч роль уйныйлар.

Яшәү рәвешен билгеләүче төп фактор — хезмәт. Бер милләт кешеләренең икенче милләттәгеләр белән аралашуы нигезендә дә нәкъ менә хезмәт ята. Белүебезчә, кеше үзенең кеше булып формалашуы өчен хезмәткә бурычлы. Ә гомумән алганда, бөтен кешелек хезмәтсез яши алмый. Шуңа күрә хезмәт үзенең характеры белән интернациональ. Әйтик, хезмәтнең бер генә төре (материаль җитештерү яки рухи хезмәт) белән дә шөгыльләнмичә, башкалар хезмәте хисабына яшәүчеләрне без сорыкортлар, паразитлар дип атыйбыз. Нәкъ менә шундыйлар, кагыйдә буларак, милләтләр арасында төрле бәрелешләрне барлыкка китерәләр. Бу уңай белән К. Маркс язганга күз салыйк: «Иске җәмгыятьнең югары дәрәҗәле кешеләре һәм хакимлек итүче сыйныфлары бары тик милли көрәш һәм милли каршылыклар ярдәмендә генә... үзләренең властен саклап кала һәм халык массаларын эксплуатацияли алалар» (К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр, 33 том, 165 бит).

Җәмгыятьнең материаль һәм рухи байлыкларын булдыручы, тарихны чын-чынлап үз куллары белән иҗат итүче киң халык массалары исә бер-берләрен яхшы аңлыйлар. Аларны гомуми хезмәт шулай якынайта.

Тормыш ихтыяҗлары төрле милләт хезмәт ияләрен бер-береннән аерып торучы киртәләрне җимерә. Мәсәлән, капитал тарафыннан бер предприятиегә тупланган эшчеләр тора-бара нинди милләттән булуларына игътибар итүдән туктыйлар, киресенчә, бер-берләренең хәленә керәләр, яшәү шартлары турында бергәләп уйлашалар, ярдәм итешәләр. Төрле милләт крестьяннарына карата да нәкъ шуны әйтергә мөмкин. Моңа илебез халыклары тарихыннан күпләп мисал китерергә була. Идел буенда яшәүче рус, татар, чуваш, мари, мордва, удмурт крестьяннары, байлар һәм дин әһелләре һәртөрле дошманлык коткысы таратуга, үзләренең дини һәм милли аерымлыкларына да карамастан, даими аралашып яшәгәннәр, чәчүлек, ат, сабантырма кебек эш кораллары белән алыш-биреш иткәннәр, печәнгә һәм уракка төшкәч, бер-берләренә ярдәмгә килгәннәр. Алай гына да түгел, крепостнойлыкка каршы, җир һәм азатлык өчен бергәләп көрәшкә күтәрелгәннәр. Кыскасы, хезмәт — халыкларны бер-берләрен ныграк аңларга, аларны теләктәшлек кадерен белергә өйрәтә торган бик шәп мәктәп ул.

Төрле милләт кешеләренең үзара аралашуы милләтләр оешкан көннәрдән үк башланган. Җитештерүче көчләргә ихтыяҗның артуы авылда крепостнойлык мөнәсәбәтләре таркалу, феодальлек богавын өзеп ату, ата-баба туфрагында ачы тир түгеп тә мохтаҗлыкта яшәү һәм башка шундый сәбәпләр кешеләрне бәхет эзләп читкә китәргә, үз милләтләреннән аерылырга, башка милләт кешеләре белән аралашырга һәм аларның яшәү рәвешендәге кайбер сыйфатларны үзләренә алырга мәҗбүр иткән.

Әйе, бергәләп эшләү һәм яшәү, промышленность пролетариатына якынаю, эшчеләр сыйныфының революцион позициясенә басу — болар бөтенесе иҗтимагый тормышның интернациональләшүенә илтүче адымнар. Эшчеләр сыйныфы исә, үзенең көрәш тәҗрибәсенә таянып, бер халыкның икенче халык исәбенә яшәргә тиеш түгеллеген башка сыйныфларга караганда яхшырак аңлый. Ул үз милләте мәнфәгате өчен көрәштә һич кенә дә аны башка милләтләрнең мәнфәгатенә каршы куймады. Данлы Коммунистлар партиясе рус пролетариатын да, илебездәге рус булмаган башка милләтләр пролетариатын да нәкъ менә шушы рухта тәрбияләде. Төрле милләт хезмәт ияләре эшчеләр сыйныфы белән иңгә-иң атлап барганда гына, пролетар интернационализм байрагы астына тупланганда гына милли һәм социаль азатлык өчен көрәштә җиңеп чыгуга исәп тота алалар иде. Ул нәкъ шулай булды да. Пролетариат һәм аның большевиклар партиясе җитәкчелегендә көрәшкә күтәрелгән хезмәт ияләренең кайнар теләктәшлеге илебездә Бөек Октябрь социалистик революциясе җиңеп чыгуда төп шартларның берсе иде. Бу исә яңача яшәү рәвеше тууга капкаларны киң ачты.

Барлык милләт хезмәт ияләрен туганлаштырган, аларның бер-берләренә хезмәттәшлек һәм дуслык нигезләрен булдырган яңа дәвер нәкъ менә Бөек Октябрь иртәсеннән башланды. Илебез халыклары шушы тарихи көннән соң бәхетле тормыш юлыннан атлап киттеләр. Аларга бер-берләренең яшәү рәвешендәге иң матур үрнәк-

ләрне үзләренә алу өчен бөтен шартлар тудырылды. Милләтләрнең балкып чәчәк атуы өчен бернинди тыюлар да, эзәрлекләүләр дә юк хәзер. СССРда яшәүче төрле раса, төрле милләт гражданнары тигез хокукларга ия. Аларның бу хокуклары СССР Конституциясендә закон тәртибендә алтын хәрефләр белән язып куелды: «Бу хокукларны тормышка ашыру СССРдагы барлык милләт һәм халыкларны һәрьяклап үстерү һәм үзара якынайту политикасы белән, гражданнарны совет патриотизмы һәм социалистик интернационализм рухында тәрбияләү белән, туган телне һәм СССРдагы башка халыклар телләрен куллану мөмкинлеге белән тәэмин ителә» (СССР Конституциясенең 36 статьясы). Алай гына да түгел, безнең Совет Ватанында гражданнарның хокукларын аз гына чикләү дә, аларга нинди расадан һәм милләттән булуларына карап аз гына өстенлек бирү дә закон тарафыннан тыела һәм хөкем ителә.

Әле узган гасырда ук Ф. Энгельс болай дип язган иде: «Милли изүне бетерү һәртөрле сәламәт һәм ирекле үсешнең төп шарты булып тора» (К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Әсәрләр, 35 том, 221 бит). Гасырлар буе колониаль изелүдә яшәгән халыклар үз милли тормышларын үзләренчә кору белән тирәнтен кызыксындылар. Бу аларның законлы таләбе иде. Илебездә социалистик революция җиңеп чыкканнан соң барлык халыкларга моның өчен бөтен мөмкинлекләр бирелде.

Совет Социалистик Республикалар Союзы төзелү барлык милләт хезмәт ияләренең иң изге өметләренә һәм мәнфәгатенә җавап бирүче ленинчыл милли политиканың гүзәл казанышы булды. «СССР төзелүнең 60 еллыгы турында» КПСС Үзәк Комитеты карарында әйтелгәнчә, «Бик кыска вакыт эчендә милләт һәм халыкларның һәрьяклап үсеше өчен безнең барлык халыкларның социалистик Ватаны — СССРдай шулкадәр дә күп эшләгән дәүләтне тарих белми» («Коммунист», 1982, № 4, 4 бит).

Илебез халыклары бердәм дәүләт союзына ирекле рәвештә берләшүнең өстенлегенә: аларның социалистик суверенлыгын тәэмин итүенә үз тормыш тәҗрибәләрендә ышандылар. Шушы дәүләт союзы кочагында алар һәрьяклап гаять зур үсешкә ирештеләр. «Бирелә илебездәге барлык милләтләрнең һәм барыннан да бигрәк рус халкының эчкерсез ярдәме бик мөһим роль уйнады. Хәзер... артта калган милли окраиналар юк!» (КПССның XXVI съезды материаллары. Казан, 1981, 58 бит).

Социалистик яшәү рәвеше барлык милләт һәм халыкларга моңарчы күрелмәгән иҗат мөмкинлекләре бирде, алар күңелендә якты киләчәккә ышаныч уятты. Алар барысы да бүген яңа бөек җәмгыять — изүдән һәм эксплуатациядән, наданлык һәм хокуксызлыктан, милли конфликтлардан азат җәмгыять төзүгә үзләреннән лаеклы өлеш кертүләре белән чиксез горурланалар. Бу җәһәттән Сарман районының «Үрнәк» колхозы терлекчесе С. Шиһапова фикере кызыклы. «Мондый горурлык хисе,— диде ул,— аерым кешеләр бәхетенә генә түгел, ә барлык совет кешеләре бәхетенә нигезләнгән чын социаль оптимизм нәтиҗәсендә туа. Совет кешеләренең бөтен яшәү рәвеше Ватан бәхете хакына ясалган хезмәт батырлыгы булып тора лабаса!» («Советская Татария», 29.3.77.).

Социалистик яшәү рәвеше формалашу өчен объектив шартлар кирәк. Чын демократиягә корылган политик система булу, Коммунистлар партиясе җитәкчелек итү, марксистик-ленинчыл идеология, барлык халыкларның казанышына әверелгән, үзенең табигате белән интернациональ булган социалистик культура — менә шулар аның нигез ташларын тәшкил итә дә инде.

Социалистик формациягә кадәр гомер кичергән кешеләрнең яшәү рәвешеннән аермалы буларак, социалистик яшәү рәвеше формалашуда субъектив фактор хәлиткеч роль уйный. Бер генә җан иясе дә колбиләүчелек, феодаль яки буржуаз җәмгыятьнең яшәү рәвеше турында хыялланмаган. Коммунизм исә, иң гадел һәм иң гуманлы яшәү рәвеше буларак, реаль җәмгыятькә әверелгәнче үк инде хезмәт халкының хыялында яшәгән, акыл ияләрен уйландырган. Аның хакында бөек утопияләр язылган. Ниһаять, аңа илтүче туры юлны фәнни коммунизмга нигез салучылар күрсәтеп бирделәр.

Кешелекнең шушы гүзәл хыялын совет кешеләре иң беренчеләр булып гамәлгә ашырды. Алар чын мәгънәсендә үзләренеке булган яшәү рәвешен иҗат итәләр.

Җәмгыятьтә хөкем сөргән буржуаз һәм вак буржуаз идеологияне, идеалистик һәм дини карашларны бетереп, алар урынына коммунистик идеология һәм диалектик-материалистик караш урнаштыру — социалистик яшәү рәвеше колач җәеп үссен өчен кирәкле төп җирлек, ул гына да түгел, мөһим закончалык.

Безнең яшәү рәвешендә дөньяга ике төрле караш — милләтчелек белән интернационализм һәрвакыт бер-берсенә каршы чыгалар. Бу уңай белән В. И. Ленин болай дип язган иде: «Буржуаз милләтчелек һәм пролетар интернационализм — менә бөтен капиталистик дөньяның ике сыйнфый лагерена туры килә торган һәм милли мәсьәләдә ике политиканы (ул гына да түгел, дөньяга ике төрле карашны) гәүдәләндерә торган, бер-беренә килешмәүчән дошман булган ике лозунг» (Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 20 том, 11 бит). Кыскасы, буржуазия яшәү рәвешен милли һәм раса каршылыкларыннан башка күз алдына да китерә алмый. Моңа мисалга АКШ, Англия, Канада, Бельгия кебек һәм башка «цивилизацияле» дәүләтләрне китерергә мөмкин.

Дөньяга әлеге ике төрле карашның бер-беренә карата дошманлыгы буржуазия властен бәреп төшерү белән генә юкка чыкмый. Моның өчен эшчеләр сыйныфына һәм Коммунистлар партиясенә буржуазия тарафыннан өреп кабартылган милләтчелек карашларына каршы озакка сузылган каты көрәш алып барырга туры килде.

Мәгълүм булганча, Совет властеның беренче елларында рус шовинистлары, украин, белорус, татар милләтчеләре котырынып ленинчыл милли политикага ябырылдылар. Мәсәлән, «мөселман» милләтчеләренең башлыгы, соңыннан гитлерчы фашистлар ялчысы Гаяз Исхакый яңача яшәү рәвешенә нәфрәтен болай дип белдерде: «Раса һәм дини сәбәпләр аркасында без руслар белән берләшә алмыйбыз. Безнең хәрәкәтебез максаты русларныкыннан бөтенләй аерыла». Солтангалиев тә «үзенең йөрәгендә рус социалистларына карата ышанмаучылык орлыгы йөртүен» яшерми. Алар әнә шулай татар хезмәт ияләренең аңын томаларга, татар халкын рус халкына каршы куярга теләделәр.

Бу җәһәттән шуны басым ясап әйтергә кирәк, милләтчелек белән көрәштә, әлеге йогышлы авыруның киң хезмәт ияләре аңына үтеп керүенә чик куюда бөек Ленин партиясе искиткеч зирәклек һәм осталык күрсәтте, зур оештыру һәм тәрбия эше алып барды. Халыкның борын-борыннан сакланып килгән бик матур гореф-гадәтләреннән файдаланып, ул хезмәт ияләрендә алдынгы караш, интернациональ бердәмлек хисе булдыруга иреште.

Югарыда әйтелгәнчә, безнең социалистик яшәү рәвеше интернационализм рухы белән сугарылган. Ләкин бу һич кенә дә нинди дә булса милли шәхеснең үзенең миллилеген җуюын, аның сүнә баруын һәм бөтенләй башка якка үзгәрүен аңлатмый. Гәрчә, безнең сыйнфый дошманнарыбыз моны шулай итеп күрергә бик тә телиләр.

Яшәү рәвешебезнең иң зур казанышларыннан берсе — совет кешесе, коммунистик җәмгыять төзүче шәхес. Әгәр дә ки бу шәхеснең тормышы, көнкүреше, рухи дөньясы һәм ихтыяҗлары фәкать үзенең милләте белән генә чикләнә икән, аның һәрьяклап үсеше һәм чәчәк атуы турында сөйләве кыен. Совет кешеләре тарафыннан куылып, хәзерге көндә капиталистик илләрдә җан асраучы буржуаз милләтчеләр төрле-төрле пычрак алымнар белән кешене аерым милли кысада яшәргә димлиләр, аңа башка халыкларның прогрессив казанышларыннан файдалану юлын биклиләр. Алар үзләренең шушы максатына ирешә калса, бу милли яшәү рәвешен гаять нык чикләр, шәхес үсешен тоткарлар, аның дөньяны танып-белү һәм үзгәртеп кору эшчәнлеген тарайтыр иде.

Социалистик яшәү рәвешенең бинниһая зур өстенлеге шунда ки: ул халыклар арасында ясалма рәвештә корылган киртәләрне курыкмыйча җимереп ата, кешегә башка милләт кешеләре белән бертигез, тиң булып иҗат итү мөмкинлеге бирә. Безнең илдә, мәсәлән, милли рамкада гына яшәүче кешене күз алдына китерүе дә мөмкин түгел. Ул үзен, рус яки үзбәк, татар яки грузин булудан бигрәк, бердәм социалистик гаиләнең бер члены, совет халкы дип аталган яңа бөек гомумилекнең аерылгысыз бер вәкиле итеп саный. Совет кешесенең яшәү рәвешендәге бер генә милли үзенчәлекне якны да инкарь итмәстән, без монда хәзер социалистик коллективизм һәм интернационализм иң мөһим, хәлиткеч фактор булып тора дип әйтәбез.

Социалистик хуҗалыкны күтәрү эшендә, яңа культура һәм яңа тормыш өчен

күрәштә, Ватаныбыз азатлыгы хакына алып барылган канкойгыч сугышларда төрле милләт кешеләре коллективизм белән интернационализмның җиңелмәс көченә ышандылар. Алар совет җәмгыятен төзүдә ясланган гаять зур җиңүләрнең уртак казаныш булуын, материаль һәм рухи байлыкларны тудыруга барлык милләт вәкилләре дә лаеклы өлеш кертүләрен яхшы аңлыйлар. Завод-фабрикаларда, колхоз-совхозларда һәм төзелешләрдә бергәләп, тату һәм дустанә эшләү, халык депутатлары Советлары, партия, комсомол, профсоюз һәм башка оешмалар эшендә тигез хокук белән, актив һәм җанлы катнашу, мәктәпләрдә һәм уку йортларында белем алу, Совет Армиясе сафларында хезмәт итү кебек игелекле эшләр яшәү рәвешебездә сакланып калган урынчылык күренешләрен һәм тар милли рамкаларны җимерә, кешеләрнең бер-берләренә карата ихтирам һәм хөрмәт итешү хисләрен үстерә, милли мәнфәгатьләрне интернациональ мәнфәгатьләр югарылыгына күтәрә.

Шушы уңайдан бөек пролетар язучысы Максим Горький фикерен искә алу кызыклы. Ул, Татарстан АССРны ун еллык бәйрәме белән котлап: «Бөтен хезмәт дөньясына эшчеләр сыйныфы алып килгән интернационализм идеясе экономика һәм культура тормышының яңа шартларын төзеп кенә калмый, ул яңа кеше тудыра»,— дигән иде. Ә бу яңа кеше бөтен җаны-тәне белән коллективизм, туганнарча хезмәттәшлек итү һәм патриотизм рухы белән сугарылган. Совет кешесенең патриотлыгы үз милләтенең улы яки кызы булу белән генә чикләнми. Аңа иң элек гомуммилли горурлык хисе хас. Ул үзен барлык халыкларның уртак эше өчен интернациональ җаваплы кеше итеп тоя.

Әйткәнебезчә, совет кешеләренең яшәү рәвешендә миллилек зур урын тота. Социалистик җәмгыять шартларында милли тормышның прогрессив сыйфатлары тагын да үсә, гомуминтернациональ сыйфатлар белән баый. Совет кешесе үзе туып үскән авыл, шәһәр һәм республиканы гына түгел, ә күпмилләтле бөтен илебезне үз Ватаны дип саный. Ул илебезнең барлык төбәкләренең дә чәчәк атуы турында кайгырта. Патриотик һәм интернациональ бурычын аңлап, йөрәгә кушканча яңа төзелешләргә китә. Кая гына барса да, ул анда үзенә төрле милләт кешеләреннән дуслар һәм фикердәшләр таба. Кайда гына булса да, ул үзен анда өендәге кебек хис итә, бердәм яшәү рәвешен камилләштерүгә үз өлешен кертә. Мәсәлән, Волгоград трактор заводын төзүдә 22 милләт вәкилләре катнашты. Ә Горький автозаводын рус туганнары белән бергә 4 меңләп башка милләт кешеләре, шул җөмләдән татарлар, чувашлар, украиннар, удмуртлар һ. б. төзеделәр. Братск төзелешендәге һәр ташта, һәр кирпечтә 50 дән күбрәк милләт кызлары һәм егетләренең кул җылысы бар. Чирәм җирләрне үзләштерүдә илебезнең миллионнан артык яшьләре һәм комсомоллары хезмәт батырлыгы күрсәттеләр.

Бәрәкәтле Татарстан туфрагында бай нефть ятмаларын үзләштерү илебездә яшәүче тугандаш халыклар хезмәттәшлеге һәм дуслыгының чын мәгънәсендә гүзәл үрнәге булды. Атаклы нефтьче, Социалистик Хезмәт Герое К. Вәлиевның горурлык белән: «Без татар нефтен бөтен ил белән, тугандаш бер гаилә белән бергә күтәрдек»,— дип әйтүе тикмәгә түгел. Татарстанга төрле төбәкләрдән 60 тан күбрәк милләт кешеләре килде. Бу үзе үк интернациональ тәрбия бирүнең бик шәп мәктәбе иде.

Татарстан нефтьчеләре илебезгә ике миллиард тоннадан күбрәк кара алтын бирделәр. Куанычлы казаныш бу. Ул республикабыз хезмәт ияләренең патриотик горурлык хисен тагын да арттыра. Үз чиратында безнең промыселларда хезмәт чыныгуы алган, интернациональ тәрбия мәктәбе узган меңнәрчә нефть чыгару осталары илебезнең башка өлкәләрендә эшлиләр, коммунистик хезмәт үрнәге күрсәтәләр.

1970 елны исә Татарстанда мәшһүр Кама ярларында чорыбызның бөек төзелеше башланды. Чаллы туфрагында кыска гына вакыт эчендә гигант автомобиль заводы корылмалары һәм ак шәһәр калкып чыкты. КамАЗны бөтен ил төзеде. Монда йөрәкләре бердәм патриотик хисләр белән ашкынып типкән романтиклар һәм энтузиастларның күпмеңле интернациональ коллективы оешты. Яшь Чаллы каласы төрле милләт уллары һәм кызларының туган шәһәренә әверелде.

Мисалга Өметгәрәй Наурбиев җитәкләгән автоскреперчылар бригадасын гына алыйк. Бу коллектив составында унбер милләт вәкиле эшли. Бригадир үзе — ингуш, Минехсән Ибраһимов белән Әсфән Яруллин — татарлар, Дмитрий Тиманов — рус, Виталий Иванов — удмурт, Роберт Имаев — башкорт, Александр Дейкун — белорус,

Евгений Дозоров — мордва, Низам Алиев — азербайҗан, Владимир Лыско — украин егете... «Алар барысы да,— ди бригадир,— бер ана балалары кебек, рухланып эшлиләр. Коллективның аерылмас сыйфатлары — дуслык, татулык. Югары хезмәт җитештерүчәнлегенә ирешүнең дә төп сере шундадыр, бәлки... Татарстан минем өчен икенче туган төбәгем булып китте хәзер. Мин монда хезмәтемнең ямен таптым. Ленин һәм «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләндем, Татарстан АССРның атказанган төзүчесе дигән мактаулы исемгә лаек булдым, КПСС сафына кердем».

Мондый интернациональ коллективларны бүген без республикабызның һәр шәһәрендә, һәр авылында диярлек очратабыз. Мәсәлән, Тәтеш районының Ленин исемендәге колхозын гына алыйк. Монда өч рус, алты чуваш һәм бер татар авылы эшчәннәре бердәм гаилә булып яшиләр. Моннан тыш, әлеге хезмәт коллективында мордвалар һәм башкортлар бар. Колхоз елның-елында авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүдә күркәм уңышлар яулый. Колхозчылар тормышы мул һәм иркен. Бу колхоз мисалында гына да без интернациональ яшәү рәвешенең матур бер чагылышын күрәбез.

Социалистик яшәү рәвеше формалашу процессында илебездә яшәүче барлык сыйныф һәм социаль группаларның, барлык милләт һәм халыкларның бердәмлеге ныгый бара. Шушы бердәмлектән башка социалистик җәмгыятебезнең экономик һәм рухи потенциалын тудыруда бер генә хезмәт казанышы яуланмас, Ватаныбыз азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен авыр сугышларда тиңдәшсез батырлыклар ясалмас иде. Бөек максат белән береккән совет кешеләренең героик эшләре безнең яшәү рәвешен яңа сыйфатлар белән бизи. Аңа дуслык һәм иптәшлек, үзара ышаныч һәм җаваплылык, кешеләр хакында кайгыртучанлык һәм аларга таләпчәнлек рухы белән сугарылган саф-сәламәт мораль-политик атмосфера хас. Социалистик яшәү рәвешенең бөтен гуманлы асылы әнә шунда. Ул кешеләр язмышын танымаслык итеп үзгәртте.

Коммунистик җәмгыять төзүче совет кешеләренең яшәү рәвеше интернациональләшүе, барлык милләт халыкларының үзара якынаюы, культураларының чәчәк атуы һәм бер-берләрен баетуы — иҗтимагый үсеш законнары нигезендә баручы табигый процесс. Бу процесс стихияле рәвештә бармый, ә партиябез һәм дәүләтебезнең максатчан оештыру, политик һәм идеологик эше белән гамәлгә ашырыла.

Совет халкының хезмәте, ихтыяры һәм таланты белән, даһи Ленин партиясенең иҗаты белән планетабызда яңа, социалистик дөнья һәм яңа, прогрессив яшәү рәвеше туды. Ул барыннан да элек кешене иң бәхетле итүгә, коммунизмга йөз тота. Киләчәк — аның кулында.

## Анатолий Чепуров,

рус шагыйре

### Кеше һәм сүз

...Кеше турында ниндидер
Сүз әйтү кирәк —
Сүз әйтми калмаслык итеп
Күзәтү кирәк.

Я үгетлә, я чәчәк бир,
Ә дәшмәү — җәза.

Ул бит сиңа я өй сала,
Я китап яза.

Ә бәлки тирләп эшлидер
Ул салкын якта...
Телгә ал аны, ул сине
Ишеткән чакта.

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәсе.

## Саидали Мамур,

таҗик шагыйре

### Мәңгелек ут

*«Без, кырык мең совет һәм поляк сугышчылары, Ватаныбызның азатлыгы өчен көрәшкән өчен шушы урында яндырылдык. Бездән берни дә калмады. Фашист ерткычлары безнең көлләребезне дә үзләре белән алып киттеләр. Без сезнең хәтерегездә генә яшибез, шәфкатьле кешеләр».*

(«Радогаш» концлагерендагы мәрмәр тактага язылган сүзләрдән)

Ничек зурлыйк сезнең батырлыкны? —
Мәңгелек бит бездән көчлерәк.
Кабер ташындагы дүрт юл шигырь
Язмышларга кереш төслерәк!

Безнең хәтер, ачы кайтаваздай,
Яңгырасын яңа чорларда.
Мәңгелеккә эпиграфтыр — мәрмәр!
Сез яшисез мәрмәр җырларда.

Таш астында сез бит йокламыйсыз.
Оран саласыз сез кирәктә!
Ә таштагы һәрбер хәреф оча,
Пуля кебек, безнең йөрәккә.

Бер минутлык тынлык! Авыр тынлык.
Бу — мәңгелек тынлык, чынлыкта.
Әйтерсең лә, сезнең гомерләр дә
Әйләнгәннәр шушы тынлыкка.

Моңсу тынлык күп тавышлы иде.
Төрле телдә җил дә елады.—
Мәрмәр таш янында. Зиратта ул
Сезнең каберләрне юллады...

Мәңгелек ут — солдат кулындагы
Байрак кебек яна, ярсына.
Сезнең йөрәкләр дә тибә анда,
Ялкынланып тибә каршыда!

## Сабир Рөстәмханлы,

азербайҗан шагыйре

### Ватандарлар үлми

Җиткәннән соң билгеле бер чиккә,
Төшеп калсам гомер атыннан,
Үлчәп куй син миңа, туган җирем,
Өч аршын җир — авыл артыннан.

Аерылмас өчен туган җирдән! —
Бу өметем көлке кебек тә,
Ышанычның көче калмас иде,
Сүнсә әгәр шушы өмет тә.

Аз да, күп тә түгел — өч аршын җир,
Якты, җылы булыр түбәндә.
Туган авыл, нәкъ элекке кебек,
Гөрләп торса минем түбәмдә.

Иркәләсә мине әнкәм теле,
Чишмәм суы торса табында,
Болыннарда инеш дулкынланса,
Кайтачакмын, димәк, тагын да.

Елармын мин бишек җырларыннан,
Еллар узар, ә җыр йокламас.
Нәселемдә мин әллә кем түгел —
Мин үлгәннән нәсел туктамас!

Туйлар гөрләр тауда — авылларда,
Дәвам итәр нәсел минем дә.
Чөнки Ватан тарихлардан зуррак,
Ватандарлар үлми илемдә.

Миңа дигән гомер, йолдыз кебек,
Сүнсә әгәр, мин ул чагында
Терелермен бодай бөртегедәй,
Туган җирем, синдә тагын да!

## Григоре Виеру,

молдаван шагыйре

### Көтү

Сугышлар тынды...
Кайтырга тиеш
Улым — сугыштан
Исән-сау килеш.

Менә күрерсез —
Ул кайтмый калмас,
Мине күрмичә
Булдыра алмас!

Сугышта сукыр
Калгандыр улым —
Шуңа ул өйгә
Тапмыйдыр юлын.

Саңгырауланды
Микән ул әллә? —
Ишетмидер шул
Мине ул хәлдә.

Улым аягын
Югалтса, өйгә
Ничек кайтсын ул
Аяксыз көйгә?!

Югалтты микән
Сугышта кулын? —
Шуңа хат яза
Алмыйдыр улым.

Калгандыр телсез,
Җуйгандыр аңын —
Әйтә алмыйдыр
Кайда туганын...

Улың сугышта
Үлде, дип беркем
Әйтмәдә миңа —
Кайтыр ул беркөн!

**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН** тәрҗемәләре.

## Гыйлемдар Рамазанов,

башкорт шагыйре,
Салават премиясе лауреаты.

### Яшел бишек

*Гомәр ага Бәшировка*

Кулларымда — өлкән дустан бүләк:
Бер тылсымлы кыйммәт сәлам-хат,
«Туган ягым — яшел бишек» үзе —
Килер буыннарга әманәт.

Эче тулы аның могҗизалар:
Кара урман, Җидегән чишмәләр,
Гаҗәп түгел, шул суларны эчеп
Дуслар туксан, йөзгә җитсәләр.

Кыйсса сөйли кебек колагыма
Ык буйлары, Арча яклары.
Чик тә белми, һич тә үтми икән
Зур әдипнең егет чаклары.

Яшел сукмак буйлап барып кактым
Каладагы ачык ишеген...
Ул өйдә юк, чыгып киткән сагынып
Туган ягын — яшел бишеген.

●

Яуда җиңеп, Карпат үрләренә,
Альп тауларына менсәм дә,
Хыяллана идем: «Илгә кайтсам,
Үкенмәс тә идем үлсәм дә...»

Исән кайттым, туган җиргә бастым,
Үлем белән янәш йөрсәм дә,
Әйттем тагын: «Киң дөньяны гизсәм,
Мин үкенмәс идем үлсәм дә...»

Илләр, кыйтгаларны айкап узып,
Үз күзләрем белән күрсәм дә,
«Мәхәббәттән әгәр уңсам,— дидем,—
Һич үкенмәс идем үлсәм дә...»

Оныкларым үсеп, инде үзем
Гомерем үрләренә җилсәм дә,
Һаман әйтәм: «Алтын туйны күрсәм,
Үкенмәс тә идем үлсәм дә...»

Еллар ярсып уза. Миңа һаман
Күңел күген бизәр нур кирәк.
Яңа офык, яңа үрләр кирәк,
Үлемнәрне җиңәр җыр кирәк.

## Адам Шогенцуков,

кабардин шагыйре

### Таңнар күзе

Таңнар, таңнар... Җирдә алар эше
Гел бер төсле була, күрәсең:
Я томалый юеш томан белән,
Я балкыта таулар түбәсен.

Ничек тели, шулай күренә ул:
Бер караңгы була, бер якты.
Тарлавыкны сары төскә буйый,
Зәңгәр итә яшел куакны.

Көн дә яңа канат кагып килә,
Иң кирәген сайлап үзенә...
Без дә, әйдә, таңнар күзе белән
Карый белик заман йөзенә.

Таң шикелле эшли, яши белик,
Җырлыйк җырның таңдай нурлысын —
Барча җырлар нык канатлы булсын,
Дәртле, зирәк, гадел, җор булсын!

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәсе.

## Фәния Чанышева,

башкорт шагыйрәсе

### Икмәк исе

Җил очыра чаган яфракларын,
Энгер мәле шаулы калада.
Җанны куандырып тирә-юньгә
Җылы икмәк исе тарала.

Әнкәсенә нидер сөйләп килә
Тере чәчкә кебек кыз бала.
Күзге бакча, җылы икмәк исе...
Ерак бала чагым сынлана.

...Тәрәзәдән бөтен кояш кергән,
Кеше саен кояш! Төшемне
Шушы җиргә җиткәч бүлдерделәр:
— Уян, әнкәй әпәй пешерде!

Һәркем сабыр көтә үз нәүбәтен,
Дәү әтием боза тынлыкны,

— Сиңа,— ди ул,— нинди телем кирәк —
Бер куллыкмы, ике куллыкмы?

— Ике куллык,— дибез,— и, садәлек,
Кайсыбызның авыз пешмәде!
Нәфселегә телем шундый юка —
Сыңар кулда сынып төшмәле.

Мин мәктәптән кайтам. Бездә кунак!
Печән салып атын тугарган.
Әнкәемнең йөзе кояш кебек —
Мич алдында шулай кызарган.

Яңа гына алган, кайнар килеш,
Күкрәгенә терәп кискәндә,
Уйлап шатлангандыр: «Ярый әле,
Әпәйнең бар чагы өстәлдә».

Икмәк безгә һәрчак тансык булды
Өйрәттеләр сабак биреп тә.
Ашъяулыкка төреп сакланды ул
Үрелеп буй җитмәс биектә.

Күзгә бакча. Җылы икмәк исе...
Ерак бала чагым сынлана.
Өстәлләрдә икмәк өзелмәсен,
Имин була күрсен дөньялар!

## Равил Шаммас,

башкорт шагыйре

### Минем йолдыз

Катлы-затлы башваткычлар эзләп,
Үткәрмәмен гомерем әрәмгә.
Күңелемдәге моңны мин сөйләрмен
Адәм теле белән адәмгә.

Алтын-көмеш вәгъдә иткәнем юк,
Мин өләшәм бары яхшылык.
Күңеленә кучсә кешеләрнең
Күңел шәмемдәге яктылык.

Утлар-сулар кичеп үткән чакта,
Җиңеләйтсәм алар адымын,
Җитә миңа. Төпсез күккә түгел,
Яшел җиргә минем бар моңым.

Күктән йолдыз чүпләп бирәм диеп
Шапырыну миңа нигә ул?!
Якты йолдызы да, тир тозы да —
Барысы да җирдә, Җирдә ул.

Күңел моңым булыр Җирем моңы —
Кешеләргә әйтер бер сүзем.
Галәм киң ул, йолдызлары күбәү...
Минем йолдыз — Җирем, Җир үзе.

## Йосыф Хаппалаев,

лак шагыйре

●

Көн дә бәйрәмнәрдә биеп,
Көн дә туй иткән чагың,—
Тауларда бар да типтерә
Дип уйлый күрмә тагын.

Утларның салкын көленә
Торганда башың иеп,—
Ялгышма, бу таулардагы
Бар учак сүнгән диеп.

### Гариплек турында

Аяк зәгыйфь, ә йөзең җыерчыклы,
Аркаң да бөкре синең... я бу чаклы
Нигә сине табигать мыскыл иткән? —
Үз-үзеннән көлгәнен белә микән?
Син үзеңне күрмисең, миннән сора —
Саф җаның күзеңдә балкып тора.

Ә бүтән бер имән кебек егеткә —
Гарип, дидем, чибәр сынын күреп тә.
Очраса — һәркем белер, таныр аны —
Елан булып ысылдый кара җаны.

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ тәрҗемәләре.

## Макс Майн,

мари шагыйре

### Лыгырдык

Бер бездә шундый мокыт:
Су буе кәгазь тотып,
Авыз суын корытып
Сөйли ул һаман нотык.

Әйткәне нәрсә дисәң,
Тора тоташ цитаттан —
Чүпләп бетерде икән
Кайсын нинди китаптан?!.

Шуңа күрә без аны
Кире яктан мактадык:
«Лектор» димәскә булып,
«Лыгырдык» дип атадык.

## Риза Халит,

кырым шагыйре

### Кояшка карап

Күнектем бик иртә, бик яшьли
Эш өчен гел янып яшәргә,
Атларга тау-ташлы сукмактан,
Болытсыз төндә дә яшьнәргә.

Мин ачы җилләргә сүз куштым,
Давылда сүнмәде күзләрем.
Ут-ялкын йоттым мин сугышта,
Утлардан туды бу сүзләрем.

Менәргә ашкынам биеккә —
Галәм дип аталган үрләргә
Һәм шунда йолдызлар чүпләргә,
Ай кызын кочаклап үбәргә.

Бар минем иң олуг теләгем:
Кояшлы юл ярып атларга.
Ил әйтә: тик шундый көч кирәк
Хәятне хафадан сакларга!

**ЗӘКИ НУРИ** тәрҗемәләре.

## *МАЙ ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!*

Мөхәммәт Мәһдиев

# АВЫЛ БЕЛЕМ СОРЫЙ

Бу елда безнең прозаиклар авыл турында байтак сөйләштеләр, бәхәсләштеләр. Бүгенге авылны тагын да ныграк өйрәнү максатыннан чыгып, сөйләшү-танышуның яңа формалары эзләнде. Без авылны яхшы беләбез, дип йөрибез, чөнки барыбыз да диярлек авылда туып үскән. Шуңа күрәдер, ахрысы, без авылга кызыклы сәяхәткә чыккандай барып кайтабыз: безне милли киемнәр киеп, ипи-тоз белән каршы алалар. Мәктәп балалары безне каршылаганда «речь»ләр сөйли, аннан безнең арадагы берәр кеше — гадәттә, бер яки ике тапкыр лауреат булганы — җавап нотыгы тота. Кичләрен культура сараенда очрашу оештырыла.

Без бу юлы проза секциясенең бүгенге авыл белән танышуын башкачарак оештырдык. Татарстанның төрле ягыннан өч-дүрт районны сайлап алдык та, колхоз җитәкчеләренә сораулы хатлар җибәрдек. Бүгенге авыл — ни ул? Бүгенге колхозчы — кем ул? Авылның перспективасы нинди? Юллары нинди хәлдә? Яшьләр авылда каламы? Калмаса, сәбәбе нәрсәдә? — һәм башка шуңа охшаш сораулар.

Шулай итеп, проза секциясенең чираттагы утырышына колхоз председательләре җыелды. Алар — күптәнге, тәҗрибәле җитәкчеләр: Актаныш районының «Чишмә» колхозы председателе Ясәви Хөсәенов, Арча районының «Чулпан» колхозы председателе Наил Сабиров. Азнакай районының «Коммунизмга» колхозына яңарак кына сайланган прдседатель Илдус Гыйлаҗев утырышка килә алмады. Мәшәкате чыккан. Без уйлаштык-уйлаштык та проза секциясенең икенче бер утырышын бу авылның үзендә уздырырга булдык.

Бүгенге авыл тормышы, колхозның үсеш перспективасы турында күп кенә җитәкчеләр белән сөйләшкән бар. Бу әңгәмәләрдә Буа районы «Искра» колхозы председателе М. Мөхәммәтҗанов, Арча районы «Курса» колхозы председателе И. Мөхәммәдиев, Балтач районы «Яңа тормыш» колхозы парткомы секретаре М. Шаһиев һ. б. иптәшләр катнашты. Аларның һәрберсендә төрле шартлар, төрле кешеләр, төрле дәрәҗәдәге материаль база, төрле юллар. Азнакай районы колхозларын асфальт юллар тоташтыра, урам уртасында асфальт, асфальт кырыенда куерып яшел чирәм үсә. Кешеләр бүгенге көндә дә ямьле урамда, табигый хәтфә буйлап йөриләр. Балтач районында да юллар күтәртелгән, авылларның күбесе олы юлга чыга ала. Аларның да эше чагыштырмача әйбәт. Республиканың иң начар юлы кайда? — дигәндә, шикләнмичә әйтергә мөмкиндер — Казан артында, Арчада. Анда район үзәген өч колхоз белән тоташтыручы 20—25 километрлык бер ара бар. «Таш юл» дип атала: Арча — «Коммунист» колхозы маршруты. Машиналар бу араны күп очракта өч сәгать уза. Батканнар (таш юлда!), ауганнар, мәтәлгәннәр... Яңгыр булганда, бу таш юлда — котчыккыч күренеш. Анда текә-текә өч тау бар, таш юл тауларны кисмичә генә түшәлгән. Арчадан чыгуга шоферларның йөзе агара башлый. Ул таулардан исән-сау узып булырмы? Кешеләр уйлый: бу юлны кем проектлаштырды, кем төзеде һәм кем дәүләт миллионнарын җилгә очырды икән? Быел матур хәбәр йөри: Арча районында

юллар сала башлаганнар, «Гидромонтаж» белән килешү төзелгән, күперләрне төзергә дә тотынганнар инде. Бик шатлыклы яңалык бу! Арчалыларның да такыр юлдан йөреп карыйсылары киләдер бит!

Кояш бер, җил бер, болытлар барысы өстеннән дә уза, яуганы да, көйдергәне дә — бер үк. Әмма колхозлар төрле. Балтач районы «Яңа тормыш» колхозы республикадагы иң нык хуҗалыкларның берсе. Бу колхоз үз эшләрен отышлы итеп, ягъни рентабельле алып бара. Рентабельлелек — бүгенге көндә зур казаныш ул. Болар бер сумны ел ахырына бер сум унөч тиен итәләр. Бу бит йөз сумны — йөз унөч сум, миллионны бер миллион йөз утыз мең сум итү дигән сүз. Боларның соңгы ун ел эчендә читтән салам да сораганнары юк. Аларның хәтта узган елгы корылыктан соң да запаста 47 эскерт саламнары бар иде. Болар быел март башында колхозчыга өченче тапкыр салам бүләләр. Һәр колхозчы ел буена саламны гына унбиш центнер ала! Бу авылларда өч китапханә, ашханә, махсус кибетләр бар. Кафесында каймак, сыра, лимонад, компот сатыла. Ел саен механизаторларның белемен камилләштерү буенча колхозның үз курслары эшли. Лекцияләрне колхозның үзендәге югары белемле агрономнар, ветеринарлар, механизаторлар укый. Без шул дәресләрнең берсендә утырдык. Лекцияне җитмешләп ирләр, егетләр тыңлый.

— Бу — ел саен шулаймы? — дибез.

— Ел саен,— ди партком секретаре.— База — бездә. Бездә тагын күршедәге өч колхоз механизаторлары белемнәрен күтәрәләр. Бу — зональный уку.

Без кадрлар белән кызыксынабыз, рентабельлелекнең серләрен ачарга тырышабыз. Мәгълүм ки, республиканың ничәмә хуҗалыгы дәүләт бюджетында утыра, бер килограмм бәрәңгесен бер килограмм әфлисун хакына җиткерә... Рентабельлелек каян килә? Каян? Аңлыйбыз: кадрлардан, фәннән, акылдан. Фән, акыл, кадр Казан артына каян килә? Казандагы югары уку йортларыннан. Бу җәһәттән без зарлана алмыйбыз. Бездә авыл хуҗалыгы өчен кадрлар әзерләүче КСХИ, КВИ, КИСИ, КФЭИлар бар. Колхозлар җитәкчелегендәге эшләрдә ничәмә-ничә белгечләр шул вузларның дипломын алган. Парадоксаль хәлләр байтак: «Коммунизмга» (Азнакайда), «Чулпан» (Арча) колхозларының председательләре — КДУның татар теле һәм әдәбияты кафедрасында белем алган кешеләр. Хәл фигыль, сыйфат фигыль кебек төшенчәләрне, ягъни дипломнарында күрсәтелгән һөнәрне, куеп торып, бүгенге көндә зур-зур хуҗалыклар белән идарә итәләр. Тәҗрибә бүген авыл хуҗалыгы белән идарә итү өчен югары белемле һөнәр ияләренең кирәклеген күрсәтә. Бүгенге көндә авыл хуҗалыгы, моңарчы беркайчан да булмаганча, шәһәр һәм промышленность производствосы белән тыгыз бәйләнешкә керде. «Яңа тормыш» (Балтач) белән югары һәм махсус урта белемле егерме алты кеше идарә итә. Агрономы — авыл хуҗалыгы, баш зоотехнигы ветеринария институтын тәмамлаган. Башка белгечләре дә шундый. Монда савымчыларны фермада бушлай ашаталар, бусы — бик мөһим эш. «Яңа тормыш»та бөтен игътибар — яшь кадрларга. Урта мәктәпне тәмамлагач, колхозда кал гына — сиңа бөтен шартлар. Армиядән колхозга кайттыңмы — кал гына, кирәк нәрсәңне сора гына — бирәләр. Синең карамакта — трактор, автомашина, комбайн. Эшлә генә! «Яңа тормыш» яшьләре эштән кайтышлый ике-өч китапханә янынннан узалар, бер кермәсәң, икенче үткәндә керерсең. Әле кафесында сыра, лимонад та эчеп чыгалар. Мин моңа сокланып әйтәм, чөнки хәтта шәһәрдә дә, кичен эштән кайтканда, кая да булса кереп, алай җиңел генә ял итеп утыру мөмкинлеге — ай-һай...

Кыскасы, бу колхоз тулы тормыш белән яши, Ватанга зур байлык өстәп яши. Аның иң җаваплы урыннарындагы югары һәм махсус урта белемле 26 кешесе хуҗалыкны да, авыл тормышын да нык җирлеккә бастырган.

Илдус Гыйлаҗевны (Азнакай) — тәҗрибәле кадрны, болай караганда, шактый җиңел, нигездән уйлап караганда исә, бик авыр бер участокка күптән түгел генә күчергәннәр. Илдус тыйнак. Безнең белән фотокорреспондент та килгән иде. Илдус шунда ук: «Мине фотога төшермәгез»,— диде.

Ярый, хуш. «Коммунизмга» колхозы ничек? Анда нинди яңалыклар бар? Бу хуҗалык дәүләт амбарына, шәһәрдә без кереп йөри торган кибетләргә, ашханәләргә, кафеларга, рестораннарга нәрсәләр бирә? Рентабельлелек ничек?

Бу хуҗалык үзенчәлекле. Әйтик, биредә «коммуналь хуҗалык инженеры» дигән штат бар. Авылда коммуналь хуҗалык инженеры? Юктыр, булмас ла... Әмма тегє иптәш бар, ул — Рәфәгать Ихсанов, ул безнең проза секциясенең утырышында катнаша һәм үз хуҗалыгы башкарган эшләр хакында сөйли. Авылда ике катлы, бер катлы уңай шартлы йортлар төзелгән, аларның ванналары, туалетлары бар. Канализация эшли. Димәк, авариясе-фәләне була, ремонт ясыйлар. Болары — шәхси хуҗалыкта. Ә фермада? Ул да хуҗалык бит! Күн танаулы тегє, безне туйдыручы сыер-үгез, бозауга эчәргә су кирәк бит! Рәфәгать Ихсанов — әнә шундый бик кирәкле вазифалар йөкләтелгән оешмага хуҗа. Алай гынамы? Файдаланылган су каядыр агып чыгарга да тиеш бит әле! Авыл мунчасын гына алыгыз. Әгәр ул урам буена салынган булса, агылган көнне аннан сабынлы су агып чыгып бөтен авылның ямен җибәрә! Ә «Коммунизмга» колхозында канализация бар дидек һәм, нәкъ шәһәрләрдәге кебек үк, ташландык суларны чистарту системасы көйләнгән... Мондый система Азнакай районы Чалпы авылында да бар. Монда башкасы да бар: нефтьле, техникалы, асфальтлы колхоз атлар асрый. Нигә ул? КРАЗның, КамАЗның булганда, ат чуртымамыни? Чалпыда 180 баш ат асрыйлар. Узган ел колхоз дәүләткә 70 баш ат тапшырган. Ат, диләр, колхоз җитәкчеләре,— арзанлы ит чыганагы. Алдагы елда колхозда яңа ат абзары төзеләчәк. Бу мәсьәлә белән КПССның Азнакай райкомы да кызыксынып тора. Әйтергә кирәк, берләштерелгән безнең утырышка КПСС райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Һәндәсә Әхмәтовна да килгән иде. Без моңа шатландык: Һәндәсә — язучылар, культура хезмәткәрләренең күптәнге дусты, аны районда да, бездә — Казанда да яраталар, чөнки ул үз районының культура сәнгатен үстерергә зур көч куючы коммунистлардан берсе.

«Ат кирәк ул,— ди колхоз председателе Илдус Гыйлаҗев,— кирәк! Фермада эшләү өчен дә, колхозчыларның вак-төяк йомыш-юлына йөрү өчен дә кирәк. Алдагы елларда кымыз да ясамакчы булып торабыз әле. Атлар тагын да күбрәк кирәк булачак»... Кымыз ясау өчен иң әйбәт шартлар Актаныш тирәсендә, Сөн буйларында бар. Үләнгә карый ул, ди. Чалпы ягы үләнендә дә шул сыйфатлар бар, имеш. Булсын, шулай булсын. Керосин, бензин, мазут янында ел тәүлеге эшләгән колхозчының сәламәтлеген нигә ныгытып тормаска?!

Илдар Юзеевның, Туфан Миңнуллинның очрашулар вакытында «фәлән-фәлән иптәш — фәлән тапкыр лауреат» дип зинһар өчен сәхнәдә сүз купайтмагыз әле, әдәбиятның үзе бөтенләй күмелеп кала бит, дип, кисәткәләгәннәре бар. Алар хаклы... Ә без барасы колхозның үзендә лауреат бар инде. Ул — колхоз бригадиры, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Фуат Шакиров. Тыйнак, эш арасында гына, кабаланып, бераз гына соңга калып килде. Керде Фуат, утырды, без колхоз җитәкчеләре белән шау итәбез. Сораулар, бәхәсләр... Фуатка да сорау бирдек.

— Сезнең бригада карабодай үстерү буенча бөтен союзда дан алды. Сезне Партия Үзәк Комитетында, СССР Министрлар Советында беләләр, телгә алалар. Менә шул данлыклы хезмәтегезнең кызыклы яклары, шигърияте турында сөйләсәгезче! Сез бит инде гектарлар, центнерлар турында гына түгел, үз хезмәтегезнең матурлыгы турында да уйлыйсыздыр?

Фуат елмая.

— Карабодай басуының ак көмеш чәчәктә утырган төне турында мәзәкне сез беләсездер инде,— ди ул янында утырган баш инженер Камил Хәйруллинга карап. Чибәр ир Камил дә елмая. Мишәрләр турындагы мәзәкне искә төшерәләр. Камил — Чистай мишәре. Ул дулкынлана, чөнки кичә генә безнең берләштерелгән утырышта авыл хуҗалыгы техникасының җәйге урып-җыю сезонына әзерлеге турында зур доклад ясады. Ул беренче утырышта без тыңлап кына утырдык. Сорауны председатель, партком секретаре, идарә әгъзалары яудырды. Язучыларның тез башында куен дәфтәре иде, аларның һәркайсы үзенә мөһим тоелган фикерне «чүпләп» утырды.

Карабодай быел йөз гектар мәйданда чәчелгән, һәр гектардан уртача 18—20 центнер уңыш көтелә. Без колхозда ике кич кундык — һәр иртәне безгә кайнар карабодай боткасы белән чәй эчерттеләр. Без җидәү идек, һәм барыбыз да бу ризыкны беренче тапкыр авыз итәбез булып чыкты. Тагын чөгендерле катык белән сыйладылар. Казан арты якларында әллә кайчан «кызыл кенәгәгә» кергән, ягъни онытылып бара торган ризыклар «Коммунизмга» колхозының табын түрендә икән.

Карабодай үстерүче Фуат Шакиров — гадәттән тыш тыйнак кеше:— Минем лауреат булуым үз хезмәтем генә түгел,— диде ул.— Мин — бригадир гына, төп эшне кешеләр үти.

Колхозда моңарчы төзелеш бик куәтле темп белән барган. Больница, урта мәктәп, интернат, зур-зур кибетләр, кафелар, культура комплекслары салынган. Болар барысы да авылның йөзен үзгәрткәннәр — культура нык тамыр җәйгән. Әмма мондый сикереш үзенең тискәре нәтиҗәләрен дә биргән. Беренчедән, бу оешмалар колхоз авылындагы бөтен яшь кадрларны йотып бетергән, икмәк, сөт, ит җитештерүчеләр саны культура, сәламәтлек саклау, сәүдә сферасындагы кадрлар исәбенә кими барган. Икенчедән, терлек абзарлары салуга игътибар җитешмәгән. Культура учреждениеләрен арттыру экономика мөмкинлекләре белән яраклаштырылмаган. Нәтиҗәдә колхоз рентабельлелектән ераклашкан, тыштан бик матур булса да, экономик базаның дөрес рельска куелмаганлыгы сизелә башлаган. Димәк, исәп кирәк, хисап кирәк. Уникe пот арпоныңа (арпа оныңа) ничат (ничә ат) кирәк, дигән борыңгы бабайлар. Әйе, ничә ат кирәген белмичә ярамый. Дөрес, төзелгән корылмалар бик матур, мәһабәт. Авыл үзәгендә — кафе. Полировкалы җиһаз, кая карама — анда чүкеп ясалган җиз бизәкләр. Затлы пәрдәләр, музыка, ак калфак кигән, ал алъяпкычлы кызлар табын тезә. Кешеләрнең кәефенә килерлек концерт программаларын магнитофонга язып алганнар: Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Нәфисә Васыйлова, Фидан Гафаров җырлый. Тукай сүзләре искә төшә:

**...Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:**
**Аh!— дисең, без ник болай соң!**
**Без дә хакның бәндәсе.**

Чыннан да... Узган язда мин туган колхозыма станциядән җәяүләп кайттым. Зират белән ат абзарлары арасында элек келәтме, абзармы булган, һәрхәлдә егерме сигезенче-утызынчы еллардан калган, сайгаклары калтырап торган бер каравыл йортына кердем. Су эчәргә иде исәп. Колхозга килгән шоферлар ашап утыралар. Ашханә икән. Какшау, алама такта өстәлләр... Шыгырдавыклы бүлмә тактасы тишегеннән калай савыт белән аш сузалар...

Чаллы авылының колачлар башка. Анда хәзер экономик базаны куәтләндерүгә йөз тоталар. КПСС Үзәк Комитетының 1982 елгы май Пленумы төп игътибарны нәкъ шуңа юнәлтә бит. Бу елда колхозда 12 мең центнер сыярлык орлык амбары, өч авылга өч котельный, дүрт силос манарасы, 400 баш үгез симертерлек тукландыру мәйданы, җылы гаражлар, бозаулар абзары, янгыннан саклау депосы салына. Биш километрлы җылылык трассасы, тугыз йорт, су саклау өчен өч буа төзелә. Киләсе елдан башлап кырык машиналык яңа автогараждан иртәнге рейска чыккан шоферлар медицина тикшерүе узачак. Колхоз бу елда дәүләткә 6400 центнер ит сатарга тиеш. Болар — грандиоз эшләр, искиткеч зур бурычлар. Әмма председатель Илдус Гыйлаҗевның бу эшләргә карата үз мөнәсәбәте бар. Хәтерлисездер: соңгы елларда колхозлар кечкенә авылларны бетереп, үзәк усадьбага туплану ягын карадылар. Газ кертү, электрлаштыру, котельныйлар төзү өчен уңайлы, янәсе. Культура учакларын шулай төзү шаукымы да булды. Ләкин монда да мәсьәләнең икенче бер көтелмәгән ягы килеп чыкты. Гыйлаҗев әйтүенчә, производствоны бер ноктага гына туплау кадрлар җитмәүгә китерә. Колхозның бөтен халкын бер үзәккә җыйгач, эшкә, хезмәт дисциплинасына контроль ясау кыенлаша. Җитәкчеләр төрле якларда булса, план үтәлешен күзәтүе уңайрак. Бөтен производствоны бер авылга туплау бүгенге көндә ул авылның урамына берничә төзелеш оешмасыннан, берничә шәһәрдән машиналар, чит кешеләр килеп тулу дигән сүз. Аларны урнаштырырга, ашату-эчертү ягын кайгыртырга, эш белән тәэмин итәргә кирәк. Авыл шулай итеп ни шәһәр, ни авыл дигән бер халәткә килә. Мондый тыгызлыкта колхозның кайбер якларында шабашка, эшсезлек, эчүчелек өчен контрольгә алып булмый торган шартлар туа. Ә кече авыл эшли дә эшли ул...

Колхоз җитәкчелегендәге югары белемле уналты белгечкә сораулар бирәбез.
— Институтлар сезне бу эшкә ни дәрәҗәдә дөрес әзерләгәннәр?

Бу сорауга баш агроном Ринат Мортазин, баш зоотехник Мөдәррис Гаязов, баш экономист Марс Казаков, терлек азыгы әзерләү буенча баш технолог Әсгать Гәрәев төрлесе төрлечә җавап бирә. Ләкин бер мәсьәләдә барысы да бердәм:

— Институт башны эшләргә өйрәтә. Монда кайткач, иң кирәге шул...

Университетның филология факультеты да башны эшләргә өйрәтә икән. Илдус Гыйлаҗев, бу колхозга килүгә, игътибарын яшьләргә юнәлткән. Чаллы урта мәктәбен быел илле егет-кыз тәмамлый. Арадан медальгә тартучылар да бар. Вузга юл — туп-туры. Мәктәп директоры Мөстәкыйм Салихов белән киңәшкәч, ике җитәкче бер карарга киләләр: Нишлибез?— дип сорыйлар алар яшьләрдән.— Әлбәттә, сезнең авылдан китәргә, тагын да укырга хакыгыз бар. Ләкин бит авыл, колхоз үзебезнеке. Әллә бөтен классыгыз белән каласызмы? Бер-ике ел эшләгәч, тагын укырсыз. Читтән торып белем алырга да була. Институтларыбыз күп. Автономияле республикалар арасында Татарстан, ихтимал, институтларга иң баедыр.

Яшьләрнең ата-аналарын да мәктәпкә чакыралар. Нишлибез? Колхозны алга алып барабызмы, әллә дәүләт бюджетына атланабызмы? Колхозга механизаторлар, савымчылар кирәк...

Һәм халык аңлый. Кайбер ата-ана авыр сулап куя. Алкышларсыз гына карар кабул итәләр: без риза. Аннан «унынчылар» сүз ала: «Мине савымчы итеп фермага билгеләвегезне сорыйм. Гаризама өстәмә итеп савымчылык таныклыгымны терким». Егетләрдән: «Мине «Коммунизмга» колхозына механизатор итеп алуыгызны сорыйм. Гаризама өстәмә итеп...»

— Берәр төрле басым ясау булмадымы?— дип сорыйбыз Илдус Гыйлаҗевтан.

— Юк,— ди председатель.— Булмады. Бу бит андый эш түгел. Намус эше. Колхозда кадрлар җитми, ата-аналар да, яшьләр дә шуны аңлады.

Без китәсе көнне Илдус Гыйлаҗев янына урта мәктәп директоры Мөстәкыйм Салихов керде. Йомышы бар икән: унынчы класс укучыларының — кызу эш арасында булса да — язучыларны күрәсе килә. Вакыт табабыз — алар да, без дә. Очрашабыз. Без сөйлибез, яшьләр йотылып тыңлыйлар. Һәрберсенең беләгендә колхозда калу уңае белән идарә бүләк иткән исемле сәгать. Аттестат алуга колхоз исәбенә көньякка ялга һәм сәяхәткә барачаклар.

— Юлларын нишләтәбез?— ди директор аптырап.

Илдус Гыйлаҗев бераз гына дәшми тора да карар «кабул итә»:

— Бәй, болар инде безнең колхозчылар бит, сезнекеләр түгел,— ди ул директорга.

— Анысы шулай...

— Бәй, алай булгач, без инде барысын да үзебез карыйбыз. Алар бит инде ял итеп кайтуга эшкә чыгалар. Яшьләрдән төзелгән ике бригада булачак: савымчылар да механизаторлар. Бу инде — зур байлык. Алар әйбәт ял итсен өчен без чыганаклар табарбыз дип уйлыйм.

Директор бәхетле. Әйе, шулай, «туган туфрак» — матур сүз генә түгел, ул — конкрет әйбер.

...Чаллы — мәһабәт, парклы, күп кибетле, монументаль сәнгать комплексы булган авыл. Азнакайданмы, Лениногорскиданмы килгән рәссамнар Чаллы авылының исемен колхоз чигенә элеп кую өчен металл хәрефләр оештырып яталар. Тукайның теге, алда китерелгән сүзләре тагын искә төште. Бездә дә — Казан артында да — колхоз чикләрен күрсәтеп торучы язулар бар. Әмма арада фанер кисәген идән буявы белән керәндерәп, ак буяуга бармак манып язган щитларны да күргәлисең: «Фәлән колхоз территориясе. Рәхим итегез!..» Ә кояш, яңгыр, буран, коры-эссе җилләр дигәнең рәхимсез. Ул щитлар таланган, кубалакланган, авышкан...

«Коммунизмга» колхозы исә ике метр биеклектәге дюраль хәрефләр ясатып колхоз чигенә биек металл баганалар утыртырга җыена. Бу хәрефләрдә кояш нуры уйнаячак: «ЧАЛПЫ»! Бу биш хәреф бик ерактан күзләрне чагылдырачак: мәһабәтлек, якты өмет, максатлар киңлеге. Монда — заман стиле! КПССның май Пленумы карарлары белән рухланган бу колхоз коллективы республикабыз тарихына зур уңышлар белән керәчәк — безнең прозаиклар аннан әнә шундый фикер белән кайттылар.

Мөсәгыйт Хәбибуллин

# ҖИРНЕҢ ХУҖАСЫ ТУРЫНДА ТИРӘН КАЙГЫРТЫП

Авыл хуҗалыгын үстерү проблемалары бүгенге көндә язучыларны да нык борчый. 1990 елга кадәргә чорга СССРның азык-төлек Программасы расланган май Пленумында Л. И. Брежнев болай диде: «...КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы 1990 елга кадәргә чорга махсус Азык-төлек программасы эшләүне кирәк дип тапты. Мондый программаны әзерләү һәм тормышка ашыру — безнең планлаштыру системасында, социалистик экономиканы идарә итүдә принципиаль яңа адым. Программа азык-төлек проблемасын хәл итүгә максатчан, комплекслы якын килүне гәүдәләндерә».

Совет язучысының иҗаты — гомумхалык хезмәтенең аерылгысыз бер өлеше. Һәр каләм остасы үзен партиянең турылыклы ярдәмчесе буларак танытты һәм таныта. Моның ачык мисалы: соңгы елларда гына да авыл хуҗалыгын үстерү проблемаларына кагылышлы матур-матур әсәрләр иҗат ителде.

Бүгенге татар әдәбияты да — социалистик авыл хуҗалыгының үсеше дәверендә килеп туа торган шактый үткен проблемаларны кузгаткан әдәбият. Бу бигрәк тә безнең прозага хас. Авыл тормышы күзгә күренеп үзгәрә — үсешкә таба бара. Язучы әнә шул үзгәрешләрне вакытында күрергә, өйрәнергә, җыеп кына әйткәндә, үз әсәрләрендә тормышчан итеп чагылдырырга тиеш.

Билгеле булганча, тарихи процессларны өйрәнү эшен галимнәр башкара, мәсьәләнең психологик ягын өйрәнү һәм аны тасвирлап бирү исә тулысы белән әдәбият бурычы. Әйтик, бүгенге көндә авылдан чыккан кешеләрнең кайсы эшче, кайсы инженер, кайсы галим булып китте дә җирне бөтенләй онытты, дип уйларга урын бар. Әмма тормышта моның гел киресе дә булгалый. Шәһәргә күчеп килгән хәлдә дә кешедә крестьян психологиясе яши икән ләбаса! Бирегә ул бәләкәй генә участок ала да шунда яшелчәсен, җиләк-җимешен үстерә — кабат җир эшенә әйләнеп кайта. Димәк, шәһәр пропискасына карап кына, паспорттагы язуга карап кына кешенең психологиясе үзгәрми икән әле. Крестьян психологиясе аның күңел төпкеллегендә ята, алай гына да түгел, крестьян психологиясе аның балалары, оныкларына күчә, хәтта алар күңелендә дәвам итә.

Әдәбиятның бурычы — авыл кешесенең социаль һәм рухи йөзен өйрәнү, мәгәр пассив рәвештә түгел, бәлки яратып, үз итеп өйрәнү. Максат — әсәрләрдә авыл кешесенең рухи дөньясын дөрес тасвирлау, бүгенге геройларны, җирнең яңа хуҗаларын тулы канлы художестволы образлар аша гәүдәләндерү. Җирнең бүгенге хуҗасы — колхозчы. Җир аңа мәңгегә бирелгән. Әмма бүген авыл буыннар алышыну чоры кичерә, авыл кешесенең психологиясе үзгәрә дибез, шуңа карамастан, аның күңелендә һаман ике теләк: берсе — «үземнеке», икенчесе — уртак эш. Җиргә булган мөнәсәбәтләр дә диалектик үзгәрешләр кичерә. Туфракны күңел биреп эшкәртүче кеше — кыр батыры, нәкъ менә шуңа ышанып тапшыра ил җирне.

Язучы алдында торган бурычны мин иң әүвәл әнә шунда күрәм. Колхозчының психологиясендәге үзгәрешләрне өйрәнергә һәм шуны әдәби чаралар ярдәмендә әсәрләрдә гәүдәләндереп, җиргә булган мөнәсәбәтен үзгәртүдә аңа ярдәм күрсәтергә кирәк. Бүгенге авыл буыннар алышыну чоры кичерә, авыл кешесенең психологиясе күзгә күренеп үзгәрә, дидек, нәкъ менә шул сәбәпле аның җиргә карата булган мөнәсәбәте дә тамырдан үзгәрүгә дучар. Хәзер колхозчы да бит инде эшче диярлек — хезмәт хакына эшли, айга ике тапкыр акча ала. Шуңа да карамастан, күңелендә әле һаман ике теләк, ике фикер тартыша: беренчесе — минеке, икенчесе — җәмгыятьнеке.

Беренчесеннән мәхрүм итсәң — ул инде синең өчен иген игүче түгел, икенчесе булмаса — ул сине ашатучы, безнең тамагыбызны туйдыручы булып калаламы? Бир аңа кирәгеннән артык җир — ул бик тиз арада хосусый милек чиренә сабышачак. Ничек итеп шуларның барысын бергә әдәби әсәрдәге бер кешегә берләштерергә, бер-берсенә комачауламаслык итәргә? Ничек итеп крестьян психологиясенә хилафлык китермичә, аның күңелендәге җир-анага, мал-туарга булган мәхәббәтне саклап калырга? Минемчә, барыннан да элек җиргә карата суына башлаган мөнәсәбәтне үзгәртергә тиешбез.

Мәгълүм ки, законны экономика китереп чыгара. Дәүләтнең югары органы законнарны рәсмиләштерә һәм игълан итә. Нинди чаралар үткәрелергә тиешле мәсьәләләр ачыклангач, шул чараларга нигезләнгән төрле положениеләр, инструкцияләр, уставлар эшләнә. Шулай итеп, закон материальләшеп тормышка ашырыла.

Колхозчыларга акчалата хезмәт хакы түләүне кертү законы бик вакытлы һәм кирәкле чара булды. Бу закон үз-үзен аклады һәм тормыш аның бик вакытлы, урынлы чара булуын исбатлады. Кичәге хезмәт көненә эшләгән колхозчы яртылаш, ә кайбер очракта исә бөтенләе белән эшче сыйфатына керде. Әмма хәзергә әле колхозчы күп очракта дәүләт исәбенә алган хезмәт хакы күләмендә продукция бирә алганы юк. Эшче белән бер чамада хезмәт хакы ала, ә менә җитештергән продукциясе — аңа тотылган расходларны капламый. Басуда икмәк уңамы, уңмыймы, сыерлар сөте күпме, азмы — бу аны артык борчымый кебек. Авыл кешесенә хезмәт хакы белән бергә гамьсезлек килде. Әнә шул гамьсезлек авылда хезмәт дисциплинасын төшерүгә китерде. Авыл кешеләре колхоз исәбенә яшәгән подряд оешмаларына — сельхозтехника, сельхозхимия, ПМК, мелиораторлар, әзерләү пунктларына эшкә урнаша башладылар. Ә бит ул оешмаларга бары тик файдалы подряд булсын, эше күп күренсен дә табышы мул килсен, югары уңыш алу, күбрәк продукция җитештерү алар вазифасына гүя керми иде... Бу оешмалар игенче психологиясенә еләп каза китерде, аның җиргә булган ышанычын, ипекәйгә хөрмәтен киметте.

Май Пленумы андый хәлләргә чик куйды. Хәзер инде районнарда АПКлар — агропромышленность комплекслары төзелә башлады. Югарыда телгә алынган күп төрле оешмаларның эше колхозның нинди уңыш алуына карап бәяләнәчәк. Ә бу инде үз чиратында подрядчикны да, әзерләү пункты кешесен дә, наряд белән эшләүчене дә җиргә игътибар белән карарга мәҗбүр итәчәк, авыл кешесе психологиясендә хезмәткә хөрмәт белән карауны, һичшиксез, ныгытачак. Кыскасы, беркем дә җиргә битараф кала алмас! Бүген инде районда эшләүче һәр кешегә — романтикмы ул, әллә агрохимикмы, асфальтлы урамда яшиме ул әллә тузанлый торганындамы, икмәк үсә торган басуга якынрак мөнәсәбәттә булырга, бүген көн аяз булырмы, яңгыр ява калса, зонтик алыргамы, юкмы икән дип кенә калмыйча, боз явып, давыл килеп, иген әрәм булмагае дип, җир өчен, безне яшәтүче мөкатдәс җир өчен янып-көеп яшәргә туры киләчәк.

Май Пленумында Л. И. Брежнев болай диде: «Бу оешмалар эшенә бәя бирү, аларның җитәкчеләренә һәм белгечләренә премия бирү нигезенә, хезмәт күрсәтүләрнең үтәлеше белән бергәттән, авыл хуҗалыгы производствосы нәтиҗәләре дә, продукция чыгышы да салыначак. Ашлык, ит, сөт җитештерү арткан икән, азык-төлек сату күбәйгән икән, премия һәм зур түләү ал. Әгәр бу күрсәткечләр кими икән, колхозларга һәм совхозларга хезмәт күрсәтүче оешма җитәкчеләре һәм белгечләре премиядән мәхрүм ителәчәк. Бу гадел булачак. Хәзерләү оешмалары эшчәнлегенә килгәндә, аңа авыл хуҗалыгы продукциясен хәзерләүнең дәүләт планнарын үтәүгә турыдан-туры бәйле рәвештә бәя биреләчәк».

Кайбер мәсьәләләр әле киләчәктә тагын да конкретрак ачыклана төшәр. Әмма әйбәт эшкә нигез салынды, калганын инде тәҗрибә үзе күрсәтер. Язучыларга район звеносы җитәкчеләренең әнә шул «психологик барьерны» ничек итеп үтүләрен күздән ычкындырмаска кирәк булырдыр. Кичәге җитәкчеләр бүген турыдан-туры җиргә бәйләнгән булып чыга: әйтик, район күләмендә барлык колхоз председательләрен дә «биеткән» сельхозтехника җитәкчесе, теләсә-теләмәсә дә, хуҗа булу сыйфатыннан киңәшче сыйфатына күчәргә мәҗбүр булачак. Моңарчы районндагы һәрбер оешманың (ә алар район саен дистәләрчә) колхоз председателенә җәза бирергә хакы бар иде. Хәзер инде алар үзләре җиргә якынрак килергә, буразнага басарга мәҗбүрләр. Мон-

да алардан, районның кичәге җитәкчеләреннән, бөтенләй икенче төрле хезмәт, эш стиле таләп ителәчәк. Язучыга моннан да кулай материалның булуы мөмкинме?!

Кичәге начальник — бүген колхоз председателенең киңәшчесе дидек. Димәк, беренче чиратта ул җирнең ниндирәк нәрсә икәнлеген, аны ничегрәк эшкәртергә кирәклеген бик яхшы белергә тиеш була. Чөнки шунсыз ул юньле киңәшче түгел. Ә кайбер җитәкчеләр, ихтимал, бу яңалыкны үзләштереп тә җиткерә алмаслардыр, һәм андыйлар, эштән азат ителеп, җирне яхшы белгән һәм югары уңыш өчен җаны әрнегән кешеләргә юл бирергә тиеш булырлар.

Авыл нәрсәгә, нигә аеруча мохтаҗ бүген? Ни җитми яңа? Язучыларның авылдагы хәлне тирәнтен аңлап, теләктәшлек күрсәтү йөзеннән чын күңелдән әйткән җылы сүзе җитми бүген авыл кешесенә. Хәзергә әле без авылдагы, колхоз тормышындагы кимчелекләрне күрсәтүдән ары китә алганыбыз юк. Аларны без хәтсез күп күрәбез, хәйран калабыз, гарьләнәбез. Ә менә авылда яшәүнең, авыл эшчәннәренең хезмәте гүзәл икәнлеген үз әсәрләребездә матур итеп, сокланырлык итеп кайсыбыз күрсәтә алганы бар? Без әлегә кимчелекләрне мөмкин кадәр күпертебрәк ачып бирергә тырышып, теләсәк-теләмәсәк тә, авыл тормышына карата укучыларыбызда тискәре фикер уята килдек. Ә бит авылның шәһәргә бөтенләй хас булмаган искиткеч матур, гүзәл яклары бар һәм без үзебез дә моңа сокланып бетә алмыйбыз. Әйтегез, ишеткәнегез бармы, авыл җирендә яшәгән кешеләрнең силикоз яки рак авыруы белән авырып, вакытыннан элек дөнья куйганнарын? Безнең кайсыбыз шәһәр җирендә һәр көн иртән яңа сауган сөт эчә һәм кичен культура йортында хозурланып тынлы оркестр тыңлый?!

Язучының җылы һәм ихтирамлы сүзе колхозчыга әнә шул психологик күчеш чорын җиңелрәк уздырырга ярдәм итәр иде. Мин бернәрсәне бик нык ышанып әйтәм: калада тормыш итүе ансатрак, яшәү ямьлерәк, ягъни шәһәр кешесе ипекәйне җиңелрәк таба, дип уйлаучылар нык ялгышалар. Әнә шуны дәлилләп бирү, укучыны ышандырырлык итеп тасвирлау, психологиянең экономикага бәйле икәнен күрсәтү һәм шуның белән бүгенге колхозчыга җылы сүз белән ярдәм күрсәтү, аның күңелендәге шик-шөбһәне алып ташлау — бүгенге язучы алдына куелган социаль заказ әнә шуннан гыйбарәт.

Язучыга, һичшиксез, социологлар һәм статистлар китапларыннан тупланган материалга таянып та проблематик очерклар язарга була. Ләкин алай эшләү генә безнең өчен җитеп бетми. Безгә үз әсәрләребез белән укучыларда җиргә мәхәббәт уяту, җир эшеннән киткән кешеләрне, хәтта әле аларның улларын һәм кызларын, балаларының балаларын кире җир эшенә кайтару теләге уятырга кирәк. Очерк өчен генә дә (повесть яки роман жанрын әйткән дә юк!) һәркем өчен үрнәк булырдай колхозчыны табарга, шундый образлар гәүдәләндерергә кирәк ки, май Пленумында Л. И. Брежнев күздә тоткан геройлардан һич тә ким булмасын: «Эш башында аны белүче, аның өчен бөтен күңеле белән борчылучы, кешеләр белән эшли белүче кеше торган участок өчен тыныч булырга мөмкин. Андый җитәкчеләр турында, ул кеше үз урынында, диләр».

Пленум үткәч тә, оешкан төстә Азнакай районына барып, «Коммунизмга» колхозы идарәсе утырышында мин дә катнаштым. Алар май Пленумы карарлары нигезендә күмәк хуҗалыкны алып бару эшендәге актуаль мәсьәләләр тикшерелде. Колхозчылар һәм белгечләр эчтәлекле чыгышлар ясады. Сөйләшү безнең өчен дә, колхозчыларның үзләре өчен дә гаять файдалы булды. Без анда шактый күп яңалык, күркәм башлангыч күрдек. Колхоз — дүрт авылны берләштергән зур хуҗалык. Аның үзәктәге авылында гына да 500 дән артык кеше эшли. Элегрәк кечерәк авылларны әнә шул үзәк булган Чалпы авылына күчереп утырту эшен планлаштырган булалар. Яңа җитәкче, үзен колхоз председателе итеп сайлаган көннән башлап, ул күченү «мәшәкатенә» чик куя. Моңарчы перспективасыз дип саналган ваграк авылларның һәркайсында йортларны генпроект буенча төзи, клублар да сала башлыйлар. Яңа председательне өркетеп тә, шелтә бирәбез, дип тә карыйлар, тик ул үзенекен итә — йортларны бөтен шартларын китереп салдыра, каралты-курасын да кайгырта... КПСС Үзәк Комитетының май Пленумы Азнакай районы «Коммунизмга» колхозы председателе Илдус Гыйлаҗевның тоткан юлы дөрес икәнлеген раслады.

Җирнең чын хуҗасын күрдек без анда. Шундый зур эшләр майтаруы ансат кына

килмәгәнен дә белдек. Иртә таңнан караңгы төнгәчә председатель эштә — хәзергә йокы да, ял да, тынгы да юк аңа. Тик ул мондый хәлне вакытлыча дип аңлата: булдыклы, акыллы ярдәмчеләр табып, эшнең шактыен аларга йөкләргә исәбе. Хәер, андый уңган ярдәмчеләрне председатель тапкан да бугай инде — быелгы уңышны урып-җыю мәсьәләсен ничек хәл итәргә дип бергәләп киңәш-табыш корып яталар иде.

Колхозчыларның председательгә җылы карашта булуларын да күрдек без. Һәммә эшне берүзе ерып чыга алмаячагын яхшы аңлап, басуларны Илдус Гыйләҗев иген уңышын теләсә ничек яхшыга үзгәртә алырдай кешегә — агрономга тапшырган. Үзе ныклап торып төзелеш һәм терлекчелек белән шөгыльләнә.

Һәйбәт йортларны да салып була бүген авылда, асфальт юллар да узар, культура-агарту биналарын да корып җибәрерсең, тик менә синең ул урыннарда хезмәт ияләре эштән соң рәхәтләнеп ял итә алырлармы? Кызганычка каршы, юк икән әле... Бик аянычлы хәл. Чаллыда зурлыгы, мәһабәтлеге, эчке матурлыгы, бизәлүе ягыннан Казандагы Төзүчеләр Сараена тиңләшерлек Культура йорты күрдек. Әмма анда культура-агарту эшләрен алып барырдай кеше юк икән. Казандагы Культура институты башлыча авыл өчен кадрлар әзерли. Аннан белем алып чыккан яшьләр, кызганычка каршы, төрле сәбәпләр табып, шәһәрдә калу ягын карыйлар. Ә бит аларны авыл көтә! Шуларның берәрсе бу колхозга эшкә килсә, аңа каралты-куралы бер дигән йорт, мал-туар да бирерләр иде.

Бүгенге көндә авыл хуҗалыгына дәүләтебез искиткеч күп акча тота. Мисал өчен ашлыкны дәүләткә сатып алу бәяләрен күтәрүне яисә колхозларның финанс хәлләрен яхшыртуны гына алып карыйк: колхозлар 9,7 миллиард сумлык бурычларыннан азат ителә. (Чагыштырып карагыз: Камадагы автогигантны салуга да шундый ук акча тотылды.) Авылда торак йортлар төзү, культура-агарту корылышлары, юллар үткәрү өчен генә дә тагын 160 миллион сум тотылачак. Мондый максатка дәүләтебезнең моңа кадәр беркайчан да бу чаклы зур сумма чыгарганы юк иде әле.

Авыл яңарганнан-яңара бара, заманча салынган йортлар калка, аларның ачык төсләргә буялган түбәләре балкып күренер... Бу үзгәрешләрне әдәби әсәрләрдә гәүдәләндерми калу мөмкин түгел. Кыскасы, авыл киң масштаблы, тирән мәгънәле социаль үзгәрешләр кичерә, һәм крестьян тормышындагы бу яңаруны, әлеге чынбарлыкны әсәрләребездә, һичшиксез, яктыртырга тиешбез.

Газета һәм журнал битләрендә язучыларыбыз еш кына публицистик мәкаләләр белән чыгалар. Анда алар хәзерге колхоз героеның, гади колхозчыларның тормышын, фидакарь хезмәтен тасвирлыйлар. Публицистика барыннан да бигрәк тормышның үзеннән алынган конкрет фактларга таяна. Бу актив жанр тормышны өйрәнергә һәм яхшыртырга, үзенең героена гына түгел, бәлки укучысына да азмы-күпме ярдәм итәргә омтыла. Чөнки аның укучысы бер иген игүче генә түгел — икмәккә бәяү дә битараф була алмый.

Баерак, алдынгырак колхозларда быелдан ук җанланып китү атмосферасы сизелә. Һәммә нәрсәдә яңару, бәйрәмчәлек, бер-береңә ышанып карау, күңел тынычлыгы атмосферасы хөкем сөрә. Ләкин бит бернинди атмосфера да үзлегеннән барлыкка килми: игенченең талантына, уңганлыгына, инициативасына юл ачылды — һәммә нәрсә югары уңыш алу максатына буйсындырылды.

1990 елга кадәрге чорга СССРның Азык-төлек программасында болай диелә: «Без тикшерә торган Азык-төлек программасы — авыл хуҗалыгын һәм аңа бәйле тармакларны күтәрүдә тамырдан борылыш кына түгел. Үзенең характеры, масштабы буенча ул бөтен халык хуҗалыгының прогрессын тәэмин итәргә тиеш».

Совет язучылары алдында торган бурыч — Азык-төлек программасының нинди максатны күздә тотканлыгын колхозчыга әйбәтләп төшендереп бирү. Барлык көчне дә, бөтен тырышлыкны да бу программаны уңышлы үтәүгә юнәлдерү зарур, чөнки без «икмәк» сүзен ишетүгә күз алдыбызга алтын башаклы иген басулары гына, икмәк кибетендә кумәчләр, ипекәйләр тулы киштәләр генә килми, бәлки Ватан сугышы, ачка интегүче Ленинград, карточка системасы, сугыштан соңгы бөлгенлек, иртән ачыласы икмәк кибете алдына кичтән үк чират торулар да килә. Боларның барысын да совет кешеләре үз башыннан кичерде.

Һәм менә без бүгенге авылны күрәбез. Авыл нәрсә уйлый, ничек уйлый? Бүген

аның бар кайгысы — иген уңышын елдан-ел арттыру, терлекчелектә тотрыклы үсеш ісауга ирешү.

Планетабызның бөек һөнәр иясе — иген игүченең тормышын, уй-хисләрен, максатын, омтылышын, мәхәббәтен, күңел тибрәнүләрен чагылдырган әсәрләр иҗат итү безнең изге бурычыбыз. Һәм без, Татарстан язучылары, бу юнәлештә өзлексез эшләп киләбез.

Икмәк өчен җан атып яшәүче язучыларыбызның исемнәрен әйтми генә үтәрмен дигән идем дә, хәер, әйтмичә дә булмас, ахры.

Гомәр Бәширов — гомере буе авыл өчен эшләде, аксакалыбызның бөтен иҗат иткән әсәрләре — авыл кешесенә багышлана. Аңа хәзер дә бу юнәлештә яңа иҗади уңышлар телибез.

Гариф Ахунов — райком секретаре хакындагы очерк өстәл артында утырып кына язылмады — авторыбыз Арча районына кабат-кабат барды. Авыл эшчәннәренә багышланган ул китабы Мәскәүдә рус телендә басылды.

Мөхәммәт Мәһдиев — оста публицист, авыл тормышын тасвирлаган документаль һәм художестволы әсәрләр авторы. Проза секциябезнең җитәкчесе. Язучыларның Азнакай районына барып кайтуын да ул оештырды. Безнең колхоз председательләре белән Казанда уздырылган очрашуны да секция оештырды. Аның авыл турында, авыл эшчәннәре турында, яңадан-яңа әсәрләр иҗат итүен көтәбез.

Вакыйф Нуруллин — әгәр төн уртасында уятып сорасалар да — мин хәтта әле төшемдә дә авыл эшчәннәрен күрәм, алар турында язудан һич туктаганым юк, дияр иде. Нәшриятта җаваплы эше белән бергә ул һаман актив язучы. Фәкать авыл кешеләре турында яза һәм язачак. Шуңа күрә аны авыл прозасы авторы дип атарга мөмкин.

Аяз Гыйләҗев — ел саен туган якларыннан урап килә, проблематик очерклар яза...

Гариф Галиев — авыл турындагы иң күп хикәя иҗат иткән, авылга мәдхия җырлаган өлкәннәребездән берсе. Укучыларны әледән-әле яңа гүзәл әсәрләре белән сөендерә. Хәзер дә үзенең игенчегә адресланган үтемле сүзен әйтер дип ышанасы килә.

Барлас Камалов — туктаусыз эзләнүчән, разведчик язучы, җаны-тәне белән, оста-матур сүзе белән ул, һичшиксез, авыл язучысы. Минемчә, Барлас йөзгә чаклы яшәсә дә — ипекәйгә, аны үстерүчеләргә сокланудан, шул хакта язудан туктамас иде. Бу изге эшендә аңа уңышлар телик.

Габдрахман Минский — авылны ярата, үзе гомер буе шәһәрдә яшәсә дә, күңеле һаман авылда. Өлкән яшьтә булуга карамастан, әле һаман яшь тавышлы прозаигыбызның илһамланып язган публицистик мәкаләләрен без әледән-әле зур кызыксыну белән укыйбыз.

Әхсән Баянов — авыл кешесе. Бу язучыга, вакытлыча гына булса да интрига белән яшәүче геройларыннан арынып, икмәккә, бураэнага, олы байлыкны яулап алучы алтын куллы кешеләргә якынрак килүне телисе иде. Ул анда да үзенең әсәрләре өчен яңа сюжетлар табачак. Аңардан шулай ук проблематик мәкаләләр һәм тирән фикерле очерклар, гомумән, матур яңа әсәрләр көтәбез.

Хәниф Хәйруллин — ел саен документаль повесть яисә очерк иҗат итәрдәй язучы. Сарманда яшәп, колхоз тормышының эчендә кайнаган бу иптәш иҗатында чак кына активрак булса да зыян итмәс иде.

Габдулла Шәрәфетдинов — әгәр чабуыннан «Азат хатын» чытырдатып тотмаса — бер көн тормастан авылга китәр иде дә гомерлеккә шунда яшәп калыр иде кебек... Бөтен фикер йөртүләре нәкъ авылча. Күп язмаса да, инде язган кадәресен дә крестьян психологиясен үтәдән-үтә күреп, тирәнтен аңлап сәнгатьчә яза. Яңа Программа, һичшиксез, бу прозаикка да иҗади азык бирер дип ышанасы килә.

Марсель Галиев — бик акрынлык белән генә җиргә әйләнеп кайта. Ә бит авыл темасыннан читләшеп чак кына ялгышты да. Тиздән аның авылга багышланган повестен күрәчәкбез. Һәм бу авыл эшчәннәре турында соңгы әсәре булмас, әлбәттә.

Атилла Расих — галим, авылга кагылышлы фән иясе, инде өлкән әдип. Галим сыйфатында ул мал-туар асрауны, аларны тукландыру юнәлешен өйрәнсә, әдип бу-

ларак галимнәр тормышын гәүдәләндерә. Бу өлкәдә безнең берданбер хезмәтчәнебез диярлек каләм остасына да уңышлар телибез.

Әмирхан Еники — хикәя һәм повесть басуларын гаҗәеп тирән сөрә торган остаз әдип. Инде хәзер кечкенә-вак авылларны урыннарыннан күчермәячәкләр, киресенчә, алар төзекләндерелергә тиеш. Димәк, аның героинясы Ак әбигә тыныч кына яшисе дә яшисе, оныклары кайтканны көтәсе дә көтәсе...

Борын-борыннан милекне саклый белү икмәкә хөрмәт белән караудан башланган. Әмма бүгенге көндә шул ризыкны капчыклап, кәрзин-кәрзин, җиңел автомобильләрнең багажнигына төяп мал-туарга ашату өчен шәһәрдән авылга ташуны ничек итеп аңлатырга? Йорт малларына бәһасе булмаган, яңа пешкән булка, батоннар ашатуны ничек итеп аңларга һәм аңлатырга? Ә чүп савытлары янына каткан ипи кирпечләре өелүенә ничек битараф калырга? Боларның барысына да җавап бер генә: ул кеше ипи өчен акча түләгән... Бик арзан бездә ипекәй, бик очсыз.

Казанда һәм Республикабызның бүтән шәһәрләрендә икмәк пешерү белән кемнәр шөгыльләнә? Кайда күпме, нинди күләмдәге булкалар пешерелә! Бу эшкә дә исәп-хисап дигән нәрсәне кертергә күптән вакыт иде. Ә менә бездән кайсыбызның шушы актуаль мәсьәләне күтәреп чыкканы бар? Футбол урынына ипи тибеп йөргән малайлар турында, хәер, Нәби Дәүли бер вакыт язып чыккан иде. Бүтән берәүнең дә моны кузгатканы булмады шикелле... Ә бит статистика безнең өчен шактый күңелсез санны китерә: бөтен ил күләмендә һәр елны җиде миллион тоннадан артыграк икмәк — чүп чиләгенә ыргытыла...

Икмәк һәрвакыт кешенең намусы урынына йөртелгән ризык булган. Һәм ул бүген дә шулай. Ә соң намусны шулай аяк астына ташлыйлар димени? Димәк, ипекәйгә кадер-хөрмәт барыбызда да бер дәрәҗәдә түгел икән әле. Икмәкнең чын бәһасен белмәүче, симерүе чамадан ашып җиткән кешенең намусын ояту һәм ипекәйгә хөрмәт тәрбияләү — бу инде язучы алдына куела торган олуг бурычларның да олугыдыр. Хәтта әйбер бәяләре дә һәр заманда икмәк бәясенә чамалап йөргән.

Икмәк исе... Икмәк тәме... Язучы үз әсәрендә һәммә нәрсәне дә икмәк белән бергә бәйләп күрсәткәндә нинди генә чагыштырулар китерми! Бүген кибетләр икмәк белән шыгрым тулы — карасы кирәкме, агымы, арышымы, бодаемы дигәндәй... Исе ни тора бит шуларның! Уңдырышлы елны — җил, яшен, алтын басулар исе, корылык елында — тузан, давыл исе... Әйе, кешегә икмәк ансат кына бирелми, табынга җиңел генә килми икмәк...

Хәзер барча басу-кырларда, 1983 елны уңдырышлы итү өчен хәзерлек эшләре алып барыла. Азык-төлек программасы яңа елдан ук җимеш бирсен өчен бик күп тырышасы, авыл эшчәннәренең фидакарь вә изге хезмәте турында ялкынлы әсәрләр язасыбыз бар безнең. Моның өчен май Пленумы куйган мәсьәләнең ни дәрәҗәдә әһәмиятле һәм тирән мәгънәле икәнен янә бер мәртәбә чын йөрәктән тоярга гына кирәк. Җир хуҗасы турында тирән кайгыртып эшлик.

# «РӘХИМ ИТЕГЕЗ, ХӨРМӘТЛЕ ЯЗУЧЫЛАР!»

*«Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәләре турында» КПСС Үзәк Комитетының тарихи карарын өйрәнеп, без быелгы август азагында Хезмәт Кызыл байрагы орденлы Мулланур Вахитов исемендәге химия комбинатында булдык.*

*Казанның Идел буе районында, 1917 елда Кызыл гвардия штабы эшләгән, хәзер комбинат идарәсе урнашкан бинада безне, әдәбиятыбыз һәм аның көзгесе «Казан утлары» журналы вәкилләрен, предприятие җитәкчеләре каршылады. Илебезнең алдынгы зур предприятиеләреннән берсе, республикабыз горурлыгы булган комбинатның директоры А. М. Рәхмәтуллин, партком секретаре И. К. Шаматов иптәшләр комбинатның тарихы, эшчеләренең героик көрәше һәм коллективның хәзерге фидакарь хезмәте турында сөйләделәр. Аннары цехларда яңа техника, эш шартлары, прогрессив алымнар, алдынгы эшчеләр белән таныштык. Сабын кайнату цехының исле сабын бүлегендә, шәм цехында, җиденче цехның сувенир бүлегендә эш процессы белән кызыксындык, эшчеләр белән якыннан таныштык, сөйләштек, дөресрәге, чын мәгънәдә дуслаштык.*

Халкыбызның ялкынлы революционеры, гражданнар сугышы каһарманы, публицист, бөек Ленин эше өчен, хезмәт ияләренең азатлыгы, бәхете, барлык милләт халыкларының дуслыгы өчен көрәштә корбан булган Мулланур Вахитов исемен йөрткән бу комбинат тарихи-революцион традицияләргә гаять бай.

Мәскәү фабрикантлары Крестовниковларның Казандагы шушы шәм, сабын, стеарин заводы эшчеләренең газаплы тормышы белән Казанда эшләгән чагында беренче буларак (1884 ел) А. М. Горький таныша. Шунда слесарь булып эшләгән Яков Шапошников белән дуслаша, бу шактый ук белемле, сугышчан атеистның самодержавиегә, изүчеләр дөньясын яклаучы кара дин әһелләренә ачы нәфрәтен онытмый һәм завод эшчеләренең революцион аңы үсә баруына соклана. Соңыннан язучы үзенең «Минем университетларым» дигән әсәрендә татар бистәсендә яшәп, үпкә авыруыннан үлгән бу батыр эшчене хөрмәт белән искә ала.

1887 елны Казан университетында самодержавиегә каршы В. И. Ульянов җитәкчелегендә студентлар башлаган революцион сходка бу завод эшчеләрен дә рухландыра, анда стачкаларга өндәү башлана. 1888 елда заводтагы каторга режимына, авыр тормышка, 14—16 сәгатьлек газаплы хезмәткә ризасызлык белдереп көрәшкә күтәрелгән, стачка башлаган 130 эшчене завод хуҗалары «кара китапка» язып, заводтан куалар.

1892 елда биредә Н. Э. Бауман алдынгы эшчеләр белән беренче яшерен марксистик түгәрәк оештырган. 1889—1900 нчы елларда Крестовников эшчеләре арасында Н. А. Семашко зур революцион эш алып барган. Шул ук елда оештырылган яшерен социал-демократик түгәрәк эшен исә партия агитаторы М. М. Әхтәмов җитәкләгән. Крестовниковлар заводы районында партия оештыручысы буларак, эшчеләрне берләштерү, алар арасында партия йогынтысын һәм политик көрәшне көчәйтү юлында ленинчыл революционер С. Г. Гассар да күп эшләгән.

1905 елда РСДРПның Казан шәһәр комитеты җитәкчесе Я. М. Свердлов бу завод эшчеләре арасында да революцион эш алып барган: биредә ул бернича тапкыр була, агитация эшләрен җәелдерә, алдынгы эшчеләр белән дуслаша һәм шул елда РСДРПның Казан комитеты заводта йөздән артык прокламация тарата.

Казандагы механика-технологик училищесында укыган чагында ул заводта С. М. Киров та булган. Аның эшчеләренең авыр тормышы турында Уржум шәһәренә болай дип язган:

«...Биредә эшчеләр көнне-төнне белмичә, ел буена һичбер бәйрәмсез эшлиләр. Сез алардан, бәйрәм көннәрендә дә ни өчен эшлисез?— дип сорасагыз, алар сезгә болай дип җавап бирерләр: әгәр без, бер генә көн эшләмәсәк тә, безнең стеарин һәм май туңа, аны яңадан эретергә кирәк булачак... Бу турыда уйласаң: ни өчен соң берәү бер нәрсә дә эшләмичә рәхәтләнеп яши дә, ә икенче берәү һичнинди ял белми, коточкыч нужалыкта яши, диярсең...»

26 Баку комиссарларының берсе Иван Яковлевич Габишев шул ук заводның механика цехында токарь булып эшләгән.

Аның әтисе Яков Николаевич та, бертуганы Федор да — шушы завод эшчеләре. Лена прискасындагы канлы вакыйгалардан соң Иван Габишев үз тормышын самодержавиегә каршы көрәшкә багышлый. Ленин партиясе сафына керә һәм сабын заводында оештырылган стачка башлыгы була. Крестовниковлар доносы буенча завод большевикларын кулга ала башлагач, партия аны 1914 елда Бакуга озата. Татар телен яхшы белгән бу революционер Бакуда татар эшчеләре арасында партия-политик һәм пропаганда эше алып бара, әзербәйҗан нефть промыселларында эшләүче һәм портта йөк ташучы татар эшчеләрен патша самодержавиесенә каршы көрәшкә туплый. Бакуда совет байрагы күтәрелгәч, ул Кызыл гвардия отрядлары оештыру үзәк штабында эшли, аны Баку Порт районы эшче һәм солдат депутатлары советы председателе итеп һәм Халык комиссарларының Баку советы члены итеп сайлыйлар. Интервентлар һәм аларның лакейлары — эсерлар Баку комиссарларын ерткычларча үтергәндә дә Иван Габишевка әле 30 гына яшь тулган була.

Комиссар Иван Габишевның исеме хәзер Казанда да мәңгеләштерелде: Казанның яңа зур бер урамы комиссар Габишев урамы дип атала. Комбинатның механика цехына аның исеме язылган мемориаль такта куелды. Цехларда Иван Габишев исемен йөртү хокукын яулап алу өчен киң җәелгән социалистик ярышта җиңгән Әмир Галимҗанов бригадасы да данлыклы комиссар исемен йөртә.

1917 елда инде завод урнашкан район Казандагы сугышчан пролетар үзәкләренең берсенә әйләнә, заводның үзендә большевиклар ячейкасы һәм Кызыл гвардия отряды оештырыла.

Мәгълүм булганча, 1918 елда В. И. Ленин кушуы буенча Казанга килгәч, Мулланур Вахитов яңа эшче отрядлары төзешә, завод эшчеләреннән ул тулыландырылган 300 кешелек отряд, башка эшче коммунистик отрядлар белән бергә, ак бандитларга каршы көрәшкә ташлана. Ул канлы сугышларда күпләр һәлак була. Дошман кулына эләккән ленинчыл комиссар Мулланур Вахитов, кыю большевик Сергей Гассар, завод кызыл Гвардия штабы членнары бертуган Константин һәм Георгий Петряевлар ерткычларча үтерелә.

Революция дошманнары һәм буржуаз милләтчеләр атып үтерер алдыннан М. Вахитовның коммунизм эше җиңүенә тирән ышанып: «...мине атачаклар. Башлаган көрәшне тәмамлагыз. Без орлыгын чәчтек, аның үсентеләре тыелгысыз үсеп чыгачак...» — дигән утлы сүзләре һәр вахитовчы йөрәгенә уелып калган. Ул сүзләр буыннан-буынга, йөрәктән йөрәккә күчеп яши. Шуңа күрә дә вахитовчылар революция каһарманнары эшен лаеклы дәвам иттерәләр, намуслы хезмәтләре белән коммунизм җиңүен якынайту эшенә үзләреннән зур өлеш кертәләр.

«Унберенче бишьеллыкта һәр елның план-заданиесен ел саен 7 ноябрьга үтәргә!» — вахитовчылар ярышының девизы әнә шундый. 1981 ел йомгаклары буенча Социалистик Хезмәт Герое Г. З. Сәлимҗанов, Ф. Г. Хөсәенова, В. С. Фатула, Х. Х. Гибашева җитәкләгән бригадалар «СССР азык промышленностеның иң яхшы бригадасы» дигән мактаулы исемнәргә лаек булганнар. Л. В. Сумбаеваның комсомолъяшьләр бригадасы шул ук министрлык һәм профсоюзлар Үзәк Комитетының Мактау грамотасы белән бүләкләнгән.

Вахитовчылар 1982 елның ярты еллык планын срогыннан элек арттырып үтәп, халыкка 40,6 миллион сумлык киң куллану товарлары эшләп чыгарганнар. Ватаныбыз — СССРның 60 еллык бәйрәме хөрмәтенә алган йөкләмәләрен үтәү өчен көрәштә без В. С. Губкина, Г. П. Бауснева, Г. З. Сәлимҗанов, Л. Ф. Тянулина бригадалары

һәм бүтән берничә бригаданың, алдынгыларның да алдынгылары булып, югары җитештерүчәнлеккә ирешкәнлекләрен белдек.

Комбинат цехларында безне ветераннарның да зур дәрт белән эшләүләре сокландырды. Мәсәлән, шәм цехында Мәдинә Гыйбадуллина, Гөлфия Габдрахманова, Суфия Закироваларның эш стажлары инде 35—40 елдан артып киткән. Бибинур Сафина алардан да уздырган: станок янында ул инде 54 ел эшли һәм фигуралы шәмнәр ясаучы иң яхшы оста икән. Сабын кайнатучы Герман ага Караваевның да комбинатта эшли башлавына 52 ел тулган. Бу өлкән ага да бик өлгер, һәм ул Людмила Жукова, Валентина Манькова кебек цехташларына бик зур осталык таләп иткән сувенир сабыннары кайнатып эшкәртү тәҗрибәсе белән уртаклашып эшли.

Комбинат директоры Альберт Мәсгутович Рәхмәтуллин бөтен коллективның 1982 ел планын арттырып һәм срогыннан элек үтәячәген зур ышаныч белән әйтте. Бу исә илгә 165 миллион сумлык продукция бирү дигән сүз! Ә бит Крестовниковлар заводы иң яхшы эшләгән 1913 елда 5 миллион сумлык продукция эшләп чыгарган. Крестовниковлар хуҗа чагында ел буе газапланып эшләгән продукцияне, азат хезмәт батырлары хәзер бер көндә эшләп чыгара!

М. Вахитов исемендәге химия комбинатында «Казан утлары» журналының шушы коллектив белән дуслыгы әнә шулай танышудан, йөрәкне йөрәккә каратып сөйләшүдән башланып китте. Комбинатның җитәкчеләре дә, эшчеләре дә, әдипләргә һәм әдәбиятыбызга тирән хөрмәт белән:

— Рәхим итегез, каләм осталары, цехларыбыз ишеге сезнең өчен һәрвакыт ачык!— диделәр.

Мөхәммәт САДРИ,
Зәки НУРИ,
Фәннур САФИН.

# Мөхәммәт Садри

## Казан коммунары

Һәйкәл иҗат иттек Вахитовка,
Гөл-чәчәкле завод эчендә,
Ул дәрт өстәп яшәр һәрбер цехка,
Ялкын тулы эшче хисендә.

Ленин аңар иң мөкатдәс булган,
Пароль итеп исемен ятлаган,
Күкрәү аша таңга барган юлдан
Ут яуса да алга атлаган.

Идел крепостен — таш диварын —
Казан җирен саклап калырга,
Озаткан Ленин батыр комиссарын
Ак фетнәне кырып салырга.

Саклап Ленин йөргән урамнарны,
Үзе туган Казан җирләрен,
Ак яуларның очырып бураннарын
Алга илткән завод ирләрен.

Ә бер кичтә Каппель куштаннары,
«Хакимнәре» Болак артының,
Тоткан аны хаклык дошманнары,
Дошманнары совет халкының.

Кара төндә аклар мылтык корган,
Элэктергәч аны кулына,
Янар таудай Казан тетрәп торган
Аткан чакта газиз улына.

Вахитов ул исән: алгы сафта
Заводларда, ферма, кырларда.
Телдән төшми иseме безнең якта,
Йөрәкләрдән чыккан җырларда.

Яши аның бу заводка килеп
Эшче отряд төзегән эзләре,
Тынмый аның: «Коммунизм, җиңеп,
Мәңге яшәр!» дигән сүзләре.

Вахитов ул һәрбер цех эчендә,
Яши һәрбер эшче хисендә,
Һәр намуслы эшче көчендә ул,—
Нәтиҗәле кайнар эшендә!

Безнең дөнья гел үзгәрә бара:
Яшь эшчеләр басты постларга,
Батыр алмаш килде, әнә кара,
Җиң сызганган яңа цехларга!

Яшь Вахитов канын коеп җиргә
Чәчкән орлык кискен көрәштә,
Шытып, үсеп чыкты туган илгә!—
Ә яшь буын изге теләккә

Ташып торган дәрт-дәрманын кушып,
Җиңелмәс көч туплап кулларга,
Утлы байрак — таң байрагы тотып,
Кыю атлый авыр юллардан.

Әйе, атлый, һәр буынга даим,
Вахитовның рухы, йөрәге,
Коммунага илткән һәр көн саен
Эшкә аша якты теләге!

Улы Казан, Идел ярларының,
Каһарманы совет халкының,
Яшәр һаман Ленин байрагының
Нурларына өстәп ялкынын!

Нуры булып яшәр кояш-таңның,
Галиҗәнап эшче хисендә,
Ул партия, халык һәм Ватанның
Бердәмлеге, эше, көчендә!

Чыннан да ул канын коеп җиргә
Чәчкән орлык ярсу көрәштә,
Шытып, үсеп чыкты туган илгә,
Яшәр өчен һәрбер йөрәктә [1].

## Рәхмәт сезгә

Берәү табына әйбәт, затлы мебельләргә,
Автомобиль алган иргә-егетләргә.
Икенчеләр — паласларга, көмешләргә,
Асыл ташлы алтын алка-йөзекләргә...

Ә мин исә шөкерана итәм
Икмәк һәм тоз куйган табыннарга,
Газиз икмәк кисәр алларыннан,
Кулым-битем юган сабыннарга!

Әйе, сабыннарга!
Икмәксез, сабынсыз
Булам мин сабырсыз.
Икмәксез, сабынсыз
Яшәми беркем дә,
Беркем дә, бер көн дә!

Йөзгә ак нур сипкән сабын,
Йөзне ак, саф иткән сабын,
Күлмәкләрне юар сабын,
Тәннән керләр куар сабын,
Чәчәк исләре тараткан,
Һәркем хуш күргән, яраткан
Алсу, яшел, исле сабын,
Җанга рәхәт — хисле сабын!..

Эштән кайтып кулым-битем юдым
Ак итеп, пакь итеп,
Рәхәткә күмелдем,
Рәхмәт әйтеп сабынга!
Ак кулым, саф кулым белән
Икмәккә үрелдем килдем дә табынга!..

Моннан илле ел элек мин
Дан җырлаган идем бер табында!
Вахитовчылар эшләгән сабынга
Мактау җырым җитсен тагын да.

Игенченең тырыш көче белән
Өзелмидер икмәк табыннан.
Һәркем ак һәм пакь яшәсен диеп
Сез өзмисез илне сабыннан.
Рәхмәт сезгә, вахитовчылар!

---

[1] Казан химия комбинатында М. Вахитовка һәйкәл ачканда укылган шигырь.

Рәис Сабиров

# ЛЕВ ТОЛСТОЙ һӘМ КАЗАН

Бу бүлекне язарга керешкәндә, бөтен илебез, бөтен кешелек дөньясы, цивилизациягә азмы-күпме кагылышы булган һәр кеше Лев Николаевич Толстойның якты истәлеге алдында баш иеп, бу гигант-художникның тууына 150 ел тулу бәйрәмен яңа гына билгеләп үткән иде инде. Бу вакыйгага уңае белән аның турында шул кадәр күп язылды ки, бу даһиның тормышындагы кыска бер чор — Казан чоры турында нидер әйтергә теләгән авторның хәлен һәркем аңлар.

Л. Н. Толстойның Казанда үткәргән еллары турында матбугатта аз язылмаган. Бер караганда, укучыларга барысы да билгеле кебек. Лев Николаевичның безнең шәһәрдә 1841 елдан 1848 елга кадәр җиде ел чамасы яшәгән булуы да, әтисе Николай Ильич вакытсыз үлеп киткәч (ә аның әнисе тагын да элегрәк, булачак язучы нибары яшь ярымда булганда дөнья куя), тугыз яшьлек малай, абыйлары Сергей һәм Дмитрий, апасы Мария белән бергә әтисенең туган сеңелесе, Казан алпавыты Владимир Иванович Юшкова кияүдә булган Пелагея Ильинична тәрбиясендә кала, ә унөч яшь тулгач, 1841 елда шушы туган апасы янына, Казанга бөтенләй күчеп килә. Хәер, Казан граф Толстойлар нәселе өчен гомумән ят шәһәр саналмый. Әле 1754—1759 елларда ук Лев Николаевичның бабасының әтисе Андрей Иванович Толстой Казанда секунд-майор[1], аннары Свияжск шәһәрендә воевода булып торган. Аның бабасы, замандашларының әйтүенә караганда, йомшак холыклы, җор телле, мәҗлесләр, театрлар, баллар яратучы һәм шул рәвешчә, күңел ачу белән бөтен бар булганын җилгә очырган кеше — Илья Андреевич Толстой да яшь вакытында Казанда озак еллар яшәгән. 1815—1820 елларда ул биредә губернатор булып торган, ләкин, әле генә саналган сыйфатлары аркасында булса кирәк, әллә ни эш майтара алмаган — 1820 елда сенат тарафыннан җибәрелгән ревизия вакытында губерна канцеляриясенең эшендә зур кимчелекләр ачылганлыктан, губернаторлыктан китәргә мәҗбүр булган. Ул Казанда үлгән һәм элекке Елан тавы монастыре зиратына күмелгән. Безгә шулай ук язучының әтисе Николай Ильичның Наполеонга каршы сугыш тәмамланганнан соң 1815 елда, отставкага чыгып, Казанга кайтканлыгы, биредә сеңелесе Пелагеяның кияүгә чыгуының шаһиты булганлыгы, әтисенең үлемен кичергәнлеге дә билгеле. һәм Николай Ильич, Л. Н. Толстой үзенең истәлекләрендә язганча, «булган барлык бурычларны капларга да җитмәслек мирас, зиннәткә күнеккән карт анасы, сеңелесе һәм тудыкасы белән торып кала». Казанда аны княжна Волхонскаяга өйләндерәләр. Лев Николаевичның абыйлары Николай (ул 1841 елда Мәскәү университетыннан Казанныкына күчә), Сергей һәм Дмитрий Казан университетында укыйлар. Сеңелесе Мария Николаевна Родионовның кызлар институтында укый.

Инде телгә алынган истәлекләрендә язучы үзенең бөтен тормышын дүрт чорга бүлә. Менә алар: «гаҗәеп матур, гөнаһсыз, шатлыклы чор, үндүрт яшькә тикле булган шагыйранә балалык чоры», «аннары — егерме еллык коточкыч чор... дан, шөһрәт

Ахыры. Башы журналның 4, 9, 10, 11 саннарында.
[1] XVIII йөздә рус армиясендә гаскәри дәрәҗә.

яулауга хезмәт итү чоры» һәм «...өченчесе — өйләнүдән башлап рухи яктан туугa кадәр булган унсигез еллык чор». Бу чорда ул «намуслы, дөрес гаилә тормышы белән» яши, шуңа күрә аны «дөньяви күзлектән караганда, әхлаклы чор дип атап булыр иде». Һәм, ниһаять, Л. Н. Толстой әлеге юлларны язган вакытка караган егерме еллык дүртенче чор. «Үткән елларда... үзләштерелгән начар гадәтләрдән» арынуны исәпкә алмаганда, язучы бу чорны «берничек тә үзгәртергә теләмәс» иде.

Безне барыннан да элек барлык бу чорларның икенчесе кызыксындырырга тиештер, күрәсең. Тагын бер кат искә төшерик: Лев Николаевич Казанга 1841 елда, унөч яшендә чакта килә. Димәк, бу чор нәкъ менә безнең шәһәрдә башланган булып чыга. Нәрсәсе белән аерылып тора соң ул? Л. Толстойның язмаларында бик тә кызыклы бер урын бар. Ул А. С. Пушкинның «Истәлекләр» дигән шигырен укуы һәм бу шигырьнең аңа көчле тәэсир итүе турында яза. Аннары Пушкинның түбәндәге юлларын китерә:

Тормышымны укыйм җирәнеп мин,
Һәм каһәрләп аны туя алмыйм.
Укыйм тетрәп, ләкин бик күп юлның
А я н ы ч ы н епап юа алмыйм.

«Тик мин,— дип яза аннары Л. Н. Толстой,— моны болайрак итеп үзгәртер идем: «аяныч...» урынына «хурлыклы» дип куяр идем». Чөнки аның үз биографиясен аңлату өчен шулай кирәк. Менә бит ничек: хәтта «хурлыклы» ук булган икән аның ул чактагы, ягъни Казан чорындагы тормыш юллары.

Инде фактларга мөрәҗәгать итик. 1844 елда уналты яшьлек Лев Николаевич, Казандагы император университетының Көнчыгыш бүлекчәсе студенты итеп алуларын сорап, бу уку йортының ректоры, действительный статский советник Н. И. Лобачевский исеменә прошение бирә. Үзеннән-үзе бер сорау туа: нигә нәкъ менә Көнчыгыш бүлекчәсенә? Л. Н. Толстойның тормышын һәм иҗатын өйрәнүче белгечләр фикеренчә, бу мәсьәләдә егетнең үз теләгеннән бигрәк шөһрәт яратучан апасы Пелагея Ильинична Юшкованың аны һичшиксез күренекле дипломат итү планнары хәлиткеч роль уйнаган. Пелагея Ильинична бу бүлекчәгә кызыга кызыгуын, тик егетебезнең эшләре әллә ни мактанырлык килеп чыкмый. Беренчедән, Лев Николаевич кабул итү имтиханнарын бирә алмый. Шуннан соң ректор исеменә икенче бер прошение керә, һәм бу кәгазьгә Н. И. Лобачевский үз кулы белән: «Өстәмә имтихан тапшырырга рөхсәт итәргә. 4 авг. 1844 ел», дигән резолюция сала.

Ниһаять, граф Толстой — университет студенты. Ничек кирәк алай беренче ярты ел үтеп китә. Студентыбыз укуга салкын карый. Бигрәк тә тарихтан хәл мөшкел. Өстәвенә Россия тарихы профессоры, аңа ерак туган тиешле кеше Н. А. Иванов белән мөнәсәбәтләр бозылып китә. Үчле, усал кеше була бу профессор. Лев Николаевич аның лекцияләренә бөтенләй йөрми башлый. Чакырып сөйләшүләр дә, хәтта карцерга утыртулар да (ул чакларда студентларны шундый җәзага да тартканнар) ярдәм итмәгән. Нәтиҗәдә — тарихтан — «икеле». Ул гына да түгел, «лекцияләргә бик сирәк йөрүе һәм тарихтан өлгермәве сәбәпле Лев Толстойга имтиханнар тапшырырга рөхсәт итмәскә» дигән карар чыгарыла.

Менә шуннан соң яшь Толстой юридик факультетка күчәргә карар итә. Биредә аңа яңадан беренче курстан башларга туры килә. Әмма монысында да студентыбызның эшләре ал да гөл булудан шактый ерак. Дөрес, юридик факультетта ул икенче курска җитә. Әмма укудан һаман тәм таба алмый ул. Университет ректоры (бу юлы инде Н. И. Лобачевский түгел, аның сабакташы һәм хезмәттәше астроном профессор Иван Михайлович Симонов) исеменә түбәндәге гариза бирелә: «Сәламәтлегем какшау сәбәпле һәм өйдәге хәлләр аркасында киләчәктә университетта фәннәр курсын үтәргә теләмичә, Сез Галиҗәнаптән мине студентлар исәбеннән төшерү, миңа барлык документларымны кире кайтару турында Сездән бәйле булган күрсәтмәләр бирүегезне түбәнчелек белән үтенәм».

Нәрсә булды соң әле бу? Өч ел гомер бернинди файдасызга үтте түгелме соң? Булачак бөек әдипнең Казан тормышы турында язган кайбер кешеләр бу сорауга уңай җавап бирү ягындарак торалар. Формаль яктан алар, билгеле, хаклы. Өстәвенә, үзе үк, ул чакларым турындагы уйлар хәзер минем бөтен тормышымны агулыйлар,

дип әйтеп тора. Моңа өстәп аның «Тәүбә» әсәреннән кайбер юлларны китерергә мөмкин: «Ул елларны коточкысыз, чирканусыз һәм йөрәк әрнүсез искә төшерә алмыйм. Мин бар күңелем белән яхшы булырга тели идем, ләкин мин яшь идем, минем дәртем бар иде, тик мин ялгыз идем. Иң әчкерсез теләкләремне тәшкил иткән нәрсәләр турында аңлатырга маташкан һәр очракта кимсетүле карашка тап була килдем, ә ачы нәфесемә бирелә башладыммы,— мине мактыйлар һәм хуплыйлар иде».

Бер яктан караганда, монда нәтиҗәнең ике төрле булуы мөмкин дә түгел кебек: аристократларга хас мәгънәсез, буш тормыш, кәеф-сафа корулар әле канатланып та җитмәгән яшь Толстойны шул тикле үзенә буйсындырган һәм ул үзенең әлеге «ачы нәфесенә» шул тикле бирелгән ки, аның лекцияләр, семинарлар, имтиханнар турында уйларга вакыты да калмаган, теләге дә булмаган.

Тик без катгый нәтиҗә ясарга ашыкмыйк әле. Беренчедән, Лев Николаевич үзе үк ул чорда тормышының «Тоташ яманлык» кына булмавы, күңелендә әледән-әле «яхшылыкка омтылыш» уянуы турында яза. Икенчедән, без мөһим бер нәрсәне — телгә алынган юлларның кайчан язылуын истән чыгармаска тиешбез. Алар 1903 елда, Лев Николаевич инде җитмеш биштә чакта язылганнар. Бу яшьтә кеше үткәндәге тормышына тәнкыйть күзлегеннән караучан, ул чактагы хаталарына аерата аяусыз булучан. Шуңа күрә бу очракта без, бәлки, аның үз-үзен чыбыркылауларына артык әһәмият бирмәскә, ул гына да түгел, Толстойны... Толстой тәнкыйтеннән якларга тиешбездер?!

Бу уңайдан Лев Николаевичның үлмәс әсәрләренә бик зур бәя бирү белән бергә, аның иҗатындагы һәм характерындагы каршылыкларны да аңлаган В. И. Ленинның күрсәтмәләрен дә искә төшерергә кирәк. Без бит Лев Толстойны тагын «толстойчы» итеп тә, ягъни, Владимир Ильич сүзләре белән әйткәндә, «халык каршында күкрәк кагып: «мин әшәке, мин кабахәт, ләкин мин әхлагымны яхшырту белән шөгыльләнәм»,— дип сөйләнүче кеше итеп тә беләбез.

Һәм, ниһаять, иң соңгысы: Лев Толстой бик тиз генә, кинәт кенә даһи художник, бөек фикер иясе булып китмәгән. В. И. Ленин сүзләре белән әйткәндә, «иҗтимагый ялганга һәм фальшька каршы искиткеч көчле, турыдан-туры әчкерсез протест белән чыгу өчен, ул бар нәрсәне үз күзе белән күрергә, үз йөрәге аша уткәрергә тиеш була. Әйдәгез, аның башыннан ахырынача «Казан материалына» нигезләп язылган «Балдан соң» хикәясен искә төшерик. Аристократ өендә мәҗлес. Безнең героебыз — үтә дә беркатлы, җаны-тәне белән гашыйк, яшь егет тә шунда. Аңа бу кичтә һәр нәрсә гүзәл булып күренә: аны гашыйк иткән сылу да, аның тәз гәүдәле, йөзеннән ягымлы елмаю китми торган өлкән яшьтәге полковник әтисе дә... Мәҗлес тәмам. Вакыт соң. Егетебезнең күзенә йокы керми. Ул, бөтен барлыгын биләп алган әчкерсез тойгыларга бирелеп, Арча кыры буйлап атлый. Таң алды. Егет очраклы рәвештә чиркангыч бер күренешнең — ниндидер гаебе булган татар солдатын җәзалауның шаһиты була.

«...Җәзаланучы, төрле яктан төшкән сугулар астында, әле артка таба чайкалып,— һәм ул чакта аны мылтыкка бәйләп алып баручы унтер-офицерлар алга таба тартеп җибәрәләр,— әле алга таба сөрлегеп,— һәм ул чакта унтер-офицерлар, егылып китүдән саклап, аны артка тарталар,— бөтен тәне белән тартышып, яланаякларын белән чаптыр-чоптыр атлый-атлый, миңа таба килә. Һәм, аңардан артка калмыйча, каты басып, бераз сикеребрәк атлап, хәрби кеше бара. Алсу йөзле, аксыл мыеклы һәм бакенбардлы бу кеше кызның әтисе иде.

Җәзаланучы, аркасына таяк төшкән саен, гаҗәпләнгәндәй, газапланудан чытылган йөзен сугучыга бора да, ак тешләрен ыржайтып, бер үк сүзләрне кабатлый. Мин бу сүзләрне ул миңа якын ук килгәч кенә ишеттем. Ул сүзләрен әйтми, ә сулкылдап чыгара иде: «Туганнар, шәфкатьле булыгыз, туганнар, шәфкатьле булыгыз...» Атлаучылар мин басып торган җирдән узып киткәч, кыска гына бер мәлдә, мин рәтләр арасыннан җәзаланучының аркасын күреп калдым. Ниндидер чуар, юеш, табигый булмаганча кызыл бер нәрсә иде бу, мин хәтта аның кеше тәне булуына ышанмадым да.

...Кинәт полковник туктап калды һәм, тиз-тиз атлап, солдатларның берсенә якын килде. Мин аның ачулы тавышын ишеттем:

— Мин сиңа күрсәтермен! Читкә сугасыңмы? Читкәме?

Һәм мин полковникның татар аркасына каты сукмаганы өчен тәбәнәк буйлы, зәгыйфь кыяфәтле бер солдатны замша перчатка кигән кечле кулы белән яңаклавын күрдем».

Юк, фараз итү сәләте, фантазиясе никадәр генә көчле булмасын, мондый нәрсәне уйлап чыгармыйлар. Мондыйны барысын да үз күзе белән күргән, үз күңелендә кат-кат кичергән, йөрәк газабы аша үткәргән кеше генә яза ала. Үзенең вак нәфесенә хуҗа булалмыйча, шуның колына әйләнеп, азып-тузып, кәеф-сафа кылып кына йөргән кеше мондый кичерешләргә сәләтлеме соң?

Димәк, без югарыда телгә алган нәтиҗәне ашыгып ясаучылар ялгышалар. Димәк, Лев Николаевичның студент булып йөргән өч елы бушка ук китмәгән. Димәк, булачак язучы, уку йорты бинасында булмаса да, Казанда үз университетын барыбер үткән. Казанда ул кәеф-сафа кылудан, аристократлар тормышының ялтыравыклы бизәкләреннән, университет стеналары эчендә хөкем сөргән өчпошыргыч тәртипләрдән күңеле кайткан кешегә әйләнгән, ә тынгысыз гакылы белән ул бар нәрсәне күзәтеп, күреп, аңына сеңдереп йөргән, аларны анализларга, бер-берсе белән чагыштырырга, нәтиҗәләр ясарга өлгергән. Шул елларда ук инде ул — бөтен феодаль-крепостниклык строеның, ул чактагы иҗтимагый, дини, әхлакый мөнәсәбәтләр системасының, кыскасы, бөтен стройның череклеген, ялган асылын аңлый башлаган художник.

Иң дөресе менә болайрак булырга тиеш кебек: бер яктан, бу атмосферага, череп баручы бу стройга аның күңеле ятмый, ул аны кабул итә алмый, икенче яктан, ул алар белән ачыктан-ачык конфликтка керергә, алар белән арасын өзәргә сәләтсез. Толстойны укуын ташларга, 1847 елда университеттан да, Казаннан да бөтенләй китәргә мәҗбүр иткән рухи драманың сәбәбе менә шунда.

Бөек Л. Н. Толстойның бу чордагы тормышына кагылышлы урыннарны республика җәмәгатьчелеге ихтирам белән саклый. Шәһәр урамнарының берсенә — элек Институтская дип йөртелгәненә — язучының исеме бирелгән. Шул ук урамда скульптор В. Пинчук ясаган бюст куелган. Алты ел эчендә Толстой яшәгән йортларның барысы да истәлек такталары белән билгеләнгән. Кыскасы, Казан Лев Николаевичны истә тота, ярата, хөрмәтли, аның бөек таланты алдында баш ия, даһиның беренче аңлы адымнарын үзендә ясаган булуы белән чиксез горурлана. Л. Толстойның «Сугыш һәм солых», «Яңадан туу» кебек зур әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителгән һәм яратып укылалар.

# РӘСӘЙНЕҢ БӨЕК ҖЫРЧЫСЫ

«Ул, туганкай, халык төркемен тәмам кол итәр өчен иблиснекедәй коточкыч көчкә ия булган зур гыйфрит...».

Бу сүзләр Россиянең бөек улы, кабатланмас таланты, әмма, холкы ягыннан бик каршылыклы шәхес — Федор Иванович Шаляпин турында. Аларны рус җиренең икенче бер даһие, бөек художник — Алексей Максимович Горький әйткән.

Тормыш юллары озак еллар буе бер-берсе белән бик кызык үрелеп барган бу ике әһел якын дуслар булган. Алар, соңрак — Ф. И. Шаляпин язганча, «таныш булмас борын ук очрашкалап», ә тормышлары бер-берсенә бик нык охшаган, ә кайбер очракларда янәшә агылып барган».

Федор Иванович 1873 елда элекке Рыбнорядскийда (хәзерге Куйбышев урамы) безнең көннәрдә мемориаль такта белән билгеләнгән агач йортта туган. Ярлы чиновник, земский управаның писаре, акыл-сәләт ягыннан әллә ни ерак китә алмаган, ихтыярсыз, еш кына үзенең болай да булыр-булмас хезмәт хакын эчеп бетерә торган һәм, исерек чагында, бик бәйләнчек кешенең улы — Федор Иванович бала вакытыннан ук кагу-сугуларны да, ачлык-ялангачлыкны да татып үскән. Алар «аена таңкә ярымга» ул чакларда Казан янындагы авыл саналган, бүген исә өлкән буын кешеләр генә хәтерли торган, шәһәр уртасында диярлек калган Әми тавында, бө-

тенләе белән җиргә сеңгән алачыкта да, Татар бистәсендә, Мәскәү урамы (хәзерге Киров урамы) чатындагы Варлаам чиркәвеннән ерак түгел урнашкан «тимерчелек өстендәге кечкенә бүлмәдә» дә торганнар. Ләкин бала хәтеренә бигрәк тә әтисе һәм әнисе белән Суконный бистәсендә подвал катындагы кечкенә ике бүлмәдә яшәгән вакытлары сеңеп калган.

Үзенең «Тормыш сәхифәләре» һәм «Маска һәм җан» дигән китапларында Федор Иванович «Суконный бистәсе» дигән сүзләрне мещанлыкның иң чиркандыргыч якларын гәүдәләндерүче уртак төшенчә итеп куллана.

Дөнья өчен Казан Федор Иванович Шаляпин туган шәһәр булуы белән генә түгел, аңарда музыка, җыр, театр сәнгате белән якыннан кызыксыну, шуларга сүнмәс мәхәббәт уянган урын булу белән дә кыйммәт. Һәр нәрсә белән кызыксынучан малайның беренче табынган кешесе ул чакларда Казанда гына түгел, бөтен Идел буенда, популяр «кәмитче Яшка, мәзәкче-шамакай Яков Мамонтов була». «Аның үткен шаяртулары, җыелган халыктан мәсхәрә белән көлүләре, аның күк күкрәүне хәтерләткән, карлыккан тавышы,— дип яза Ф. М. Шаляпин.— һәм гомумән бөтенләе белән ул үзе миндә буйсындыручан һәм ягымлы тәэсир уята иде. Ул кеше минем күз алдымда бүтәннәрнең куркусыз хуҗасы, аларны кулга ияләштерүче булып килеп баса,— мин, барлык кешеләр һәм, хәтта полиция дә, прокурор үзе дә аңардан куркалардыр, дип ышана идем».

Тиздән Федор Шаляпинның тормышында аның киләчәктәге юлын билгеләүдә шактый зур роль уйнаган икенче бер мөһим вакыйга була. Аларның татар бистәсендә яшәгән чагы. Кышкы кичләрнең берсендә, шимбә көнне Федя бүтән малайлар белән Варлаам чиркәве янында уйнап йөри. Уйный торгач, туңа бу һәм җылынып чыгар өчен әлеге чиркәүгә керә. Керә... һәм бүленгән уены турында да, фани дөньядагы бүтән нәрсәләр турында да оныта — гомерендә беренче тапкыр хор җырлаганны ишетә. Хорда олылар белән бергә — аның кебек малайларның да булуын, аларның кулларына кәгазь тотып җырлауларын күргәч, Федяның гаҗәпләнүе тагын да арта.

Һәм, ниһаять, 1885 ел. Унике яшьлек малай гомерендә беренче тапкыр Казан театрына эләгә. Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк, 1867 елда хәзерге Ирек мәйданында (элек ул Театр мәйданы дип аталган) салынган театр, белгечләр фикеренчә, элеккеге театр биналарының бик матур үрнәге саналган. Ул биш яруслы, зур сәхнәле, 1240 кеше сыйдырышлы була. Әлеге көнне аның сәхнәсендә П. Сухонинның «XVI гасыр азагында рус туе» дигән драмасын куялар. Тәэсиргә бирелүчән сәләтле малайның театрда күргәннәр белән ни дәрәҗәдә әсәрләнүе турында язып торуның кирәге бар микән?

Шул вакыйгалар йогынтысында Федорны артист булу, җырчы булу хыялы, театрда эшләү теләге биләп ала. Бу чакта ул регент[1] Щербицкийның хорында «исполатчик» булып (ягъни тиешле хезмәт хакының яртысын гына алып) җырлап йөри. Соңыннан— приход училищесында укыганда да, сапожник Андоевта ярдәмче мастер булып эшләгәндә дә, Печенкинның ссуда кассасында кәгазьләр күчереп утырганда да, «эшендә җитәрлек тырышлык күрсәтмәгәне» өчен бу контордан куылгач та, әтисе кушуы буенча, Арчадагы һөнәр училищесында укып йөргәндә дә, һәм ике ай үтәрүтмәс, әнисенең үлүен сылтау итеп, аннан качып диярлек яңадан Казанга кайткач та Федор шул ук бер хыял белән яшәгән. Көннәр буе авызына валчык та капмыйча, эш таба алмый шәһәрдә каңгырап йөргәндә, күбрәк үзе кушкан «Скважина» дигән кушаматы белән эндәшүче, форсат чыккан саен «Синнән, Скважина, гомумән, шайтаным да чыкмас»,— дип кабатларга яратучы әтисенең кыйнауларын татыганда да бу теләк, бу хыял аның башыннан чыкмаган.

Ниһаять, безнең шәһәрдә үк, аның шул теләге тормышка аша. 1890 елның көзендә Идел-Кама кунак йорты[2] бүлмәләренең бер ишеген, бар булган кыюлыгын җыеп, шыксыз озын ябык гәүдәле, начар ес-башлы бер үсмер шакый. Бүлмәнең хуҗасы Казанга үзенең Уфадагы театры өчен солистлар җыю нияте белән килгән провинциаль артист Семенов-Самарский икән. Үсмер театр хорында җырларга теләге барлыгын әйтә. Һәм ул, беренче карашта ук, артист күңеленә ошый булса кирәк,

[1] Регент — чиркәү хорының дирижеры.
[2] «Волжско-Камские номера» (хәзерге Ленин урамында).

тегесе, тәвәккәлләп, әле исеме-аты чыкмаган бу егетне, аена унбиш сум хезмәт хакы түләп, эшкә алырга риза була.

Федор Иванович Шаляпинны театр, музыка сәнгатенең иң югары баскычларына күтәргән, аны сәнгать күгендә беренче дәрәҗәдәге «йолдыз» иткән, тиңдәшсез опера җырчысы һәм, ниһаять, Россиянең горурлыгы иткән һәм илле еллык юлның башлануы була бу. Унҗиде яшьлек Шаляпин Казан белән әнә шулай аерылыша. Гәрчә безнең шәһәрдә булачак бөек артистка бәхетле һәм шатлыклы көннәр әллә ни күп тәтемәсә дә, Федор Иванович Казанны һәрвакыт яратып һәм сагынып искә ала. Инде бөтен дөньяга танылган җырчы булгач та әледән-әле туган якка кайтып чыга.

Шәһәр белән саубуллашканнан соң бирегә ул беренче тапкыр җиде ел үткәч, 1897 елда килә. Шәһәрдән-шәһәргә, театрдан-театрга күчеп йөрүләр белән бәйле авырлыклар, опера сәхнәсендә беренче уңышлы чыгышлар, Тифлиста ул чагында бик атаклы саналган белгеч Д. Усатовтан җырлау осталыгына өйрәнүләр, башкаланың император театры һәм Мәскәүдәге шәхси опера сәхнәләрендә беренче чыгышлар инде артта калган була. Казан җәмәгатьчелеге үзенең танылган якташын бик җылы каршы ала. Аның концертлары зур уңыш белән үтә.

Федор Иванович чит илдә яшәгәндә дә Казанны бик сагына. «Тормыш сәхифәләре» китабында ул: «Минем бик гүзәл Урта диңгездә дә, Атлантик океанда да булганым бар, шулай да бүгенгә кадәр кара кучкыл, тымызык Кабан күлен яратып истә тотам»,— дип яза. Максим Горькийның 1938 елда Капридан үзенең 60 еллыгына туган илгә кайтканын, бүтән шәһәрләр белән беррәттән, Казанда да булуын белгәч, Шаляпин аңа Парижнан болай дип яза: «Хатта синең Казанда булуың турында укыгач, азрак ямансулап алдым. Хәтердә, күз алдында торгандай булып, дөньядагы барлык шәһәрләрдән дә гүзәлрәк (минем өчен, әлбәттә) булган шәһәр үсеп чыкты. Үземнең анда үткән бөтен тормышымны: бәхетләрне һәм бәхетсезлекләрне, гадәти көннәрне һәм масленица бәйрәмнәрен, гимназисткаларны һәм кибетче кызларны, ссуда кассаларын һәм аяк киеме мастерскойларын искә төшердем һәм уйларым белән кадерле Казан театры янында тукталдым да, елап җибәрә яздым...».

Сүз уңаенда халкыбызның горурлыгы булган бу ике бөек затның үзара мөнәсәбәтләренә бераз тукталыйк. Әле бүген дә кайчак аларның дуслыгы, аерым алганда, безнең шәһәр белән бәйле тормышлары турында бик үк төгәл булмаган сүзләр ишетергә туры килә. Федор Ивановичның истәлекләренә караганда, алар Алексей Максимович белән беренче тапкыр Казанда түгел, 1897 елда, Шаляпин Мәкәрҗә ярминкәсендә җырлар өчен килгәч, Нижний Новгородта очрашалар. «Патша хакына яшәү» (М. Глинканың «Иван Сусанин» операсы революциягә кадәр шулай аталып йөртелә — Р. С.) операсы барганда, тәнәфес вакытында, Шаляпинның артист бүлмәсенә Максим Горький керә. «Сез дә безнең кебек Исаакий икәнсез (Россиядә сукбайлыкта йөрүчеләрне шулай дип атаганнар — Р. С.), дөресме шул,— дип сорый Горький һәм җирле сөйләмгә хас акцент белән өстәп куя: «Сез рус мужигын бик оста гәүдәләндерәсез. һәм гәрчә мин андый русча-немецча сюжетларны яратып бетермәсәм дә, балаларын искә алучы Сусанин булып елавыгыз ошады».

Менә шул кичтән башлап, дип яза Шаляпин, безнең арада озакка сузылган эчкерсез кайнар дуслык башланып китте. «Күпләр, янәсе, мин үсмер чакны һәм яшьлегемне Горький белән бергә үткәргәнмен, аның белән бергә Иделдә эшләп йөргәнмен, янәсе, без бергәләп хорда җырлаучы булыр өчен имтихан тотканбыз да, аны хорга кабул иткәннәр, ә минем тавышым булмаганга алмаганнар, дип сөйлиләр һәм язалар. Боларның берсе дә дөрес түгел... Ә безнең хорда җырлаучы булырга имтихан тотуыбызга килгәндә исә, чыннан да, без икебез дә антрепренер Серебряковның хорын яшь тавышлар белән тулыландыру өчен Казан гражданнарына мөрәҗәгать итүенә җавап бирдек, ләкин бу вакытта без әле таныш түгел идек. Горькийны кабул иткәннәр, ә мине юк, чөнки ул миннән дүрт яшькә өлкәнрәк: аның тавышы инде формалашкан булган, ә минеке әле үзгәрә иде...»

Бу ике титанның дуслыгы утыз ел дәвам итә. Моның шулай икәнен аларның замандашлары — ул вакыттагы әдәбият һәм сәнгать әһелләре, аларның хатлары раслый. Тик менә 1930 елның җәендә бу дуслык җитди сынау үтәргә мәҗбүр була. Эш нәрсәдә соң? Алексей Максимович моңа кадәр дә Шаляпин холкындагы тискәре

якларны күреп, белеп тора. Катлаулы, каршылыклы кеше була Федор Иванович. Кайчак ул, әйтик, забастовка күтәргән эшчеләр файдасына яисә халык театры оештыру фондына кич буе бушлай җырларга риза, ә кайчакларда исә үтә саран, бер тиен өчен сәгатьләр буе тарткалашырга әзер. Аның мал туплауга, баюга омтылышын икенче хатыны М. В. Петцольд һәм чит илдә аның тирәсендә бөтерелгән төрле вак җанлы кешеләр төрлечә куертып торганнар. Өлешчә Максим Горькийның киңәшләре, дусларча үгетләүләре аркасында аңарда туган илгә, Советлар Россиясенә кайту теләге күп тапкырлар уяна. Ләкин һәр очракта әлеге кешеләр аны бу уеннан кире кайтаралар, һәм ул нәге теләгән тормышка ашыра алмый кала. Алексей Максимович, хәленнән килгәнчә, аңа бу кимчелегеннән арынуда ярдәм итәргә тырыша. Ләкин 1930 елда булган вакыйга аны да чыгырыннан чыгара. Ул елны Шаляпин, истәлекләрен рөхсәтсез басып чыгаруда гаепләп, безнең нәшриятка каршы, Совет хөкүмәтенә каршы Франция судында эш кузгата. Суд, әлбәттә, бик хаклы рәвештә аның урынсыз дәгъвасын кире кага. Әмма Алексей Максимович бу хурлыклы эше өчен үз дустын гафу итә алмый.

...Федор Иванович Шаляпин — халык арасыннан чыккан кеше, гомеренең соңгы көннәренә кадәр ватаны турында сагышланып, үзе язганча, «бернәрсә белән дә алыштырып булмый торган печән исе, рус аты исе аңкып торган гади печәнлекне» сагынып, үзенең зур талантының читтә үсә, чәчәк ата алмавын сизеп-күреп яшн. А. М. Горькийның үлеме уңае белән чыгарган язмаларында аның бу турыдагы фикерләре белән тулысынча килешеп, болай ди: «Горький да, без барыбыз да үз илебезнеке, үз халкыбызныкы, һәм без, мин кайчак үз-үземне юаткан төсле рухи яктан гына түгел, физик яктан да, барлык яра җөйләребез, барлык сөялләнгән урыннарыбыз һәм барлык бөкреләребез белән аның белән булырга тиешбез».

Ничек кенә булмасын, даһи якташыбыз һәрвакыт безнең илнеке булып килде һәм шулай булып калачак та. Максим Горький хаклы: «Федор Иванович Шаляпин — бөтен дөньяга: менә ул Рәсәй, менә аның халкы нинди — юл бирегез аңа, ирек бирегез, дип, күз камаштыргыч якты һәм шатлыклы бер кычкыру кебек ул, һәм һәрвакыт шулай булып калачак!».

# ИСТӘЛЕКЛЕ ИСЕМНӘР

Казан университетының ишегалды аша күпләрнең үткәне бардыр һәм, бәлки, төп корпус каршында, аңардан көньяктарак урнашкан, бер-берсенә бик охшаш ике гүзәл бинага игътибар иткәне, яннарында тукталып, архитектура формаларының искиткеч камиллегенә сокланып күпләр басып та торгандыр. Аларның уң ягына, университетның Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе урнашкан, икенчесенә — элекке химия лабораториясе, бүген А. М. Бутлеров исемендәге химия фәнни-тикшеренү институты. Искиткеч гүзәл анатомия театрының ике ягына симметрияле итеп салынган, ишеге — фронтон һәм колонналар белән, беренче катының тәрәзәләре аркалар белән бизәлгән ике катлы бу биналар — талантлы архитектор, университет комплексын төзеп бетерүгә үзеннән бик зур өлеш керткән Н. П. Коринфскийның хезмәт җимешләре — аерым бер сөйләшүгә лаек нәрсәләр. Әмма безне бүген бу биналарның тик берсе бөтенләй башка яктан кызыксындыра.

Бу бинаның стенасында истәлек такталарының күплегенә дә игътибар итми калмыйсың. Бер бина стенасында җидәү алар! Шул кадәр атаклы кешеләрнең эшчәнлеге белән бәйле булган мондый бина безнең Казанда гына түгел, бөтен илдә дә бармак белән генә санарлыктыр. Кешеләре дә нинди диген әле! Бу кыска язмада аларның һәркайсы турында озаклап сөйләргә мөмкин булмаганлыктан, алар башкарган кайбер эшләргә йөгерек күзәтү ясау белән чикләнергә туры килә.

Истәлек такталарының беренчесе профессор Карл Карлович Клаус хөрмәтенә куелган. Бу танылган химик Казанга 1837 елда чакырыла. Лаборатория бинасының төзелеп кенә беткән чагы була. Аның үз сүзләре белән әйткәндә, чит илләрдәгеләр белән чагыштырганда да иң әйбәт лабораториягә килеп эләгә Карл Карлович. Галим-

гә тикшерену эшләрен зур колач белән алып барырга мөмкинлек ачыла. Клаус бәхетенә университетның һәм ватаныбыз химиясенең киләчәктәге язмышы бәхетенә каршы, аның белән бер үк вакытта диярлек, бер үк кафедрада, шул ук атаклы лабораториядә, аның белән иңгә-иң торып, русның икенче бер атаклы галиме Николай Николаевич Зинин эшли.

Клаус университетта башта химия кафедрасында адъюнкт һәм без телгә алган лабораториянең мөдире, 1839 елдан экстраординар (штаттан тыш) профессор, ә 1844 елдан башлап Дерпт университетына күчкәнче — ягъни 1852 елга кадәр — ординар профессор булып эшли. 1844 ел аның өчен аерата уңышлы була. Бу елны ул үзенең атаклы ачышын ясый — «рутений» (латинчадан тәрҗемәсе — «Россиянеке» дигән сүз) исемле яңа элемент таба. Химия лабораториясендәге җиһазлар, бүгенгеләр белән чагыштырганда, шактый примитив, спектраль анализ дигән нәрсә әле юк, Д. И. Менделеевның бүген галимнәргә табигатьнең иң тирән серләренә үтеп керергә мөмкинлек бирә торган периодик системасы әле билгесез бер вакытта ясалган булуы бу ачышның әһәмиятен тагын да арттыра. Шунысы да бик мөһим — «рутений» — әлеге периодик системадагы элементларның безнең илдә табылган берданбере. Бу металл хәзер медицинада, иң төгәл приборлар ясау өчен китә торган төрле кушылмаларда киң кулланыла.

Атаклы рус химигы Николай Николаевич Зинин — Казан университетын тәмамлый һәм укыту, фәнни эш алып бару өчен кафедрада калдырыла. Үзенә кадәр эшләгән һәм үзеннән соңгы күп кенә галимнәр кебек үк, Николай Николаевич та химиягә турыдан-туры гына килми. Ул университетның физика-математика факультетын тәмамлый, анда даһи Н. И. Лобачевскийның, дөнья әйләнеш сәяхәттә катнашкан мәшһүр астроном И. М. Симоновның һәм талантлы математик М. Бартельсның лекцияләрен тыңлый. Укуын тәмамлагач физика кафедрасында калдырыла, күпмедер вакыт студентларга астрономиядән лекцияләр укып йөри. Һәм бары тик ике елдан соң гына Н. Н. Зининның фән өлкәсендәге юлы кискен борылыш ясый — ул бөтен барлыгы белән химия фәненә кереп чума. Химия кафедрасына күчкәннән соң аны чит илгә командировкага җибәрәләр. Булачак профессор күп кенә Көнбатыш Европа илләрендә күренекле галимнәрнең лекцияләрен тыңлый, химиядән тыш биология, медицина белән кызыксына. Россиягә кайткач, 1841 елда докторлык диссертациясе яклый һәм шул ук елны экстраординар профессор итеп билгеләнә.

Казан университетында Н. Н. Зининның экспериментатор-галим таланты ачыла. Ул дөньяда беренче буларак реакция юлы белән анилин матдәсен китереп чыгара. Аның фән тарихына «Зинин реакциясе» дигән исем белән кереп калган ачышы гаять зур практик әһәмияткә ия. Ләкин Николай Николаевич бу гүзәл ачышының үз иле — Россия халык хуҗалыгында кулланыш табуын күрә алмый үлә. Бу урында рус фәнен үстерү өчен ничәмә-ничә еллар бер ялгызы көрәшеп йөргән даһи Ломоносовны, «ут машинасын» инглиз Уаттан күп элек уйлап тапкан, ләкин ачышының тормышка ашуына ирешә алмаган Ползуновны, күп кенә оригиналь механизмнар иҗат итеп тә үзен таныта алмаган, мәсхәрәгә дучар ителеп, хәерчелектә үлгән талант иясе Кулибинны, радионы ачкан, ләкин патша хөкүмәте тарафыннан кире кагылган Поповны, электр лампасы уйлап табуда Маркони белән Эдисонны шактыйга уздырган Яблочковны һәм Россия җирлегендә гаять зур авырлыклар белән иҗат иткән башка акыл ияләрен искә алып үтәргә мөмкин. Николай Николаевич Зининның ачышы белән дә шундыйрак хәл туа. Анилинны синтезлау ачышы химия промышленностен, аерым алганда, буяу-лак промышленностен үстерүдә гаять зур роль уйный. Ләкин башта Россиядә түгел, Германиядә кулланыш таба.

Ул заманның күренекле химигы А. В. Гофман 1880 елда, Н. Н. Зининның вакытсыз үлүе турында ишеткәч, Германиянең химия җәмгыяте утырышында ясаган чыгышында: «Әгәр Зинин нитробензолны анилинга әверелдерүдән гайре бүтән берни эшләмәгән булса да, аның исеме химия тарихы битләренә алтын хәрефләр белән язылган булыр иде», — ди.

Әгәр Казан химия мәктәбенең без телгә алган вәкилләре шәһәргә университетны тәмамлау яисә шунда эшләүләре аркасында гына бәйле булсалар, исеме бөтен дөньяга танылган, бик хаклы рәвештә химиянең бөек реформаторы дип аталган галим Александр Михайлович Бутлеров — тумышыннан ук «безнең кеше».

Александр Михайлович 1828 елда Казан губернасының Чистай шәһәрендә туа. Аның балачагы Кама буйларында, Наполеонга каршы сугышларда катнашкан отставкадагы офицер әтисе Михаил Васильевичның имениесенә якын гына урнашкан Урман Шенталасы авылында әнисе ягыннан туганнары гаиләсендә үтә. Казанда гимназиядә укый, университет тәмамлый, үзенең атаклы остазлары К. Клаус һәм Н. Зинин лекцияләрен тыңлап, химияне өйрәнә...

Башта гыйбрәтле дә, көлке дә булган ике вакыйганы искә төшереп үтик.

Саша Бутлеровка әле сигез яшь кенә чакта хәлле кешеләрнең балаларын гимназиягә керү өчен хәзерли торган хосусый пансионнарның берсендә укып йөргәндә, пансион урнашкан бинаның подвалында шартлау була. Түрәләр алдында бик тырыш, өлгер күренергә омтылучы ялагай тәрбияче Рональд подвалдан шактый куркынган, бите-башы корымга буялган Сашаны нәртеп чыга. Яшенә күрә гаять кызыксынучан, эзләнүчән һәм тырыш малай, әлеге подвалга төшеп, химик тәҗрибә ясап карамакчы булган, шартлау шуннан чыккан икән. Сашаны карцерга ябалар. Ләкин теге үтә тырыш, «акыллы баш» тәрбиячегә бу әле аз тоела. Ул пансионда яшәүче балаларның барысын да ишегалдына җыя, Бутлеровның муенына карага ак белән «Бөек химик» дип язылган такта аса да аны тәмам мәсхәрә итәр өчен шулар янына алып чыга. Язмыш соңыннан теге «белдекле» педагогтан бик ачы көлә, Александр Михайлович Бутлеров дөрестән дә бөек химик, ватаныбыз фәненең горурлыгы булып китә.

1849 елда, егерме ике яше тулыр-тулмас, Александр Михайлович үзе тәмамлаган Казан университетында фәнни-тикшеренү һәм укытучылык эшенә тотына. Хәер, монда безнең игътибарга лаек тагын бер нәрсә бар икән. Кандидатлык дәрәҗәсен ул (элек мондый дәрәҗәне университет бетергән вакытта биргәннәр) химиядән шактый ерак торган һәм «Урал-Идел фаунасында көндезге күбәләкләр» дип аталган хезмәте өчен ала. А. М. Бутлеров университетта остазларыннан берсе профессор Карл Клаус һәм ул чакта Казан уку-укыту округының попечителе хезмәтләрен башкарган даһи математик Н. И. Лобачевский үтенече буенча калдырыла. Егерме өч яшендә ул инде — магистр, революциягә кадәрге Россиядә беренче гыйльми дәрәҗә иясе. Егерме биш яшендә исә факультетның гыйльми советы карамагына «Эфир майлары турында» дигән докторлык диссертациясен тапшыра. Бу хезмәтендә ул үзе китереп чыгарган яңа матдә — пулегонның төп сыйфатларын тасвирлый һәм шул рәвешчә табигатьтәге химик кушылмаларны өйрәнүгә нигез сала. Әмма, оппонентларның берсе булган профессор Савельевның хезмәтне канәгатьләнмәслек дип бәяләве аркасында, факультет советы диссертацияне кире кага. Әлбәттә, ни эшләгәнен, нәрсәгә кул күтәргәнен үзе дә белмәгән бу кешенең тискәре фикере генә Бутлеровның фән өлкәсендәге үсешен тоткарлый алмый, ул үзенең диссертациясен Мәскәү университетына барып күпләрне таңга калдырыр дәрәҗәдә уңышлы яклап кайта. 1854 елда егерме алты яшьлек Бутлеров профессор була, университет студентларының иң яраткан педагогларыннан санала башлый. Ләкин лекция уку — яшь галим алып барган эшнең бер өлеше генә. Аның өчен иң төп шөгыль — фән, тикшеренүләр, лаборатория, пробиркалар янында үткәргән йокысыз төннәр. Фәндә үз сүзен әйтер өчен ул күп укый, уйлана, тикшерә, эзләнә. Ул махсус рәвештә Петербургка, үзенең остазы Н. Н. Зинин янына бара һәм соңрак аның белән бу очрашуны үзенең үсешендә бөтен бер эпоха дип атый. Ул чит илләргә командировкага йөри, андагы, бигрәк тә Франциядәге, галимнәрнең химия өлкәсендәге казанышлары белән таныша. Университет ректоры итеп сайлангач ул ике генә ел эшли, 1863 елда фән хакына бу урыннан баш тарта.

Чит илдән Россиягә кайтканнан соң ул тагын бөтен барлыгы белән фәнгә, үзенең экспериментларына чума. һәм аңарга кадәр барлык химиклар тел-теш тидергесез хакыйкать дип танылган нәрсәләргә «селтәнә». Ул замандагы укымышлылар, органик матдәнең молекулалары беркайчан да кешегә үзләренең серләрен ачмаячаклар, дип санаганнар. А. М. Бутлеров бу фикерне кире кага һәм органик кушылмаларның валент мөмкинлекләреннән чыгып барлыкка килүләрен, молекулалардагы атомнарның үзара бәйле булуларын, бу хәлнең табигать законы икәнлеген раслый. Органик кушылмаларның төзелеше теориясе соңыннан «Бутлеров теориясе» дип аталган, органик химиянең нигезендә яткан ачыш әнә шулай туа.

1868 елның сентябрендә Петербург университетының ординар профессоры итеп расланганч, ә 1871 елда, Россиянең Фәннәр академиясе составына сайланганнан соң да Александр Михайлович Казан белән, безнең яклар белән элемтәсен өзми. Казан университетының почетлы профессоры итеп сайлануын ишеткәч, ул балаларча шатлана. Галим һәр җәйне диярлек Чистай өязендәге Бутлеровка авылына кайтып йөри, анда умартачылык белән шөгыльләнә. Ләкин бу да — эш юктан эш булсынга йөрү түгел, фәнгә нигезләнгән бик җитди шөгыль. 1871 елда А. М. Бутлеровның «Умарта корты, аның яшәеше һәм умартачылыкның төп кагыйдәләре» дигән күләмле хезмәт язуы шул турыда сөйли. Аның бу хезмәте соңрак Бөтенроссия иркле экономик җәмгыятьнең мактау кәгазенә лаек була. А. М. Бутлеровның тагын «Умарта кортларын ничек үрчетергә» дигән популяр брошюра язып бастырганлыгы да билгеле.

Александр Михайлович Бутлеров турындагы сүзне аның ундүрт яшьлек чагында әтисенә язган хатына мөрәҗәгать итеп тәгәллик. Ул: «Ватан файдасына эшләгән кыен батырлыкларымнан соң мин, ниһаять, балачагым үткән шау-шусыз куышта, минем өчен кадерле кешеләр арасында, яшәү шатлыгын тәүге кат татыган урында тынычланырга теләр идем...» дип яза.

Бу теләк кабул була. 1886 елның мартында Александр Михайлович аяк кан тамырларының кинәт авырта башлавын сизә, Бутлеровкасына кайта, өй тирәсендә йөри дә башлый, ләкин шул ук елның августында һич көтмәгәндә дөнья куя.

А. М. Бутлеровны Петербург университетының профессоры итеп тәкъдим кырткәндә, бөек рус химигы Д. И. Менделеев болай дип язган: «Химиядә Бутлеров мәктәбе һәм Бутлеров юнәлеше яши». Менә шушы Бутлеров юнәлешен Казан университетында һәм илебезнең бүтән фән үзәкләрендә хәзер аның күп санлы шәкертләре дәвам иттерә.

Монда барыннан да элек фәнни карашы гаять киң булган галим-теоретик Владимир Васильевич Марковников исемен атарга кирәк. Ул, Казан университетының утыз бер яшьлек доценты, 1869 елда гыйльми советка үзенең докторлык диссертациясен тәкъдим итә һәм бу хезмәтендә А. М. Бутлеровның химик төзелеш теориясен тагын да үстерә, аны атомнарның бер-берсенә үзара йогынтысы теориясе белән тулыландыра. Әгәр Бутлеров химик кушылмаларда атомнарның урнашу тәртибен ачкан булса, Марковников тәгълиматы атомнарның бер-берсе белән бәйләнешләрен аңлата.

Казан университетында А. М. Бутлеровның иң яраткан һәм иң якын шәкертләреннән берсе исеме бөтен дөньяга танылган, фәнне күп кенә әһәмиятле ачышлар белән баеткан галим Александр Михайлович Зайцев була. Үзе Казанда туып үскән, бирергә икенче ирләр гимназиясен, аннары университетны тәмамлаган бу кеше 1870 елда, утыз ике яшендә темасының тирәнлеге һәм теоретик яктан актуальлеге белән таңга калдырган докторлык диссертациясен яклый. Ул берничә ел В. В. Марковников белән иңгә-иң торып бер кафедрада эшли, ә соңгысы Одессага киткәч, органик химия кафедрасының һәм химия лабораториясенең мөдире булып кала. 1907 елда Россия Фәннәр академиясе аңа академик исеме тәкъдим иткәч тә (ул чакларда академик кеше башкалада яшәргә тиеш була) ул бу тәкъдимне кире кага, туган университетына, Казанга турылыклы булып кала.

А. М. Зайцев аңлы тормышының күп өлешен, А. М. Бутлеров тәгълиматын үстерүгә багышлый. Үзенең яраткан остазы күрсәткән юлдан барып, ул өченчел спиртларны табу юлын ача. Ул тәкъдим иткән синтезлар нигезендә уннарча органик кушылмалар: ылыслы агачларда, эфир майларында очрый торган һәм медицинада, лак-буяу промышленностенда киң кулланыла торган матдәләр — терпеннар, витаминнар, гормоннар табыла. Ул Россиядә химия фәнен производство белән бәйләүгә нигез салучылардан берсе булган, Казандагы бертуган Крестовниковларның сабын заводы (хәзер М. Вахитов исемендәге химия комбинаты) өчен технологик процессларны эшләгән.

Ниһаять, Казан химия мәктәбенең иң күренекле вәкилләреннән берсе, бу мәктәпне гомеренең алтмыш елы буе җитәкләгән, күбебез әле исән чагында күреп калган академик, Социалистик Хезмәт Герое, Дәүләт премиясе лауреаты Александр Ерминенгельдович Арбузов һәм аның шәкертләре турында берничә сүз әйтергә чират җитте.

Без башта ук телгә алган мәһабәт бинадагы А. М. Бутлеров исемендәге фәнни-тикшеренү институты хәзер үзенә бер төрле реликвиядән санала. Биредә Казан химия мәктәбенең иң күренекле галимнәре эшләгән кабинет моннан йөз ел элек булган хәлендә саклана. Китаплар — А. М. Бутлеровның шәхси китапханәсеннән. Кызыл агачтан сырлы бизәкләр төшереп эшләнгән шкафларда шушы лабораториядә чыгарылган препаратлар саклана. Хәзер бу кабинетка Александр Арминенгельдовичның улы Борис Александрович Арбузов «хуҗа». Ул үзе дә — академик, Социалистик Хезмәт Герое, А. М. Бутлеров юнәлешен дәвам иттерүче галим.

— Менә рутений,— ди ул, әлеге шкафлардагы препаратлар белән таныштырып.— Менә Н. Н. Зинин китереп чыгарган анилин, менә А. М. Бутлеровның йодлы метиленны, реакцияләр ясаганда Бутлеров файдаланган үлчәү. Бу шкафта Казан химия мәктәбенең инде безнең чорда, совет чорында ирешелгән уңышларын чагылдыручы коллекция: Александр Арминенгельдович Арбузов һәм аның шәкертләре синтезлаган фосфорлы органик матдәләр.

Революциягә кадәр һәм аннан соң да әле күп еллар буе бинада нибары берничә кеше эшли иде,— дип дәвам итә Борис Александрович.— Гыйлем Хәйрович Камай белән без икәү, беренче аспирантлар буларак килгәндә, лабораториянең штаты мөдирдән һәм өч ассистенттан тора иде...

Танылган химик, Дәүләт премиясе лауреаты, татарлардан беренче профессор, бераз вакыт университетның ректоры булып торган кеше Гыйлем Камай турында да берничә сүз әйтеп китәргә кирәк. Химиягә, фәнгә бик авыр юллар белән килә ул. Башта ат куучы булып эшли, Идел пристаньнарында йөк ташый. Укырга-язарга да ул Иделдәге пароход исемнәрен укып өйрәнә. Бөек Октябрь бу гади татар егетенә белем алырга, профессор дәрәҗәсенә ирешергә мөмкинлек бирә. Гыйлем Камай — үзенең остазы А. Е. Арбузов башлаган фосфорлы органик матдәләр һәм кушылмалар өлкәсендә үз сүзен әйткән зур галим.

Совет органик химиясен үстерүдә,— фәнни яктан да, оештыру ягыннан да,— Арбузовлар династиясенең роле гаять зур. Династиянең башлыгы Александр Арминенгельдович бу мөһим эшкә, бигрәк тә фосфорның органик кушылмаларын өйрәнүгә үзенең җитмеш ел гомерен багышлаган. Ул ачкан һәм соңыннан «Арбузов реакциясе» дип аталган реакция фосфорорганик кушылмаларны синтезлауның төп юлы булып тора. «Бүгенге фосфорорганик матдәләр химиясе,— дип язды күренекле совет галиме академик А. Н. Несмеянов,— бөтен дөньяда танылганча,— башлыча Арбузов химиясе».

А. Е. Арбузовның улы Борис Александрович фәнни эзләнүләрнең текә сукмагына студент елларында ук баса һәм менә илле елдан артык инде шул сукмактан атлый, практика өчен бик кирәкле булган табигый кушылмалар — терпеннарны өйрәнә, химиягә физика һәм математика алымнарын кертеп, Бутлеров теориясен үстерә, тирәнәйтә.

Безнең шәһәр бүген дә химия фәненең иң зур үзәкләреннән берсе булып кала. Хәзер химиядә Бутлеров юнәлешен, аның традицияләрен зур-зур коллективлар үстерә. Ләкин бу әле күренекле галимнәрнең яңа исемнәре тумый яки тумас диган сүз түгел. Университет ишек алдындагы мәһабәт бинаның стенасы еллар үткәч яңадан-яңа истәлек такталары белән бизәләр.

Вахит Хаков,
филология фәннәре докторы

# СОВЕТ ЧОРЫНДА ӘДӘБИ ТЕЛЕБЕЗНЕҢ ҮСЕШЕ

Бөек Октябрь социалистик революциясе милли телләрнең үсешендә яңа этап булып тора. Хаким сыйныфларның бетерелүе, яңа экономик һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең туы кешеләр психологиясендә дә зур үзгәрешләр китереп чыгарды. Миллионлаган хезмәт ияләре илдәге вакыйгаларга, социаль тормыш мәсьәләләренә катнашып китте. Яңа чор, яңа иҗтимагый төзелеш татар әдәби теленең үсешенә дә йогынты ясады. Телнең иҗтимагый функциясе киңәйде, аның структур яктан үсеше өчен зур мөмкинлекләр ачылды. Әдәби тел җанлы сөйләм нигезендә тагы да баеды, үсте һәм камилләште, гасырлар буе халыкның зирәк акылы һәм бай тәҗрибәсе җирлегендә туган тел-стиль чаралары актив кулланылышка керде. Әдәби тел, культуралы сөйләм үрнәге буларак, төрле өлкәләр, төбәкләрдә яшәгән татар халкы арасында киң таралып, халык теленең югары казанышына әверелде.

Советлар Союзындагы 130 дан артык тел арасында татар теленең тоткан урыны кечкенә түгел. 1979 елгы халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча, илебездәге халыклар арасында татарлар (руслар, украиннар, үзбәкләр, белоруслар, казакълардан кала) алтынчы, ә РСФСРда (руслардан кала) икенче урында тора. Ә төрки халыклар арасында үзбәкләр, казакълардан соң, өченче урынны шулай ук татарлар тәшкил итә.

Тел мәсьәләсе һәрвакыт зур иҗтимагый проблемаларның берсе булып килде. Революциядән соң бу мәсьәләгә аеруча игътибар үзәгенә куелды. Телнең җәмгыятьтә тоткан роле, аның нормалары һәм үсеш юнәлеше турында съездлар, конференцияләр, киңәшмәләр үткәрелде. Бу мәсьәлә вакытлы матбугат битләрендә, фәнни хезмәтләрдә киң чагылыш тапты. Әдәби тел тирәсендә кызу көрәш барды, дискуссияләр кабынып китте, бәхәсләр, фикер каршылыклары туды, һәм төрле агымнар барлыкка килде.

Татар әдәби теленең революциядән соңгы үсеше, әлбәттә, элекке традицияләрдән, телнең гомуми эволюциясеннән аерып каралмый. Мәгълүм булганча, татар теле — язма традицияләргә ия булган элгәреге иске язулы телләрнең берсе. Шуңа күрә аның әдәби тел нормалары революциягә кадәр үк ныклы калыпка салынган, XIX гасырда һәм XX йөз башында ук халык сөйләү теленә якынайган була. Бик күптәннән башланган бу процесс совет чорында яңа шартларда дәвам итә. Революциядән соңгы әдәби тел — элеккенең дәвамы һәм яңа үсеш баскычы ул. Тел белеменә багышланган фәнни-теоретик әдәбиятта татар теленең шул тарихи урыны дөрес күрсәтелә[1]. «Татар теле әдәби язма традицияләрнең күптәнге булуы ягыннан,— дип яза В. А. Аврорин,— СССР халыкларының телләре арасында алгы урыннарның берсен алып тора. XIII—XIV йөзләрдә үк инде татар телендә зур поэтик әсәрләр языла»[2] «СССР халыклары әдәби телләренең үсеш закончалыклары» дигән китапта: «Совет чорында иске язулы телләр үзәренең эчке ресурсларын төрле дәрәҗәдә файдаланалар. Мәсәлән, рус теленең сүзлек составы үзенең эчке ресурсларын максималь эшкә җигү юлы бе-

[1] Советское языкознание за 50 лет. Изд-во «Наука», М., 1967, 250—275 битләр.
[2] Аврорин В. А. Проблемы изучения функциональной стороны языка. Изд-во «Наука», Л., 1975, 104 бит.

лән үсә. Украин, белорус, үзбәк, азербайҗан, әрмән, грузин, латыш, литва, молдаван, таҗик, татар, эстон һәм башка кайбер телләрнең лексик-семантик системасы, нигездә, аларның эчке мөмкинлекләре җирлегендә үсә»,[1] — диелә.

Әдәби телләрнең үсешендә төп ике чорны билгеләп үтү әһәмиятле. Аларның берсе — теге яки бу халыкта язма әдәби телнең барлыкка килү һәм башлангыч үсеш чоры. Икенчесе — әдәби телнең тулысы белән халык сөйләү теленә нигезләнүе, икенче төрле әйткәндә, халык теленең әдәби тел функциясендә йөри башлаган чоры. Боларның һәр икесе халыклар тарихында зарури иҗтимагый шартлар туганда гына өлгереп җитә. Тел мәсьәләләрен тикшергәндә шулай ук ике юнәлешкә игътибар итү зарури. Аның берсе — телнең үсеше һәм нормалары белән бәйләнешле теоретик проблемалар. Икенчесе — тел нормаларын эшкәртү һәм телнең гамәли кулланылышы белән бәйле мәсьәләләр. Шушы нигездә татар тел белемен һәм телнең үсешен тыгыз мөнәсәбәттә өйрәнү бурычы килеп баса. Бер яктан, теге яки бу тарихи чорда тел белеменең торышын ачыклау, аңа хәзерге күзлектән чыгып бәя бирү, икенче яктан, тел нормаларының үсешен, андагы үзгәрешләрне билгеле бер эзлеклелектә күрсәтү һәм динамикада ачу төп максат булып тора.

Бөек Октябрь социалистик революциясе булу белән көн тәртибенә татар телен гамәлгә кую мәсьәләләре килеп баса. Бу — зур әһәмияткә ия иҗтимагый проблемаларның берсенә әйләнә. Телне гамәлгә кую мәсьәләсе ул вакытта социалистик төзелешкә бәйле күп кенә төшенчәләр белән яңәшә йөрде. Моның өчен әдәби тел нормаларын бөтен халык өчен аңлаешлы итеп эшкәртү, аны халыкка якынайту, язу системасын, алфавитны җиңеләйтү, бөтен халыкның укый-яза белүенә ирешү, учреждениеләрдә, рәсми-җәмәгать урыннарында татар телендә эш итү, аны мәктәпләрдә, урта һәм югары уку йортларында укыту, тиз арада милли кадрлар әзерләү кебек катлаулы мәсьәләләрне хәл итәргә һәм алар буенча ашыгыч чаралар күрергә кирәк иде.

Социалистик җәмгыять төзүдә бөтен ил күләмендә катнашу халык властен ныгыту, илдәге үзгәрешләрне-яңалыкларны белеп тору, яңа тормышның төп эчтәлеген аңлау максатларыннан чыгып, Коммунистлар партиясе һәм Совет хөкүмәте үзенең беренче декретларында ук телнең җәмгыятьтә тоткан урынына һәм туган телнең гамәлгә куелышына зур игътибар бирделәр. 1918 елның май аенда Казанда Бөтенроссия мөселман укытучыларының өченче съезды үткәрелә. Бу съезд Татарстанда беренче гыйльми оешма — Гыйльми һәйәт (фәнни коллегия) сайлый, аның каршында төрле бүлекләр оештыра. Съездның көн тәртибенә татар теле орфографиясен яхшырту мәсьәләләре дә куела. Аларны хәл итүдә Мәскәүдән Үзәк Мөселман Комиссариатыннан килгән Г. Ибраһимов актив катнаша. Шулай ук съездда татар филологлары һәм укытучылары Ш. Әхмәдиев, М. Корбангалиев, Г. Алпаров, Х. Бәдигый, Г. Сәгъдиләр дә куелган мәсьәләләрне тикшерүгә ярдәм итәләр һәм зур булышлык күрсәтәләр. Татарча язу системасы һәм аны камилләштерү буенча Фатих Сәйфи докладын тыңлана.

Тел мәсьәләләрен тикшерү берникадәр тукталып торса да, Казан ак чехлардан азат ителү белән, Гыйльми һәйәт үзенең эшен яңарта. Аның председателе итеп, Мәскәүдә Үзәк Мөселман Комиссариатында Г. Ибраһимов белән бергә эшләүче, элек Истамбул университеты профессоры булган Мостафа Сөбхи билгеләнә. 1919 елның гыйнварында Казанда тел мәсьәләләренә багышланган Бөтенроссия күләмендәге конференция ачыла. Анда татар теленең язу һәм орфографиясенә караган күп мәсьәләләр тикшерелә. Конференцияне М. Сөбхи алып бара. Татар филологларыннан һәм язучыларыннан тыш бу конференциядә күренекле тел белгечләре — тюркологлар да (А. Н. Самойлович, Н. Ф. Катанов, С. Е. Малов, В. А. Богородицкий, Н. И. Ашмарин) катнаша.

Соңга таба Гыйльми һәйәт Татарстанда телне гамәлгә кую эшләре белән җитәкчелек итә, һәм ул Гыйльми үзәк дип йөртелә башлый. 1923 елдан аның башында күренекле әдип һәм галим Г. Ибраһимов тора. 20 нче елларда татар телен гамәлгә ашыруда, әдәби телнең лексик, фонетик, грамматик нормаларын эшкәртүдә һәм яхшыртуда Гыйльми үзәк гаять зур эш башкара.

[1] Закономерности развития литературных языков в советскую эпоху (внутриструктурное развитие старописьменных языков). М., «Наука», 1973, 17 бит.

1920 елның 27 маенда Автономияле Татарстан Совет Социалистик Республикасы төзү турындагы декретка кул куела. Бу татар халкы тарихында иң зур вакыйгаларның берсе була. 1921 елның 25 июнендә Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты председателе Б. Мансуров һәм Татарстан Халык Комиссарлары Советы председателе С. Сәетгалиев имзасы белән Татарстанда татар телен гамәлгә кую турында декрет кабул ителә. Декретта бөтен хөкүмәт оешмаларында татар телендә эш итү мәҗбүри куела, татар телен гамәлгә ашыру буенча махсус комиссия төзелә һәм татар халкының милли кадрларын хәзерләү буенча курслар ачу мәсьәләләре күтәрелә. Шулай ук язуда яңа имланы нигез итеп алу, беренче баскыч рус мәктәпләрендә теләгән кешеләр өчен татар теле һәм татар мәктәпләрендә рус теле укытуны кертү, татар телендә эш алып бара торган халык мәхкәмәләре ачу һәм эш кәгазьләрен нинди телдә язу мәсьәләләренә дә зур урын бирелә. 1920 елның 19 декабрендә Гыйльми үзәк эшләгән проект нигезендә Татарстан республикасы Халык Комиссарлары Советы «Хәреф һәм имла турында декрет» кабул итә. Бу декрет буенча татар язуына реформа кертелә, авазлар өчен алынган билгеләрнең — хәрефләрнең 4 формада (шәкелдә) йөртелүе бетерелә, нигез итеп баш шәкел гамәлгә куела. Шул рәвешчә, сузык авазларга билге алу һәм аны камилләштерү мәсьәләсе хәл ителә. 1921 елда республиканың Үзәк Башкарма Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советы татар телен Татарстан территориясендә рус теле белән беррәттән, бертигез хокукта йөртү турында декрет кабул итә. Шулай итеп, бу мәсьәлә зур политик кампаниягә әверелде. Татар телен гамәлгә ашыру һәм аны җитәкләү эше 1922 елда Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты каршында төзелгән Үзәк һәм кантон комиссияләренә йөкләтелә. Үзәк һәм кантон комиссияләре директива бирү һәм контроль ясау белән генә чикләнмичә, закон проектларын хәзерләүдә, статистик материаллар туплауда катнашалар, төрле оештыру эшләре белән шөгыльләнәләр, рус һәм татар телләрен яхшы белгән кадрлар туплауга да игътибар итәләр.

Мәктәпләрдә һәм башка уку йортларында татар телен укыту мәсьәләләре дә — телне рәсми яктан гамәлгә куюның аерылгысыз бер өлеше. 1922 елның 8 маенда республика Үзәк Башкарма Комитеты Татарстанның барлык урта, югары һәм профессиональ-техник уку йортларында, совет властеның беренче елларында ук уку йортларында татар телен махсус укыту предметы буларак кертү төп максат итеп куелганча, татар теле укыту турында махсус карар кабул итә. Мәктәпләр өчен дәреслекләр төзүне тизләтү, аларның эчтәлеген яхшырту мәсьәләсе көн тәртибенә килеп баса. Шул ук егерменче елларда татар тел белемен үстерү һәм әдәби телне эшкәртү юнәлешендә киң күләмдә конкрет эш алып барыла: тел белеменең төрле тармаклары интенсив рәвештә өйрәнелә, күп кенә фәнни һәм практик хезмәтләр дөнья күрә, әдәби телнең лексик, фонетик, грамматик һәм стилистик нормаларын эшкәртү буенча зур эш башкарыла. Татар теле белеме иҗтимагый тормыш белән, аның теоретик һәм практик мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнештә үсә башлый. Үз хезмәтләре белән тел фәнен үстерүчеләрнең берсе Г. Ибраһимов булды. Шулай ук Җамал Вәлиди, Галимҗан Шәрәф, Хуҗа Бәдигый, Гыйбад Алпаров, Мөхетдин Корбангалиев, Гыймад Нугайбәк, Нигъмәт Хәким кебек күренекле телчеләрнең хезмәтләрен дә искә алып үтмичә мөмкин түгел. Нигездә, әдәбият галимнәре, язучылар булсалар да, Г. Сәгъди, Г. Рәхим, Ф. Сәйфи, Г. Толымбайларның да тел белеменә караган хезмәтләре бар. Аннан соңрак шушы ук юнәлештә Л. Җәләй, М. Фазлуллин, В. Хангильдин һ. б. зур фәнни эш башкардылар. Алар барысы да фәндә тирән эз калдырды.

Татар филологиясен үстерүдә зур энтузиазм белән иҗат иткән бу «кодрәтле төркем»нең эшчәнлеге бөтен совет тюркологиясенең гомуми үсешенә дә зур йогынты ясый. Киң масштабтагы мондый дәвамлы фәнни эш башка төрки халыкларда ул елларда әле мондый киң колач алмаган була. Шунлыктан егерменче елларда безнең татар тел гыйлемендә куелган һәм билгеле бер дәрәҗәдә тикшерелгән проблемаларның гомуми тюркологик әһәмияте бар. Бу, һичшиксез, Казан тюркология мәктәбенең бай традицияләре белән бәйләнгән.

Октябрь революциясеннән соң, бигрәк тә 20—30 нчы елларда әдәби телнең үсеш закончалыклары турында төрле карашлар барлыкка килде. Бу — тел белемен марксистик-ленинчыл тәгълимат нигезенә кору, аны яңа баскычка күтәрү юнәлешендәге

эзләнүләр белән дә һәм кайбер тикшерүчеләрнең субъектив карашлары белән дә бәйләнгән. Нәкъ шушы чорда совет тел белеменең үсеш юнәлеше турында бәхәсләр туды. Үзеннән-үзе аңлашыла, төрки телләргә хас күренешләрне өйрәнү белән беррәттән, рус һәм Европа тел белемендәге яңалыкларга һәм өйрәтмәләргә дә мөрәҗәгать ителде. Шуңа күрә татар лингвистлары күп мәсьәләләрдә рус тел белгечләренең фикерләренә кушылалар, еш кына тулы бер юнәлеш яки агымнар татар тел белеменә дә үтеп керә. Шулар арасында иң киң таралганы Н. Я. Маррның «Яфетик теория»се белән бәйләнешле хезмәтләре булды.

Бу «яңа тәгълимат» иҗтимагый тормышта телнең өскормә булуын һәм аның сыйнфый күренеш икәнлеген, шулай ук телнең эволюцион юл белән генә түгел, ә революцион юл белән дә үсү мөмкинлеген расларга омтылды. Шунлыктан, әлеге «карашлар» йогынтысында күп хезмәтләр язылды, алар еш кына һәр телнең үсешендә нигез итеп алынды.

Ул чорда «яңа тәгълимат»ны илдәге барлык милли телләрнең үсеш тарихына туры китерергә тырышу, һәр телнең эволюциясен бер юнәлештә генә ачарга омтылу чынбарлыкка туры килми. Мондый юнәлеш тел белгечләрен төп проблемалардан читкә этәрә, күренекле телчеләребезне шактый тирән ялгышларга китерә иде. Октябрь революциясеннән соң, татар тел белемендә тамыр җәя башлаган вульгар социологизм күренешләре нәкъ шуның белән аңлатыла.

«Яңа тәгълимат» таралган чорда күпчелек татар лингвистлары дөрес позициядә тордылар. Җәмгыять белән тел арасындагы мәсьәләләрне, теге яки бу сыйныфның телгә йогынтысын тикшергәндә, алар төрле факторларны да искә алдылар. Г. Ибраһимов, мәсәлән, болай язды: «Телләр үзләренең төзелүе, җиңеләюе хәрәкәтендә кинәт революция ясый алмыйлар. Татар буржуазия мәдәнияте эчендә туган яңа татар теле, гәрчә борынгы төрки телдән халыкка якынаю юлында зур бер адым атласа да, эшче-крестьянның бөтенләй үзенеке булып җитә алмады. Бу хәл тарихи-мәҗбүрилек иде»[1]. Татар телен фәнни тикшерену өлкәсендә һәм тел белемен марксистик-ленинчыл методологиягә коруда зур өлеш керткән Г. Алпаров хезмәтләре дә зур әһәмияткә ия булды.

Татар сөйләмен элекке язма традицияләр һәм халыкның сөйләү теле нигезендә тагы да үстерү, аны башка телләрдән кергән сүзләр, аерым чаралар хисабына баету һәм телнең эчке мөмкинлекләреннән киңрәк файдалану совет чоры әдәби теленең төп үсеш юнәлешен билгеләделәр. Әмма тел нормаларын бу юнәлештә үстерү һәм камилләштерү кискен көрәш шартларында барды. Төрлечә фикер йөртүчеләр булды, төрле агымнар яшәп килде. Караш аерымлыклары еш кына алынма сүзләрне кайсы телдән алу мәсьәләсендә килеп чыкты. Бу елларда бер-берсеннән аерылып торган өч агым яшәп килгәнлеге ачык күренә: 1) Язма тел белән җанлы сөйләмнең тыгыз үрелеп баруына нигезләнгән агым (элек-электән кабул ителгән алынма сүзләрне телдә калдыру, яңа төшенчәләрне белдергәндә халыкара һәм рус сүзләренә мөрәҗәгать итү); 2) Татар телендә халыкка аңлашылып җитмәгән гарәп, фарсы сүзләрен сакларга өндәүчеләр һәм ул телләрне чыганак тел итеп санаучылар агымы; 3) Татар телендәге рус сүзләрен, андагы тел чараларын киң кулланыны яклаучылар агымы. Болар эчендә башка юнәлешләрне алга сөргән төркемнәр дә булды. Мәсәлән: татар теленең үз мөмкинлекләреннән генә файдаланырга теләүче пуристик юнәлешне һәм элек булган, ләкин соңыннан телдән төшкән сүзләрне, тел чараларын кулланырга өндәүчеләрне, шулай ук алынма сүзләр өчен төп чыганак итеп Көнбатыш Европа телләрен генә файдаланырга кирәк дип чыгучы аерым төркемнәрне санап үтәргә мөмкин.

Бу елларда татар теленең сүз ясау һәм башка эчке мөмкинлекләреннән файдалану, халыкара сүзләргә мөрәҗәгать итү нәтиҗәсендә меңнәрчә уңышлы яңа сүзләр, атамалар төзелә. Барлык фәннәр һәм идарә эшләре буенча бик күп лексик берәмлекләр гамәлгә керә. Мәсәлән, 1927 елда эшкәртелеп кабул ителгән атамалар саны гына да 15 меңнән артып китә[2].

[1] Ибраһимов Г. Татар телен җиңеләйтү буенча тезислар. «Мәгариф» журналы, 1924, 3—4 сан, 170—17 бит.
[2] Кара: «Мәгариф» журналы, 1927, 10—11 сан, 66 бит.

Совет чорында әдәби телнең үсүе һәм камилләшүе белән бәйле үзенчәлекләрнең күбесе лексик-семантик үзгәрешләргә карый. Бу өлкәдәге төп тенденцияләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт иде.

**Халыкның сөйләү телен нигез чыганак итеп алу.** Яңа төшенчәләрне белдерү һәм әдәби телне халыкчан юнәлештә үстерү өчен телнең үз сүзлек хәзинәсе төп чыганак булып хезмәт итте. Совет чорында бу юнәлеш моңа кадәр күрелмәгән дәрәҗәдә киң үсеш ала. Элек язма әдәбиятта зур урын алган бер төркем сүзләр сөйләү теле формалары белән алыштырыла. Мәсәлән, **мәркәз** урынына **үзәк**, **хәят — тормыш**, **мәмләкәт — ил**, **мәшрыйк**, **мәгъриб**, **мөндәриҗә**, **мөтәхәссис** сүзләре урынына **көнчыгыш**, **көнбатыш**, **эчтәлек**, **белгеч** дип алу норма булып китә. Бу сүзләрдә яңа мәгънә төсмерләре дә чагыла. Мәсәлән, **тормыш** сүзе, иҗтимагый-публицистик мәгънәгә ия булып, дөньядагы ике политик система төшенчәсен дә белдерә:

Пәрдә әкрен генә күтәрелә,
Зур пәрдәнең ике ягында
Ике тормыш күренә.

(һ. Такташ. Давылдан соң)

Шулай итеп, элекке телдәге кайбер алынма сүзләрнең һәм халыкта киң таралмаган лексик берәмлекләрнең сөйләү теле үзенчәлекләре хисабына үзгәрүен күп мисаллар белән расларга була. Революциядән соң барлыкка килгән иҗтимагый үзгәрешләр сүзлек хәзинәсенең төрле катламнарын хәрәкәткә китерә, киң байлыкны кузгата. Моңа кадәр тар кулланылышта булган сүзләр күп жанрларга күчә. Әдәби телне халык сөйләменә якынайту максатында телнең эчке резервларыннан файдалану мәсьәләсе беренче планга калкып чыга. Аерым лексик категория буларак, гади сөйләм сүзләренә дә игътибар көчәя. Аларның үзләренә хас лексик-семантик үзенчәлекләре барлыкка килә. Гади сөйләм сүзләренең барысы да әдәби телдә тотрыклы урын алмаса да, алар халык телендә киң таралган лексик чаралар рәтендә караланар — бигрәк тә матур әдәбиятта һәм публицистикада эмоциональ-стилистик төсмерләр бирүдә катнашалар. Мәсәлән, **чурылдау**, **сыктау**, **каударлану**, **чәрәшмәү**, **икәпүсез**, **базымлы**, **шымып** кебек гади сөйләм сүзләренең төгәл мәгънәләре контекстта гына ачыла, башка сүзләр белән бәйләнешкә кереп, алар үзләренә хас мәгънә төсмерләренә ия булалар. Мондый сүзләрнең кайберләре әдәби телгә дә үтеп керә, кайберләре исә билгеле бер өсәрдә генә саклана, озак вакытлар телдә үзләренең кулланылышын саклыйлар.

**Сүзнең күп мәгънәлелеге белән бәйләнешле үзгәрешләр.** Яңа төшенчәләрнең барлыкка килүе һәм телнең үсеше нәтиҗәсендә сүзләрдә яңа мәгънә төсмерләре һәм семантик үзгәрешләр туа. Теге яки бу мәгънәгә беркетелгән мәгънәләр тагы да аныклана һәм конкретлаша төшә. Халыкның культура һәм белем дәрәҗәсе үсү җанлы сөйләмдә киң таралган мәгънә үзенчәлекләренең дә киң күләмдә нормалашуына китерә. Сүзләрдә элек-электән килгән төрле мәгънә төсмерләре бер килеш кенә тормый, вакытлар үтү белән төрле үзгәрешләргә тартыла. Бу — җәмгыятьтәге вакыйгалар һәм тормыш-көнкүреш хәлләре белән тыгыз мөнәсәбәттә бара. Кайбер мисалларга мөрәҗәгать итик. Сүздәге күпмәгънәлелекне **бәйге** сүзе мисалында ачык күрергә була. Әлбәттә, бу сүздә күптәннән килгән ат чабышы мәгънәсе үзен нык саклый:

Җирән кашка, башың чайка,
Бәйгеләрдә сынатма!

(М. Җәлил. «Җирән кашка».)

Ярыш төшенчәсе бирелгәндә, бу сүз сөйләмдәге төрле эчтәлеккә якынайтыла. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, эчке кичерешләрне сурәтләгәндә дә **бәйге** сүзе контексттагы эчтәлеккә яраклаша. Мәсәлән: «Әллә нинди буш хыялларга батып, Ник мәхәббәт белән чыктым бәйгегә?..» (К. Нәҗми. «Ант».)

Югары пафослы публицистик әсәрләрдәге күчерелмә мәгънәдә килгән **бәйге** сүзе көрәш төшенчәсен аеруча калку бирә:

Кайда сез, әй илне саклаучы
Баһадирлар! — Нигә

Чыкмыйсыз алтын сарайга
Каршы канлы **бәйгегә!**

(Һ. Такташ. «Күләгәләр»)

**Сыйныф** сүзе белән бергә килгәндә, ул мәгънә ягыннан тагы да югарырак яңгыраш ала:

«Сукыр кануннарга каршы түгел, Сыйныф **бәйгесендә** канга буялган». (Д. Фәтхи. «Металл тавышлары»)

Һәр автор **бәйге** сүзенә эчтәлекне ачуга ярдәм итәрдәй яңа төсмерләр өстәргә тырыша. Ә. Фәйзи аны авылда уңыш өчен, муллык өчен көрәш мәгънәсендә куллана:

Сәлам сиңа! Уңыш **бәйгесендә**
Алдан килә алдың!
Сәлам сиңа! Данлы җиңүләрнең
Серен белә алдың!

(«Сәлам Советлар Татарстанына»)

Бер сүз аша төрле мәгънә белдерүнең шулай үсеше үз нәүбәтендә, бер үк төшенчәне төрле сүзләр белән белдерү мөмкинлеген дә бермә-бер арттырып җибәрә. Сүз полисемик берәмлекләрнең телнең синонимик байлыгын үстерүдәге роле турында бара. Сүзләрдә яңа мәгънә төсмерләренең артуы халык сөйләмендә аерым мәгънәгә беркетелгән сүзләрнең иҗтимагый функциясе киңәюгә дә китерә. Бөек Ватан сугышы чорында язган әсәрләрендә Ф. Кәрим **бәйге** сүзен зур тантана, бәйрәм мәгънәсендә куллана:

Фашистларның башын кисү **Бәйгесе** бу яз. («Идел егете»)

Бу очракта ул иҗтимагый функциядә **туй** сүзенә синоним булып килә: «Шул **туйда**, шул бөек бәйрәмдә пролетариатның кадерле түрендә син булырсың» (Ш. Әхмәдиев). **Туй** сүзенең халык бәйрәме, зур тантана төшенчәсендә кулланылуы күптәннән килә. Аның фольклор стилендә матур үрнәкләре бар. **Бәйге** сүзендә андый мәгънәләр бирелсә дә, ул күбрәк үзенең беренчел мәгънәсенә омтыла. Шунлыктан аның сабантуй, ярыш төшенчәләрен белдергән очраклары киң таралган. Мәсәлән:

Омтыла җан **бәйге** аты сыман Мәйданнарга һаман, яшәүгә... (Х. Туфан).

Төп мәгънә белән мөнәсәбәттә, **бәйге** сүзенең сахра, кыр, ярыш урыны мәгънәсендә кулланылган очраклары да күзәтелә: Тора ул тау, ачып таш күкрәген **Бәйгедәге** җилләр каршында. (Ә. Маликов)

Ниһаять, **бәйге** сүзе кешенең эчке кичерешләрен, психик халәтен тирәнрәк сурәтләү өчен абстракт төшенчәдә дә килә ала: «**Бәхет бәйгесе** өчен көрәштә алышыр кеше җитми аңа» (Х. Хәйруллин. «Картлык кемгә шатлык»). Рәсми әдәбиятта һәм публицистикада бу сүз аша конкурс төшенчәсе дә бирелүе мөмкин. Мәсәлән: «Ак халатлы повар кызлар зур бәйгегә — башкалабызның ашханәләр тресты күләмендә уздырылачак конкурска әзерләнәләр» («Социалистик Татарстан» газетасы). Телнең үз мөмкинлекләреннән иркен файдалану һәм халык сөйләмендәге сүзләрне киңрәк куллану нәтиҗәсендә әдәби телдә яңа мәгънә төсмерләре арту, бер мәгънә нигезендә төрле төсмерләр белдерү юнәлеше совет чорында аеруча киңәеп китә. Моны барлык стильләрдә һәм сөйләм төрләрендә ачык күрергә мөмкин.

**Функциональ стильләрнең үсеше.** Революциядән соң һәр төрле сөйләм күп яклап байый, терминологик һәм профессиональ лексика киң үсеш ала, матур әдәбиятның, иҗтимагый-публицистик һәм фәнни әдәбиятның лексик-семантик мөмкинлекләре арта.

Художестволы сөйләм телнең киң эчке мөмкинлекләреннән файдаланып, күп төрле сурәтләү алымнарын эшкә җигә, алардагы мәгънә үзенчәлекләре киңәя һәм катлаулана. Сүзләрнең күчерелмә мәгънә белдерә башлаулары да сәнгатьле сөйләмнең эчтәлеген баета. Телдәге синонимик байлыктан файдаланугa зур игътибар ителә. Матур әдәбият әсәрләрендә сүзләрнең җегәре арта. Аларда чорның кайнар сулышы, публицистик пафосы чагыла. Мәсәлән, халык сөйләү теле берәмлеге булган **аләм** сүзе

революциянең җиңүле адымын белдергән гомуми төшенчәне аңлатуга күчә: «Көн килер кодрәт **әләмем** Җир күгендә ялтырар...» (Һ. Такташ).

Җыйма исем рәвешендәге **әләм** сүзе бөтен дөнья эшчеләрен берләштерүче символ булып та яңгырый: «Кузгал, бөтен галәм, ярлы халык, Бәйнәлмиләл — **әләм** астына». (М. Җәлил).

Бу сүзнең нейтраль кулланылышы күбрәк чәчмә сөйләмдә — публицистикада зуррак урын ала. **Әләм** сүзенең нәкъ шушы мәгънәне чагылдыра торган **байрак, флаг** кебек синонимнары да бар. Гражданнар сугышы чорында **әләм** сүзе шул заманның романтик рухына туры килә иде. Шунлыктан ул халык сөйләменә тартымрак булды, ә **байрак** сүзе исә рәсми телдә, язма сөйләмдә күбрәк кулланылды. Хәзерге телдә дә, бигрәк тә публицистикада **әләм** сүзе үзенең нейтральлеген саклый. Мәсәлән: «Шагыйрь шигъри җанын вәхшилек сарае өстенә кызыл әләм итеп күтәргән Мусаларны күздә тота». («Социалистик Татарстан» газетасы.)

Иҗтимагый-публицистик әдәбиятның да лексик-стилистик ягы һәм сөйләм төзелеше киң үсеш ала. Бу — стильнең төп асылын билгели торган иҗтимагый-политик төшенчәдәге сүзләрнең халык сөйләү теле хисабына баюы характерлы үзенчәлекләрнең берсе. Публицистик стильдә революциягә кадәр үк башланган юнәлеш тагы да үсә, халыкара кулланылышта йөргән күп сүзләр татар теленең сүзлек хәзинәсендә ныгып кала. Мәсәлән, манифестация, партия, пионер һ. б. Шулай ук яңа сүзләр һәм тәгъбирләр зур урын ала (җәмәгатьчелек, оешма, хуҗалык, коммунар, колхоз, совхоз, совет, комсомол, район, райком, комитет, комиссар, радио һ. б.). Сөйләмдә мондый лексик берәмлекләрнең үзләренә хас мәгънә үзенчәлекләре барлыкка килә. Алар башка стильләргә дә үтеп керәләр.

Фәнни стильне үстерү, әдәби телнең фәнни терминологиясен булдыру буенча да гаять зур эш башкарыла. Халыкның сөйләү телендә йөргән күп кенә сүзләр фәнни атамалар булып китә (почмак, кыр, яссылык, юнәлеш, чыгыш, тигезләгеч, үзлек, сыеклык, эремә, күзәнәк, күзүлчәм һ. б.). Сөйләү теле нигезендә яңа тезмә сүзләр барлыкка килә: туры почмак, озынлык үлчәве, яктылык дулкыны, таҗ яфракчыгы, халык утырышчысы, сайлау хокукы, чәнечкеле чыбык һ. б.

**Алынма сүзләрнең кулланылышы.** Элек-электән урнашып киткән һәм совет чорында активлашкан алынма сүзләр турында да әйтеп үтик. Егерменче елларда ук Г. Ибраһимов болай билгеләп үткән иде: «Хәзер әдәби телнең, әдәби әсәрләрнең тенденцияләрен, барышларын караганда, без гарәпчәдән дә, урысчадан да мөмкин кадәрле котылуга таба юнәлгәнлеген күрәбез. Матур әдәбият бу юлда беренче булып тора. Тарихи-иҗтимагый әсәрләрдә дә шул ук юнәлеш хөкем сөрә»[1]. Ул үз фикеренең дөреслеген раслау өчен, кайбер тикшерүләр үткәрә, әдәби әсәрләрдә татар сүзләренең уртача 92—98 процент күләмендә булуын билгели. Кави Нәҗми дә бу якка игътибар итә. «Матур әдәбиятыбыз үсә,— ди ул,— тел осталарыбыз көннән-көн көчәя баралар. Тел үзе дә чит сүзләрдән тазара бара. Безнең хәзерге хикәяләребездә, шигырьләребездә чит сүзләр (гарәпчәсен, русчасын, көнбатышчасын бергә җыеп санаганда) 4 яки 6 проценттан артмый»[2].

Татар халкының борын-борыннан Көнчыгыш илләре белән аралашып яшәве, шул нигездә политик-экономик һәм культура мөнәсәбәтләренең үсеше татар телендә гарәп, фарсы сүзләренең кулланылышына киң юл ачкан. Татар теленең тарихи үсешендә гарәп сүзләре шактый зур урын алып тора. Алар башта язу-китап теле өчен хас булса, вакытлар үтү белән сөйләшү теленә дә үтеп кергәннәр, әдәби телнең язма яки сөйләме төрендә тәмам урнашып җиткәч исә сүзлек хәзинәсенең тулы хокуклы берәмлегенә әйләнгәннәр. Әдәби телдә җанлы сөйләмнең киң мөмкинлекләреннән файдалану, язма сөйләм һәм сөйләшү теле арасында аерманың кимүе нәтиҗәсендә, гарәп һәм фарсы сүзләренең дә таралу һәм кулланылу сферасы үзгәрә. Аларны берничә төркемгә бүлеп карарга була: 1) Гарәп сүзләренең күп өлеше әдәби телнең һәр ике формасында да тигез дәрәҗәдә үзләшеп китә (асыл, җәүһәр, файда, гадәт, кәеф, мәктәп, мәрҗән, нәсел, кадер, кыяфәт, рәсем, сабый, сәгать, сәхнә, тәртип, вакыт һ. б.). Моңа фарсы сүзләре дә өстәлә: базар, былбыл, бәхет, гәүһәр, гөл, келәм, мәйдан, наз, намус, хуҗа, дару, чишмә, азат, шәһәр, һөнәр һ. б.

[1] Ибраһимов Г. Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак? Казан, 1927. 35 бит.
[2] Нәҗми К. Мәсьәләне кую урынында. «Кызыл Татарстан» газетасы, 18 февраль, 1927 ел.

2) Гарәп сүзләренең бер өлеше, билгеле күләмдә сөйләү теленә үтеп керсә дә, күбрәк язма сөйләмдә кулланылуы белән аерылып тора. Мәсәлән: даирә, агъза, әмер, этраф, форсат, һиҗрәт, нашир, нәкыш, нәсыйхәт, канун, рәссам, сәхифә, варис, хакыйкать, хиссият һ. б. Фарсы сүзләре: бостан, гәрчә, гүя, дәнә, дәрвиш, дастан, дәһшәт, падишаһ, пайтәхет, хаҗ, фәрман, ядкарь, җиһан һ. б.

3) Сөйләү теленә хас булмаган гарәп һәм фарсы сүзләре дә бар. Мәсәлән: фасыл, нотык, кадим, кыйсса, садә, шивә, тәкрар, хосусан, мәгърифәт, мәҗмуга, мөкәммәл, мөбарәк һ. б. Алар тар кулланылышка күчәләр, кайберләре телдән төшеп калалар.

Моннан тыш, халыкка ят булган бер төркем гарәп, фарсы сүзләре хәзерге әдәби телдә бөтенләй кулланылмый: җаһил (надан), гази (сугышчы), игътикад (ышану), истисна (чыгарма), ләихә (проект), мәгъдән (металл), мәхбүс (тоткын), мизан (үлчәү), баб (бүлек), җәнүб (көньяк), бәйнәлмилал (халыкара), җөмһүрият (республика), мәсьүл (җаваплы), тимсах (крокодил) һ. б.

Гомумән, совет чоры әдәби теле хәзинәсендә гарәп, фарсы сүзләре шактый урын били. Фәнни терминологияне баетуда һәм камилләштерүдә дә алар киң күләмдә катнаша. Татар халкының күпчелек кеше исемнәре дә гарәп, фарсы сүзләреннән тора.

Революциядән соң иҗтимагый аралашуда һәм халыкның көндәлек тормышында рус һәм Көнбатыш Европа телләре сүзләре дә киң кулланыла башлый. Мондый алынма сүзләрнең күбесе — Көнбатыш Европа телләренеке. Алар барысы да диярлек татар теленә рус теле аша керә. Үзләренең чыганаклары ягыннан Көнбатыш Европа сүзләренең төп өлеше латин һәм грек телләренә барып тоташа, төрле лексик катламнарга карый (лаборатория, вентилятор, меридиан, вакансия, темперамент, талант, функция һ. б.). Совет чорында алынма сүзләрнең характеры үзгәрү татар халкының рус һәм Европа культурасына омтылышы белән тыгыз мөнәсәбәттә карала. Яңа төшенчәләрне белдерү шул җирлектә бара.

**Телнең үз эчке төзелеше белән бәйле үзгәрешләр.** Телнең эчке мөмкинлекләреннән киң файдаланыла, гасырлар буенча формалашып килгән структура тагы да үсә һәм камилләшә. Әдәби тел нормаларының үсеше искергән кайбер язма тел үзенчәлекләренең кулланылыштан төшүе, җанлы сөйләмнең өстенлек алуы нигезендә бара. Ләкин бу әдәби телнең берьяклы гына үсеше түгел: элекке хәзинәгә яңа үзенчәлекләр өстәлә тора, язма сөйләм халык теле белән бик тыгыз үрелеп килә. Монда яңа җәмгыять белән бәйләнешле иҗтимагый-тарихи вакыйгаларның йогынтысы һәм социолингвистик факторларның да роле зур.

Безнең телдә сүзләргә кушымчаларның ялгану мөмкинлекләре бик киң. Шул нигездә тел баеый, кушымчаларда яңа мәгънә төсмерләре барлыкка килә. Төрле сүз төркемнәренә ялгана торган ясагыч һәм тәр кушымчаларының кулланылу ешлыгы арта. Кайбер кушымчалар совет чорында нормалашалар. Сыйфат ясаучы **-чыл** кушымчасы, мәсәлән, шундыйлардан (**халыкчыл, хыянәтчел, кунакчыл, сакчыл, вакчыл**). Ул алынма сүзләргә дә ялгана (**советчыл, партиячел, ленинчыл**). **-Чан** кушымчасы ялганган сыйфатлар җанлы предметларга хас үзенчәлекләрне эченә алалар (**халыкчан, эшчән, сүзчән**). Бу аффикс процессны белдергән сүзләргә ялганып та сыйфатлар ясый (**кайгыртучан, сынучан**).

Телнең грамматик һәм стилистик структурасы да кайбер үзгәрешләр кичерә. Моны морфологик категорияләрнең, синтаксик һәм стилистик системаның тагын да ныгуында һәм халык сөйләменә якынаюында ачык күрергә мөмкин. Совет чорында татар теленең грамматик структурасы халык сөйләменең эчке мөмкинлекләреннән һәм элекке язма формалардан киң файдалану җирлегендә үсә. Әдәби телнең морфологик төзелешендә сүз төркемнәре аерым категорияләргә тагын да байый, тулылана бара, аларның кулланылу сферасы киңәя, халык сөйләү телендәге күп формалар әдәби нормаларга әверелә.

Шулай итеп халык сөйләменең төп байлыгын үзендә туплаган хәлдә, әдәби тел сөйләм культурасының иң югары казанышы булып китә. Бай һәм камил әдәби тел үсә — халыкның үз тарихында яңа үсеш баскычына ирешү нәтиҗәсе ул.

# АВЫЛ КЕШЕСЕНЕҢ МАТУРЛЫГЫ

Юк, авыл кешесе белән шәһәр кешесен каршы куярга теләү түгел бу. Бездә — бигрәк тә авыл һәм шәһәр темаларына язылган әдәбият турында сөйләшкәндә — аларны бер-берсенә каршы куеп, ялгыш җибәрү очраклары инде шактый җитәрлек булды. Кайвакыт, шәһәр тормышы турында уңышлы иҗат ителгән әсәрләр күбәеп киткәч, без гел шул тема хакында гына сүз куерта башладык һәм әдәби үсешне бары тик шулай гына күрергә ияләнә яздык. Ә авыл кешеләренә багышланган талантлы әсәрләр күп туган чорда киресенчәрәк булды шикелле — бөтен сөйләшүләрнең үзәгендә авыл кешеләре, җир кешеләре генә торды.

Ә бит чынлыкта әдәбият бу кешеләрнең берсен дә үгисетмәскә тиеш. Чөнки аның өйрәнү объекты — авыл да түгел, шәһәр дә түгел — ә кеше.

Драматург Юныс Әминовның Татарстан китап нәшриятында басылган «Драмалар һәм комедияләр»[1]ен укыгач та үзәктә кеше торганын күрәсең. Язучы өчен вакыйганың кайда баруы артык мөһим түгел, аны кешеләрнең нинди булуы, ничек яшәүләре, нинди максат белән гомер итүләре нык уйландыра. Әдипне шулай ук аерым алынган бүгенге көн генә дә кызыксындырмый. Чөнки бүгенгенең башы — кичәгедә, үткәндә. Ә аларны бергә, бербөтен итеп күрә алмасаң — тормыш дигән зур һәм дәвамлы күренешне дөрес, тирән аңлау булмаячак.

Китап «Умырзая чәчәкләре» исемле эпик драма белән ачылып китә. Бу — бүгенге матур тормышның беренче умырзаялары, авылда социалистик яшәеш урнаштыру өчен гомерләрен дә кызганмаган фидакарьләр турындагы әсәр. Юк, драматург аны революция темасына өлеш кертү өчен генә язмаган. Безнеңчә, ул — китаптагы иң уңышлы әсәрләрнең берсе. Үзеннән күп еллар алданрак яшәгән һәм иске тормыш белән кискен көрәшкә ташланган каһарманнарны әдип ничек итеп безнең көндәлек терелтә алган соң? «Бу әсәрне Татарстан республикасы Әгерҗе районы Салагыш авылында 1919 елның 14 марты көнне ак фетнәчеләр тарафыннан вәхшиләрчә үтерелгән Сәхәбиев Вәҗи, Күкрәков Хәбибрахман һәм башка коммунистларның батырлыгына чиксез соклану һәм тирән ихтирам белән багышлыйм»,— дип яза аңа кереш сүздә автор. Әйе, менә кайда ята сер. Әдип, гап-гади кешеләрнең ничек итеп батыр, каһарман булуларын аңларга һәм шуны безгә дә күрсәтергә теләп, эпик драма иҗат иткән. Әсәрне укыганда шунысы игътибарны тарта: күп кенә китапларда очрап инде туйдыра башлаган купшы сүзләр, ышандыру көченә ия булмаган гыйбарәләр бирeдә юк дияргә мөмкин: безнең алда гади авыл кешеләре, гади авыл сөйләшүе. Әмма алар арасында инде социализм өчен көрәш килеп кергән, шушы хәл бер авылның кешеләрен икегә бүлгән. Геройларның сүзләре гадилектән, гадәтилектән күтәрелеп, кайсыбер очракта героик һәм хәтта романтик төсмер алсалар да, үз-үзләрен тотышлары буенча алар — югары идеяне аңлаган чын җир кешеләре. Мисалга бер генә өзек китерик. Драма алдыннан бирелгән прологта инде һәйкәлгә әверелгән каһарманнар сүз ала. Әсәрнең төп герое Максут, бүгенге чор кешеләренә дәшеп, мондый сүзләр әйтә: «...Әллә арагызда кешегә бары тик бер генә тапкыр бирелә торган гомернең кадерен белмичә, башкалар утырткан агачларның әзер җимешләрен генә ашап, тормышны бизәү өчен үзләре берни эшләргә теләмәүчеләр дә бармы? Бар икән — димәк, алар безне аңламаганнар. Без алай түгел, ә менә болай яшәдек...» Нинди гади, шул ук вакытта нинди җитди сүзләр. Чын сүзләр! Ир-ат әйтә торган сүзләр —«Без алай түгел, ә менә болай яшәдек...»

Максутлар авылы менә-менә аклар ку-

[1] Әминов Юныс. «Драмалар һәм комедияләр». Казан, 1981.

лына кучәргә тиеш, кызыллар вакытлыча чигенеп баралар. Ләкин шул аз гына вакыт эчендә авыл байларыннан икмәк җыярга һәм аны якындагы пристаньга килеп туктаган баржага озатып өлгерергә кирәк. Максут элегрәк Петроградта Ленинны тыңлау бәхетенә ирешкән. Аның колагында Ильич сүзләре минут саен яңгырап тора: «...Сез җыйган икмәк революциянең гомерен бер минутка озайтыр, ә шул бер минут безгә чиксез гомер китерер». Игътибар итик — язучы бөек юлбашчы сүзләренең кырыс хакыйкать иң ярылып ятканнарын гына ала. Бу сүзләр килеп керү гади бер татар авылындагы сыйнфый көрәшкә көчле масштаблылык, киңлек һәм тирәнлек бирә. Шул ук вакытта Максут ише бик күп фидакарьләрнең көрәшләре бер олы идея белән берләштерелә, бүгенге тормыш көрәшләренә килеп ялгана. Максутлар эше, аларның көрәше Ленин көрәше белән ялгана, тоташа. Максут һәм аның көрәштәшләре барыбер үз дигәннәрен эшлиләр: икмәк җыйнала, баржага озатыла, һәм баржа социалистик илнең ачыгучы шәһәрләренә таба юл ала. Ләкин революция өчен зур эш эшләгән кыю егетләр үзләре аклар кулына эләккән. Алар һәлак булалар. Соңыннан, драманың иң ахыргы күренешендә яңадан һәйкәлгә әверелгән каһарманнар телгә килә: «...Ирекнең, гомерегезнең, тормышның һәм кешенең кадерен белегез!» Бу әсәр Юныс Әминов иҗаты өчен бик характерлы дияргә кирәк.

Аның бүтән драма һәм комедияләрендә дә кешеләрнең чын матурлыгы, эчке матурлыклары шундый игътибар белән, җентекләп өйрәнелә. Бары тик чорлар гына алышына, урыннар гына үзгәрә. Ә кеше шул ук: яхшы белән яман арасында талпынып яшәүче кеше — күңеле белән яхшылыкка омтылса да, чынлыкта бик еш кына чабуы нәрсәгәдер ябышкан һәм шуннан тиз генә ычкынып китә алмаучы кеше. Һәм тагын арада якты ут кебек балкучылар. Таза, нык иманлылар. Үз юлын тапкан һәм шуннан ышанып атлаучы кешеләр.

«Язылмаган законнар». Ю. Әминов исеме телгә алыну белән, һәрвакыт диярлек әнә шул әсәр китерелә. Чыннан да, илленче елларның уртасында ук язылуга карамастан, һаман да җитди мәгънәгә ия булып калган пьеса ул. Театрларыбыз сәхнәләрендә күп мәртәбәләр уйналды, һәм тамашачы аны яратып кабул итте. Ни өчен бүген дә кызыксынып укыла соң бу драма? Мәгаен, шуңадыр: анда кешеләр яшәешенең шактый четрекле мәсьәләләре күелa. Эчтәлегенә килгәндә, әдәбият өчен инде бик үк яңа булмаган гадәти мәхәббәт «өчпочмагы» да күренергә мөмкин: Шәйхенур, Фәридә, Назлыбикә. Әмма бүгенге тормыш куйган әхлак проблемалары яктылыгында әсәр яңа балкыш ала, яңа яссылыкларда ачыла. Мәсәлән, Шәйхенур белән Фәриданең арасы бозылуга бер Шәйхенур гына гаепleme? Көн буе фермада эштә булган, ә кич идарә утырышларында катнашырга мәҗбүр Фәридә бөтен яктан да акланамы? Драманы бүген яңадан укыганда язучының катлаулы чынбарлыкны чагылдыруын, тормыш хәлләрен тирән ачуын күрәсең. Биредә дә персонажларның һәр сүзе, һәр хәрәкәте ныклап мотивлаштырылган булу сокландыра. Бер карагандa гади генә кебек тоелган сүзләр көчле психологик тирәнлеккә ия. Алар күңел түренә үк үтеп керә, кайнар теләктәшлек яисә кискен нәфрәт уята. Менә драманың бер героинясы Фәридә сөйли: «— Онытыргамы? Үткәннәрнеме?.. Юк, юк. Яхшы хәтерлим. Сез Назлыбикә белән калдыгыз. Кайгыдан башымны түбән иеп, кайнар күз яшьләремә буыла-буыла чыгып киттем мин сездән. Бәлки, ул ялгышкандыр, уйларыннан кире кайтыр, мине яңадан үз янына чакырыр дип, соңгы өметем белән салкын капка баганасына сөяләп, сезне озак, бик озак көттем. Иң якын, иң яраткан кешемнең шулкадәр мәсхәрә итүенә күңелем ышанмады. Йолдызлар калыктылар, ай да чыкты, сез чыкмадыгыз. Мин, гарьләнүдән ут кебек кызышкан йөземне бәхетсезлектән калтыранган кулларым белән каплап, тын, караңгы урамнар буйлап ялгызым киттем. Әткәйнең таныш капкасын ачып кердем. Баскычка мендем, ләкин ишек шакырга көчем җитмәде. Кире төштем. Шул вакыт кинәт күз алдыма кара дулкыннарын ярга бәреп аккан Иж елгасы килде. Аның төпсез упкыннары миңа яшьтән таныш бит. Капка тавышына гаҗәпләнгән әткәй үзе килеп чыкмаса, белмим... Йокысыз үткән төннәремнең санын белмисез шул сез. Бер төн эчендә күз яше белән чылатып ташланган кулъяулыкларның санын белмисез шул сез. Барсына да түздем, барсына да чыдадым. Ә сез тыныч йокладыгыз ул төннәрдә. Минем хәсрәтем сезне борчымады». Шактый озын монолог тын да алмыйча укыла. Чөнки безнең алда героиняның йөрәк хисләре ташый, ургыла. Драматург безне әнә шул көчле стихиягә оста алып керә. Без кешенең күңел дулкыннары, кү-

нел давыллары уртасында калабыз. Онытылып, шул тормыш белән яши башлыйбыз. Тамашачы өчен дә, укучы өчен дә әле озак еллар буена искермәячәк бу драманы бүген яңадан күздән кичергәндә, Назлыбикә һәм Майлыбикә линияләренең, шулай да, әдәбияттагы илленче елларны искә төшерүен әйтмичә китеп булмый. Чөнки аларда — барысы да начар, алар һәммә яктан да тискәре. Анасы да, баласы да. Шунлыктан Шәйхенурның күпмедер вакыт Назлыбикә белән торуы да күрә торып ялгышу төслерәк аңлашыла. Бу героиняның Шәйхенурны кызыктырырдай башка яклары игътибардан читтәрәк кала. Әмма без аларның ниндидер күләмдә булырга тиешлеген чамалыйбыз. Чөнки төп героебыз Шәйхенур авылның бик акыллы, уңган егете иде. Ул юкка-барга гына алданырга тиеш түгел! Ә тулаем алганда, «Язылмаган законнар» бүгенге көн тормышы өчен бик актуаль яңгырый. Аның исеме үк әхлак кануннарын алга куя, кешеләрне аларга карата игътибарлы булырга чакыра.

Драматургның икенче бер әсәрендә авыл яшьләре алма бакчасы утырту эшенә тотыналар. Бу — яңа, матур һәм иң кешелекле яшәү символы булып аңлашыла. Ләкин аның өчен яшьләргә җирне карт, черегән тамырлардан чистартырга, җимеш бирүче яңа тамырлар утыртырга кирәк.

«Тамырлар» комедиясендә шул олы идея җанлы гәүдәләнеш таба. Гапсаттар, Хәерниса — замандашларыбыз холкында бүген дә чагыла торган шәхси милекчеләр, бары тик үз ихтыяҗларын гына алга куеп яшәүчеләр. Ә яшьләр бергә-бергә эшләргә, бергә-бергә яшәргә омтылалар. Драматургның ике төрле бу омтылышларны образлы итеп бирүе дә бик уңышлы: яшьләр: «Бакча яз саен ак чәчәккә төренер. Без синең белән актан киенеп шушы бакчада йөрербез. Агачлар да ак... Киемебез дә ак, чәчебез дә ак, бигрәк тә халык алдында йөзебез ак»,— дип хыялланалар, халык алдында йөз аклыгын иң зур максат итеп куялар. Ә картларны (аерым алганда — Хәернисаны) мүкле саз үзенә тарта, аңа яңа мунча өчен мүк кирәк... Юк, драматург бирегә мәсьәләне беркатлыландырмый. Ул «кешенең үз хуҗалыгы өчен тырышуы — начар» дигән фикер әйтми. Ул: кешеләрнең ялгыз-ялгыз гына эшләргә, ялгыз-ялгыз гына матур тормыш корырга теләүләре дөрес түгел, ди. Драматург Хәернисаларның, Гапсаттарларның үз мунчаларын өмә белән күтәрергә каршы булуларыннан көлә. Автор халкыбызның гомергомергә бергәлеккә омтылып яшәгәнлеген расларга тели. Күмәкләп эшләүнең кешегә күңел яктысы, йөз аклыгы китерүен матур итеп, сәнгатьчә итеп әйтә. «Тамырлар» комедиясенең ахырында Гапсаттар картның, үзен уратып алган яшьләргә карап: «Күбәйдегез сез, безне тәмам чолгап, бетереп алдыгыз. Болай булгач, эшләр хәзер сезнеңчә барыр инде»,— диюе дә, туры мәгънәсеннән бигрәк «бөтен тормыш» мәгънәсендә аңлашыла.

Китаптагы тагын ике драма әсәре авыл тормышы, авыл кешеләре хакында. Аларда да — шул ук гади хезмәт кешеләре, бүгенге көн сулышы.

Китапка тупланган күп кенә әсәрләр алдына «вакыйга Иж буе авылларының берсендә бара»,— дигән сүзләр язылган. Ә ахырда, аларның язылу урыны буларак, «Баржы» дип куелган. Димәк, драматург бу әсәрләренә материалны әнә шул авылда яшәп һәм эшләп тапкан. Аның бик күп геройларының прототиплары шул җирдә — Иж буенда яшәгән.

Соңгы елларда, якында гына ГЭС төзелү нәтиҗәсендә, Иж суы бик киңәйде, диңгез булып диярлек җәелде. Баржы да үз урынын су иркенә биреп килә хәзер. «Андый авыл юк шул инде» диләр хәзер бу як кешеләре.

Әмма әдәбиятның көче нәкъ менә шундый чакларда күренә дә икән. Авыл үзе юк, җирләрен су басып килә — ләкин аның әдәби әсәрдәге гомере дәвам итә. Алай гына да түгел: бу кешеләр, бу геройлар татар укучысының һәркайсына да якташ, авылдаш кебек — чөнки алар бөтенесе бер чор, бер тормыш, бер көрәш кешеләре.

Бу әсәрләрнең прототиплары йөргән сукмаклар КамГЭС төзелү уңае белән су астында калса да, геройларны халык йөрәгенә илтүче юллар беркайчан да өзелмәячәк. Чөнки ул юл — кешеләрнең күңелләре эченнән салынган юл.

**МАНСУР ВӘЛИЕВ.**

Гали Арсланов

# ТЕЛ ВӘ ЛӨГАТЬ АЛМАШЫП

Сүзне чак кына ерактанрак башлап китик әле: режиссер һөнәренең шәҗәрәсеннән. Сәхнә тамашасы белән идарә итүченең театрдан аерылгысыз булуыннан. Ләкин, шул ук вакытта, сәхнә уеннарын оештыра башлаудан алып бүгенге режиссура сәнгатенә кадәр бик күп буыннарның гаять зур хезмәте кирәккәнен дә онытмыйк. Дөнья театр тарихына мөрәҗәгать итсәк, художество ягыннан бербөтен спектакль тудыру сәнгатен — режиссураны француз театрында, мәсәлән, А. Антуанның «Ирекле театр» спектакле сәхнәгә куелган көн (1887 ел) белән бәйләп карыйлар. Шул ук елларда Венада танылган режиссер Генрих Лаубе беренче булып ансамбль характерындагы спектакль иҗат итә. Лондонда Чарльз Кин күмәк күренешләрне сәхнәгә кую методикасы өстендә эшли. Рус театрында мондый яңарыш процессы 1898 елда Мәскәү Художество театры ачылу белән башлана.

Татар театрында режиссура сәнгате чын мәгънәсендә театрның үзе белән бергә туа. Чөнки, мәгълүм булганча, Казанда беренче спектакль куелган вакытка режиссер хезмәте инде дөнья сәхнәсендә үз урынын алырга өлгерә. Рус режиссура сәнгатендә, мәсәлән, К. С. Станиславский, В. И. Немирович-Данченко, В. Э. Мейерхольд кебек танылган шәхесләрнең уңышлы эшчәнлеге, аеруча К. С. Станиславскийның сәхнә иҗаты психологиясе өлкәсендәге кызыклы эзләнүләре зур нәтиҗәләр бирә. Бөек реформаторларның яңа идеяләре милли театрлар үсешенә дә уңай йогынты ясый. Урыннардагы сәхнә энтузиастлары Мәскәү Художество театрына охшарга тырышып иҗат итә башлыйлар. Бу аралашу-йогынты күпсанлы гастрольләр вакытында да, рус актерлары һәм режиссерлары татар труппаларында эшләгәндә дә актив бара.

Русның беренче провинциаль сәхнә осталарыннан берсе Николай Зимовой, булачак «Сәйяр» труппасында эшли башлап, 1907—1908 ел сезонының бернинчә ае дәвамында аңа сизелерлек ярдәм күрсәтә: әле бөреләнә генә торган милли театрның тәҗрибәсез актерларына сәхнә әлифбасын өйрәтә, аларны киң карашлы, бай рухлы иҗат кешеләре итеп тәрбияләргә тырыша. «Ул минем рухи үсешемә тәэсир итте,— ди Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская үз истәлекләрендә,— ул мине тормышка дөрес күз белән карарга, начарны һәм матурны аера белергә өйрәтте. Ул яхшы актер иде һәм безгә... реалистик юлдан үсәргә булышты»[1]. Габдулла Кариев аны соңыннан да үзенең беренче сәхнә остазы итеп хөрмәт белән искә ала.

Тагын биш еллап вакыт үткәч, татар театры үз үсешендә мәгълүм уңышларга ирешеп өлгерә: даими актерлар составы, милли репертуар, кышкы сезон өчен бина булдырыла. Милли драматурглардан Г. Камал, Я. Вәли һәм башкаларның әсәрләренә «теше үтсә» дә, әлегә татар режиссурасы Н. В. Гоголь, А. Н. Островский пьесаларына ныклап тотына алмый, Көнбатыш Европа классикасына исә якын да килми.

Менә, ниһаять, «Йолдыз» газетасы 1913 елның 29 мартында Шәрык клубы театрында Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясе куелачагын хәбәр итә[2]. Әлегә

---

[1] Кашшаф Г. Беренче артистка. Казан, 1958, 26 бит.
[2] Мортазин бенефисы.— «Йолдыз», 1913, 24 март.

әсәрне кую өчен шәһәр театрыннан артист Загорский чакырыла. Татар театры беренче тапкыр Европа классикасына мөрәҗәгать итә һәм «Сәйяр» труппасы рус режиссеры белән иҗади элемтәгә керә.

Эштә кыенлыклар да аз булмый, билгеле. «Сәйяр»ның декорацияләре дә, костюмнары да юк. Кайбер рольләрне башкарып чыгарлык артистлар җитешми. Әйтик, леди Мильфорд роленә актриса булмау сәбәпле, Загорский пьесаны ике актка диярлек кыскартырга һәм аннан леди линиясен тулысынча төшереп калдырырга мәҗбүр. Режиссерның зур мәшәкатьле хезмәте җилгә очмый — бөтен компонентлары да үз урынында булган, тулы һәм җитлеккән спектакль иҗат ителә. Артистларның талантлы яңа яклары белән ачылып китә. Мәсәлән, Фердинанд ролен башкарганда В. Мортазин-Иманский үзен романтик рухлы, тирән кичерешләргә сәләтле актер буларак күрсәтә[1]. «Президент ролен оста артисларымыздан Кариев уйнады,— дип яза Г. Кәрам.— Кариев ул көнне шактый авыру булса да, уенында косурлык (кимчелек) күренмәде. Билгакес (киресенчә), бәгъзы бер (кайбер) урыннарда гаять рухлы уйнады (мәсәлән, Гофмаршал илә мөхавәрәсе (әңгәмәсе)...»[2] К. Тинчурин-Вурм да тамашачыларның хәтеренә кереп кала. Шул ук Г. Кәрәм фикеренчә, Вурм образын бу кадәр әйбәт башкару үрнәгеn ул чакта хәтта рус сәхнәсендә дә табуы кыен булган.

Тулаем алганда, спектакль уңыш белән бара һәм татар театрының алга таба үсешенә бик зур өлеш кертә. Беренче чиратта ул «Сәйяр»ның яшь режиссерлары Г. Кариев һәм В. Мортазин-Иманский өчен мөһим сабак була. Алар декорация, кием, грим кебек тәэсир чараларының әһәмиятен тирәнрәк аңлап калалар, драматургия материалы белән кыюрак һәм иҗадирәк эш итәргә өйрәнәләр. Шул көннәрдән башлап тәрҗемә әсәрләр труппаның еллык репертуарында нык урын ала һәм кайчакта хәтта милли пьесалардан ешрак та куела башлый. Мәсәлән, 1915—1916 ел сезонында «Сәйяр» афишаларындагы 28 пьесаның 15 е — тәрҗемә әсәр була.

Кайбер сезоннарда тәрҗемә пьесаларны сәхнәгә кую өчен рус режиссерлары һәм актерлары даими эшкә дә чакырылганнар. 1914—1917 еллар сезоннарында, мәсәлән, «Сәйяр»дә М. А. Громов һәм Н. Михаленко эшләгәнлеге билгеле. Алар Мольер, Шиллер, Гете, Гоголь, Островский һәм Чехов әсәрләрен сәхнәгә куялар. Әлеге спектакльләрдә беренче артистларыбыз иҗат иткән гаҗәеп образлар исемлеген дә карап үтәргә мөмкин: Г. Кариев башкаруындагы Городничий, Дудукин, Президент һәм Миллер, К. Тинчуринның Незнамов һәм Хлестаковы, Г. Болгарскаяның Катерина һәм Кручинина рольләрендә уйнаулары... һәркайсы татар театрының иң күренекле хезмәтләре хисабына керерлек образлар.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң рус—татар театр багланышлары тагын да тыгызрак һәм нәтиҗәлерәк төс ала. Татар театры үзенә укымышлы режиссерлар һәм артистлар әзерләү эшенә керешә. 1919 ел башларында З. Солтанов җитәкчелегендә Әстерханда беренче татар драма студиясе төзелә. 1920 елның 15 июнендә Самарада — Идел аръягы хәрби округы политбүлегенең мөселман секциясе каршында — татар драма һәм музыка студиясе, ә 1923 елның январь аенда Казанда Татар театр техникумы ачыла. Яшьләрне актерлык осталыгына һәм режиссер хезмәте серләренә К. Тинчурин һәм З. Солтанов кебек остазларыннан тыш, П. Талбузин, З. М. Славянова, Б. Н. Смолин, Я. П. Гамза һәм А. М. Кречетов кебек рус актерлары һәм режиссерлары да өйрәтә. Чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә ике йөзгә якын кеше театр белеме ала. Алар арасында — СССРның халык артисткасы М. Даутова, РСФСРның атказанган һәм ТАССРның халык артистлары Х. Уразиков, Камал III, Г. Булатова, ТАССРның халык артисты Х. Сәлимҗанов, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе профессор Ш. Сарымсаков, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Р. Ишморат һәм башка бик күпләр.

1930 елның июнендә Татар дәүләт академия театры коллективы Мәскәүдә уздырылган СССР халыклары сәнгатьләренең Беренче олимпиадасында катнаша. Олимпиаданың үзендә һәм аннан читтә дүрт спектакль күрсәтелә: «Утлы бохра» драмасы

[1] Казанлы Фатыйх Сәйфи. Шәрык клубы сәхнәсендә «Мәкер вә Мәхәббәт».— «Йолдыз», 1914, 18 февраль.
[2] Кәрам Г. Татарча театр.— «Йолдыз», 1913, 4 апрель.

(русчадан Г. Уральскийның иҗади тәрҗемәсендә), К. Тинчуринның «Ил» һәм «Зәңгәр шәл» музыкаль драмалары, «Эшче» операсы (М. Гафури либреттосы, Г. Әлмөхәммәдов, С. Габәши, В. Виноградов музыкасы). Спектакльләрне караганнан соң Олимпиада жюрие яшь татар режиссерлары тәрбияләү эшен камилләштерү кирәклеген билгеләп үтә. Олимпиада сабаклары һәм җәмәгатьчелек фикерләре эзсез калмый, әлбәттә. Утызынчы елларда талантлы сәнгатькәрләр арасыннан сайлап алып укырга җибәрелгән Г. Исмәгыйлов, С. Булатов, Г. Ильясов, соңга табарак — Ш. Сарымсаков һәм К. Тумашева татар сәхнәсе үсешенә зур өлеш керткән режиссерлар булып җитлегәләр. Татар дәүләт академия театрында эшләү һәм аерым әсәрләрне кую өчен рус режиссерлары чакырыла (Н. Чиркин, Н. Фрид, Б. Фердинантов, Б. Великанов, Е. Амантов). Режиссер-консультант сыйфатында чакырылып, ике сезон эшләгән Г. Хавис хезмәтләре аеруча тәкъдир ителүгә лаек. Ул репертуар сайлау, репетицияләр үткәрү, сәхнәне җиһазлау мәсьәләләре буенча күп төрле тәкъдимнәр кертә. Хавис театр эшчәнлегенең барлык тармакларында төгәллек, тәртип һәм хисап булуына ирешергә омтыла. Режиссер-куючы вазифасын да башкарып, 1935—1936 ел сезонында Г. Хавис Островскийның «Яшенле яңгыр»ы һәм Мольерның «Тартюф»ы буенча бер-бер артлы ике спектакль куя.

1934—1935 елгы сезон уртасында ТДАТка Мәскәүдән атказанган сәнгать эшлеклесе И. Н. Берсенев җитәкчелегендә тәнкыйтьчеләр бригадасы килә. Бригада сезонның өч спектаклен — Р. Ишморатның «Ил өчен», Г. Исмәгыйловның «Тормыш чакыра» һәм Г. Ильясовның «Соңгарган фәрман» дигән әсәрен куйый. Бу спектакльләрдән алган тәэсирләрен И. Берсенев «Театр Советской Татарии» дигән мәкаләсендә («Советский театр», 1935, № 1) язып чыга. Татар режиссерлары кайчакта тиешенчә игътибар бирмәгән грим, яктырту һәм башка зур «вак-төякләр»дән тыш, ул төп кимчелекне спектакльләрнең стиле бертөрле булмауда күрә. Аның фикеренчә, бу «татар академия театрының әле үз методын, үзенең төп юнәлешен ачыкламавыннан килә». «Советский театр» журналының икенче бер корреспонденты И. Суриковка да «театрның иҗади йөзе турында аз уйлыйлар» кебек тоела. Болар һәммәсе дә театр эшендә, әлбәттә, исәпкә алына.

Утызынчы еллар уртасыннан башлап театрга Мәскәү һәм Ленинград югары уку йортларыннан укырга җибәрелгән яшь режиссерлар кайта башлый. ГИТИСта И. Я. Судаков, А. Л. Грипич, Б. А. Сушкевич шәкертләре булган Г. Исмәгыйлов, С. Булатов, соңрак Ш. Сарымсаков һәм К. Тумашева кайта. Алар пропагандалый торган К. С. Станиславский системасы Г. Кариевның реалистик мәктәбе традицияләрендә тәрбияләнгән актерлар һәм режиссерлар өчен бик якын була. Шуңа күрә дә алар кыска вакыт эчендә системаның төп принципларын үзләштерә һәм үз эшләрен аның таләпләре нигезендә үзгәртеп кора алалар. Уфада 1938 елгы гастрольләр вакытында бу ике театрның иҗат принциплары уртак булуы, Кече театрның «Щепкинча» реалистик традицияләре йогынты ясаганлыгы билгеләп үтелә («Красная Башкирия», 1938, 30 июль).

1940 елның гыйнварында театрның художество җитәкчесе итеп аңарчы Воронежда рус драма театрына 12 ел җитәкчелек иткән Е. Г. Амантов билгеләнә. Шушы ук елның мартында театрның ачык партия җыелышында чыгыш ясап ул, актерлар коллективына югары бәя бирү белән бергә, аларның эш шартларыннан канәгать булмавын белдерә һәм булган кимчелекләрне кичекмәстән бетерү мәсьәләсен куя. Спектакльләрнең материаль-финанс ягыннан тәэмин ителеше дә аңа ошамый, аның фикеренчә, бу — спектакльләрнең художество сыйфатына зыян китерә. Әмма Амантов бигрәк тә театрның репертуарын формалаштыруга зур игътибар бирә һәм үз эшчәнлегендә һәрвакыт идея-художество ягы тел-теш тидермәслек булган драматургия материалына йөз тота. Аның Г. Камал исемендәге театрда куйган беренче спектакле А. Арбузовның «Таня» пьесасы буенча була. Режиссер шушы ук пьеса буенча Революция театрында А. М. Лобанов куйган спектакльне белә, әмма аның финалы белән килешми. Революция театры спектаклендә Таня, никадәр генә үзгәрсә дә, һаман ялгыз килеш кала. Ул бер генә нәрсәне: беренче мәхәббәтнең ялган булуын гына аңлый. Г. Камал исемендәге театр спектаклендә исә Таня ялгыз түгел. Ул профессия үзләштерә, лаеклы тормыш иптәше таба. Режиссер актерлар составы белән зур, җентекле эш алып бара. Нәтиҗәдә аларның күбесе менә дигән характерлар тудыра. Иң уңышлылары итеп Ф. Ильскаяның

Танясын, Г. Булатованың Шамановасын, Камал III һәм Ф. Халитовның Германын телгә алырга кирәк. Яшь артист Г. Зиатдинов башкаруында Соколов образы да ачыш була. «Е. Г. Амантовның бик яхшы режиссерлык эше һәм халык артисткасы Ф. Ильскаяның талантлы уены «Таня»ны әһәмиятле театраль вакыйга итте,— дип яза Г. Кутуй.— Режиссер Е. Г. Амантов үзен бу спектакльдә образларны гади һәм матур итеп ачып бирә белүче яхшы художник итеп кенә түгел, ә бәлки тормыш турында, кеше турында, безнең чынбарлыкта хатын-кызның роле турында фикер йөртүче итеп тә танытты» («Красная Татария», 1940, 16 апрель).

В. Шекспирның «Ромео һәм Джульетта» трагедиясе Е. Амантов күңелен үзенең «зур оптимистик стимулы» белән үзенә тарта. Ул, режиссер фикеренчә, яшьләрнең мәхәббәт өчен көрәшендә, иске көнкүрешнең традицион нигезләрен какшатып, иреккә чыгучы яңа шәхеснең дөньяга карашында чагылыш таба.

«Шекспир әсәрләре моңарчы да татар телендә куелса да (мәсәлән, «Отелло», «Гамлет»),— дип яза спектакль турында Г. Кутуй,— татар тамашачысы даһи драматургның поэзиясе белән чын-чынлап, ихтимал, беренче тапкыр «Ромео һәм Джульетта» спектаклендә танышкандыр. Режиссер Амантов, художник Сперанский һәм Ромео белән Джульетта рольләрен башкаручы артистлар Камал III һәм Фатыйма Ильская дәрт һәм поэзия ташып торган спектакль тудырганнар» («Красная Татария», 1940, 16 ноябрь).

Е. Амантов Г. Камал исемендәге театр өчен этап булган «Хуҗа Насретдин» спектакленә дә (Н. Исәнбәт әсәре) шактый өлеш кертә... «Хуҗа Насретдин»— халык зирәклегенең үлемсезлеге турында күңелле, матур тамаша» дип яза Г. Кутуй («Красная Татария», 1940, 21 сентябрь) һәм моның режиссерлар Х. Уразиков, К. Тумашева һәм Е. Амантов хезмәте икәнлеген күрсәтә.

Мәскәүдә 1941 елда буласы Татар сәнгате декадасына хәзерлек барган көннәрдә инде йөз тапкырга якын куелган бу спектакльне яхшырту буенча эшләүне танылган рус режиссеры В. М. Бебутовка тапшыралар. Ул үзенә спектакльне матур, бәйрәмчә итү максатын куя. Аның уенча, музыка спектакльнең эчтәлеге белән органик рәвештә үрелеп барырга, әсәрне көчәйтергә тиеш була, балет, хор һәм вокал номерлары кертү дә планлаштырыла. Аларның кайберләрен башкару опера һәм балет театры артистларына тапшырыла. Ләкин, бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, Татар сәнгате декадасы була алмый кала һәм Бебутовның «Хуҗа Насретдины» да күрсәтелми, әлбәттә. Сугыш елларында да ул безнең театрда эшләвен дәвам итә, рус һәм Көнбатыш Европа классикасы әсәрләрен, замандаш рус драматургиясе пьесаларын куя. («Эрджикинез» («Хокуксызлар князе») — В. Г. Брагин, «Яшенле яңгыр»— А. Н. Островский, «Печән өстендәге эт»— Лопе де Вега һәм «Король Лир»— В. Шекспир). «Король Лир»ны куйганда ул иң элек башкаруда ансамбльлеккә, бөек трагедиянең мәгънәсен бөтенлекле итеп ачуга омтыла. Лир ролендә Х. Әбҗәлилов әйләнә-тирә дөньяны танып-белү темасын һәм шәхси тема — кызларына мөнәсәбәт темасын бергә берләштерә. «Рольгә лирик мотив кертү, Шекспир чорындагы «гаепле Лирга» әйләнеп кайту бу спектакльнең кыйммәтле сыйфатларыннан берсе булды». Әнә шундый югары бәя биреп, танылган совет шекспирчысы М. М. Морозов спектакльне совет сәхнәсендә Шекспир әсәрләре буенча куелган иң яхшы эшләр белән бер рәткә куя.

Сугыштан соңгы елларда да татар театры өчен актер һәм режиссер кадрлар әзерләүдә рус режиссерларының роле зур булды. 1944 елдан 1949 елга кадәр А. В. Луначарский исемендәге ГИТИСның режиссер-педагоглары җитәкчелегендә татар студиясе актерлык әзерлеге үтә. Студияне тәмамлаучылардан иң яхшылары әле хәзер дә Татарстан театрларында уңышлы эшләп киләләр. Алар арасында РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисткасы Ш. Әсфәндиярова, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Г. Хөсәенов, ТАССРның халык артистлары Г. Камалова, А. Галиева, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе П. Исәнбәт һәм башкалар бар. 1952 елда ГИТИСны А. Д. Попов һәм М. О. Кнебель шәкерте Р. Тумашев тәмамлап чыга. Ул хәзер — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Драма һәм комедия театрының баш режиссеры.

1961 һәм 1973 елларда исә Г. Камал исемендәге академия театры составына

М. С. Щепкин исемендәге театр училищесы һәм Ленинград дәүләт театр, музыка һәм кино институты студияләре шәкертләре килеп кушылды. Режиссер-педагоглардан Н. Глазков һәм В. Смирнов хәзерләгән, РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты Р. Таҗетдинов, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган артисты Ә. Шакиров, ТАССРның халык артистлары Р. Шәрәфиев, Н. Ихсанова, Н. Дунаев, Л. Дачко шәкертләре Ш. Бариев, И. Әхмәтҗанов, Ш. Галиуллин хәзер Г. Камал исемендәге театр репертуарын төпкә җигелеп тарталар. Мәскәүдә ГИТИСны тәмамлаган, А. Лобановта укыган М. Сәлимҗанов, Академия театрының хәзерге баш режиссеры, 1962 елда А. Н. Островскийның «Котырган акчалар» пьесасы буенча үзенең беренче спектаклен куйды.

Рус режиссерларының Г. Камал исемендәге театрда сугыштан соңгы эшчәнлекләре дә игътибарга лаек. А. Михайловның һәм М. Новохижинның М. Горький пьесасы «Дошманнар» һәм Н. Погодин пьесасы «Баһадирлар» буенча куйган спектакльләре милли театр үсешенә шактый өлеш булды.

1981—82 елгы сезон башында басылган баш мәкаләсендә «Правда», бу сезонның йөзе СССР төзелүнең 60 еллык юбилее белән билгеләнәчәген күрсәтеп, юбилейга әзерлек барышында иҗади элемтәләрне көчәйтү, театр культураларының бер-берсен баетуы өчен булган мөмкинлекләрдән тулырак файдаланырга чакырган иде. Әйе рус һәм татар сәнгатьләре арасындагы, милли театрның идея-тематик һәм стиль палитраларын баета торган элемтәләр хәзер һаман ныграк системага кереп бара. Рус драматургиясе әсәрләренә мөрәҗәгать итү, режиссерларның, актерларның, сәхнә бизәүчеләрнең уртак постановкаларда катнашуы — дуслыкның бу һәм башка төрле формалары инде традициягә әйләнде. Әмма, бүгенге театрның казанышларына күз салганда, шунысын һәрвакыт истә тотарга кирәк: дуслыкның, хезмәттәшлекнең нигезе милли театр яши башлаган беренче елларда ук салынган иде, һәм ул театрның бөтен тарихы буена дәвам итеп килде.

# АВЫЛ БЕЛӘН ШӘҺӘР АРАСЫ

СОЦИОЛОГ ЯЗМАЛАРЫ

Авылга, аның социаль-экономик һәм культура мәсьәләләренә карата бездә элек-электән зур кызыксыну яшәп килә. Хәер, бу мөнәсәбәтнең башкача булуы мөмкин дә түгел, чөнки, мәгълүм ки, авыл экономикасы халыкның материаль хәле ниндилеген хәл итүдә төп рольләрнең берсен уйный. Авыл хуҗалыгы азык-төлек җитештерүнең һәм җиңел промышленность өчен чимал әзерләүнең төп чыганагы булып тора. Шунлыктан авылга кагылышлы проблемалар да катлаулы. Партиянең XXVI съездында Л. И. Брежнев: «...бу мәсьәләләрне радикаль хәл итү максатыннан чыгып, махсус программа, азык-төлек программасы төзү кирәк табылды,— диде.— Ул авыл хуҗалыгы продукциясен әзерләүнең сизелерлек алга китешен тәэмин итәргә тиеш». Ел саен 238—243 млн. тонна ашлык җитештерү унберенче бишьеллыкның иң мөһим бурычларыннан санала.

Бу максатка ирешү өчен авыл хуҗалыгы ихтыяҗларына 190 млрд. сумга якын чыгым тоту планлаштырылды. Колхоз-совхозларда тракторлар, комбайннар, автомобильләр һәм минераль ашламалар бирү арттырылачак. Болар һәммәсе авылның экономикасын үстерү өчен эшләнә.

Әмма хикмәт экономикада гына да түгел. Хәзер безнең 100 млн. чамасы кеше авылларда яши. Димәк, илнең социаль куәте дә, өлешчә, авылыбызның ниндилегенә, аның һәм экономик, һәм социаль үсеш дәрәҗәсенә бәйле.

Уфа авиация институтының социологик лабораториясе кайбер шәһәрләрдә алып барган тикшеренүләре нәтиҗәсендә шушындый мәгълүматлар алды: Уфада яшәүчеләрнең — 44, Стәрлетамакта — 50, Чаллы кешеләренең 40 процентка якыны авылдан килгәннәр икән.

Соңгы ун ел эчендә авыл хезмәтчәннәренең техник яктан көчле коралландырылуы һәм хезмәт җитештерүчәнлегенең югары үсеше аркасында колхоз-совхозларда шөгыльләнүче кешеләр саны нык кимеде. 1959 елгы исәпкә алу вакытында авыл кешеләренең саны барлык халыкның 52 процентын тәшкил иткән булса, 1970 елда аның — 44, ә 1981 елда 37 процентка калуы беленде. Соңгы тапкыр уздырылган исәпкә алулар арасында гына да Советлар Союзы халкы 20,7 миллионга, ягъни 8,6 процентка үскән. Шәһәрдә яшәүчеләр саны исә 27,6 миллионга артты. Бу хәл шәһәр халкының табигый үсеше, авыл кешеләренең калага күчеп тора башлавы һәм кайбер авыл пунктларының шәһәрләргә әйләндерелүеннән (15,6 млн.) килеп чыкты.

Монда китерелгән бик күп саннар һәммәсе катлаулы социаль процесслар хакында сөйли. Элегрәк без халыкның шәһәрдә яшәргә тырышуын авылларда мәктәпләр, клублар, кибетләр җитешмәве белән аңлата идек. Хикмәт аларда гына да булмаган икән. Кешеләр ул учреждениеләрнең бардыгын гына түгел, шәһәрдәгечә үк төгәллек белән эшләвен, мәктәбенең төпле белем бирүен, клубының нечкә зәвыкларны канәгатьләндерерлек чаралар үткәреп торуын да телиләр. Кибетләрдә яхшы товарлар булсын, кешеләргә, шулай ук яхшы сыйфатлы көнкүреш хезмәте күрсәтелсен! Бу кадәресе, әлбәттә, авылдагы җитәкчеләр алдына зур бурычлар куя: алар кешеләр ихтыяҗын күңелләренә якын кабул итәләрме, авыл халкының һәр теләген тормышка ашырырга тырышаларму, әллә салкын битарафлык саклыйлармы? Хәзер шәһәрдә генә түгел, авыл җирләрендә дә кешеләрнең буш вакыты артканнанарта. Димәк, ял итү урыннары — культура сарайлары, китапханәләр, стадионнар, кинотеатрлар да күбрәк кирәк була бара. Шунсыз бүгенге заман кешесенең һәрьяклап үсүе, камилләшүе мөмкин түгел. Безнең авыллар күзгә күренеп һәм тиз үзгәрәләр. Аларның шулай алга китүе тарих өчен дә яңалык. Шунысы аеруча мөһим: экономиканың һәм социаль якның үсү процесслары бер-берсе белән тыгыз элемтәдә тора. Әйтик, әгәр хәзерлекле белгечләр белән тәэмин ителмәгән булса, колхоз яки совхоз паркын күпсанлы машиналар белән тутырудан гына бер тиенлек файда да алып булмаячак. Авылның алга барышы идеәэ итүе ифрат кыен булган, катлаулы социаль процессларга өзлексез игътибарлылык таләп итә. Монда гаять күп төрле якларны истә тотып эшләргә туры килә. Авыл кайда урнашкан: тиз генә күченеп китәргә уңайлы булган, зур калаларга якын җирдәме яки эчкәре, тып-тын аулак почмактамы ул?

Совет власте елларында безнең илдә меңләгән яңа шәһәрләр барлыкка килде. Ерак Запорожьены яки Себердәге кайбер пунктларны санамаганда, аларның иң зур күпчелеге моң-очы тын гына яшәп яткан авыллар яки кечкенә шәһәрләр янында үсеп чыга да яшәешкә өр-яңа сулыш өрә. Күп очракта яңа төзелешләр тәэсире әстенлек ала һәм хәлиткеч булып кала.

Мисалга Чаллыны алыйк. 1959 елда анда 16,2 мең кеше яшәгән, 1970 елда — 39,9 мең, хәзер исә 350 мең дип исәпләнә. Үсешнең төп терәге — елына 150 мең зур йөк машинасы эшләп чыгара торган Кама автомобиль комплексы. Бу төзелеш Татарстанның төньяк-көнчыгыш өлешендә Чаллы, Түбән Кама, Зәй, Яңа Зәй, Алабуга, Минзәлә кебек шәһәрләрне эченә алган зур бер территориаль-производство комплексын барлыкка китерде. Хәзер Чаллының үзендә хезмәт итүче һәр дүрт кешенең өчесе урта, махсус урта яки югары белемлеләр. Бөтен камазчыларның белем дәрәҗәсе, уртача чыгарганда — 11,3 еллык. Программалы идарә итүгә көйләнгән меңнәрчә станоклары, роботлары һәм 250 автомат линиясе булган предприятиегә шундый эшчеләр кирәк тә иде. Каян җыелганнар соң алар? Беренче булып монда авыллардан һәм шәһәрләрдән кулында комсомол путевкасы булган яшьләр килде.

Чаллыга ераклардан да, калага якын гына авыллардан да килделәр. Чаллы районында (хәзерге Тукай районы) шәһәргә китүчеләр саны аеруча артты. Йомылып, тын гына яшәп яткан авыл тормышы белән чагыштырганда яңа шәһәрдәге шартлар күп мәртәбә өстенрәк иде. Чаллыда исә эш көчләренә мохтаҗлык үскәннән-үсә барды. Районлагы бу процесс әле дә, ил күләмендә исәпләнгән тизлек белән чагыштырганда, күп мәртәбәләр кызурак бара.

Тагын бер мәсьәләне ачыклыйк: авылдан кемнәр китә? 9,3 проценты — механизаторлар (алар, ил күләмендә алганда, авыл кешеләренең 3,3 процентын тәшкил итә); 3,6 проценты — терлекчеләр (ил күләмендә — 4,6 процент); 2,5 проценты — авыл хуҗалыгы белгечләре (ил күләмендә — 0,6 процент). Бу саннардан күренгәнчә, Чаллы яны авылларыннан иң кирәкле кадрлар — механизаторлар һәм белгечләр китә. КамАЗ төзелеше башлангач, Чаллы тирәсендәге авыллардан иң яшь, укымышлы кешеләр шәһәргә күчте.

Миңа Тукай районының авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы Фаяз Мөҗәһитов белән сөйләшергә туры килде.

— Авыллардагы кадрларны ничек сакларга уйлыйсыз?

— Шәһәрнекеннән һич тә ким булмаган культура-көнкүреш шартлары тудырачакбыз, әйбәт өйләр салачакбыз,— диде ул.— Яшьләрне КамАЗдагы техника кызыктыра. Димәк, колхоз-совхозлардагы хезмәтне дә механикалаштырырга, автоматлаштырырга кирәк булачак...

Сер түгел: КамАЗ янындагы авылларның ихтыяҗына да зур игътибар бирелде. Аларны уңайландыруда бөтен ил катнашты. Тугызынчы бишьеллыкта гына да бу эшләргә Чаллы районының авыл хуҗалыгына моңарчы булган барлык бишьеллыкларда тотылган кадәр чыгым бүленә.

Чаллы янындагы колхоз-совхозлар үзләренең эшләрен КамАЗ таләпләренә җайлаштыралар: алар хәзер ерактан китереп йөртүе кыен булган, зур күләмле яки тиз бозылучан продуктлар әзерләүгә йөз тоталар. Халык депутатларының Тукай районы Советы Башкарма Комитетының план комиссиясе председателе Әнисә Зиннәтуллина бу хакта безгә ачыктан-ачык әйтте:

— КамАЗ хәзер безнең алга үз таләпләрен куеп кына тора,— диде.— Хәзер бөтен район КамАЗ теләкләрен үти, шуңа җайлаша.

Башкача мөмкин дә түгел иде, чөнки тиз арада үсеп чыккан зур шәһәргә авыл хуҗалыгы продукциясе бик күп күләмдә кирәк була башлады. Шуңа бәйле рәвештә авылның экономикасы тамырдан үзгәрергә мәҗбүр.

Чаллыдагы төзелешләр Тукай районы авыл хуҗалыгына китергән яңалыклар менә нинди: басулар мәйданы 82327 гектардан 70757 гектарга калды. Шул исәптән бөртеклеләр чәчүгә, бәрәңге һәм яшелчәләргә кирәклесе дә кимеде. КамАЗ төзелеше киң колач белән барган тугызынчы бишьеллыкта районда бөртеклеләрдән уңыш алу кимετелә төште. Чөнки монда яшелчә, сөт, ит кебек якын-тирәдән китерелүе отышлырак, тиз арада бозылу ихтималы булган продуктларны күпләп җитештерү таләп ителде. Районның авыл хуҗалыгы структурасы үзгәртелде, хуҗалыклар арасында специальләшү башланды. Хәзер райондагы хуҗалыкларда хезмәт бүлешү түбәндәге юнәлештәрәк: «Челнинская» совхозы мөгезле эре терлекләр симертә, «Татарстан» совхозы дуңгызчылык һәм бөртеклеләрдән уңыш җыю белән шөгыльләнә, «Ворошиловский» совхозы яшелчә үстерә һәм нәселле бозаулар үрчетә, «Ильбухтинский» совхозы яшелчә, бәрәңге һәм сөт җитештерә...

Хуҗалыкларның кайбер тармаклар буенча эре берләшмәләргә тупланувы да торган саен киңрәк колач ала. Мәсәлән, терлекләрнең нәселен яхшырту өчен Калинин исемендәге, Чкалов исемендәге, М. Җәлил исемендәге һәм «Коммунизм» колхозлары. «Ворошиловский», «Гигант», «Ильбухтинский», «Татарстан», «Чулпан» совхозлары бергә берләште. Нәселле бозаулар үрчетү, мөгезле эре терлекләр үстерү һәм электр энергиясеннән файдалану буенча да шундый ук эре берләшмәләр барлыкка килде. Районда елына 56 мең центнер ит җитештерә торган дуңгызчылык комплексы, 100 млн. йомырка бирүче кошчылык фабрикасы, 30 гектарлы теплица һәм елына 10 млн. бройлер үстерүче фабрика салынды.

Шәһәр таләпләренә җавап бирергә тырышу йөзеннән Тукай районының чәчү мәйданнары структурасына да, терлекчелеккә дә мөһим үзгәрешләр кертелә. 1975 елда 22596 тонна сөт җитештерелсә, 1980 елдагы сөт 30090 тонна булды, ит 4819 тоннадан (1975 ел) 14030 тоннага җиткерелде. Мондый алга китешкә нигездә терлекләрнең баш санын арттыру һәм аларның продуктлылыгын яхшырту аркасында ирешелде. Бу юнәлештә тагын да зуррак күрсәткечләр булсын дигәндә, терлекләрнең һәм кош-кортның нәселен яхшыртырга, чәчүлекләрне киңәйтергә, ашлама кертергә, сугарулы басуларны арттырырга, эш процессын механикалаштырырга, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрергә кирәк.

Тугызынчы һәм унынчы бишьеллыклар дәвамында колхоз-совхозларның материаль-техник җегәре шактый ныгыды. Аларның энергия куәтләре ун ел эчендә ике тапкырдан күбрәккә артты. Бу хәл һәм кырчылыктагы, һәм терлекчелектәге күп кенә эшләрне механикалаштырырга, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрергә мөмкинлек бирде. Авыл кешеләренең шәһәргә китүе өзлексез ешаеп торганда, хуҗалыкны шунсыз җайга салып та булмый. Тукай районында бу чара шактый уңышлы хәл ителә килде.

Колхоз-совхоз хезмәтчәннәренең саны киму белән бергә, аларның сыйфат ягы да үзгәрә: укымышлылары китеп бара, һөнәрсезләр, аз белемлеләр кала бирә. Андый кешеләргә катлаулы техниканы ышанып тапшырып булмый, нәтиҗәдә хезмәт җитештерүчәнлеге түбәнәя.

Каршылыклар, шул рәвешчә, үзеннән-үзе туып кына тора. Аны тормыш ихтыяҗлары, яңа шәһәр шартлары үзләре үк китереп чыгаралар. КамАЗга авыл кешеләренең эшкә килүе дә кирәк, шәһәр зурайган саен, колхозлар җитештергән продукциянең күләмен арттыру да сорала.

Шәһәр яны авылларындагы хуҗалыкларның экономика структурасы үзгәрү һәм техника белән баетылуы монда яшәүчеләрнең һөнәрләренә, башкарган эшләренең эшчәнлегенә дә яңалык кертә. Тугызынчы һәм унынчы бишьеллыклар дәвамында Тукай районы авылларындагы хезмәтчәннәр арасында эше тулысынча яки өлешчә механикалаштырылган кешеләр саны ике мәртәбә артты. Химик-лаборант, сөт җитештерү блогы мастеры, сугару механизаторы, электромеханик, су сиптерүче кебек өр-яңа һөнәр ияләре барлыкка килде. Авылларның үзәк фигурасыннан саналучы механизаторлар кулына К-700 кебек яңа төр машиналар тапшырылгач, аларның белем дәрәҗәсен күтәрү зарурлыгы туды. Шушы еллар эчендә Тукай районында 752 кеше— сыерларны машина белән савучы, 208 кеше — җылылык системасында эшләүче оператор, 9 кеше төрле механик җайланмаларны көйләүче мастер-оператор, 31 кеше — терлек фермаларындагы механизмнарны төзәтүче слесарь, 30 кеше электромонтер һөнәренә өйрәтелгән. Шуңа карамастан, бу мәсьәлә әле ахырынача хәл ителмәгән.

Кешеләрнең авыллардан шәһәргә китүе бер караганда, хуҗалыкларны кыен хәлгә куйса, икенче яктан, бу процесс колхоз-совхозларның техникага йөз белән борылуына, алга китүенә сәбәп була. Тукай районындагы колхоз-совхозлар Чаллыдагы промышленность предприятиеләре белән тыгыз элемтәгә керделәр. 1970—1980 елларда Чаллыдагы шеф-предприятиеләр район хуҗалыкларына 16 млн. сумлык хезмәт күрсәткән: терлек абзарлары, орлык, яшелчә, бәрәңге саклау биналары, автотрактор парклары һәм гаражлар, культура һәм көнкүреш объектлары салынган; кайбер хуҗалыкларның электрлаштыруга булган мохтаҗлыгы канәгатьләндерелгән. «Камгэсэнергострой» берләшмәсендә авылдагы төзелеш эшләре өчен җавап бирүче махсус «Сельстрой» идарәсе булдырыла.

Чаллыдагы бинниһая зур төзелешләр Тукай районы авылларында Советлар Союзының һәр авылында өзлексез дәвам итүче гадәти процессны бик нык тизләтте һәм күрсәткечләрне гомумсоюз дәрәҗәсеннән югарыракка күтәрде. Монда шулай ук безнең авылларга хас булмаган кайбер каршылыклар да кискенләште.

Чаллы шәһәре һәм Тукай районындагы авыллар мөнәсәбәтен өйрәнүдән чыгып, түбәндәге конкрет нәтиҗәләрне әйтергә була: күршесендә зур промышленность комплексы һәм яңа шәһәр салыну авылларның тиз һәм ышанычлы үсешенә китерә. Авыл белән шәһәр аерымлыклары сизелерлек кими — алар бер-берсенә якынаялар. Әмма бу мәсьәләнең кайбер кимчелекле яклары да бар. Андый хәлләр булмасын өчен, КамАЗны һәм Чаллы шәһәрен төзү проектында ук якын тирәдәге авылларны үзгәртеп кору шартлары да каралырга тиеш булган. КамАЗ тәҗрибәсе безгә киң колач белән үсүче районнарда социаль проектлау булдырылырга кирәклеген ачык раслады. Бу очракта район үзәгенең яңа бурычларын да онытырга ярамый. Кибетләр, культура, сәламәтлек саклау учреждениеләре тирә-юньдәге авылларның ихтыяҗын да канәгатьләндерерлек булсын.

Шәһәргә якын авылларны комплекслы рәвештә социаль проектлау, беренчедән, хезмәтнең тамырдан үзгәрүен; колхоз-совхоз фермаларының комплекслар белән алмаштырылуын, хуҗалыкара кооперацияләр, специальләшүләр җирлегендә кайбер эшләрнең урталлануын күздә тотарга тиеш.

Икенчедән, шәһәр тирәсендә яшәү шартлары нәкъ яңа калалардагы кебек үк булган зур поселокларның барлыкка килүен дә искә алырга кирәк.

Өченчедән, шәһәргә китүне өнәмичә, авылда калган өлкән яшьтәгеләрне үзләренә муафыйкъ эш белән тәэмин итүне кайгыртырга кирәк булачак.

Дүртенчедән, яңа зур шәһәр салганда, якындагы авылларның мәнфәгатен дә искә алырга.

Билгеле булганча, яңа шәһәрләр янындагы авылларны үзгәртеп кору бик зур чыгымнарга бәйләнгән. Андый акчаны кайдан алырга?

Безнең карашыбызча, бу чыгымнар яңа шәһәр сала башлаган министрлыклардан алынырга тиеш, чөнки авылларның үзгәреше төзелешкә бәйле рәвештә килеп чыга бит. Шунлыктан яңа шәһәрләргә проект төзегәндә үк авылларның тамырдан үзгәрешенә кирәкле чыгым сметага кертелергә тиеш. Тагын шунысы да бар: авылларны төп төзелешкә тотынганчы ук үзгәртә башлау хәерле, чөнки авыл кешеләре шәһәргә китә башлагач, кечкенә фермаларны зур комплексларга әйләндерү кыенга килә.

Яңа шәһәрләр үз тирәләрендәге колхоз-совхозларның продуктларны мөмкин кадәр күбрәк җитештерүен тели, алар моңа мохтаҗ. Шулай икән, димәк, авыллар турында кайгыртучанлык та тулысы белән шәһәр салучылар җаваплылыгына тапшырылырга тиеш. Үз янында хәзерге заманча корылган авыллары булган шәһәр генә бүгенге тормышка тиң рәвештә яши һәм хезмәт итә ала.

**Рәшит КАМАЕВ,**
философия фәннәре кандидаты.

## Нигъмәт Ихсанов

# СӨРГЕН БАТЫРЫ

Гаделбай Чалымов, мировой судья булып эшләүче кардәше Мирзатин сөргенгә җибәрер дип куркып тормады, үзенекен итте — ятимлектә, котү көтеп үткән яшьлеге өчен агасыннан үч алырга карар бирде. Агасының комсызлыгы аркасында вакытыннан элек гүргә кергән ата-аналары өчен дә үч аласы килә иде аның. Тик, кавырсыны катканчы, бу уен ул күңел түрендә генә йөртте.

Еллар үтә торды. Гаделбай әүвәлгечә хезмәтче крестьяннар белән бергә алпавыт утарында гомер итте, шулар белән бергә эшләде. Гаделбайның мужиклар белән бертигез... бергә эшкә җигелүе, алар арасында көн күрүе агасына ошап та бетми иде.

— Гадел, син бит алпавыт кардәше, ташла бил бөгүеңне.

— Бил бөгеп эшләү гомерне генә озынайта ул, абзый, сиңа да моны белеп тору зыян итмәс,— Гаделбайның әллә уйнап, әллә чынлап биргән бу җавабы агасының күңеленә хуш килмәде, ул арты белән үк борылды.

Измаил байның сәүдәсе һаман үсә, киңәя барды, губерна чикләреннән үтеп, Омскига, Тобольскига һәм Казанга ук барып җитте, сарык тиреләрен ул хәтта Новониколаевскига да илтеп сата иде.

Чалымовлар нәселеннән иң өлкәне булган Измаил мәдрәсәне атасы исән чакта ук тәмамлаган иде. Аннары учитель яллап ике ел сабак алганнан соң русчага өйрәнде һәм, шул гыйлеменә таянып, утар белән идарә итә башлады. Йорт хезмәтчеләре яллады, сарык көтүләрен ишәйтте, урман кисү эшенә алынды, вагрaк эшләрен алып барырга ярдәмчеләр булдырды.

Хәзер инде сәүдә эшләре аны йорт-җиреннән дә, Семипалатның үзеннән дә шактый озакка аерып-аерып тора иде. Имение белән идарә итүне улларыннан берсенә тапшырмый хәле юк иде аның. Бай бу эшне егермесен яңа тутырган төпчек улы Мортазага бирде. Чөнки аның доверенныйлар белән дә, хезмәтчеләргә карата да каты бәгырьлелеген белә иде. Измаил байның дилбегәне Гаделбайга да тапшырасы килде килүен: яше дә егерме бишнең теге ягында, акыл-фигыле дә әйбәт, тәскә-биткә дә аллага шөкер. Әмма Гаделбайның сау тәнендә уй-фикерләре дә бик туры иде шул, Измаил байны мәсьәләнең шул ягы шүрләтте.

Гаделбай сарык тиресе урынына бүре тиресе ябына алмый иде. Ул кешеләрне ярата, алар арасында гомер итеп, шулар белән берләттән эшләү аңа кулайрак иде.

Ә инде олы улы Мирзатинны ничек кенә булса да укытырга, белемле кеше итәргә карар бирделәр. Сәләте булмаса да егетне гимназия классларында йөрттеләр, аннан этеп-төртеп чыгарганнан соң да ул алпавыт утарында ара-тирә генә күренгәләде. Шәһәрдә, әби-туталары арасында булды, аңа укытучылар ялладылар. Әллә никадәр акча түгеп, аңа югары юридик белем бирделәр, Мирзатин мировой судья булды. Кыя-




фәте белән ул чандыр гына бер кеше иде. Маңгаенда һәрвакыт күзлек булыр: башта матурлык өчен генә кигән иде, аннары күзләре начарланды — күзлексез күрми башлады.

Тормышның законнарны белүе чамалы булса да, Измаил бай үзенең улларын, шул җөмләдән Гаделбайны да ара-тирә сынап карарга, хуҗалык алып бару, кешеләрне белү, яхшыны яманнан аера алу буенча сораулар бирергә ярата. Ул Гаделбайның арада үткен икәнен, укымышлылыгы зур булмаса да, тәпле фикер йөртә белүен чамалый иде. Тик Гаделбай, байга файда китерү ягын уйламый, бөтенләй башкача, җирдәге гаделлекне хезмәткә дөрес хак түләүне, йорт хезмәтчеләренең яшәү шартларын яхшыртуны телгә алып сөйли.

— Агымга каршы барасың, юләр! — Байның соңгы сүзе шул була.

Алар уртак тел таба алмыйча аерылалар. Мене шуңа күрә дә хуҗалыкны сай акыллы, тәҗрибәсез Мортазага тапшырырга туры килде. Ә ул берни белән дә исәпләшеп тормый. Крестьяннарның сырхавына да, хәтта үлүләренә дә исе китми. Яман хәбәрләр ишеткәндә:

— Алланың язганы шулдыр,— дип кенә җавап бирә.

Измаил байның дәүләте зур, берничә мең баш куе, бия көтүләре, үз кирәге өчен асрала торган сыерлары, әллә ничә йөз дисәтинә чәчү җире, печән болыннары, урман-аланнары бар иде. Куй, бия көтүләре Ишим буенда урман арасындагы болынлыкларда йөри. Мортаза авылларга бик кирәк чакта гына барып чыга: я сарыкларны вакытында кырыкмаган өчен, я печән чабуны сузган өчен, я сөттән майны аз алган өчен кешеләрне җәзалап кайта.

Мортаза Гаделбайга гына каршы сүз әйтүдән тыелып йөри. Әмма берсендә кул астындагы крестьяннарына, бигрәк тә Кыскаболактагы кешеләргә аеруча каты кылана ул. Хезмәтчеләр ачлыктан кырыла башлый.

Бу хәлләрне ишеткән Гаделбай агасы Измаилга хат язып сала: «Абзый, кайтып бу юлбасар Мортазаның арт сабагын укыт әле. Синең крестьяннарыңның ачка интегүе, кырылуы аңа көлке генә. Үзең беләсеңдер, хәзер бит заманы башка. Кара халык бөтен җирдә бунт күтәрә һәм крепостное правоның бетерелүен таләп итә. Һәм дөрес эшлиләр. Әгәр кайтмасаң, мин аңа җәзаны үзем бирермен...».

Бу чакта Измаил бай Казан тиречеләре белән элемтә булдырган икән. Сарык тиресе, каракүл, сабын кайнату чималы белән сәүдә итеп йөри. Казандагы Аппаков, Гыйззәтуллин кебек мәшһүр байлар белән алыш-биреш итеп, тәтәйләр белән типтереп, актрисалар белән бенефислар ясап йөреп, байтак гомере үтә. Ул хәтта Семипалатка кайткач та, Гаделбай белән очрашмый, хат язу белән генә чикләнә. Үз уенча, бик тәфсилләп язган хатында ул алпавытлар һәм сәүдәгәрләр доньясы какшамаслыгын, мәңгелек булуын бәян итә, егетне шуңа ышандырырга тырыша. Шунда ук «кара» халыкның буйсынуын, тез чүгеп торуын аның табигатеннән үк килүен телгә ала. Бәс шулай икән, бу форсаттан файдаланырга да кирәк. Хат болай дип тәмамлана: «...Син барысын да киресенчә эшләмәкче буласың. Ходайдан курык, Мортазаны тыңла! Ул бит синең дошманың түгел, туган тиешле кешең».

Гаделбай хатны укыгач рәхәтләнеп көлде. Аннары кинәт тынып калды, йодрыкларын йомарлап: «Мортаза — миңа туган түгел, ул минем дошманым, канечкеч ул»,— дип ике арадагы мөнәсәбәтләрнең тәмам өзелүен белдерде.

Кымыз, бәйге чоры җитте. Элекке елларны башка кешеләр кебек Гаделбай да моңа алдан әзерләнеп куя, бәйрәмдә көрәшкә чыга, җиңүче булып, бүләккә тәкә алгач, аны шунда ук чалып, пешерергә куша, һәммә кешене сыйлый торган иде. Быел исә Гаделбай бәйрәмдә дә ачылып китмәде, йомылып йөри бирде. Эшенең дә җае китте. Кичләрен, инеш буена уенга чыгасы урында, башын куллары өстенә куеп, түшәмгә карап, уйга чумып ята иде.

Бу хәлгә аптырашкан кешеләр арасында болай дип сөйләнделәр:

— Гаделбай агасыннан яман хат алган икән. Мортаза белән бикләнеп талашканнар ди. Гаделбай Мортазага «Буып үтерәм мин сине, зобаный!»— дип кычкырган.

— Тәүфыйклы олан бит ул Гаделбай, эш ярата торган гадел кеше, ник кенә алай итә икән?!

Суыкболакта Гаделбай турында төрле сүзләр йөри бирде. Яше утызга җитә, көче ташып тора, диләр. Чуен герләрне туп кебек кенә чөя, кызлар белән генә күңел ачып йөргәне юк...

Уңыш исә мул булды. Мортаза старосталардан, игеннәрне тизрәк сугып бетерергә, амбарга салырга дип, таләп итеп кенә торды. Мортазаны атасы ашыктыра иде. Ашлыкны Павлодарга, Омскига, Тобольскига озатып калырга кирәк...

Атлы ике кеше килеп кергәндә, Суыкболакта чиләкләп яңгыр коя иде. Бу икәү Котлыболактагы доверенный белән хезмәтче булып чыкты.

Доверенный, чыланган битен сөртеп, сүз башлады:

— Гаделбай Сәлимович, бу Мортазаның кыланышларына түзәр хәлебез калмады...

— Ни булды?

— Ашлыкны бөртегенә кадәр Ишимга алып киттеләр, тегермән тартмый, он юк. Ашарга бирми.

— Амбарда ашлык бөтенләй калмадымыни?

— Орлыкка дигәне бар да...

— Тагын нәрсә? Ник яшерәсең?

— Серне чишсәк, Гаделбай, безне ат урынына кыйнатачаклар.

— Сезне түгел, мине кыйнарлар. Әйтегез!

— Мортаза Измаил байдан яшереп бер амбар ашлык калдырды. Анысына амбар язуы язмаска, тоз заводына җибәрергә кушты. Мин шуны Ишимга озатыр өчен атлар әзерлим.

Доверенныйның сүзләрен ат караучы раслады:

— Ярый, кайтыгыз, мин карармын. Ашлыкны беркая да озатмый торыгыз. Минем янга килүегез турында ләм-мим,— диде Гаделбай.

Берничә көн үтте. Доверенный инде иртәгесен ашлыкны төяп озатырга керешмәкче иде, төнлә ут чыгып, икмәк янды.

Урядник килде. Янгын булган җирне караганда ул гәрәбәдән ясалган мөштек тапты, аннары туфракта калган итек эзен үлчәп алды һәм китеп барды.

Ут салучы Гаделбай икәненә шикләнмәделәр, Мортаза да мөштекнең Гаделбайныкы икәнен раслады.

Гаделбай үзе дә кире кагып тормады. Тик ул шунысын да әйтте:

— Мортаза урлаган бу ашлык бөтен гаиләнеке, шунлыктан хәл эчендә тикшерелергә тиеш.

Измаил бай эшне судта тикшертмәкче иде дә, Мортазаның намуссызлыгы аны да тыелып калырга мәҗбүр итте. Ул:

— Ахирәттә алла җәзалар, ә монда үзегез хәл итегез,— диде.

Олы улы Мирзатин аңлатып бирде:

— Юриспруденция күзлегеннән караганда, бу — бик авыр җинаять, моның өчен каторгага, таш кисәргә җибәрү тиеш. Ләкин бик кайнар табигатьле булуын, юкка да чыгырдан чыгарга торуын исәпкә алып...

Гаделбай аны ачу белән бүлде:

— Мине акылдан язган дип әйтергә теләмисең димәк?

— Алай ук түгел. Тик синең, бу — политика, дип, авыз суы корытуың юньлелеккә китермәс...

— Мин әле яшь, көчем җитәрлек. Әле башым исән чакта гаделсезлеккә каршы көрәшүдән туктамам!— дип ярып салды Гаделбай һәм өйдән чыгып китте.

1872 елның сентябрендә кардәше Мирзатин егерме сигез яшьлек, әле өйләнмәгән Гаделбай Сәлимов Чалымовны җиде елга сөргенгә җибәрергә хөкем итте. Якутия губернасына барышлый, юлда качуыннан куркып, Гаделбайның аягына богау салырга диделәр.

Гаделбай ябылган Семипалат төрмәсе җинаятьчеләр һәм политик гаепләнүчеләр белән шыплап тутырылган иде. Тик Гаделбай монда озак ятмады, аны, этапка кертеп, Барнаул ягына озаттылар.

Барнаулга якынлашкан саен, күе чикләвек әрәмәләре ешайганнан-ешая бара. Урыны-урыны белән матур кара кучкыллы ылыслы урманнар аша үтәсең, аларны тау үзәннәре алыштыра...

Барнаул — һәм аның әйләнә-тирәләре дә — колонналар, фасадлар белән зурдан кубып төзелгән. Бу якларда алтын, көмеш, кургашын чыгаралар. Рудниклар исә, күбесенчә — император галиҗәнапларының шәхси милке.

Боларны ишеткәч, Гаделбайның каны тагын да кыза төште. Үзенең абыйсына да, этап йортларындагы кешелексез мөнәсәбәтләргә карата да ачуы кабара барды. Этапны озатучы офицер да бик рәхимсез иде. Ул нормадагы утыз урынына көненә кырык бишәр чакрымга, кайчак аннан да ераккарак куа. Юк кына гаеп өчен дә тоткыннарны теләсә күпме кыйный. Ни өчен җәзалавын да аңлатып тормый. Ни теләсә, шуны эшли, — власть тулысынча үз кулында.

богауларын шалтыр-шолтыр китереп үр менеп киләләр иде. Шул чакта каршыга искәрмәстән ике көпчәкле арбага җигелгән ат килеп чыкты. Ул кушаяклап чаба, туп-туры кешеләр өстенә килә. Кучерның төсе киткән, сүзен әйтер хәле юк. Сөргенгә баручылар арасында да ыгы-зыгы купты, алардан тик кем дә булса берәр нәрсә эшләрлек хәлдә түгел иде. Моны күреп, офицер ярсыган атын тыя төшеп, бар тавышына кычкырды: «Кузгаласы булмагыз! Конвой, стройга якынрак кил». Тоткыннар бергә өелде. Дулаган ат ул арада төркем янына ук килеп җитте. Ә алда упкын, өгәр мәтәлсәң, сөягең дә калмый. Арбада берәүнең илереп кычкырганы ишетелә иде: «Алла хакына ярдәм итегез! Сабый хакына!».

Шул минутта Гаделбай, куркуын онытып, офицер Строговның янәвына карамыйча, чылбырларын шалтыратып, арба ягына атылды, дилбегәгә асылынды. Строговның кычкыруына карамастан, аның артыннан бөтен этап ябырылды. Таныш булмаган кучерны гына түгел, сөргенгә бергә баручы иптәшне дә коткарырга кирәк иде. Строгов, атының тезгенен кысып, тыныч кына карап тора, сакчылар исә, мылтыкларын кысып тоткан килеш, ни эшләргә дә белми иде...

Гаделбайның тимердәй куллары атны кырт күтәрелгән тау ягына каерды. Ат гөрселдәп җиргә ауды. Коточкыч киеренкелек шатлык белән алмашынды. Бөтенесе Гаделбайны мактарга керештеләр. Карт кучер куанычыннан ни эшләргә белми, елыйелый рәхмәт укый, әле Гаделбайны, әле арбадагы онычын кочып үбә. Бала аягын авырттырган да, шуны шифаханәгә алып барулары икән. Аннары ул иске чикмәне эченнән каешланып беткән янчыгын чыгарып, Гаделбайга сузды. Анда барлы-юклы өч сум акча икән. Гаделбай, әлбәттә, аны алмады, үзенең дә шатлануын белдереп, кулын күкрәгенә куйды, башын иде.

Шунда халык төркеме янына Строгов чаптырып килеп җитте һәм Гаделбайга камчы белән уңлап-суллап сыдыра башлады: «Менә сиңа, менә сиңа хәзергә, калганы туктагач булыр!». Кич җитте. Төньяк җиле күкне кургашындай авыр кара болытлар белән каплады. Инде яңгыр да сибәли. Кечерәк кенә бер авылга җиткәнче манма су булдылар. Сөргенгә баручыларны авыл читендәге бер ташландык йортка тутырдылар.

Бөтенесе үз эше белән мәшгуль: кем утын яра, кайсы мич яга, хатын-кызлар табак-савыт шалтырата, киемнәр киптерә, ашарга әзерләп азаплана. Бер-берсенә авыз ачып сүз әйтүче дә юк, сагаюлы тынлык хөкем сөрә. Строгов исә вәгъдәсен онытмады, берничә коралны кеше ияртеп килеп тә җитте. Стражниклар Гаделбайны өйдән төрткәләп чыгардылар да лапас астына алып кереп киттеләр. Иске агач караватка йөзтүбән сузып салдылар, тычкан уты кебек кенә фонарь яктысында камчылый да башладылар.

Строгов китүгә, Гаделбайны өйгә алып керделәр, анда ул әкренләп аңына килде. Җәрәхәтле аркасын бәйләделәр. Шәмсиямал исемле бер кыз аны аеруча ихластан тәрбияләде. Шәмсиямалның күзе Гаделбайга күптән инде төшкән иде. Сүз кушарга җае гына чыкмый килде. Егетнең бу кыюлыгы, кешеләргә ярдәмгә һәрвакыт әзер торуы кызны тәмам сокландырды. Гаделбай кыйнап ташлангач, Шәмсиямал Строговның янавыннан да куркып тормады, авыруны карый-тәрбияли бирде. Соңрак алар өйләнештеләр.

Сөрелеп килгән кешегә Якутскида да эш табу җиңел түгел икән: кая барсаң да, мыскыллап карыйлар. Гаделбайны, күп тикшеренеп тормыйча, эшкә алган бердәнбер урын купец Кушнарев артеле булды. Бер генә кисәтү әйттеләр:

— Бил бөгеп тапканың үзеңнеке булыр, хәйләләсәң, куарбыз да чыгарырбыз.

Гаделбай белән Шәмсиямалга баракта бер почмак бүлеп биргәннәр иде, аннары яшьләр үз көчләре белән бәләкәйрәк кенә бер өй өлгертеп керделәр. Бербер артлы тәгәрәп балалар туа торды, сөрген еллары сизелми дә үтеп китте. Гаделбай инде туган иленә кайту турында уйлап та карамады: «Андагы алпавытлар да кеше хезмәте белән көн күрә. Шулай булгач, нигә анда кайтып азапланырга?! Юлга акча туздырып йөрергә генә туры киләчәк...

Язларын Себердә дә сабан туе үткәрәләр икән. Шунда көрәштә катнашып, Гаделбай бер танылган көрәшчене егып салды һәм бүләккә яше тулган тана алды. Шуны үстереп, сыерлы булдылар. Тагын бераздан, сөт саткалап, урман эшендә эшләп, ат сатып алдылар. Авыр хезмәт билне шактый бөксә дә, рухы нык иде әле аның. Шәмсиямал фәкыйрьлектән баш чыкмауга зарланып утырган бер кичне Гаделбай:

— Ленин дигән бер кеше җитәкчелегендә бөтен Рәсәй халкы патшага каршы күтәрелә икән, революция әзерлиләр икән,— дип сөйли.— Тиздән байларның кикриге шиңәр, дигән сүз бу.

— Каян белдең аны?

— Кешегә ычкындыра күрмә. Кичә безне, сөргендәгеләрне, большевик Ярославский җыйган иде. Шунда үзебезнең Габидулла Бәшировны да күрдем. Беләсеңме, нәрсә ди: «Кирәк булса, байларны куарга ярдәм итәрсез, сез бит сөрелгән кешеләр»,— ди.

1918 елның август кичендә алар хатыны белән икәү өйдә шулай сөйләшеп утыралар иде. Балалар идәнгә тезелешеп йокларга яткан. Ир белән хатын, үткәннәрне искә төшереп, алданиләр күрәселәрен күз алдына анык китерә алмыйча пышылдашалар. Ул көннәрдән соң вакыйгалар озак көттермәде, Якутиядә дә Совет власте урнашты.

Тик бераздан бирәдәге хәлләр гаять катлаулана. Контрреволюцион элементлар, кулаклар һәм акгвардиячеләр ярдәмендә фетнәчел төркемнәр оештырып, Якутскига һөҗүм әзерлиләр. Шәһәргә юл тоткан ак отрядларга отпор бирү өчен сөргендәгеләрнең ярдәме кирәк була.

РКП(б)ның губерна бюросы Якутскида мөселман дружинасы оештырырга карар итте. Дружина составына ирле-хатынлы Чалымовлар да керде. Шәмсиямал бик оста элемтәче иде. Ул гади бер хатын булып иң җаваплы, бик хәтәр разведкаларга йөрде. Гаделбай үзе исә Якутск тирәсендәге коралны бәрелешләрдә катнашты, Владимировка өчен бәрелештә аеруча батырлык күрсәтте.

Шәмсиямал бу юлы яңа бер банданың Владимировкадан Якутскига һөҗүм итәргә җыенуын хәбәр итте. Моны ишеткәч, дружина командиры Әхмәдулла Тәхфәтуллинга шул бандаңы Владимировка аша үткәрмәскә приказ бирелде.

Тәхфәтуллин Владимировкадагы сәүдәгәр Юшков өенә урнашты һәм дошман юлына баррикадалар ясады. Читтәге өйләргә мылтыклы дозорлар куелды.

Чалымов:

— Әхмәдулла абый, әйдә ялган засадалар да ясыйбыз,— дип, яңа тәкъдим кертте.

Тәкъдим кабул ителә. Җирле халык ярдәме белән төрле төштә баррикада сыман өемнәр эшләнә. Чалымов отделениесенең тугыз кешесе бөтен поселокны гүя кызыллар белән тулы итеп күрсәтергә тиеш иде. Бандитлар шул тозакка эләкте һәм ясалма баррикадаларга ата башладылар. Владимировканы төнге сәгать уннарда алырга җыенуларын белеп, Тәхфәтуллин Ларионов дигән кешене Артемьев бандасына каршы җибәрде. Коралсыз-нисез Ларионов туганнары белән күрешергә баручы кеше булып кылана.

Бандитлар отряды Ларионовка тау итәгендә очрый. Шунда алдан барган дозор авазы:

— Тукта! Кем? Каян киләсең?

— Владимировканыкы,— ди Ларионов.

Артемьев каршына китереп бастыргач, сораша башлыйлар.

— Владимировкада кызыллар юк, дип, ялганламыйсыңмы?

— Валлаһи менә! Анда бары да тыныч. Мин бит шунда яшим. Менә Табагага туганнар янына барышым.

— Кара аны, әгәр алдашсаң, башыңны борып үз кулым белән өзәрмен. Җибәрегез, китә бирсен,— ди банда башлыгы.

Тынычланып калган Артемьев разведкасыз-нисез генә алга ашыкты.

Тәхфәтуллин, бандитлар төркемен поселок капкасына якын ук үткәрде дә пулеметчыга команда бирде:

— Сиптер әйдә!

Ай яктысында Чалымовның да пулемет көпшәсен уңга-сулга боргалавы күренә иде. Берничә бандит кырткә сәрлекте, калганнары, поселокны тылдан алырга исәп тотып, икенче читтәге өйләргә таба ыргылдылар. Чаптырып кермәкчеләр иде дә, пулеметын кирәкле якка күчерергә өлгергән Чалымов дошманга тагын ата башлады... Банда ягыннан исә: «Юлга таба борыл! Чигенергә, качарга кирәк!»— дигән тавышлар килде.

...Гаделбай Чалымов ул чакта әле Якутиядәге татар дружинасына кергәнче үк, сәүдәгәр Кушнаревтан китеп, Якутиянең легендар полководецы Строд Иван Яковлевич отрядына язылды. Шул походларда, Амга һәм Тата өчен барган сугышларда аягы яраланып, ул отрядтан аерылып кала.

Сугыштан соңгы елларда Чалымов йөкчеләр бригадиры була. Алданда бер-бер артлы ачылган алтын прискаларына кирәкле йөкләр ташый. Ләкин юл йөргәндә әле тәзәлеп тә бетмәгән яралары ачыла да аны аяктан ега һәм аннары инде савыга алмый...

Бөтен гомерен хезмәт халкының бәхете өчен көрәшеп үткәргән большевикның шаулы тормышы әнә шулай уза. Аның кабере Якутскидагы зиратта, патша самодержавиесе чорында «рәшеткәсез төрмә» дип йөртелгән шушы якка сөрелеп килгән башка иптәшләренеке белән янәшә (Истәлек тактасында астан дүртенче исем). Якут дусларыбыз республикасының бүген һаман батыраеп һәм матураеп чәчәк атуында аның да өлеше бар.

# ҖЫРЧЫ ШАГЫЙРЬ

*Әхмәт Ерикәйнең тууына 80 ел*

Әхмәт Ерикәй исемен әйткәч, иң әүвәл «җырчы шагыйрь» дигән сүз искә төшә. Чөнки халкыбыз арасында киң таралган бик күп көй-моңнарны Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключарев, Нәҗип Җиһанова, Рөстәм Яхин кебек мәшһүр композиторларыбыз шагыйрь Әхмәт Ерикәй сүзләренә иҗат иткән. Алар көн саен диярлек радио, телевидение тапшыруларында яңгырый, профессиональ һәм һәвәскәр осталар чыгышларында башкарыла.

Ә. Ерикәйнең йөзләгән җырлары арасында Ленин, Ватан, Туган җир турындагылары аерым урын алып тора. Әйтик, «Дуслык турындагы җыр»дагы (С. Сәйдәшев музыкасы) сүзләр күпкә-озакка күңелгә сеңеп кала:

**Үстергән дә безне — чын дуслык,**
**Көч биргән дә безгә — чын дуслык.**
**Дуслык булса, яшәр гомергә**
**Бөтен җир шарында тынычлык.**

Аның җырларының дуслыкка, мәхәббәткә, яшьлеккә багышланганнары шундый ук якты тойгы белән өретелгән.

Ә. Ерикәй шигырьләренең тагын кызыклы бер үзенчәлегенә игътибар итик. Музыкаль әсәрләр ни өчен нәкъ менә шушы автор сүзләренә күбрәк язылган? Югыйсә безнең элек-электән чын шагыйрьләргә бай җиребездә бүтән әйбәт шигырьләр дә аз түгел бит. Әллә чорыбызга яки данлы хезмәт батырларына тиң бик әйбәт шигырьләр җыр өчен артык катлаулылармы? Халык күңелен тулаем биләп ала алмыйлармы? Дөрес, бездә яңа җырлар туа тора. Аларның кешеләр тормышында, эшендә, яңа бәхетләр яулау көрәшендә шактый гына хезмәт итәрдәйләре дә, камиллеккә ирешкәннәре дә байтак һәм кыска гомерлеләре, төссезләре дә бар. Ә. Ерикәй иҗатында үзенчәлек, нигездә, шигырьдәге эчке музыкальлектән, ритмика төзелешеннән гыйбарәт булса кирәк. Шигъри төзелеш, музыкага ятыш булсын өчен, күп вакытта һәр строфада бердәй кабатланып дәвам итә. Шигырь төзелешендә кечкенә генә хилафлык та җөмләдәге сүзләр янсә иҗекләр басымын бозарга мөмкин. Әйе, җыр булачак шигырь юлларының офыклары киңрәк, мәгънәсе саллырак, аларга таләп тагын да зуррак ул. Ә. Ерикәйнең әнә шундый музыкаль тоемы, иң популяр җырлары, романсларындагы халыкчан тел, фикри гадилек күп санлы җыр сөючеләрне җәлеп итте. Шагыйрьнең танылган җырчыларыбыз яратып башкарган шигъри юлларыннан тагын берничәсенә игътибар итик:

**Көн аяз, килә яз чәчәккә күмелеп,**
**Син дә кил, Сәрвиназ, шатлыклы көн кебек.**
**(Халык көе.)**

**Тормыш авырлыгын күрде**
**Яшь-яшь кенә булса да,**
**Күрше кызы, ярлы кызы**
**Комсомолка Гөлсара.**
**(Җәүдәт Фәйзи музыкасы.)**

Темалары буенча бер-берсеннән шактый аерылып торсалар да, аларда берүк дәрәҗәдә матур һәм моңлы музыкаль аваз ишетәсең. Һәм нәкъ менә шул көйләреннән аерылгысыз рәвештә Ерикәй шигырьләре күңелдә ачык яңгыраш табалар.

Ә. Ерикәйдән моңа охшаш җылы, лирик юлларны күпләп табып булыр иде. Аларда оригиналь рифмалар да, «шаккаттыризм» да юк, ләкин табигый күңел җылылыгы бар, әнә шул җылылыктан синең дә күңелең актырып киткәндәй була.

...Шагыйрь Башкортстанның Дуван районы Өлкәндә авылында ярлы гаиләдә туган. Бөек Октябрь революциясе давылы шаулап узганнан соң, нәни ялчы, көтүче булып йөргән Әхмәткә дә тормыш җиңелдә. 1927 елда ул Мәскәү журналистлар институтында укый башлый һәм бераздан күп кенә поэмалар авторы, танылган шагыйрь, журналист булып җитлегә. Сугыш елларында фронт газеталарының берсендә бераз эшли — шигырьләр иҗат итү белән бергә батыр сугышчыларыбыз турында мәкаләләр, әдәби очерклар яза. Сугыштан соң (1945—1950 елларда) Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе булып эшли. Әдәбиятта күрсәткән хезмәтләре өчен хөкүмәтебезнең беренче бүләгенә лаек була.

«Ул җырларында халык иҗатыннан файдаланырга ярата. Халыкчан чагыштырулар, шигъри бизәкләр, тапкыр мәкальләр шагыйрьнең иҗатын баетуга ярдәм итәләр»,— дип яза күренекле шагыйрь Нури Арсланов Ә. Ерикәйнең 60 нчы елларда басылып чыккан «Сайланма әсәрләр»енә кереш сүздә. Аның халыкчан шигырьләренә әле бүген дә яңадан-яңа җырлар языла һәм аларны күп җырчылар, коллективлар башкара.

**ФӘННУР САФИН.**

# ЯШЬЛЕК ХЫЯЛЛАРЫН ҖИЛКӘН ИТЕП

*Мостафа Ногманның тууына 70 ел*

Шагыйрь Мостафа Ногманның күп кенә җырлары бик бәхетле язмышка очрады. Моның хикмәте нәрсәдәдер — кистереп кенә әйтеп булмый. Заман һәм көн таләп иткән теманы укучы теләгәнчә бирә алудамы, әллә шул уңышлы текстка композиторның таланты да килеп кушылу шигырьнең язмышын хәл итәме — моны әйтүе кыен. Әмма бер нәрсә бәхәссез: Мостафаның «Яшьлек хыяллары», «Татбригада сугышчылары җыры», «Каеннар шаулый», «Актаныш таңнары», «Оныта алмыйм», «Әниләр», «Таулар биек», «Салагыш болыннары», «Ак җилкән» кебек җырлары концерт залларында, радио-телевидениедә һәркөнне диярлек яңгырап торалар.

Шагыйрьнең кайбер җырлары сәхнәгә, эфирга кинәт килеп керәләр дә, ике-өч тапкыр башкарылуга ук популяр әсәрләрдән исәпләнә башлыйлар. Шагыйрьнең «Яшьлек хыяллары», «Каеннар шаулый» кебек җырлары беренче башкарылганда ук тыңлаучының күңелен җәлеп иттеләр. Кыскасы, җыр патшалык иткән теләсә кайсы залда Мостафа Ногман әсәре яңгырамый калмады һәм әле дә ишетелми калмый.

Мәктәп балалары арасында киң билгеле аның әсәрләре. Арадан иң зурысы һәм әһәмиятлесе — Ульяновларның Казан чорына багышланган «Кокушкино таңнары» дигән поэмасы. Аңарда яшь Володя Ульяновның Кокушкино авылы малайлары белән дуслыгы. Ульяновлар гаиләсенең Идел буе халыкларына ихтирам белән тигез караулары гади, ләкин күңелдә калырлык шигъри юлларда сурәтләнгән. Татар малае Хәйдәр белән гимназист Володяның дуслыгы самими һәм сокландыргыч.

Гимназия укучысы Володя ярлы татар малае Хәйдәрнең күңеленә өмет яктылыгы сибә: «Син борчылма, безнең әти килсен әле, ду китерер өяздәге түрәләрне — Я, җәмәгать! Янчыкларны ачыйк бераз. Мәктәп кирәк балаларга, якты класс! Әлифбадән кирәк, дияр, эш башларга, сездән үрнәк алсын, дияр, башкалар да!»

Һәм тагын шундый раслау:
Әти безнең бөтен Сембер өязендә

**Авылларны йөреп чыкты бер-бер артлы.**
**Ерак-ерак салаларда чувашларга,**
**Мордваларга күпме яңа мәктәп ачты!**

Володяның әтисе Илья Николаевич — рус, татар, чуваш, мордваларның якын дусты — алар арасына мәгърифәт нуры таратучы киң күңелле акыл иясе итеп шулай тасвирлана.

Кокушкино крестьяннарының ачы язмышы белән танышу Володяда царизмга нәфрәт тойгылары уятучы әһәмиятле фактор була. «Гаделсезлек тудыручы — димәк, патша. Фәкыйрьләргә җәбер салган патша үзе!..» Володяның кискенләшә бара йөзе.

Ленин, революция, гражданнар сугышы — шагыйрьнең иң яратып иҗат иткән темалары ул. Халкыбызның батыр уллары, аларның язмышы белән бик нык кызыксына. Батырлар турындагы тарих, матбугат битләрендәге һәр яңа хәбәрне балаларча шатланып каршылый, дулкынлана. Тарихчылар Пугачев армиясендә хезмәт иткән полковник Бәхтияр Канкаев турында яңа документлар таптылар — М. Ногман моны зур тәэсирләнү белән кабул итте, ниһаять, «Бәхтияр батыр» дигән җыр туды. «Пионерская правда» газетасы (ул үзе дә бервакыт аның Казандагы үз хәбәрчесе булып эшләде) Советлар Союзы Герое Шәрифҗан Казанбаевның батырлыгы турында язып чыкты — Мостафа Ногман геройның туган ягы Сараш авылына барып кайтмыйча үзенә тынгылык тапмады. Аннан Мәскәүгә, Үзәк хәрби музейга... Аннан Шәрифҗанның каберенә — Молдавиягә. «Үлмәс чәчәк легендасы» әнә шулай туды. 1965 елда илебез Бөек Ватан сугышында җиңүебезнең 20 еллыгын билгеләргә әзерлек башлагач, шагыйрь тагын тынычлыгын җуйды — тышкы дөньядан аерылган кебек булды, очрашканда-сөйләшкәндә һәрвакыт Ватан сугышында катнашкан, шунда ятып калган исемсез геройлар турында сөйләде — еш кына аның күзләрендә яшь бөртекләре ялтырап ала иде. Бөек юбилей көне килеп җиткәч, шул исемсез геройларга буыннар сәламен, ихтирамын сөйләгән җыр яңгырады:

**Югалтулар алып килде сугыш,**
**Күпме дуслар кайтмый калдылар.**
**Шул дусларның йокыларын саклап,**
**Ак каеннар моңсу шаулыйлар.**

Бөек Ватан сугышы темасы — шагыйрь өчен ахырынача изге тема булып калды.

1980 елда чыккан «Җырлыйк әле» дигән китапка М. Ногманның егерме бишләп җыр тексты кергән. Димәк, аның иҗаты сиксәненче елларда да күкрәк киереп яши. Радио һәм телепрограммаларда, сәхнәләрдә яши. Аның җырлары Казанда, республика авылларында, Мәскәүдә, Ташкентта, Каракалпакстанда да яши, кешеләр рухын баетып яңгырый.

М. Ногманның композиторлар белән эшләве үзенчәлекле иде. Сара апа Садыйкова белән алар заманында адреслы берничә багышлау-җыр иҗат иттеләр. Бу җырлар кайбер шәһәр, авылларның үз әсәрләренә, үз байлыкларына әйләнеп кенә калмадылар («Балкый Шәйморза утлары», «Туган авылыма», «Бер гүзәлен сагынам Чишмәнең»), — болар туган як темасын музыка сәнгатендә яңгыратучы гомумхалык әсәрләре булып киттеләр.

М. Ногманның җыр иҗаты зур зәвыклы композитор Рөстәм Яхин белән хезмәттәшлектә аеруча тулы ачылды. Бу хезмәттәшлекнең төп юнәлешләреннән Лениниана («Ул Казанда яшәгән»), хәрби-патриотик тема («Әлмәт егете — ил бөркете»), «Татбригада сугышчылары җыры», «Каеннар шаулый», «Акчарлаклар оча Иделдә» һ. б.), яшьлек-мәхәббәт хисләренә, туган туфракка мәдхия («Киек казлар китә», «Оныта алмыйм», «Идел ярларына басып торам», «Бөдрә таллар», «Күзләрем тик сине эзлиләр», «Гел синең хакта» — барысы да Рөстәм Яхин белән!) — бүгенге җыр сәнгатебезнең тутыкмас, күгәрмәс энҗе якутлары булып торалар.

Мостафа Ногманның «Яшьлек хыяллары» дигән җырында мондый юллар бар:

Тик бер генә нәрсә бели мине,
Тик бер генә теләк күңелемдә
Йөрәккә дәрт тулып,
Илемә лаек булып
Яши алсам иде гомеремдә.

Шагыйрь үз шигырьләрендәге әнә шул хыялына тугрылыклы буларак үсте, иҗат итте... һәм ул безнең күңелләрдә әнә шундый иҗатчы буларак яши дә.

**М. СӨНГАТОВ.**

# ЙӨРӘКТӘГЕ ЭЗЛӘР

*Газиз Мөхәммәтшинның тууына 50 ел*

Газиз Мөхәммәтшинның җитди әдип икәнлеге әллә кайдан күренеп тора иде. Йөзе-бите, өсте-башы, кешеләр арасында үзен тотышы — хәтта сөйләшүләре, елмаюларына кадәр «менә нинди булырга тиеш безнең агай-эне» дип белдерә иде кебек.

Арабыздан ул бик иртә китте. Хәлбуки әдәбиятыбыз күгендә үз йолдызын кабызып китте. Газиз Мөхәммәтшин безнең укучылар өчен бик күп әсәрләр язып калдырды. Аның «Без әле җирдә яшибез» китабы тәрбияви әһәмияте ягыннан гына түгел, җылылыгы, яктылыгы, йөрәк кылларын тибрәндерерлек шигърилеге белән дә күңелгә якын.

Аның шактый оста язылган «Йөрәктәге эзләр» романы — беренче саф мәхәббәт турында, яшьлек турында, беренче аерылу газабы, беренче сагыну хисләре турындагы әсәр. Әмма бу кадәресе романны язарга этәргеч мотивлар гына бит әле. Әсәрнең мәгънәсе исә эчтәрәк, тирәндәрәк: кешенең җирдәге бурычлары, олы мәнфәгать һәм мещанлык мәнфәгатенең мәгънәсе турында, шул олы мәнфәгатькә мещанлык күләгәсе төшкәч, яшьлекнең картаюы, мәхәббәт гөленең сулуы турында ул әсәр. Картиналар тәэсирле, эпизодлар җанлы, характерлар истә калырлык. Роман тормышны тирәнтен өйрәнеп, материалны кичереп, йөрәктән үткәреп язылган. Шуңа күрә бүтән йөрәкләргә барып җитә дә инде ул.

Әдип пьесалар да язды. Ләкин аның төп стихиясе, Газизне язучы Мөхәммәтшин иткән жанры хикәя иде. Моңсу хикәяләр, нурлы хикәяләр, уйландыра тирән фәлсәфи хикәяләр һәм... һәм көлке хикәяләр. Безнең прозада Мирсәй Әмир юморы бар. Аңардан соң проза юморында иң актив һәм нәтиҗәле эшләгән язучы, әлбәттә, Газиз Мөхәммәтшин булды. Ул юмордан шаркылдап көлмисең, фәкать елмаясың гына. Бертуктаусыз елмаясың һәм эчеңнән генә, кайдан килгән үзеңә дә аңлышылып бетмәгән ниндидер гаҗәеп җылы тойгылардан сөенәсең, сафланасың. «Ике әби бәрәңге ала» әсәрендәге әбиләр сөйләшүеннән дә, «Вәт минем кияүләр»дәге эчкерсез картның кияүләрен үтереп мактавыннан да, «Зәңгәр күлмәк» хикәясендәге самими әңгәмәләрдән дә күңелләргә әнә шундый сөенечле хис иңә.

«Ике әби бәрәңге ала» хикәясе хакында сүз чыккач, Газиз Мөхәммәтшинның елмая-елмая сөйләве исемдә: «Дәресен әйтергә кирәк, егетләр, өстәл артына утырып язмадым мин аны. Авылга кайткач, киртә буена чыгып яттым да, бәрәңге бакчасында әбиләр сөйләшкәнне тыңладым. Әнә шул әбиләр әңгәмәсен генә күчереп алдым кәгазьгә. Билләһи менә, өстәсәм, үземнән биш-алты сүз өстәгәнмендер...»

Бәлки, чынлап та, шулай булгандыр, бәлки, түгелдер. Әмма шунысы хак — гаять тормышчан, һәм халыкчан Газиз Мөхәммәтшинның хикәяләре. Бу жанрда ул Г. Ибраһимов, Ш. Камал, К. Нәҗми, Ә. Еники, И. Гази, М. Әмир традицияләрен дәвам итте һәм бу традицияләрне яңартуга, баетуга да күп өлеш кертте. Хикәянең сюжет-композициясенә, ритмикасына, теленә зыян китермичә, фикерен кыска, җыйнак итеп, чын сәнгатьчә итеп әйтеп бирү сәләтенә ия иде язучы.

Моннан дистә еллар элек Гали Хуҗиев редакциясендә чыгарылган «Идел» альманахы битләрендә язучының «Автобус кичегеп килә» дигән хикәясе басылган иде. Автобустагы кешеләрнең характерларын тулысынча ачып бетереп, берсеннән-берсе кызыклы типлар, үзенчәлекле образлар иҗат итеп, бик тә кызыклы, яңа конфликтка корган иде автор кыска гына хикәясен. Соңрак бу алымны, мондый сюжетны мин рус һәм башка милләт язучыларының әсәрләрендә, кинофильмнарда очраткаладым. Ләкин ул әсәрләрнең һәммәсе дә миңа ни өчендер Газиз Мөхәмматшин хикәясенә иярәп иҗат ителгәндер сыман тоела иде.

Әйбәт хикәя — үзе бер вакыйга. Ул әйбәт роман-повестьлар кебек үк күңелдә озак яши, синең сердәшең, дустың булып китә. Ә. Еникиның «Әйтелмәгән васыять»е, А. Гыйләҗевнең «Үги ана яфраклары», Г. Газинең «Тургай картая микән?»е һәм, ниһаять, шулар арасында Г. Мөхәмматшинның «Дулкыннар» дигән хикәясе... Болар — хикәя жанрының бөтен таләпләренә туры китереп иҗат ителгән, әйбәт поэма, чын шигырь кебек җырлап торган әсәрләр.

Тирән белемле, эрудицияле язучы Газиз Мөхәмматшин «коеп куйган әдип» кенә түгел иде. Минзәлә якларында туып үскән егет, Минзәлә педагогия училищесын һәм Казан педагогия институтын тәмамлаганнан соң, Себер якларында укытучы булып эшләде. Татарстанга кайткач, «Чаян» журналында әдәби хезмәткәр, «Ялкын» һәм «Казан утлары» журналында баш редактор булды. Әмма, иң куанычлысы шул: Газиз Мөхәмматшин чын язучы иде. Ул беркайчан да, бер әсәрендә дә купшы бизәкләргә, ясалма кичерешләргә, көчәнеп, әмәлләнгән эпизодларга, җансыз характерларга урын бирмәде. Аның язганнары барысы да чын, ихлас, тормышчан булды. Газиз Мөхәмматшин безгә бигрәк тә әнә шул сыйфатлары белән кадерле.

**ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН**

# ОСТАЗ

*Кәшифә Тумашеваның тууына 80 ел*

Татар хатын-кызларыннан югары белем алган беренче режиссер, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Кәшифә Тумашева 1903 елның 7 гыйнварында Татарстанның Балтач районы Нөнәгәр авылында туа. Кәшифәне әле сабый чагында ук әтисенең якын туганнары Себергә, Өркет шәһәренә тәрбиягә алып китәләр. 1910 елда рус мәктәбенә укырга йөреп, рус теле һәм арифметика өйрәнә. Аннан соң җәдиди кызлар мәдрәсәсендә укый. Мөгаллимә булырга хыялланган яшь кыз һаман белемгә омтыла һәм Өркеттә гимназия тәмамлый.

Давыллы еллар була бу. Гражданнар сугышының Себердә дөрләп торган чагы. Яңалык өчен кулына корал тотып көрәшкән яшьләр арасында Кәшифә культура-агарту эшләре алып бара. Большевиклар оештырган җирле драма түгәрәгендә исә иң актив катнашучыларның берсе була.

1919 елның декабре азагында канечкеч Колчак бандаларын эшче отрядлары тармар итәләр, ниһаять, Өркеттә Совет власте урнаша. Озак та үтми, шәһәрдә беренче профессиональ мөселман театр труппасы оештырыла. Рәхим Тумашев режиссерлыгында Ш. Усмановның «Канлы көннәр»е, Г. Кариевның «Артист»ы һәм башка авторларның әсәрләре сәхнәгә куела. Бу спектакльләрдә баш рольләрне башкарып, Кәшифә үзен сәләтле артистка итеп таныта. 1921—23 елларда Семипалат профессиональ татар театр труппасы куйган бик күп спектакльләрдә төп рольләрдә уйный һәм театр, сәнгать буенча белем алу нияте белән 1923 елда Казанга кайта. Кәшифәне Казан театр техникумына кабул итәләр. Аны ул 1926 елда уңышлы тәмамлый һәм шул техникумда укытучы булып кала. Нәкъ менә шул елларда аңарда режиссерлык таланты ачыла. Үзенең иҗади дуслары белән берничә спектакль куюда катнаша. Радиога эшкә чакырыла. К. Тумашева режиссерлыгында татар телендә беренче радиоспектакльләр яңгырый башлый.

1931 елда К. Тумашева Мәскәү театр институтының режиссерлык факультетына укырга керә һәм, аны уңышлы тәмамлап, 1939 елда Татар дәүләт академия театрына режиссер булып кайта. Биредә ул Х. Фәтхуллинның «Күзләр», Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин», А. Әхмәтнең «Үги кыз», Д. Аппакованың «Тапкыр егет», Г. Камалның «Хафизәләм иркәм», «Беренче театр», «Бүләк өчен» пьесаларын куя. Бу вакытта инде Кәшифә ханым Тумашева татар театрларында эшләүче күренекле режиссерларның берсе булып таныла. Ул куйган спектакльләр озын гомерле булалар, кайберләре шактый еллар сәхнәдән төшми уйналып килә. Ә «Хуҗа Насретдин», «Тормыш җыры» (М. Әмир әсәре) спектакльләре татар театрында үзенә бер вакыйга булып таныла һәм дистәләрчә еллар уйналып киләләр.

К. Тумашева татар язучылары, драматурглары әсәрләрен сәхнәләштерү белән бергә классиканы да онытмый. М. Фәйзинең «Галиябану», «Ак калфак», Жан Мольерның «Жорж Данден», А. Островскийның «Ярлылык гаеп түгел» һәм башка бик күп кенә классик әсәрләрне сәхнәгә куя. Бу спектакльләр өстендә эшләгәндә ул педагог буларак та үзенең бар белемен, талантын, энергиясен театрның яшь көчләрен тәрбияләүгә бирә. Кайсы гына театрда эшләмәсен, тынгысыз күңелле К. Тумашева иң элек арымас-талмас педагог булды. 1955 елда Республика күчмә театрына баш режиссер булып күчкәч, аның бу эшчәнлеге тагын да киңрәк күләм алды. Актерлар белән уздырылган һәр репетиция сәнгать дәресенә әйләнә. Биредә ул сигез ел эчендә 30 дан артык әсәрне сәхнәләштерә, театр бу елларда гаять бай иҗат тәҗрибәсе туплый, үз традицияләрен булдыра, чын-чыннан үз иҗат йөзен таба, уннарча яңа талантларны үстерә.

Кәшифә ханым, режиссер буларак, драматурглар белән дә бик күп эшли. Ш. Мәҗитовның «Резидәкәй», Г. Насрыйның «Яшел эшләпә», Х. Вахитның «Яшерен зәләр», Ш. Зәйнинең «Хәзрәт үгетләргә килә», «Таң җыры» кебек спектакльләр нәкъ әнә шундый иҗат җимешләре булдылар.

Күпчелеге үзешчән сәнгатьтән килгән яки тәҗрибәсе аз булган актерлардан торган труппаны К. Тумашева яңа үрләргә алып менә. Н. Хикмәтнең «Сөер кеше», К. Тинчуринның «Сакла, шартламасын», Р. Ишморатның «Үлмәс җыр», Д. Юлтыйның «Карагөл» әсәрләре буенча куелган спектакльләре яшь актерлар өчен осталык мәктәбе булалар.

Татар театр тарихы бик күп фидакарьләрне белә. К. Тумашева — шуларның берсе. Иң күренеклеләрнең берсе дисәк тә, хата булмас. Ул тәрбияләп үстергән уннарча талантлы актерлар бүген театр сәнгатебезнең күгендә үзләре йолдыз булып балкыйлар һәм һәрвакыт тормышка тирән мәхәббәт белән карарга өйрәтүче, киң күңелле остазлары Кәшифә Тумашевага зур рәхмәтләрен әйтәләр, аны сагынып искә алалар.

**РӘШИТ ХӘНИПОВ.**

# МАТУРЛЫКНЫ ЯКЛАП

*Дэллюс Ильясовның тууына 60 ел*

Сугыштан соңгы еллар. Бөтен ил сугыш җимергән хәрабәләрне торгызу белән мәшгуль. Сугыш кешә күрә, тоя алган бөтен нәрсәгә кагылган: җиргә-күккә, тәнгә-җанга, үткән көннәргә, киләчәккә...

Республикабыз театрлары да шул хәлләттә: бик күп талантлы артистлар фронтта һәлак булган, карт буын артистларның кайберләре тормыштан китеп барганнар. Сугыш афәте тимәсә, алар да яшәрләр, иҗат итәрләр иде әле.

Нәкъ менә шул көннәрдә — 1946 елда Мәскәүдән А. В. Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) драма студиясен тәмамлап, республикабыз театрларына бер төркем талантлы яшьләр кайта. Сәнгать дөньясы иркен сулап куя, яңа алмашка өмет белән карый.

Бу яшь иҗатчылар арасында киләчәктә татар совет театрының данлы сәхифәләрен язышачак талант иясе Дэллюс Ильясов та бар иде. 24 яшьлек бу егет илтәшләреннән әллә ни аерылып тормый диярлек. Тик... ул инде рухи яктан корычтай чыныккан, сугыш кырларында утны-суны кичкән, күрсәткән батырлыклары өчен Ватан аның күкрәгенә Кызыл Йолдыз ордены һәм берничә медаль таккан.

Сугыш һәм сәнгать. Беренчесе — коточкыч дәһшәт, икенчесе — мәңгелек матурлык. Дэллюс, әнә шул матурлыкны яклап сугышкан кеше буларак, сәхнәдә дә үз идеалларына тугрылыклы булып кала. Балачактагы хыялы тормышка аша: ул — театрда. Ә алда — иҗат дип аталган иксез-чиксез зәңгәр офык!

Иҗат юлына аяк баскан яшь актерга таяну ноктасы кирәк. Аны төрле кеше төрлечә эзли. Күпләр ялгыша да. Дэллюс бу мәсьәләне дә солдатча хәл итә. Режиссер Гали Ильясов һәм РСФСРның атказанган артисткасы Гөлсем Камскаяларның улы булуын онытмый. Ләкин алардан яклау да көтми. Әти-әнисенә тиң иҗатчы булырга тырыша ул. Рус һәм татар телләрен камил белгән егет Бөгелмә рус драма театрына китә. Берникадәр эшләгәч, Казан Яшь тамашачылар театрына кайтып, күзгә күренерлек берничә образ тудыра. Тик аның күңеленә күптәнге олы хыялы тынгылык бирми. Аның татар сәхнәсендә — Касыйм Шамил, Хәлил Әбҗәлилов, Камал III, Габдулла Шамуков кебек атаклы сәхнә осталары арасында иҗат итәсе килә. һәм ул моңа да ирешә. Гомеренең соңгы 30 елын Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсенә багышлый. Бу сәхнә аның йолдызлы күге дә, бәхет тапкан җире дә булып кала.

Д. Ильясовның иҗатын барлаганда, аның тормыш юлын күз алдына китермичә булмый. Якты таланты булу өстенә, яшьтән үк зур тормыш юлы узган, яшәү тәҗрибәсе туплаган шәхес иде ул. Шуның өстенә олы сәхнә осталары иҗатының иң яхшы сыйфатларын өйрәнә килде. Ә болар, үз чиратында, аңа классикада һәм бүгенге көн драматургиясе әсәрләрендә бик күп якты образлар тудырырга булышты. Шулар аша актер театр сәнгатенең югары үрләрен яулады. Ул тудырган бик күп образларга лирик нечкәлек, драматизм хас. Аның геройлары кеше күңелен ниндидер бер йомшаклык, изгелек, сөйкемлелек белән яуладылар. Еллар узу белән, аның иҗат диапазоны киңәйде. Ул бер үк осталык белән кешеләр арасында имгәк булып яшәүчеләрне фаш итүче үзенчәлекле образлар да тудырды. П. Бомаршеның «Фигароның өйләнүе»ндә — Базиль, Х. Вахитның «Ике килен-килендәш»ендәге Камәретдин, Т. Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү»ендә Галим һәм башка образлар күңелдә әнә шул яклары белән саклана.

В. Шекспирның «Отелло»сында Родриго, М. Фәйзинең «Галиябану»ында Хәлил, Г. Боровикның «Канлы күләгәләр» әсәрендә Эрнесто Рохас, Н. Фәттахның «Кол Гали»ендә Актай, Н. Думбадзеның «Борчылма, әнием» әсәрендә Гурген һәм башка бик күп үзенчәлекле образлар тудырган артистны халык үз күрде, үзенең олы рәхмәтен әйтте. Аңа Татарстанның халык артисты дигән иң хөрмәтле исем бирелде.

Солдат, коммунист, халык артисты Д. Ильясовның олы үрнәге бүген аның шәкертләре иҗатында дәвам итә.

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ.

# БЕРЕНЧЕ ШАХМАТЧЫБЫЗ

*Рәшит Нәҗметдиновның тууына 70 ел*

Рәшит Нәҗметдиновның исеме илебездә дә, дөнья шахматчыларына да яхшы таныш. Тормыш сөючән, ташып торган энергияле, искиткеч кешелекле якташыбыз чын мәгънәсендә тылсымчы булып танылды. Шахмат комбинацияләрен ул соклангыч итеп кора, аларны зур осталык белән ахырына җиткерә белә иде.

Һәр спортчының бәхетле саны була. Рәшит Гыйбатович бишле санын ярата иде. Ул биш тапкыр РСФСР чемпионы, биш мәртәбә — призер булды, биш тапкыр —

СССР беренчелеге финалында, биш мәртәбә халыкара турнирда катнашты һәм югары урыннарны яулады. Коллекциясендәге призларны Бухарест һәм Сочидан, Монголия һәм Ирактан, Ростов һәм Харьковтан, гомумән, үзе катнашкан барлык турнирлардан диярлек алып кайтты. Әмма ул турнирларда яуланган беренче урыннар белән түгел, ә шахмат партияләренең иҗади эчтәлекле, комбинацияләренең искиткеч оригиналь булуы белән шөһрәт казанды. Аның бик күп партияләре шахмат шедеврларының алтын фондына кереп калды.

Талантлы якташыбызның шахмат белән кызыксынуы ничек башланган соң? Рәшит ярлы крестьян гаиләсендә туа, биш яшьтә ятим кала. Аңа кәҗәләр һәм казлар көтәргә, гомумән, авылдагы төрле эшләрне башкарырга туры килә. 1921 елда малай балалар йортына эләгә. Тик ул анда озак яшәми, үз теләге белән китеп Кызыл Армия сафларында хезмәт итүче Кави абыйсы (булачак әдип Кави Нәҗми) 1922 елда Казан хәрби мәктәбе комиссары итеп билгеләнә һәм энесе Рәшитне дә шәһәргә алдыра. Малай мәктәптә укый башлый.

...1923 елның сентябрендә абыйсы яшәгән йорт баскычыннан менеп барганда Рәшит очраклы рәвештә «Смена» журналының ертылган битен таба. Анда аңлаешсыз рәсемнәр, диаграммалар һәм ниндидер билгеләр басылган. Алар шахмат уены кагыйдәләре аңлатмасы булып чыга. Рәшит берничә көннән әлеге «теория»гә бераз төшенә башлый... Аннары, көннәрнең берендә, пионер сборына алданрак килгәч, ул Коммунистик клубның (хәзер анда авиация техникумы) уку залына күз сала. Анда бер төркем егетләр утыра. Өстәлләрдә — Рәшит журнал битендә күргән рәсемнәр кебек фигуралар. Баксаң, алар шахмат уйныйлар икән. Арадан берәү малайны үзе белән уйнарга чакыра. Фигураларның йөрешен әлеге журнал битеннән генә өйрәнгән пионер, ике ялгыш эшләсә дә, көндәшен җиңә. Шахматчылар түгәрәге җитәкчесе Н. А. Самсоновка укучы малайның уены авруча ошый. Ул, шәһәр шахмат клубы җитәкчесенә атап, Рәшиткә бер кәгазь бирә. Анда: «Өметле, кабул итүегезне үтенәм!» — дип язылган була.

1927 елның кышында Рәшит беренче тапкыр призга лаек була. Казан укучыларының беренче шахмат чемпионатында ул барлык иптәшләрен ота — унбиш мөмкинлектән унбиш очко җыя. Шәһәрнең пионер отряды вожатые комсомол Володя Дьяконов аңа чаңгы бүләк итә.

Рәшит Казанның кече чемпионатында да беренче урынны ала. Аннары шашка белән дә мавыга башлап, биш-алты ай эчендә беренче категория ала һәм 1928 елның февралендә Казан шәһәре чемпионы исемен яулый. Бу хәл күпләрне гаҗәпләндерә. Үзләрен очраклы җиңелгәнгә санаучылар аңа:

— Бәхетең бар икән, киләчәктә бу хәл кабатланмас! — диләр.

Рәшит кызып китеп:

— Бөтенегез белән берьюлы сеанс уйныйммы?! — дип, бәхәс куерта.

Чемпионатта катнашучыларның унбересе дә, өстәл янына тезелеп утыра һәм... Нәҗметдинов тагын барысын да ота. Шуннан соң «Шахматы и шашки в рабочем клубе» журналында «Казан вундеркинды» дигән мәкалә басыла...

1929 елда Нәҗметдинов автономияле республикалар һәм өлкәләрнең чемпионы була. Сугышка кадәрге елларда Казан беренчелегендә җиңелүне белми, РСФСРның иң оста шашкачыларының берсе булып танылa.

Шулай да Рәшит Гыйбатович әкренләп шашкадан аерыла, чөнки шахматта үзенең иксез-чиксез фантазиясе өчен зуррак мөмкинлекләр барлыгын күрә.

Турнирлар, турнирлар, турнирлар... Шахматчының гомере гүя еллар белән түгел, турнирлар белән исәпләнә. Шәһәрнең Михаил Еремин, Петр Колчурин, Алексей Хрусталев, Николай Косолапов, Петр Ермолин, Николай Нейков кебек көчле шахматчыларын җиңеп, Рәшит, чын көрәшче һәм оста уенчы, позицияләрне тирән аңлаучы буларак, унсигез яшендә үк Казан чемпионы исемен яулый. Ләкин аның таланты бөтен тулылыгы белән комбинацион уенда ачыла. Ул һәрвакыт кискен көрәшкә омтыла, уенны кыю рәвештә катлауландыра, яшерен комбинацияләр таба. Турнирлардагы көндәшләре аның йөрешенә каршы бердәнбер дөрес йөреш таба алмый интегәләр, чөнки Нәҗметдинов тактик фикер йөртергә дә гаҗәп оста була.

Казан педагогия институтының физика-математика факультетында укыганда (аны 1940 елда тәмамлый) шахмат корифейларының, барыннан да элек Чигорин, Алехин һәм Ласкерның иҗатын тирәннән өйрәнә, күп төрле стратегик һәм тактик алымнарны үзләштерә. Бу исә аңа тиздән Россия шахматчыларының спорт мастерлыгына кандидатлары сафына басарга булышлык итә.

Нәҗметдинов оста һөҗүм итәргә ярата, инициативаны үз кулына алу өчен, югалтулар алдында да тукталып калмыйча гаҗәеп сизгер уйный.

Бөек Ватан сугышы елларында Рәшит — политрук. Сугышны Германиядә тәмамлый. Сугыштан соң, ул яңадан шахматчылар сафы солдаты. 1950 елны Горькийда, РСФСР шахматчыларының XI чемпионаты финалында берьюлы өч сикереш ясый: беренче призны яулый, Россия чемпионының алтын медален һәм шахмат буенча спорт мастеры исемен ала.

...Филармониянең концерт залындагы алты өстәл янында унике шахматчы утыра. Аларның һәркайсы РСФСР чемпионы булырга өметләнә. Гроссмейстер Болеславский, танылган мастерлар Кан, Новотельнов, Дубинин, Камышев, Аронин... Нәҗметдинов кына — мастерлыкка кандидат. Ләкин ул үз көченә, үзенең мөмкинлекләренә ышана. һәм кыю көрәшә: тугызынчы турда Михаил Камышевны отып, мастер исемен яулый.

Шуннан соң Нәҗметдинов, гроссмейстерларны һәм мастерларны артта калдырып, тагын дүрт тапкыр РСФСР чемпионы була.

1954 ел. Бухарест. Халыкара турнирда беренче чыгыш. Чит илләрнең күренекле гроссмейстерлары һәм мастерлары белән ярышу. Нәтиҗә: Рәшит Италия чемпионы Энрико Паолины ота (бу уен турнирның иң кызыклы партиясе дип табыла, үткен комбинацион партиянең язмасы дөньяның барлык шахмат китапларында чыга). Яңа Зеландия чемпионы Роберт Вейд, Румыниянең халыкара мастерлары Теодор Сабо һәм Виктор Чокылтя, Польша чемпионы Богдан Слива да аның «тозагына» элэгэ. Ә швед гроссмейстеры Гидеон Штальбергны җиңеп, бу турнирда мактаулы икенче урынны ала һәм шушы беренче чыгышында ук аңа шахмат буенча халыкара мастер дигән исем бирелә.

Шахматтагы җиңүләр өчен алган өч дистә алтын, көмеш, бронза медальләр һәм жетоннар арасында илебезнең командалар ярышында беренчелекне яулаган өчен бирелгән ике алтын медаль дә бар. Ул ике тапкыр — 1954 елда «Спартак» ирекле җәмгыяте һәм 1955 елда Россия федерациясе командасы составында — Советлар Союзы чемпионы була.

1958 ел. Сочи. Шахмат буенча РСФСРның XVIII беренчелеге. Рәшит Россия чемпионы исеменә төп дәгъвачы гроссмейстер Лев Полугаевский белән очраша һәм шакмаккыч оста җиңә. Үзенең «Сайланма партияләр» китабында Нәҗметдинов моны: «Уйналган партияләр арасында бу иң кызыклысы» дип билгеләп үтә.

1961 ел. Баку. СССРның XXIX чемпионаты. Рәшит каршында — шахмат корольләре арасында сенсация ясаган дөнья экс-чемпионы Михаил Таль. Романтик рухта, кискен, кыю, тәвәккәл уйнаучы ике оста очраша һәм... Таль бирелергә мәҗбүр була.

Нәҗметдинов шахмат тарихында иҗади эзләнүләре белән генә түгел, ә шахмат тактасындагы көрәшнең асылын үзенчә аңлавы белән дә кереп калды. Ул турнирларда үзенең көндәшләрен дошман як итеп санамый, аларга иҗади ярышта шахмат сәнгате әсәре тудыручы иптәше итеп карый. Йомшак характерлы, шәфкатьле кеше буларак, шәхси конфликтларны яратмый, үзенең партнерларын чын күңелдән хөрмәт итә белә. Шуңа күрә күренекле шахматчылар арасында аның якын кешеләре күп, ә гроссмейстерлар Смыслов, Таль, Спасский, Гелер, Полугаевский, Холмов, Крогиус аның чын дуслары иде.

1971 елда Ирак шахмат федерациясе укытучы җибәрүне үтенеп мөрәҗәгать иткәч, Рәшит Гыйбатович кандидатурасына тукталалар. Багдад университеты студентлары өчен беренче лекциясен Рәшит Гыйбатович немец телендә сөйли. «Совет шахмат мәктәбе» темасына укылган бу лекция студентларда һәм укытучыларда зур кызыксыну уята. Ул утыз тактада берьюлы сеанс биргәндә дә уңышлы чыгыш ясый: ике партия генә ничьяга тәмамлана, калганнарын ота. Иракның көчле шахматчылары белән оештырылган осталыкны үстерү күнегүләре, галим-медиклар алдында ясалган лекцияләр, күп тактада уйнау сеанслары барысы дусларча уза. Ирак шахмат федерациясе

җитәкчеләре Совет иле вәкиле чыгышларыннан бик канәгать булып калалар, күренекле мастер белән очрашулар бу илнең шахмат тормышын шактый җанландырып җибәрә. Нәҗметдинов Рәшит Ирак шахмат федерациясенең Почетлы члены итеп сайлана.

Гомеренең соңгы елларында Нәҗметдинов турнирларда сирәгрәк чыгыш ясаса да, элеккечә үк шахматчылар сафында кала бирде. Аның тренерлык эшчәнлеге активлашты. Ул РСФСР җыелма командасы, «Спартак» спорт җәмгыяте үзәк советы җыелма командасы тренеры вазифаларын башкара. Дөнья беренчелегенә Ботвинник—Таль матчы алдыннан ул Рига гроссмейстерының консультанты була һәм аңа дөнья чемпионы Михаил Ботвинникны җиңәргә ярдәм итә. Шушы 1962 елда Нәҗметдиновка СССРның атказанган тренеры дигән мактаулы исем бирелә. Казанның яшь шахматчылары аның мәктәбен үтте, аның байтак шәкертләре мастерлыкка кандидат, дүртесе — В. Волошин, А. Смирнов, Я. Дамский һәм Н. Мөхәммәтҗанов — мастер исемен алуга иреште.

Нәҗметдинов китаплар да язды. Аның татар телендә язылган «Шахмат уены», рус телендә «Сайланма партияләр» исемле китаплары киң популярлык казанды.

Шахмат уенын пропагандалау буенча озак еллар нәтиҗәле эшләве һәм югары класслы спортчылар әзерләве өчен Рәшит Гыйбатовичка Татарстан АССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исем бирелде. Аның сугышчан бүләкләре янына «Аеруча хезмәт күрсәткәне өчен» медале өстәлде.

...1962 елның декабрь кичендә Казанда Р. Г. Нәҗметдиновка 50 ел тулу юбилеен билгеләп үткәндә дөнья экс-чемпионы Василий Смыслов чыгыш ясады. Бөтенсоюз шахмат федерациясе вицепрезиденты Яков Рохлин исә халыкара мастер турында сөйләгәндә болай диде:

— Татар халкы тапкырлар һәм зирәкләр уеныннан саналган шахмат белән борын-борыннан таныш, ләкин Рәшит Нәҗметдинов кебек талантлы шахматчыны дөньяга ул беренче мәртәбә бирде.

**РӨСТӘМ КИЛМӘТОВ.**

# ХУШ, БЕЗНЕҢ ӘДӘБИ БӘЙРӘМНӘР ЕЛЫБЫЗ!

Сүзне бик күп буыннар өчен озак елларга якты хатирә булып каласы өч тарихи дата белән өч исемнән башлап китү кирәктер биредә.

1917 елда дөнья шаулатып җиңгән социалистик революция Россия халыкларын сыйнфый һәм милли изелүдән коткара, барлык милләтләрнең социаль-политик дәрәҗәләре һәм культуралары тигез-тиң булып, үзара аралашып үссен өчен чикләнмәгән мөмкинлекләр тудыра.

1920 елның май аенда бөек юлбашчыбыз Ленин кул куйган декрет белән РСФСР составында безнең Татарстаныбыз автономияле Республика ителә.

1922 елның шул ук аенда партиябез татар укымышлылары, әдәбият һәм сәнгать осталарына тормышта советчыл яңарышлар яулап көрәшер өчен көчле һәм тутыкмас яңа бер корал — «Безнең юл» исемле иҗтимагый-политик һәм әдәби-нәфис журнал бирә.

Җисеменә бик туры китереп, аның алга таба үзгәртелә килгән исемнәре дә отышлы сайланган:

«Яңа юл» — озак дәвам ителәсе зур маршрутта политик яктан һәм культура өлкәсендә үсешнең төп юнәлешен сайлау һәм аны партия компасы белән билгеләү символы;

«Атака»— дөньяда әле беренче социалистик илнең эчке һәм тышкы дошманнарга каршы дәвамлы, катлаулы, кискен көрәше, һөҗүмнәренә ишарә;

Ә соңрак, әдәбият һәм сәнгать оешмаларын партия һәм хөкүмәт карарлары буенча үзгәртеп корулар башлангач — «Совет әдәбияты». Бу елларда инде журналның эчтәлеге һәм формасы белән милли культурабызны һәрьяклап үстерә, аның барча тугандаш әдәбиятлар белән бәйләнешен ныгыта торган, үзен батырлык һәм матурлык елъязмасы буларак тиз таныткан зур эшчәнлеге башлана. Бу — илне индустрияләштерү, авыл хуҗалыгын күмәкләштерү, культура революциясе бурычларын хәл итү, кадрлар әзерләүне тизләтү, табигый байлыкларны күбрәк һәм тизрәк ачу өчен кирәк. Әдипләр Татарстанда һәм башкалабыз Казанда электр станциясе, яңа юллар, ясалма каучук заводы һәм башка күп төрле завод-фабрикалар салган, элеккеге химия, мех, күн эшкәртү производстволарын киңәйткән, МТСлар ачкан, илнең Днепрогэс, Магнитка, Уралмаш, Турксиб кебек төзелешләрендә күпләп эшләгән якташларыбызның хезмәт батырлыгын берүк дәрәҗәдә киң яктырткан әсәрләр иҗат итә һәм бастыра. Чөнки 6 миллионнан артыграк халкыбызның яртысыннан күбрәге әле хәзер дә илнең барча якларында яши һәм макталып хезмәт итә бит.

Ватан сугышында җиңү яулаганда да журнал көрәшнең алгы сызыгында була, сугышка хәтле күләмдә бер өзлексез чыгып, аның һәр саны фронтларга озатыла, окопларда, блиндажларда укыла, солдат сумкаларында килеш һөҗүмнәргә керә, утлар-сулар кичә. Аңа подписка сугыштан соңгы ике дистәдән артык ел инде бөтенсоюз каталогы буенча кабул ителә, аны теләсә кайсы бүтән республикалар һәм өлкәләрдә һәм чит илләрдә дә укучылар күп.

Җаваплылык. Укучылар таләбе!..

Юк, бу тикмәгә әйтелми. Журналның бер генә эшен дә плансыз алып бару мөмкин түгел. Басыласы һәр әсәрнең нинди яңа сүз әйтүе, заман герое һәм иҗтимагый тормышның портреты нинди яңа буяулар белән сызылуы, үзәккә куелган теге яки бу проблеманың укучыга гына түгел, ә чынбарлыкның үзенә дә ни дәрәҗәдә актив йогынтылы буласын кат-кат уйларга кирәк. Әйе, һәр санның тематик һәм жанр төрлелеге, авторлар составы, хәтта материалларның күләм пропорцияләре дә, аз мәйданга күбрәк информация сыйдыру бурычыннан чыгып, кат-кат үлчәнә-исәпләнелә, конкрет максатка юнәлдерелә, координацияләнә. Менә шул инде ул журналның «үз йөзе», «үз холкы» дигән тирән мәгънәле төшенчәләр. Аның рубрикалар төре, фәлсәфәсе һәм теле дә, килеш-килбәте, зирәклеге-тапкырлыгы һәм елмаю-көлүләре дә матур һәм бары тик үзенекечә булсын, һәм алар укучылар даирәсенең халыкчан җирлегенә дә нигезләнсен, гомумсоюз журналларга куелган таләпләргә дә тигезләнсен дип аңларга кирәк моның бөтенесен.

Соңгы елларда, уртача алганда, журналыбызның 12 томында 2—3 роман, ким

дигәндә 8—10 повесть, ике дистәләп хикәя, 3 яки 4 поэма, сәхнәдә күп уйналып сыналган 2 пьеса (инде укыр өчен!), 25—30 шагыйрьнең яңа шигырьләре (шуларның чирегә диярлек укучыга беренче тәкъдим ителә торган яшьләр иҗатыннан була), 15-20 очерк һәм публицистик чыгыш басыла килде. Шуларның укучы яратып кабул иткән һәм русчага тәрҗемә ителеп чыгарганнары да, илебезнең төрле театрлары сәхнәләрендә уйналганнары да шактый күп булды: Г. Минский, А. Гыйләҗев, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, М. Маликова, Вакыйф һәм Ибраһим Нуруллиннар прозасы, С. Хәким, Ә. Баянов, Ш. Маннапов поэзиясе, Т. Миңнуллин, Р. Хәмид пьесалары һ. б. Аларга персонажлары, сюжетларының бүгенге көн һәм туган як җирлеге белән тыгыз бәйләнеш ныклыгы, һәр минутта шулар пульсын тоеп яшәү хас. Шул ук вакытта аларны илнең бөтен бер зур әдәбияты бизмәне белән үлчәргә, шуңа куелган югары идея-нәфислек критерийларыннан чыгып та бәяләргә мөмкин. Чөнки ул әсәрләрдә язмышлары халык язмышы белән уртак ителгән көчле, көрәшүче характерларның тырыш хезмәтен сәнгать буларак күрсәтергә омтылыш зур.

Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият һәм сәнгать тәнкыйте» турындагы карарыннан соң журнал тәнкыйте бигрәк тә прозаны җентекләп күзәтү юнәлешендә, яхшы якка бик нык үзгәрде. Аның төпле, тирән, конкрет, ышандырулы фикер йөртү сәләте, профессиональ осталыгы, эшчәнлек темпы, иңһаять, кичә, бүген, иртәгә проблемаларын нык бәйләнештә, комплекслы өйрәнергә тырышлыгы артты, һәм ул елдан-ел көчәя тора. Хәзер безнең һәр алты каләм остабызга инде Союз члены булган, күбесе фән докторы яки кандидаты дәрәҗәле бер тәнкыйтьчебез һәм әдәбият белгечебез бар. Күпчелек яңа китаплар рецензияләнә, әдипләрнең иҗат портретлары әледән-әле эшләнә. Ә менә поэзия тәнкыйте шундый ук актив һәм күпкырлы түгел әле диярга мөмкин — чөнки жанрның һәм аерым авторларның поэтик осталык «серләре» анализланмый диярлек, бу үтә оператив булырга тиешле нәфис жанрга тормышчанлык һәм үткенлек җитенкерәмәүнең, аңарда сюжетсызлык үзен бик нык сиздерүнең сәбәпләре һәрьяклап өйрәнелми әле. Сүз уңаеннан безнең тәнкыйть кайбер шагыйрьләрнең гражданлык сыйфатларын да бәяләргә, үшәннәрне, иртә профессиональләшкән «эшсезләр»не дә камчыларга тиештер дип әйтү да бик кирәк. Журналыбызның хәзерге ике әдәби постыннан — Питрәч районында чәчүлек җирләре 6000 гектар, колхозчыларның хуҗалык саны меңгә якын булган Вахитов исемендәге колхоз, Казанда елына 65 миллион сумлык продукция эшләп чыгара торган Вахитов исемендәге химия комбинаты — берсенә дә барып карамаган, шул коллектив эшчәннәре турында бер юл да язмаган авторларыбыз күп әле...

Драматургиябез үсешен һәм сәхнә әсәрләре язучы авторларыбыз иҗатын да шундый ук күзлектән карап, тирәнрәк һәм проблемалырак итеп анализлый торган тәнкыйть тә бик кирәк безгә. Һәм ул тормыш сынаган, шул сынауда өстенлек иткән позициядән — сыйнфыйлык, партиялелек, халыкчанлык принципларыннан бер адым да читкә тайпылмасын, комплементлар темпераментын шулай ук кимета төшсен иде.

Бу барыннан да элек инде җитлегү бусагасына аяк баскан, актив эшләүче, хәтта әдәбиятыбызның гомуми үсешенә йогынты ясый алган яшь алмашыбыз өчен бик кирәк. Аларга әле эшлисе дә эшлисе бит! Моның өчен аларның тормыш көрәшләренә җитди карашлары бар, бүгенге көн яшәешенең төп проблемаларын тирәнтен аңлау теләге — ягъни замандашлары характерының ныклыгын иң тирән психологик кичерешле урләрдә, кискен ситуацияләрдә сурәтләп сынау теләге көчле. Киләчәктә нинди жанрда төпләнү ниятенә карамастан, зур әдәбиятка китерә торган очерк һәм публицистика жанрында эшләүгә менә кемнәр бер дә икеләнмичә кызы алынырга тиеш.

Журналыбызның бу санында без «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик тәрбия практикасы белән иҗади элемтәләре турында» КПСС Үзәк Комитеты кабул иткән карар да бар. Тиздән хуплашып без чал тарихка озатасы 1982 елны тагын да матурлаган, озакка истәлекле иткән бер эшлекле бәйрәм булды бу безгә.

Шул карарны тормышка ашыру йөзеннән, очерк һәм публицистика проблемасы бүген башкарасы эшләребез арасында иң алгы планга куела да инде. Моның өчен бездә бөтен мөмкинлекләр бар. Теләсә кай тарафка юл алып, зур масштаблы яңа проблеманы хәл иткән хезмәт коллективын яки аерым эшчәннәрне тап, йөрәгең тибешен шулар хезмәте ритмына көйлә һәм күргәннәреңне-белгәннәреңне мөмкин кадәр оста итеп журнал укучыларына сөйлә! 1983 елның декабренә кадәр дәвам итәчәк конкурска, инде белдерелгәнчә, илебезнең әле алдагы бишьеллыкларда да хәл ителәсе аграр программа темасы очерклары һәм публицистикасы кабул ителә. Аны үзе оештырган һәм бүләкләрне дә үзе бирәчәк журналыбыз битләрендә әсәрләрнең сыйфат билгесе куярлык һәркайсына яшел урам һәрвакыт ачык булачак. Ерак һәм якын юллар командировкалары бирелә.

Бу безнең һәркайсыбызны иҗатыбызның күбрәк һәм яхшы сыйфатлы булуы турында эшчеләр һәм игенчеләрнең конкрет үрнәгендә кайгыртырга өйрәтер, үз эшең турында гына түгел, ә бөтен бер коллективтагы тату һәм саф атмосфера, яхшы мораль климат турында җитди уйландырыр, хезмәт кешеләренең һәркайсы шулай ук иҗатчы икәнен, бездә һәркемнең эш сәгатьләре һәм таланты иҗтимагый байлык булуын тирәнтен аңларга булышыр.

Сүзне хөрмәтле укучыларыбызга адресланган берничә теләк һәм үтенеч белдереп тәмамлыйк: журналыбызның 60 еллыгы бәйрәме шатлыгын тагын бер уртаклашыйк.

Һәр укучының журналга үз юлы, үз карашы һәм үз дәгъвалары бар. Ләкин аны бөтенесе дә бердәй яратып, көтеп ала һәм, әйтергә кирәк, үзенчә бәяләп, анализлап укый, шул хакта хатлар яза. Киңәшчесе һәм дустына карата ул киң күңелле дә, кирәк икән — таләпчән һәм кырыс та, җаны яраткан әсәрне хуплап кабул итә, саруын кайнатканын кире кага. Шундый туры сүзле, эчкерсез, гадел һәм турылыклы патриот булганнары өчен барлык укучыларыбызга да редакциянең, редколлегиянең һәм бөтен авторларыбызның рәхмәте зур.

...Халыклар һәм ил тормышында 60 ел — тарих гасырларының бер мизгеле генә диярлек аралык ул. Ләкин шул ук вакытта совет чорының тугандаш халыклары семьясында яшәгән ул елларны бөтен бер гасыр белән тиңләргә мөмкин. Чөнки:

**Без бит һаман алга ашыгабыз —**
**Без походта, юлда һаман да.**
**Без заманны һаман ияртәбез,**
**Иярәбез һаман заманга.**

Менә тиздән шул юл безне яңа елга алып керәчәк. Йөрәкләребез авазын бөтен ил, җирдәге алдынгы кешелек тавышына кушып, без дә әйтербез шунда:

— Хуш, безнең зур истәлекле бәйрәмнәр елыбыз! Хуш, 1982!

— Хуш киләсең, 1983! Өйләребез һәм күңелләребез түренә кыю уз. Шунда балкыйсы нурларың мул булсын. Бөтен көчебез, иҗатыбыз һәм хезмәтебезне синең яктыңны атом бомбасы болытлары белән каплатмас өчен бердәм сафларда армый-талмый эшләрбез һәм бердәм көрәшербез!

**ЗӘКИ НУРИ.**
Октябрь, 1982.

# 1982 ЕЛДА «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫНДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

КПСС Үзәк Комитетының, СССР Верховный Советы Президиумының, СССР Министрлар Советының Коммунистлар партиясенә, совет халкына Мөрәҗәгате. № 12.
Советлар Союзы Коммунистлар партиясе Үзәк Комитеты Пленумы турында информацион белдерү. № 12.
Иптәш Ю. В. Андропов речь. № 12.
Иптәш К. У. Черненко речь. № 12.
Юрий Владимирович Андропов. № 12.

*КПСС Үзәк Комитетында*

КПСС Үзәк Комитеты «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәләре турында» карар кабул итте. № 12.

*КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карары*

1982 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турында. № 7.

*Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы*

«Казан утлары» журналын Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләү турында. № 8.

СССРның ТӨЗЕЛҮЕНӘ 60 ЕЛ

Арсланов Н. Уналты гына икән. Шигырь. № 2.
Афзал Г. Абыйлар үткән юл. Шигырь. № 3.
Батыев С. Бердәм, тату гаиләдә. № 12.
Гатауллин Р. Яңа җырым. Шигырь. № 7.
Зарипов И. Дуслар тугрылыгы. Очерк. № 8.
Зыбаерова Д., Баинов М. Таң җыры. Очерк. № 10.
Коваленко Л. Иң кадерле истәлек. № 11.
Миңнуллин Р. Батырлар җыры. Шигырь. № 8.
Низамиев Р. Ватанымның бер көне. Шигырь. № 11.
Нури З. Очрашсыннар җырда халыклар. Шигырь. № 12.
Рәхим Г. Ил җырына кушыл, республикам! Шигырь. № 6.
Сафин Ф. Ил бәйрәмен котлап. Шигырь. № 5.
Фасеев К. Киләчәге тагын да матуррак. № 12.
Әюпов Х. Бәйрәмнәр. Шигырь. № 9.
Әйди Т. Тылсымлы кеч. Очерк. № 11.
Әхмәтҗанов Р. Без — халык. Шигырь. № 4.
Юзеев И. Ленин дәшә безгә. Шигырь. № 1.
Яруллин Ф. Уртак сыйфат. Шигырь. № 10.

В. И. ЛЕНИННЫҢ ТУУЫНА — 112 ЕЛ

Булатов Ә. Юлбашчының гомерлек юлдашы. № 4.
Сабиров Р. Ульяновлар. № 4.

БЕЗНЕҢ ЛЕНИНИАНАГА ЯҢА ЮЛЛАР

Дабин А. Гомернең алтмыш минуты. Шигырь. № 4.
Карапетян Б. Йөрәк еракта кура. Поэмадан өзек. № 4.
Маари Г. Владимир Ильич һәм Ваам Терян турында сүз. Шигырьдән өзек. № 4.
Шәрипов Х. Таяныч нокта. Шигырь. № 4.

Шәкрулла. **Мавзолейда.** Шигырь. № 4.
Җаббаров Җ. **Аның булмасендә.** Шигырь. № 4.

«ПРАВДА» ГАЗЕТАСЫНА — 70 ЕЛ

Айнетдинов А. **Казанышларыбыз елъязмачысы.** № 5.

«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 60 ЕЛ

Мәрдиева М. **Эзләнүләр һәм үсеш юлыннан.** № 5.
**Әдәбиятыбызның якты көзгесе.** Журналның юбилее уңае белән бер төркем язучыларның анкетага җаваплары. № 5.

ЖУРНАЛ ТАРИХЫНЫҢ ЯКТЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

Кәрим Ф. **Сибәли дә сибәли.** Шигырь. № 5.
Такташ Һ. **Җырланачак җырлар турында.** Шигырь. № 5.
Җәлил М. **Боз ага.** Шигырь. № 5.

БӘЙРӘМ БУКЕТЫНА МАЙ ЧӘЧӘКЛӘРЕ

Арсланов Н. **Үз-үземә.** Шигырь. № 5.
Афзал Г. **Бурыч.** Шигырь. № 5.
Баттал С. **Тансык күренеш.** Шигырь. № 5.
Гаташ Р. **Мөһаҗир.** Шигырь. № 5.
Латыйп Г. **Мин түшемдә.** Шигырь. № 5.
Миңнуллин Р. **Каракалпак шагыйре Ибраһим Йосыпов турында шаян шигырь.** Шигырь. № 5.
Садри Мөхәммәт. **Киев турында җыр.** Шигырь. № 5.
Фәйзуллин Р. **Дулкыннар кочагында.** Шигырь. № 5.
Юзеев И. **Киләчәккә аваз.** Шигырь. № 5.
Яруллин Ф. **Күптән инде.** Шигырь. № 5.
Әхмәтҗанов Р. **Сабан туенда.** Шигырь. № 5.

ПРОЗА

Бәширов Г. **Бибек нигә елый.** Хикәя. № 10.
Вәлиев М. **Зилә.** Новелла. № 4.
Вәлиев Р. **Иске сәгать дөрес йөри.** Повесть. № 6.
Галиев Г. **Истә, һаман да истә...** Хикәя. № 12.
Галиев М. **Ерак урман авазы.** Повесть. № 7.
Гаффар Ә. **Бишек.** Повесть. № 12.
Еники Ә. **Соңгы китап.** № 12.
Кашапов Г. **Солдат иртә ир була.** Лирик-драматик хроника. № 2.
Кәрами Р. **Өзелгән чәчәк.** Хикәя. № 3.
Лотфи Г. **Пума белән Кәберлә.** Повестьтан өзек. № 10.
Мирхәйдәров Р. **Безне онытмагыз...** Повесть. № 4.
Мәһдиев М. **Исәнме, Кәшфи абый!** Повесть. № 8.
Расих А. **Ямашев.** Роман. № 1, № 2.
Сафин А. **Хыял.** Хикәя. № 6.
Сафин М. **Чаллы этюдлары.** № 6.
Сәлимҗанов Р. **Кечке аваз.** Парчалар. № 6.
Тимбикова К. **Кышкы талпыну.** Повесть. № 10.
Фәттах Н. **Сызгыра торган уклар.** Роман. № 3, № 4, № 5.
Хафизова Р. **Сөенечле хәбәр.** Хикәя. № 3.
Хисматуллин Р. **Сусау.** Хикәя. № 6.
Хәмидуллин Л. **Буранлы төндә.** Хикәя. № 11.
Хуҗин М. **Өч каен ышыгы.** Хикәя. № 11.
Хәбибуллин М. **Сулар үргә акса да.** Роман. № 7, № 8, № 9.
Хәсәнов А. **Авыр миссия.** Хикәя. № 1.
Хөсни Ф. **Мәшәкатьле озын сәфәр.** Юл язмалары. № 5.
Чурбанов А. **Беренче җәй.** Хикәя. № 6.
Шамов А. **Кире беткән кыз.** Хәрби корреспондент язмалары. № 4.
Шәмси С. **Җәйнең кып уртасында.** Хикәя. № 11.
Әдһәмова Г. **Үкенечкә калмасын!** Кечкенә повесть. № 9.
Әмирханов М. **Соңгы җыр.** Хикәя. № 11.
Әһлиуллина Ф. **Гөлбакчада.** Ярымәкият. № 3.

ПОЭЗИЯ

Алешков Н. **Уяналсам...** Шигырь. № 6.
Асылбаева Р. **Бер ак болыт...** Шигырь. № 6.

Арсланов Н. **Ана сөте белән.** Шигырьләр. **№ 9.**
Арсланов Н. **Дүрт атым.** Шигырьләр. **№ 1.**
Афзал Г. **Алты дистәнең өстекиән.** Шигырьләр. **№ 7.**
Баттал С. **Ике йөз елдан соң.** Поэма. **№ 10.**
Баубекова-Кожевникова Р. **Хәтерлим.** Шигырьләр. **№ 3.**
Воздвиженский Л. **Сагынып...** Шигырь. **№ 6.**
Вәлиев М. **Дөнья дигән йортыбыз.** Шигырьләр. **№ 11.**
Газизов М. **Субайлар.** Шигырьләр. **№ 6.**
Гатауллин Р. **Алтын кош каурые.** Шигырьләр. **№ 12.**
Дәүли Н. **Ветеран йоклый алмый.** Шигырьләр. **№ 2.**
Закиров Р. **Күпер чыкканда.** Шигырьләр. **№ 12.**
Зиннәт К. **Синең туйда.** Шигырь. **№ 6.**
Зьйдуллин Р. **Ташларгамы җанны чиксезлеккә.** Шигырьләр. **№ 11.**
Зәйнашева Г. **Яшел үзәнлек.** Шигырьләр. **№ 3.**
Зөлфәт. **Йөрәкләрдә үлмәс дастан.** **№ 8.**
Игәнәй Я. **Утлы корыч.** Шигырьләр. **№ 6.**
Измайлова Н. **Өлешемә тигән көмешем.** Шигырьләр. **№ 3.**
Имаев Р. **Ут кирәк.** Шигырь. **№ 6.**
Кувайцев Е. **Дәү әнием хатирәсе.** Шигырь. **№ 6.**
Кутуй Р. **Шагыйрь.** Шигырьләр. **№ 11.**
Латыйп Г. **Тормыш һәм гаделлек.** Шигырьләр. **№ 1.**
Лимонова И. **Дөнья...** Шигырьләр. **№ 6.**
Мадьяров Н. **Чаллы.** Шигырьләр. **№ 6.**
Малков Ю. **Кояш батты...** Шигырь. **№ 6.**
Мансуров З. **Шөгыль.** Шигырьләр. **№ 10.**
Миңнуллин Р. **Йолдызлар арасында.** Шигырьләр. **№ 2.**
Мортазина А. **Язгы төннәр.** Шигырь. **№ 6.**
Мостафин К. **Хыял кошы.** Шигырьләр. **№ 10.**
Мостафин Э. **Уйлан, кеше.** Шигырьләр. **№ 12.**
Мәхмүдов Ә. **Мизгелләр.** Шигырьләр. **№ 12.**
Мәҗитов З. **Яңа шигырьләр.** **№ 9.**
Низамиев Р. **Мең авазлы заман.** Шигырьләр. **№ 4.**
Рахман Р. **Авылда.** Шигырь. **№ 6.**
Рафиков М. **Тол ана.** Шигырьләр. **№ 2.**
Рәхимова Б. **Ишелә, җимерелә...** Шигырьләр. **№ 3.**
Сафин Ф. **Туган җир.** Шигырьләр. **№ 11.**
Сибгатуллин К. **Хыялыбыз башкаласы.** **№ 6.**
Сирай Д. **Солдат улыма хатлар.** **№ 2.**
Туктарова В. **Бөреләр.** Шигырь. **№ 3.**
Федосенко М. **Җил тегермәне.** Шигырь. **№ 6.**
Фәйзуллин Р. **Бу җырлар.** Шигырьләр. **№ 4.**
Фәйзуллина М. **Авылдан хатлар.** Шигырьләр. **№ 3.**
Харис Р. **Хәбәр.** Шигырьләр. **№ 7.**
Хисамов Н. **Төрле еллар дәфтәреннән.** Шигырьләр. **№ 10.**
Хәбибуллин М. **Табындым.** Шигырь. **№ 6.**
Хәким С. **Эзлиләр Европа буйлап...** **№ 5.**
Хөснуллин Х. **Тукайның яңа ватаны.** Шигырь. **№ 6.**
Шабаев М. **Кеше булып...** Шигырьләр. **№ 11.**
Шакирҗанова Л. **Сәмарканд базары.** Шигырьләр. **№ 11.**
Шәйхи М. **Кичерешле уй.** Шигырьләр. **№ 6.**
Шәрипов Р. **Сүнгән чакта...** Шигырьләр. **№ 11.**
Шәрифуллина Э. **Җиркәем, җирем, җир генәм.** **№ 3.**
Шәфикова К. **Бүген җилләр талгын исте.** Шигырьләр. **№ 3.**
Юлаев П. **Юатучы.** Шигырь. **№ 6.**
Юнысов Р. **Очыш.** Шигырьләр. **№ 4.**
Яруллин Ф. **Йөреп тора хатлар гына.** Шигырьләр. **№ 9.**
Әхмәтҗанов Р. **Яңа шигырьләр.** **№ 4.**
Әхмәтҗанов Р. **Мәхәббәт исәнлегенә.** **№ 8.**
Әюпов Х. **Чакыру.** Шигырьләр. **№ 7.**

## СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ

Миңнуллин Т. **Монда тудык, монда үстек.** Драматик повесть. **№ 10.**
Сафиуллин Ю. **Менә без дә үсеп җиттек.** Комедия. **№ 8.**

## ДУСЛАР ЖЫРЫ

Виеру Г. **Көтү.** Шигырь. **№ 12.**
Гончаров В. **Куликово кырында.** Шигырьләр. **№ 4.**
Емельянов А. **Сыбызгы.** Хикәя. **№ 4.**
Капустин А. **Тозлы чык.** Хикәя. **№ 9.**
Күгелтдинов Д. **Моабит төткыны.** Поэмадан өзекләр. **№ 9.**
Ляпин И. **Йөрәк.** Шигырьләр. **№ 11.**
Мамур С. **Мәңгелек ут.** Шигырь. **№ 12.**
Майн Макс. **Лыгырдык.** Шигырь. **№ 12.**
Ошанин Л. **Әдәбият институтын тәмамлаган дусларыма.** Шигырьләр. **№ 5.**
Рамазанов Г. **Яшел бишек.** Шигырьләр. **№ 12.**
Рөстәмханлы С. **Ватандарлар үлми.** Шигырь. **№ 12.**
Сафин Р. **Җирем моңы.** Шигырьләр. **№ 1.**
Халит Р. **Кояшка карап.** Шигырь. **№ 12.**
Хаппалаев Й. **Көн дә бәйрәмнәрдә биеп...** Шигырь. **№ 12.**
Хәлим А. **Беренчеләр.** Поэмадан өзекләр. **№ 6.**
Чанышева Ф. **Икмәк исе.** Шигырь. **№ 12.**
Чепуров А. **Кеше һәм сүз.** Шигырь. **№ 12.**
Шаммас Р. **Минем йолдыз.** Шигырь. **№ 12.**
Шогенцуков А. **Таңнар күзе.** Шигырь. **№ 12.**
Шәмсетдинов Н. **Ан-2.** Шигырьләр. **№ 6.**

## КЛАССИК ӘДӘБИЯТ ҮРНӘКЛӘРЕ

Горький М. **Республика корольләренең берсе. № 11.**

## БЕЗДӘ КУНАКТА: ТӨНЬЯК ОСЕТИЯ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

Дарчиев Д. **Арба җыры.** Шигырь. **№ 7.**
Джикаев Ш. **Иксез-чиксез...** Шигырь. **№ 7.**
Кайтуков Г. **Эпиграммалар. № 7.**
Кодзати А. **Терек.** Сонет. **№ 7.**
Малиев В. **Назыйм.** Шигырь. **№ 7.**
Муртазов Б. **Бөркет.** Шигырь. **№ 7.**
Плиев Г. **Батыр куян.** Шигырь. **№ 7.**
Хетагуров К. **Хуш!** Шигырьләр. **№ 7.**
Ходов К. **Әткәмне уйлап.** Шигырь. **№ 7.**
Хостикоева З. **Еллар, юллар...** Шигырь. **№ 7.**
Цагараев М. **Кояш.** Шигырь. **№ 7.**
Цирихов М. **Умырзая.** Шигырь. **№ 7.**
Царукаев А. **Көзге урман.** Шигырь. **№ 7.**

## ӘДӘБИ АЛМАШЫБЫЗГА ЯРДӘМГӘ

Данилов Софрон. **Синең тавышың. Иң гүзәл хатын. № 5.**
Касумов Ә. **Кичектең... Соңгы хат. № 5.**
Кутуй Г. **Сагыну. № 5.**
Максуд М. **Каравылда. № 5.**
Тургенев И. С. **Маша. Чыпчык. Эт. № 5.**
Әмирхан Ф. **Чәчәкләр китерегез миңа! № 5.**
Әсгать Ф. **Чәчәкләрдән — сүзләр. № 5.**
Җәбран Җәлил Җәбран. **Күңел җыры. Яңгыр җыры. Гүзәллек җыры. № 5.**

## НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Бәшәр Р. **Кызык булыр иде, әl** Шигырьләр. **№ 6.**
Галиев Ш. **Маяк.** Шигырьләр. **№ 10.**
Нигъмәтуллин А. **Кул гына чыдасын.** Шигырьләр. **№ 8.**

## ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Булатова К. **Хәзерге Дон-Кихотның яңа кыйссасы. № 3.**
Кәшфелзадә. Бер риваять. Шигырь. **№ 4.**
**Ватан сугышы елларының көлке капчыгыннан. № 4.**
**Таулардагы кайтаваз. № 1.**
**Телдән-телгә күчә көлке сүз. № 9.**

## ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Абдуллин Ф. Көмеш тәңкәле нигез. № 6.
Беляев Р. К. Батырлык һәм матурлык тантанасы. № 6.
Вәлиев Р. Сиреньнәр. № 6.
Гаффар Ә. Сиксән беренче ел икмәге. № 1.
Гаффар Ә. Бакча. № 3.
Дунай Ф. Дәү апа. № 6.
Зарипов Х. Җиләк өлгереп килә... № 3.
Кашапов Г. Ашкын йөрәк. № 6.
Мөэминова Э. Без дә үсеп җиттек... Очерк. № 10.
Насыйров Ф. Упкыннар аша. № 2.
Рәкыйпов Ш. Сөенчегә — алтын сәгать. Очерк. № 10.
Садри М., Нури З., Сафин Ф. «Рәхим итегез, хөрмәтле язучылар!». № 12.
Садри М. Казан коммунары. Шигырьләр. № 12.
Сәгыйтов Т. Кеше хакына. № 3.
Хамматов Ш., Закиров И. Муса Җәлил һәм Мәскәү матбугаты. № 2.
Хамматов Ш. Яңадан сафка. № 5.
Хисамов Ш. Лена вакыйгаларына — 70 ел. № 4.

## МАЙ ПЛЕНУМЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

Бәдретдинов Х. Авылым каһарманнары. Очерк. № 11.
Зарипов М. Сыеры барның сые бар. № 7.
Мәһдиев М. Авыл белем сорый. № 12.
Рафиков М. Чаптар туктамый. Очерк. № 9.
Хәбибуллин М. Җирнең хуҗасы турында тирән кайгыртып. № 12.

## УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

Вәлиев М. Себер язмалары. № 2.
Максудов Р. Өй туйлары соңламас. № 4.

## КАЗАН АЛАРНЫ МӘҢГЕ ОНЫТМАС!

Сабиров Р. Бөек юлның башлангычы. Беренче марксист. Ике даһиның университетлары. Зиратта булган вакыйга. Пушкин Казанда. Галим, ректор, китапханәче. Шлиссельбург тоткыны. Лев Толстой һәм Казан. Рәсәйнең бөек җырчысы. Истәлекле исемнәр. № 9—12.

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Вәлиев М. Авылыбыз моңын югалтсак... № 6.
Вәлиев Р. Халык исеменнән сөйлим дисәң... № 10.
Галиуллин Т. Еллар чакырдылар еракка. № 6.
Галимуллин Ф. Юл кешесе. № 3.
Иделле Г. Дусларыбыз иҗаты турында. № 11.
Лаисов Н. Шигърият — табигать сагында. № 6.
Маннапов С. Дөньяның кыл уртасында. № 2.
Маннапов С. Хәтер. № 5.
Маннапов С. Дәвам. № 10.
Миңнуллин Ф. Заман һәм повесть. № 2.
Мусин Ф. Дуслык, туганлык җепләре. № 7.
Мөхәммәдиев Р. Язлар тагын килер... № 3.
Мөхәммәдиев Р. Идея-эстетик офыклар киңәйгәндә. № 7.
Нуруллин И. Әдәбиятта шартлылык турында. № 4.
Хәйри Х. Яңа дулкын. № 1.
Хәсәнов М. Әйдә халыкка хезмәткә! № 1.
Уңышлар белән тынычланмаска! КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» карарына 10 ел тулу уңае белән язучыларның редакциягә җибәргән җаваплары. № 1.

## БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Ихсанова Л. Сабыйлыкта кунакта. № 9.
Ягъфәров Р. Дәү китап. № 9.
Әгъләмов М. Нәниләрне онытмагыз! № 9.

## ЯЗУЧЫ УЙЛАНУЛАРЫ

Миңнуллин Т. Кызыл тышлы дәфтәрдән. № 9.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

Вәлиев М. Авыл кешесенең матурлыгы. № 12.
Госманов М., Хисамов Н. Дәрдмәнд әсәрләренең яңа басмасы. № 3.
Зөлкарнәев Ф. Соклану сәләте. № 6.
Кәримуллин Ә. Мәрҗани турында яңа сүз. № 11.
Миңнуллин Р. Бишек тирбәлергә тиеш. № 4.
Мостафин Р. Түбән Каманың бәхетле язмышы. № 3.
Мостафин Р. Беренче заттан. № 6.
Низамиев Р. Тугрылык. № 3.
Сверигин Р. Төсләр һәм кешеләр. № 7.
Халиков А., Гыйззәтуллин М. Фәнгә яңа өлеш. № 2.
Шәфигуллин Ф. Кешелек танына күтәрелгәндә. № 3.
Ягъфәров Р. Күңел юанычы, тормыш көзгесе. № 2.
Ягъфәров Р. Бик кирәкле эш. № 4.
Әйди Т. Үз йөзен саклап. № 7.

## КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

Бәйрәмова Ф. Флера Гыйззәтуллина. Сәлам хаты. № 2.
Габиди Ә. Нәби Дәүли. Мин җырдә калам. № 2.
Гайнетдинов Х. Разил Вәлиев. Без — кояш балалары. № 6.
Мөхәммәдиев Р. Хәниф Хоснуллин. Алтын тояк. № 6.
Низамиев Р. Рәшит Бәшәр. Яшел океан. № 6.
Рәшитов Я. Хуҗи Мәхмүтов. Кечкенә дә төш кенә. № 2.

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА

Зиннәтуллина Ә. Бер хикәя поэтикасы. № 8.
Сәхәпов Ә. Табигать исеменнән. № 8.
Юнысов Р. Фантастикага чынлык кирәк. № 8.

## ӘДӘБИ МИРАС

Баһаветдинова Д., Әхмәтҗанов М. Такташ хатлары. № 8.

## ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА

Гайнетдинов М. Бетмәс гамем, нидәндер бу! Әбелмәних Каргалыйның тууына 200 ел тулу уңае белән. № 7.
Шәрипов Ә. Иҗади хезмәттәшлек тамырлары. № 11.

## КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

Саттаров Г. Унберенче караш. № 2.
Сафин Ш. Шиһабетдин Мәрҗани кульязмасы. № 4.

## МАТБУГАТ һӘМ КУЛЬТУРА

Шәрәфетдинов Г. Китап — чорыбыз көзгесе. № 7.

## ТЕЛ БЕЛЕМЕ

Хаков В. Совет чорында әдәби телебезнең үсеше. № 12.
Юсупова А. Беренче карлыгачлар. № 3.

## ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

Гыйльманов Г. Вакыйга һәм хис гармониясен эзләп. № 11.
Мостафин Р. «Шагыйрь композитор булырга тиеш». № 11.
Мөхәммәтшин Р. Яңа әдәбият бишеге янында. № 11.

## СӘНГАТЬ

Айдарская Ә. Хыял канатларында. № 8.
√ Арсланов Г. Тел вә легать алмашып. № 12.
Вәлиева Д., Шаһиева Р. Күңел җәүһәрләре. № 3.
Вәлиева Г. Терекләк агачы. № 6.
Вәлиев Ф. Татарларда керамика сәнгате. № 11.
√ Горшков В. Сабан туйлардан — дөнья сәхнәсенә. Профессиональ балетыбыз тарихыннан. № 1.

Гыймранова Д. Картаймас иҗат. № 1.
Ильская Ф. Истәлекләрем. № 1.
Коздоба Е. Чишмә җыры. № 7.
Фәхретдинов Р. Халык көйләре һәм Илһам Шакиров. № 10.
Шәрифуллина Э. Җанга шифа. № 9.
Әхмәтҗанов Р. Бер йолдызың миннән булыр. № 9.

ХАЛЫК ИҖАТЫ

Себер татарлары әкиятләре. № 2.

И. И. ШИШКИННЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Якупов Х. Якты тәрәзәләр урманга карый... № 2.

ХӨСӘЕН ЯМАШЕВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Хәсәнов Х. Сүнмәс учак. № 1.

СОФЬЯ РАДЗИЕВСКАЯГА 90 ЯШЬ

Ихсанова Л. Олы бәхет иясе. № 6.
Радзиевская С. Мең еллык төн. Романнан өзек. № 6.

МАНСУР МОЗАФФАРОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Таҗиева К. Ул тормышка гашыйк иде. № 3.
Татарстан әдәбияты һәм сәнгате эшлеклеләренең композитор Мансур Мозаффаров турындагы истәлекләреннән өзекләр. № 3.

НУРИ АРСЛАНОВКА 70 ЯШЬ

Мансуров З. Үзгәрде рух, китте җан уянып. № 9.

ГАЛИМҖАН ЛАТЫЙПКА 70 ЯШЬ

Әхмәдуллин Ш. Юлың уң булсын, шагыйрь! № 1.

БЕЗНЕҢ САФКА

Галиев Ш. Рашат Низамиев. № 11.
Гатауллин Р. Харрас Әюпов. № 11.
Ихсанова Л. Нәбирә Гыйматдинова. № 11.

ТӨРЛЕСЕННӘН

Гыйләҗев И. Экспедицияләр эзеннән. № 8.
Еники Ә. Очрашу һәм аерылышу. № 1.
Зәбиров Х. Мин Тукайга ышанам. № 4.
Ихсанов Н. Сөрген батыры. № 12.
Камаев Р. Авыл белән шәһәр арасы. Социолог язмалары. № 12.
Молчанова М. А. Н. Анненская Казанда. № 10.
Хәйретдинов С. Сөенечле юллар. № 7.
Хәмзин К. Шагыйрьне искә алу. № 4.
Шакир С. Долматовский татар сугышчылары турында. № 7.
Әюпов Г. Онытылмас очрашу. № 10.

ИСТӘЛЕКЛӘР

Муллануров М. Һәйкәл янында уйланулар. № 1.

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Вәлиев М. Кем ул Сабир Шәрипов! № 7.
Гобәйдуллин Х. Барый Тархановның тууына 90 ел. № 9.
Гобәйдуллин Х. Сәхнә фидакаре. № 8.
Гобәйдуллин Х. Ә. Синяеваның тууына 90 ел. № 10.
Гәрәй Р. Җыры атлый безнең сафларда (Г. Хуҗиның тууына 70 ел). № 10.
Ильская Ф. Саф күңел. № 8.

Кумысников Х. **Нәҗип Гайнуллин. № 7.**
Кумысников Х. **Оста да, остаз да иде. № 8.**
Килмәтов Р. **Беренче шахматчыбыз (Р. Нәҗметдиновның тууына 70 ел). № 12.**
Мөлеков М. **Ил батыры. № 3.**
Мөхәммәдиев Р. **Бәйрәмнәр дәвам итсен. (А. Әхмәдуллинга 50 яшь) № 10.**
Сафин Ф. **Җырчы шагыйрь.** Ә. Ерикәйнең тууына 80 ел. **№ 12.**
Сафиуллина Ф. **Исемнәрнең серен ачучы. № 7.**
Сөнгатов М. **Яшьлек хыялларын җилкән итеп. (М. Ногманның тууына 70 ел). № 12.**
Шакир С. **Димнең җырчы егете. № 8.**
Шәфигуллин Ф. **Йөрәктәге эзләр. (Г. Мөхәммәтшинның тууына 50 ел). № 12.**
**Әбрар Шәминның тууына 70 ел. № 7.**
Әхмәтҗанов Р. **Матурлыкны яклап. (Д. Ильясовның тууына 60 ел). № 12.**
Хәнипов Р. **Остаз.** К. Тумашеваның тууына 80 ел. **№ 12.**

**Укучы сүзе. № 4, № 11.**

**Укучының күңел дәфтәренә. № 1, 3, 4, 5, 7.**

Нури З. **Хуш, безнең әдәби бәйрәмнәр елыбыз! № 12.**

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. № 1—№ 12.**

## ЯҢА ҖЫРЛАР

Сара Садыйкова музыкасы. Флера Гыйззәтуллина сүзләре. **Күзләреңә әллә күз тидеме! № 3.**
Разим Вәлиуллин музыкасы. Гәрәй Рәхим сүзләре. **Соңладык. № 2.**

..................

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## СССР ЮБИЛЕЕН КАРШЫЛАП

КПСС өлкә комитетының Политик мәгариф йортында оештырылган ике атналык курсларда укучы пропагандистлар республиканың фән һәм иҗат интеллигенциясе белән очраштылар. Очрашуда СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы президиумы председателе урынбасары, физика-математика фәннәре доктоы, профессор М. А. Илһамов, Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Ф. М. Миңнуллин, Художниклар союзы идарәсе председателе Ә. И. Тумашев, Композиторлар союзы идарәсе председателе урынбасары Б. Г. Мулюков, Кинематографистлар союзының беренче секретаре И. А. Алексеев иптәшләр катнашты. Алар СССР төзелүнең 60 еллыгы уңае белән республика фән учреждениеләре һәм иҗат союзлары баш карган эшләр турында сөйләделәр, пропагандистларның сорауларына җавап бирделәр.

## «КАЗАН УТЛАРЫ»НА ПОЧЕТ ГРАМОТАСЫ ТАПШЫРУ

Совет әдәбияте өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм беренче саны чыгуга 60 ел тулу уңаеннан Татарстан Язучылар союзы органы — «Казан утлары» журналы Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнгән иде.

22 сентябрьдә ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов бу югары бүләкне журнал редакциясе коллективына тапшырды. Шушы уңай белән ул редакция хезмәткәрләрен кайнар котлады һәм аларга совет әдәбиятын үстерүгә өлеш кертүдә яңадан-яңа уңышлар теләде.

## ЯШЬ ШАГЫЙРЬЛӘРНЕҢ БӨТЕНСОЮЗ ФЕСТИВАЛЕНДӘ

ВЛКСМ Үзәк Комитеты һәм СССР Язучылар союзы Львов шәһәрендә яшь шагыйрьләрнең XII Бөтенсоюз фестивален уздырды. Анда, семинар җитәкчесе буларак, шагыйрь Равил Фәйзуллин да катнашты.

## МУСА ҖӘЛИЛГӘ БАГЫШЛАНГАН КИЧӘ

Филология фәннәре кандидаты Исхак Зәбиров Үзбәкстандагы Карши шәһәренең музыка училищесында герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичәдә чыгыш ясады, күп санлы сорауларга җавап бирде.

## ЧАЛЛЫ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Чаллы язучылар оешмасының КПСС Үзәк Комитетының май (1982 ел) Пленумы карарларын тормышка ашыру бурычларын тикшерүгә багышланган киңәйтелгән җыелышы булды. Анда оешманың җаваплы секретаре Разил Вәлиев, матур әдәбиятны пропагандалау бюросы хезмәткәре Мансур Сафин илебезнең Азык-төлек программасын тормышка ашыруда бүлек язучыларының ничек катнашулары турында сөйләделәр. Җыелышта шулай ук «Ләйсән» әдәби берләшмәсе членнары да катнашты.

*
* *

Урып-җыю вакытында авыл хезмәтчәннәренә культура хезмәте күрсәтү өчен Чаллы язучыларыннан алты бригада оештырылды. Алар Тукай, Алабуга, Түбән Кама, Зәй, Мамадыш районнарында игенчеләр белән очраштылар, үзләренең яңа әсәрләре белән таныштырдылар.

*
* *

КамАЗның яшь шагыйрьләре «Тарловка» санаториесендә дәваланучылар белән очраштылар. Очрашуда катнашучылар туганнар каберлегендә булып, сугышта һәлак булганнар һәйкәленә чәчәкләр куйдылар.

*
* *

Язучылар оешмасы, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләренең культура бүлекләре оештырган әдәби-музыкаль кичәләрдә «Казан утлары» журналының баш редактор урынбасары Ринат Мөхәммәдиев, җаваплы секретаре Роберт Миңнуллин, поэзия бүлеге редакторы Радиф Гатауллин, Татарстан Язучылар союзының җаваплы секретаре Мөсәгыйт Хәбибуллин, өлкән шагыйрь Нури Арсланов, Чаллы язучылар оешмасы секретаре Разил Вәлиев журналның үткән юлы, бүгенге тормышы һәм киләчәге турында сөйләделәр, басылып чыгачак әсәрләр белән таныштырдылар, әдәбият сөючеләрнең күп санлы сорауларына җавап бирделәр.

Журнал редакциясе коллективы хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә актив катнашуы өчен, шулай ук журналның 60 еллык юбилее уңае белән КПССның Түбән Кама шәһәр комитеты һәм халык депутатларының шәһәр Советы башкарма комитеты Почет грамотасы белән бүләкләнде. Очрашуларда катнашкан язучыларга «КамАЗ төзелеше ударнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Язучылар шулай ук Әлмәт шәһәрендә, Сарман районының Җәлил поселогында укучылар белән очраштылар.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

Азнакай районының Ленин исемендәге колхозында әдәбият-сәнгать көне уздырылды. Анда язучылар Г. Афзал, Ф. Гыйльметдинов, Р. Рәкыйпов, К. Булатова, Азнакай районының «Гөлстан» әдәби берләшмәсе членнары Н. Әхмәдиев, Р. Зыятдинов, Җ. Хәбибуллин катнашты.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

Буа районындагы чуваш авылларында очрашу өчен күрше республикадан кунаклар килде. Чувашстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, шагыйрь һәм драматург Александр Калган, прозаик-сатирик Григорий Луч, шагыйрь Василий Эндипов һәм Чуваш дәүләт музыкаль театры солисткасы, яшь композитор Марина Ильичевалар ындыр табакларында, җәйләүләрдә, төзелеш мәйданнарында һәм культура йортларында очрашулар үткәрделәр. Очрашуларда язучы Камил Кәримов та катнашты.

Тәнкыйтьче Р. Мостафин Зеленодольск шәһәренең 1 нче тегү фабрикасында патриот-шагыйрь М. Җәлил турында сөйләде.

Татарстан китап нәшриятының баш редакторы, язучы В. Нуруллин Казан шәһәрендәге 19 нчы ГПТУда укучыларны үзенең соңгы вакытта иҗат иткән «Һәлакәт» повесте һәм башка әсәрләре белән таныштырды.

Балалар язучысы Л. Ихсанова Урицкий исемендәге культура сараенда яшь совет гражданнарына паспорт тапшыру тантанасында катнашты һәм тәбрик сүзе белән чыкты.

Язучылар В. Нуруллин, Р. Кәрами, Татарстанның атказанган артисты М. Галиев һәм баянчы Т. Хөсәенов Ясалма күн заводының тулай торагында үткәрелгән әдәбимузыкаль кичәдә катнаштылар.

Казан шәһәренең Маяковский исемендәге клубында драматург Д. Вәлиев белән очрашу булды. Ул үзенең иҗат планнары белән уртаклашты, сорауларга җавап бирде.

ТАССР Культура министрлыгы каршындагы культура работниклары белемен күтәрү курсларында укучы китапханә мөдирләре алдында язучы Ш. Рәкыйпов чыгыш ясады. Бу очрашуда сүз күбрәк яшүсмерләрне патриотик рухта тәрбияләү хакында барды.

## ХЕЗМӘТЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм җитмеш яше тулу уңаеннан шагыйрь **Нури Арсланов**, СССР Верховный Советы Президиумы Указы белән, **Халыклар Дуслыгы** ордены белән бүләкләнде.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты **Илдар Зиннурович Хәйруллинга**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы белән, **«Татарстан АССРның атказанган артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Совет цирк сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы белән, Татарстан цирк коллективы артистлары **Дамир Хәбибрахманович Гыйбадуллинга — «Татарстан АССРның халык артисты»; Ринат Рифкатович Әхмәтҗановка, Габделхак Абдуллович Гыйбадуллинга** һәм **Марат Муллахмәтович Шәһиевка «Татарстан АССРның атказанган артисты»** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

129

Индекс 73210

**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии